БАСМА ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ ТАТАР КОНГРЕССЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЗАКАЗЫ БУЕНЧА ӘЗЕРЛӘНДЕ

Әлеге китапны бастыруда күрсәткән ярдәм өчен
Олег Алексеевич Колесниковка
һәм Лена Рафик кызы Колесниковага
ихлас рәхмәтебезне җиткерәбез

Казан
2024

Идея авторы: Л. Р. Колесникова

12+

**Әхмәт Рафиков. Сагынырсыз әле...** – Казан: «Заман» нәшр., – 2024. – 240 б.

Сезнең алдыгыздагы китапка татар язучысы, шагыйре, педагог һәм журналист, Бөек Ватан сугышы ветераны Әхмәт Рафиковның әсәрләре, шул исәптән әлегә кадәр беркайда да басылмаган повесть һәм хикәяләре тупланган. Озын һәм тынгысыз тормыш юлы үткән язучының әлеге җыентыкка кертелгән әсәрләре күпмедер дәрәҗәдә автобиографик, шуңа күрә аларда автор яшәгән вакытның рухы дөрес чагылыш тапкан.
Китап Чиләбе өлкәсе Закон чыгару җыены депутаты, Чиләбе өлкәсе Татар конгрессы рәисе Лена Рафик кызы Колесникова инициативасы буенча басылган.
Җыентык 12 яшьтән өлкәнрәк укучыларга аталган.

© Әхмәт Рафиков
© «Заман» нәшрияты

**Әхмәт РАФИКОВ**

# *Сагынырсыз әле...*



**Лена Колесникова**
Чиләбе өлкәсе Закон чыгару
җыены депутаты,
Чиләбе өлкәсе Татар
конгрессы рәисе

**Кадерле дуслар!**

Фронтовик шагыйрь Әхмәт Мәхмүт улы Рафиковны һич шикләнмичә авыл прозасы остасы дип тә атарга мөмкин. Авылда туып-үскән, авыр крестьян хезмәтен бик иртә үз җилкәсендә татыган, кулакларны сөрү һәм күмәкләшү вакытларын үз күзе белән күргән язучы җирне, шунда тир түккән кеше хезмәтен кадерләргә, кырыс авыл тормышы кануннарын аңларга өйрәнгән.

Аның геройлары – күпләребез белән янәшәдә генә яшәүче гади кешеләр. Алар үсәләр, үзләре өчен бу якты дөньяны ачалар, яратырга һәм иң мөһиме – гаилә, нәсел, тугрылык, эчкерсезлек төшенчәләрен, бәхетнең туган якта гына булуын аңларга өйрәнәләр.

Әхмәт Мәхмүт улы Рафиковның гади телдә язылган хикәяләре якты образларга һәм эчкерсез юморга бай. Алар, көндәлдә иң матур хисләр уятып, укучыны шатланырга, кызганырга һәм уйланырга мәҗбүр итә. Әхмәт Мәхмүт улы Рафиков варисларына бай иҗади мирас калдырган. Авторның һәр әсәре – тормыш, туган җиребез, яшәү яме турында.

# ЭЧТӘЛЕК


Автор турында ........ 6
Хәтергә уелып калган сагыш, яки Онытылмас хатирәләр ........ 9

П о в е с т ь л а р ........ 17
Сагынырсыз әле, малайлар ........ 18
Ялгышлар һәм язмышлар ........ 60

Х и к ә я л ә р ........ 154
Гөлниса ........ 155
Йолдыз Кашка ........ 169
Җамалия апа Сәхипкә кем була? ........ 190
Бүре белән күзгә күз ........ 196
Рәхмәт, Мәсфия апа ........ 202
Боз киткәндә ........ 212
Җендер бу, балык түгелдер... ........ 227

К е ч к е н ә х и к ә я л ә р ........ 233

# АВТОР ТУРЫНДА

Әхмәт Мәхмүт улы Рафиков – татар шагыйре, прозаик, педагог, журналист. Бөек Ватан сугышы ветераны.

1916 елның 5 декабрендә Казан губернасы Спас өязе Иске Камка авылында (хәзерге Татарстан Республикасы Әлки районы Камкино станциясе) туган. Кечкенәдән үк авыр крестьян хезмәте күрә, 1921 һәм 1931 еллардагы ачлыкны кичерә. Авылдан кулакларны сөрү һәм крестьяннарны күмәкләштерү кебек вакыйгалар аның күз алдында бара.

1933 елда Алпар мәктәбен тәмамлаганнан соң колхозда эшли. 1940 елда Алабуга мәдәни-агарту техникумын тәмамлый, Югары Майна авылының (хәзерге Татарстан Республикасы Алексеевск районы) сигезьеллык мәктәбендә тарих һәм география укытучысы булып эшли.

1941 елда Әхмәт Мәхмүт улы Суворов орденлы Брянск Кызыл Байраклы 323 нче укчы дивизиясенә – телефончы, ә аннары атлы фельдъегерь булып хәрби хезмәткә чакырыла. Аның хәрби юлы Карачев, Брянск, Гомель шәһәрләре аша үтә, ул Белоруссияне һәм Польшаны азат итүдә катнаша, яралана. Госпитальдән соң 60 нчы укчы дивизиясендә хезмәтен дәвам итә, аның составында Берлинны штурмлый, анда кабат авыр яралана.

I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен», «Сугышчан казанышлар өчен», «Варшаваны азат иткән өчен», «Берлинны алган өчен», «Германияне җиңгән өчен» һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

Кайткач, Әхмәт Рафиков мәктәптә эшләвен дәвам итә. 1952 елдан партия район комитетының пропаганда бүлегендә эшли, аннары Биләр район газетасының редакторы булып хезмәт куя. 1973 елда Әхмәт Мәхмүт улы даими яшәү өчен Чиләбегә күчenә.

Әхмәт Рафиков үзенең беренче шигырьләрен 1930 нчы елларда Алабугада укыганда яза. Ул шигырьләр сакланып калмаган. Сугыш елларында язылган шигырьләре дә сакланмаган. 1980 нче еллардан Әхмәт Мәхмүт улы Уралда шагыйрь һәм прозаик буларак танылa. Аның әсәрләре «Ватаным Татарстан», «Кызыл таң», «Дуслык», «Туган як», «Чистай хәбәре», «Таң», «Хәзинә» газеталарында, «Мәйдан» һәм «Агыйдел» журналларында басыла. Муса Җәлил (хәзер – Акмулла исем.) исемендәге әдәби берләшмәнең иң өлкән әгъзасы буларак, Әхмәт Рафиков татар һәм башкорт әдәбиятчыларының «Чиләбе чишмәләре» (2002), «Сөенче» (2003), «Чиләбе моңнары» (2007), «Дуслык тирмәсендә» (2012) кебек коллектив җыентыкларда даими катнаша. Ул шулай ук «Күңелдәге уйлар», «Миләшләр», «Тормыш дәрьясында», «Мәңгелеккә үтеп барышлый» шигырь җыентыклары, «Галия» һәм «Калугадан Берлинга кадәр» повестьлары кергән китаплар авторы да.

2022 елның декабрендә аңа 106 яшь тула. Ул дөньяда шундый олы яшькә кадәр язган иң өлкән шагыйрь булган һәм булып кала.

Әхмәт Рафиков 2023 елның гыйнварында вафат була.



# ХӘТЕРГӘ УЕЛЫП КАЛГАН САГЫШ,
## яки
# ОНЫТЫЛМАС ХАТИРӘЛӘР

1923 елның май аенда без, сигез хуҗалык, Иске Камка, Киез Оболенский кырына, кечкенә каенлык каршындагы тау өстенә бер яклы урам булып күченеп утырдык. Бистәгә Сабанчы дип исем бирелде. Бездән биш-алты йөз метрда гына, Чирмешән буенда, – 1914 елда гына төзелеп бетеп эшли башлаган спирт заводы. Посёлок белән завод арасында – идәннәре бетонлап эшләнгән, 200 гә 200 метр кызыл кирпеч стеналы, йөз башка исәпләнгән атлар йорты. Без күченеп килгәндә завод, атлар йорты, заводның корылмалары – барысы да исән иде әле. Заводны күрше авыл – Гоголиха кешеләре саклый.

Бер ел үттеме икән, хуҗасызлыктан файдаланып, шул авыл кешеләре, төннәр буе заводның калай түбәсен, корылмаларын, ишек-тәрәзәләрен, нарат идәннәрен сүтеп ташый башладылар. Алардан көнләшеп, Сабанчы, Зирекле халкы да шул кәсепкә керește. Шулай итеп, бер-ике ел эчендә заводның коры стеналары гына калды, шуннан соң 1925–1926 нчы

елларда заводның таланып бетмәгән эчке машиналарын, зур-зур чаннарын сүтеп, дүртәр-алтышар ат җигелә торган махсус арбаларга төяп, Алексеевскига ташыдылар. Пар тегермәнен дә сүтеп каядыр алып киттеләр. Шуннан соң әкренләп атлар йортын, аннары заводның стеналарын сүтә башладылар. Тирә-як авыллар кызыл кирпечне шуннан гына сүтәләр иде. Бу хәл 1950 нче елларга кадәр дәвам итте, шул рәвешле Биләр районының ул вакыттагы җитәкчеләренең хуҗасызлыгы нәтиҗәсендә спирт заводы юкка чыкты. Ул еллардагы хуҗасызлыкның, башбаштаклыкнын шаһиты булып хәзер: «Кешеләр, болай эшләмәгез, болай җимермәгез!» – дигән шикелле, заводның 35–40 метр биеклектәге кызыл морҗасы гына утырып тора. Хәер, 1950 нче елларда Әлки МТСнан тракторлар белән морҗасын да сүтеп алырга дип тә килгәннәр иде, тик бер кирпеч тә ватып ала алмагач, кире китеп бардылар.

...Сабанчының матур табигате, уңдырышлы җирләре, кечкенә булса да каен урманы, җиләк-җимешле әрәмәләре, Чирмешән болыннары бик күпләрне үзенә тарту нәтиҗәсендә, 1925–1926 елларда Сабанчыга Алпардан 15 хуҗалык, башка авыллардан да 13 хуҗалык килеп, Чишмә, Алмагач тау башларына урнаштылар. Шулай итеп, Сабанчының бер яклы урамы километрга кадәр сузылды.

Шул ук вакытта, 1926–1927 елларда, завод территориясенә Алпардан янә 13 хуҗалык күчеп килеп, үзләренә аерым бистә булып урнаштылар. Посёлокка Уракчы дип исем бирделәр. Шулай итеп, ике йөз – өч йөз метр арада ике торак пункт пәйда булды.

...Ул елларда тирә-якта колхозлар юк иде әле. 1928 елның гыйнвар урталары иде, Сабанчыда, тугыз хуҗалык берләшеп, машина ширкәте (машинное товарищество) оештырылды. Аны оештыручылар укытучы Ситдыйк Урманчиев белән 1920 нче елларда укытучылык эшен ташлаган Мәхмүт Рафиков булдылар. Аларның тырышлыгы белән, шул елның язгы чәчүенә ике чәчкеч, тимер тырма кайтарылды. Соңрак урак өстенә янә бер урак машинасы, ашлык сугу машинасы һәм ашлык чистарткыч (веялка) алынды. Җирләр әле берләштерелмәгән иде. Һәр хуҗалык машиналардан чиратлап, ике-өч йорт берләшеп файдалана идек. Чөнки хуҗалыкта бер генә ат. Ә чәчкечкә – ике, урак машинасына – ике, ашлык сугу машинасына дүрт ат җигелә иде.

Ләкин машина ширкәтенең уңай яклары белән беррәттән, җитешсез яклары да ачыкланды. Бер хужалык машинадан файдаланганда, икенче берәүләр чират җиткәнне көтәргә мәҗбүр була иде. Шул житешсезлекләрне искә алып, шул ук көзне, 12 октябрь көнне, Сабанчыда беренче күмәк



хуҗалык оешты. (Бу эштә дә югарыда әйтелгән ике кеше башлап йөрде; күмәк хужалыкның рәисе итеп Гарифулла Хамидуллин, хисапчы итеп Мәхмүт Рафиков сайланды, бакчачы итеп Галим Рәхимкулов билгеләнде.) Әлегә эш коралларын гына берләштерделәр. Җәй башыннан атлар йорты сала башладылар, ул өлгергәч, атлар да берләштерелде. Хәзер инде без, малайлар, сукага ялгыз түгел, сигезәр, унар малай бергәләп сукалыйбыз, печән җыйганда, көлтә ташыганда, чүп утаганда да малайлар-кызлар бергәләп эшлибез, безгә күңелле. Эшкә барырга ашкынып торабыз.

1925 елда Сабанчыга беренче «Фордзон» трактор кайтты. Аны каршы алу өчен, Сабан туена барган шикелле, бөтен авыл җыелган иде. Тракторчы булып Әлкидән Хафиз дигән кеше килде, шул көннән башлап, без, малайлар, трактор яныннан бер дә кайтмый башладык. Трактор Латра буенда ташландык җирләрне сукалый. Без, кем алдан килә, шул тракторга елгадан бер чиләк су китереп салабыз да, тракторга утырып, бер тапкыр әйләнәбез. Аннан чиләкне икенче малай ала. Бер әйләнгәч, янә чират алып, Латрада какы, балтырган, кыргый суган ашап, шаярып, чират җиткәнне көтәбез. Кич трактор авылга кайтканда, тракторны кызлар каршы алалар...

...1932 елның февралендә Сабанчы белән Уракчы бер колхозга берләште. Ул җыелышта колхозның исемен Уракчы дип калдырдылар. Күмәк хуҗалыкның рәисе итеп Сабанчыдан Ибраһим Гыйрфанов сайланды. Хисапчы итеп Уракчыдан Сәлахов Бәдретдин сайланды. Элек хисапчы да, тимерче дә булып эшләгән Мәхмүт Рафиков тимерче булып калды.

1928 елда безнең Сабанчыда мәктәп юк иде әле. Ситдыйк абый бер өйдә беренче икенче классларны гына укыта. Без – сигез малай, өч кыз – Алпар мәктәбенә йөреп укый башладык. Өчебез – Вәлиев Гата, Атнабаев Рәфгать һәм мин – икенче класска барып кердек. Ул елларда башлангыч класс укучылары авылның төрле почмагында, аерым хуҗалар өендә укый иде. Без, икенче класслар, Мулла очындагы өйнең өске катында укыйбыз. Без инде өчебез дә, Алпарга килгәнче, гарәпчә дә, латинча да укый-яза белә идек. Шул сәбәпле безгә бер дә кызык түгел, без белгәнне генә өйрәтәләр. Бер чирек беткәнче йөрдек тә өченче класс укытучысы Сафия апага киттек.

– Сафия апа, без сездә укырга телибез, – дибез.

– Нишләп икенчедә укырга теләмисез? – ди Сафия апа.

– Анда гел без белгәнне генә укыталар.

Шуннан соң Сафия апа безне парталарга утыртты һәм бездән гарәпчә дә, латинча да укытып, яздырып карады. Рәсем ясатты.

– Ярар, булдырасыз икән, малайлар. Иртәгә икенче класс китапларыгызны укытучыгызга тапшырыгыз да миңа килегез! – дип, безне шатландырды. Шулай итеп без өченче класста укый башладык.

Сафия апа искиткеч игътибарлы, укучыларны оештыра, ярата, чын күңелдән бирелеп эшли белә торган талантлы укытучы иде. Без, укучылар да, аны чын күңелдән яраттык. Алар ире Гариф абый белән икесе дә абруйлы укытучылар иде. Кибет янындагы өйнең икенче катында яшиләр иде. Сафия апада без ике ел укып, дүртенчене бетердек.

Кызганыч ки, без Алпар мәктәбен тәмамлап киткәч, 1936–1937 елларда Гариф абый белән Сафия апаны, гаепләп, кулга алганнарын ишетеп, бик борчылган идек. Аларны нининдидер халык дошманы булуына беребезнең дә ышанасы килмәде. Аларнның язмышлары ни белән беткәндер, хәзергә кадәр белә алган юк.

...1930 елның февраль ае аеруча хәтердә калган. Ул төнне бөтен авыл халкын тетрәндергән хәл булды: без апам белән мәчет каршындагы өйдә квартирда тора идек. Төнлә йоклап ятканда: «Мәчет яна!» – дигән тавышка күзләремне ачып җибәрсәм, мәчет манарасыннан төшкән яктылык бөтен өйне яктыртып тора. Сикерешеп чыктык та, аннан-моннан киенеп, мәчет мәйданына йөгердек. Халык инде шактый күп җыелган. Биш-ун минут мәчет әйләнәсе халык белән тулды, берәү дә янгын сүндерергә өндәми дә, якын да бармый. Мәчет тирәсендәге нарат такталарны аера башлаганнарны да куып җибәрәләр. Без: «Нигә берәү дә янгын сүндерми икән?» – дип аптырап торганда: «Тимәгез, якын бармагыз! Ходай үзе биргән, үзе ала!» – дигән тавышка койма такталарын алырга омтылганнар да кире чигенде. Шулай итеп, халык манарадан башланган янгын бөтен мәчет бинасын элеп алганны, нигезенә кадәр янып беткәнче кул кушырып карап торды. Мәчет мәйданындагы ярты метр кар эреп, кара җиргә әйләнде. Мин ул турыда бер шигырьдә дә язган идем әле:

*Сүз йөреде колактан колакка,*
*Имеш, картлар шулай иткәннәр.*
*Безгә дә, сәвиткә дә булмасын дип,*
*Мәчеткә ут төрткәннәр.*

Бу Алпарда дингә каршы алып барылган сәясәтнең аяныч нәтиҗәсе иде. Шул рәвешле, ачлыктан соң, 1924 елларда гына Галимҗан бай төзеткән өр-яңа нарат мәчет юкка чыкты.

...Ул елларда Алпар мәктәбе Әлки районында бердәнбер җидееллык мәктәп иде. Анда Кузнечиха районыннан да, Әлки, Әхмәт авылларыннан да килеп укыйлар иде. 1926–1931 елларда Алпар мәктәбенең 5–7 классларында бик күп 18–22 яшьтәге детдом балалары укыйлар иде. Алар аерым йортларда хуҗалар белән бергә торып, бергә ашап яшиләр иде. Хуҗага бары 7–10 сум түләп торалар. Бик әдәпле, матур киенеп йөриләр. Без, чабаталы малайлар, аларның шыгырдап торган штиблетлар, яхшы костюм, чалбарлар киеп йөрүләрен күреп, без дә шулай киенеп йөрсәк иде дип, алардан бик көнләшә идек. Чөнки алар ай саен 30 сум стипендия алалар, аның күп өлеше кулларында кала. Мәктәпнең атлары, сыерлары, куяннары, яшелчә үстерү өчен ярыйсы гына бакчасы бар. Терлекләрне укытучы һәм завхоз җитәкчелегендә укучылар карый. Җәй көннәрендә укучылар һәр класс унар көн укытучы җитәкчелегендә бакчада эшли идек. Без, мәсәлән, Сабанчыдан 7 км йөреп, Сафия апа җитәкчелегендә һәр көнне дүртәр сәгать яшелчә утыйбыз, су сибәбез һ. б.

1932/33 уку елында мәктәпнең интернаты өлгерде. Без ул елны Әлки якларыннан килгән укучылар белән интернатта торып укыдык. Интернатның ашханәсендә үзебез үстергән яшелчәләр күп кулланалар иде. Интернатта тору күңелле дә, уңай да, дәресләрне дә бергә әзерлибез. Аяз, матур көннәрдә Әлки малайлары белән кар өстеннән яланаяк йөгерү ярышлары оештыра идек. Чатыр чабып манарасыз мәчеткә кадәр барабыз. Аннан, борылып, интернатка кайтып йөгерәбез.

1929/30 уку елында Алпар мәктәбенә Казаннан Арсаев һәм Ашмасов дигән яңа укытучылар килү мәктәп тормышын бик нык җанландырып җибәргән иде. Арсаев шәп гармунчы, җитез, үткен, яхшы оештыра белүче иде. Ашмасов көчле тавышка ия, опера һәм романс җырларын яхшы башкаручы җырчы иде. Мин аның Казан студиясеннән җырлаганын сугыштан соң да ишеткәнем бар. Җыр, драма түгәрәкләрен дә алар җитәкләгән иде.

Авыл клубында югары класс (детдомнар) укучылары белән ай саен спектакльләр куйдылар. Баш рольләрне үзләре искиткеч оста башкарып, «Галиябану», «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Наёмщик» спектакльләрен халыкка күрсәттелар. Алар уйнаганда авыл клубында (мәчеттә) алма төшәр урын да булмый, бүлмә шыгрым тулы була иде. Мәктәп бинасында кичләрен югары класс укучылары белән төрле темага «Бәхәс кичәләре» алар оештыралар иде. Ул кичәләрдә шундый кызу була, чара 3–4 сәгатькә сузыла. Шундый бәхәсләрнең берсен үзем дә, тышкы тәрәзәгә ятып, сәгатьләр буе тыңлаганым бар. (Чөнки анда түбән классларны кертмиләр иде.)

Алпар мәктәбендә ике ел эшләгәннән соң, алар үзләренең Казаннарына кайтып киттеләр. 1932/33 уку елына мәктәпкә математикадан

Заһитов һәм китек иренле (шулай хәтердә калган) яңа директор килде (фамилиясен хәтерләмим). Ул соңыннан Әлки районында (сугыш елларында) райком секретаре да булып торды. Шул елны без Алпар мәктәбен тәмамладык. Шуннан ике ел колхозда эшләдем.

...1930 нчы елларда Алпарда кулак хуҗалыкларга каршы алып барылган көрәш турында да берничә сүз әйтеп китим әле: ул елларда Алпарда партячейка секретаре булып Габделхак Сәлахов эшләде. Алпар – биш мәчетле авыл, өч участокка бүленгән иде.

1 участок – иске авыл. Ул кибеттән түбән таба, тыкрык чатындагы өйдә. 2 участок – аргы якта (Чирмешәннең сул ягы). 3 участок – яңа Алпарда. Участокта кичләрен һәр көнне 1–2 коммунист, 2–3 комсомол һәм 4–5 пионер дежурда була идек, минем үземә 1930/31 уку елының кышында беренче участокта өч мәртәбә дежурда булырга туры килде. Без, өч-дүрт пионер, чакырасы кешене өенә барып алып киләбез дә, сорау алганны карап, бер читтә эскәмиядә утырабыз. Сорау алучы – районнан килгән (Әлки кешесе) урта буйлы, киң җилкәле, таза гәүдәле, карап торырга да юньсез тоелган кырык яшьләрдәге кеше иде. Исемен хәтерләмим. Без аны ОПС КРЕСТ дип кенә йөртә идек. Ул үзе кул да куя белми, имза урынына «+» билгесе генә куя иде. Ул бездән бик озак Галимҗан байны эзләткәне хәтердә.

Без чакырып килгән кешене идән уртасына бастырганда, ул өстәл артында тәмәке тартып утыра торган була иде. Чакырылган кеше кереп басу белән, ул усал гына карап ала да, папиросын сул кулына алып, уң кулы белән кесәсеннән ашыкмыйча гына зур кара наганын чыгарып өстәл өстенә куя. Аннары, тәмәкесен уң кулына алып, сул кулы белән наганны сул як кесәсенә сала. Наган сул кесәдә булса, ул шул ук эшне киресенчә башкара. Ул бу эшне шундый ләззәт белән эшли, күзләре гел чакырылган кешедә була. Янәсе, ничек, тәэсир итәме?

ОПС КРЕСТ булмаган (ул башка участокларда булганда) көнне без олылар ни сөйләгәнне тыңлап, шаярып ятабыз.

1933/34 уку елының кышында Әлки районында беренче мәртәбә концерт группасы эшли башлады. Аны 1933 елның җәендә Әстерханнан кайткан артист Әзәл Яһүдин оештырган иде. (Әзәл абый үзенең биографиясендә Әлки районында эшләве турында язганмы? Ул кадәресен белмим). 1933/34 уку елының кышында Әлки районы авылларында концертлар куеп йөрде. Аның моңлы көйләрне бик оста уйный торган (16 телле гармунда!) гармунчысы бар иде. Ул уйнаганда апалар, әниләр яулык читләре белән күзләрен сөртеп утырганнары бүгенгедәй күз алдында.



Хәтерем ялгашмаса, исеме Борһан иде түгелме икән? Әзәл абыйлар безнең Сабанчыга да ике тапкыр килделәр. Алар килгәндә бөтен авыл, баласы-чагасы мәктәпкә җыела. Басып торыр урын булмый торган иде.

Әзәл абый үзе биш кешене тота. Алга чыгып басар иде дә: «Бер ярмадан ботка пешереп булмый, диләр, менә мин сезгә берүзем ботка пешереп карыйм әле...», – дип, халыкны бер көлдереп алыр да, тальянын тартып, җырлап та җибәрер иде. Аннары кинәт туктап, бер шигырь сөйләп алыр. Аннан янә гармунын тартып, башын артка чөеп, авыл урамындагыча берәр җыр җырлар. Шунда ук туктап, авыл яшьләречә биеп күрсәтер. Бераздан, кинәт туктап, берәр мәзәк сөйләп ташлар, шуның артыннан ук берәр поэманы көйгә салып, гармун уйный-уйный шуны сөйләр иде. Әйтерсең лә, сәхнәдә берничә кеше... Ә ул бөтен кешенең шаккатырып берүзе концерт бирә.

Әзәл абый сүзнең, шигырьнең тәмен белеп, искиткеч оста итеп сөйли белә иде. Мин үзем дә шигырь сөйләргә аңардан өйрәндем. Соңыннан, үзебез концертлар оештыра башлагач, Габдулла Тукайның «Яңа Кисекбаш»ын, Һади Такташның «Мокамай», «Тун трагедиясе»н өйрәнеп, сәхнәдә яттан сөйли башладым.

Ул елларда кешеләрнең моңлануларын да, елауларын да, кызганыч вакыйгалар булганда уфтанып сызлануларын да еш күрергә була иде. Ләкин заманалар нинди авыр булуга карамастан, кешеләр төшенкелеккә бирелмәделәр. Рухи байлыкларын югалтмадылар, диясем килә.

Әзәл абый концертлар биреп районда бер кыш кына эшләде. Районда аның эшен дәвам итүчеләр булганмы, юкмы? Ул кадәресен әйтә алмыйм. Әзәл абый үзе 1934/35 уку елында үзенең туган авылы Яңа Чаллыда ачылган җидееллык мәктәптә укытучы булып эшләде. Мәктәптә эшләгәндә дә, укытучылар, авыл яшьләре катнашында концертлар оештырып, театрлар куеп, армый-талмый эшләде. 1934 елның 7 ноябрендә ул шул мәктәптә укытучы минем апам – Гөлсем Рафиковага өйләнде. Мәктәптә укулар беткәч, 1935 елның җәендә апам белән безгә, Сабанчыга кайтып, атна-ун көн торып киттеләр. Апам белән Чишмә, Каенлык тау буйларында йөреп, Чирмешәндә су коенып ял иттеләр. Кичләрен, югары өйнең баскыч өстенә утырып, Әзәл абый гармунда, әтием скрипкада уйнап, Гөлсем апаны җырлаталар иде. Мин Әзәл абыйга җизни димичә, абый дия идем. Авылдан соң алар Чаллыга кайтып озак та тормадылар, укытучылык эшен ташлап, Казанга күченеп киттеләр. Анда баргач, Гөлсем апа педрабфакка укырга керде. Әзәл абый үзенең һөнәре буенча филармониягә урнашты. Ләкин, кызганычка каршы, 1936 елның февралендә

алар Гөлсем апам белән аерылыштылар. Укытучы булып бергә эшләгәндә туган мәхәббәт, икесе ике җиргә йөреп эшли башлагач какшадымы? Сәбәбен әйтә алмыйм, Гөлсем апам озак еллар мәктәп директоры, укытучы булып эшләде. Ләкин шуннан соң тормышка чыкмады.

...1920–1930 нчы елларда бергә уйнап, бергә Алпар юлын таптап, сабан сөреп, печән, көлтә ташып йөргән малайларның күбесе 1941–1945 еллардагы сугыш кырында ятып калды. Генерал буласы яшьлек дустым, капитан Гата Вәлиев – Ленинград фронтында, Рәфгать Урманчиев – Украина җирендә, Рәфгать Атнабаев, Габбас Рәхимкулов, Гаптулла Галиев, Мидхәт Урманчиев, Зөхәт Сәлахов һ.б. төрлесе төрле җирләрдә һәлак булдылар. Хәзер аларның уллары, оныклары, төрлесе төрле якларда дөнья көтеп, тормыш итеп яшиләр. Гата Вәлиевнең улы, полковник дәрәҗәсенә җитеп, отставкага чыкты. Рәфгать Урманчиевнең улы Чиләбедә баш инженер булып эшли һ.б...

Тормыш дәвам итә...

Сугыштан соңгы елларда Сабанчының да Чишмә, Алмагач тау башлары бушап калды. Сабанчы исеме төшеп калса да, Уракчы булып яши авыл. Совхозның йөз баш сыерга исәпләнгән терлек фермасы, 4–5 йөк машинасы Уракчыда, авылның киң болыннарын, матур табигатен дә шуларга кушсаң, шулар авылны таратмый, авылдагы яшьләрне, читкә киткәннәрне дә сагындырып, үзенә тартып тора.

Сабанчы-Уракчы, Алпар якларында үткән ул еллар хәзер дә, онытылмаслык истәлек булып, йөрәк түрендә саклана.

Әхмәт Рафиков,
Бөек Ватан сугышы инвалиды.
Чиләбе шәһәре.



# П О В Е С Т Ь Л А Р

# САГЫНЫРСЫЗ ӘЛЕ, МАЛАЙЛАР

Ул төнне Гата юньләп йоклый алмады. Кичтән алар шәһәргә баргач, кичке уеннар булмас дип, соңгы мәртәбә кичке уенга чыктылар. Әтәч кычкыра башлаганчы, урамда уйнадылар. Кайтып, әнисе җәеп куйган урынга – агач караватка менеп ятты да стенадагы кечкенә сәгатьнең келт-келт йөргәнен тыңлап ята башлады. Иртән торып, ерак юлга чыгасылары исенә төште дә, ул шул турыда уйланды: «Безне Илгизәрнең дәү абыйсы – Ибраһим бабай озата бара. Ул инде күп йөргән, дөнья күргән кеше. Безне пароходка утыртып җибәрсә, Казанга баргач, мәктәпне үзебездә табарбыз», – дип уйлады. Аннан аның башына берсе артыннан икенчесе җавап сорый торган яңа уйлар агылды. Казанга баргач, кайда кунарбыз? Беребезнең дә белгән кешесе юк. Рәфгать ул «вокзалда кунарбыз» ди дә бит, анда бер-ике кич кенә кунып була... Әгәр беребезне генә алсалар? Торагы булмаса? Кире кайтырга туры килә... Тек-тек-тек...

Тек-тек йөргән сәгать тавышы әкренләп ераклашкан кебек булып, Гатаның күзләрен йокы сөреме чолгап алды да ниндидер сихри рәхәткә алып кереп китте. Җавапсыз калган күптөрле сораулар аның күз алдында якты күренешләр булып кайдадыр чакыра, әйди башлады... Менә алар пароходта баралар... Нигәдер пароход та Гата рәсемдә күргән пароходларга охшамаган. Тышы нинди икәнен дә аерып булмый торган тонык төстә. Эче ниндидер, яшелме шунда... Үзе ап-ак томан шикелле су диңгезе эченнән бара. Бер җирдә дә туктамый, бара да бара... Тек-тек-тек... Менә ак томан эчендә текә яр күренде. Караса, шул яр өстеңдә Рәфгать басып тора. Уяу, пароход читендә басып барган Гатаны күреп алды да, башындагы ямьшәеп беткән кепкасын салып, Гатага изи башлады:

– Монда чык! Нишләп анда торасың?! – дип чакыра. Ике арада ап-ак томан шикелле су... Менә Гата да:

– Мине калдырма! Бергә барабыз! – дип кычкыра башлады. Кычкыра-кычкыра, һич тавышы чыкмый... Кинәт ак томан шикелле су юкка чыкты да, Рәфгать аның кулын тотып алды. Кулы нигәдер салкын... Нигә соң әле ул кулын Гатаның маңгаена куя? Кулыннан яңа сауган сөт исе килгән кебек. Сыек томан эченнән тонык кына тавыш килде:

– Тор, улым...

Бернәрсә белән дә алыштыргысыз тәмне йокысын бүлмәскә тырышып, Гата күзләрен ачмыйча гына икенче якка борылып ятты.

– Әз генә йоклыйм әле... Бу әни дә, таң белән уятмаска ярамаганмы инде? Йокының иң тәмле чагында, – дип уйлады ул. Һәм тиз генә борыннан ук томаланырга дип юрганын тартам дигәндә, әнисенең яңа сауган сөт исләре килеп торган кулын маңгаенда тоеп, күзләрен юри генә ачкан иде, караватянында әнисенең басып торганын күрде. Шулай да торасы килми. Бар теләге – йокы. Йокы... Йокы...

– Тор, улым! Иртәрәк ятарга иде аны! Ибраһим абзаң: «Иртә кузгалабыз, яктыра башлау белән, уятып җибәр малаеңны», – дигән иде.

– Әйдә, тор! Битеңне су белән юып җибәрсәң, йокың ачылыр. Кинәт Гатаның ерак юлга чыгасы башына барып җитте дә, урыныннан торып, алпан-тирпән әнисе артыннан кече якка чыкты. Аралыктагы таз эченә куелган комганнан салкын су белән битен чылаткандай итеп, сөлгегә сөртте дә өстәл артына кереп утырды. Чынаяк өстенә әнисе салып куйган сөтне кулына алды.

– Улым, яхшылап аша! Әнә каймаклы катык чыгарып куйдым. Ипи белән шуны аша, – диде Кәримә апа, улына карап.

– Әни, бер дә ашыйсы килми бит әле, – диде Гата, кулындагы сөттән бушаган чынаякны өстәлгә куеп.

– И-и, бала, ул бер чынаяк сөт белән Үргәагарга да җитә алмыйсың бит. Соңыннан бик теләсәң дә, бу сыйлар булмас. Алайса, иписез генә булса да, шул катыкны капкалап бетер!

Гата каймаклы катык савытын алдынарак тартып куйды да агач кашык белән катыкны тиз-тиз генә капкаларга кереште.

– Улым, юлга дигән акчаңны чалбар кесәңә куй! Төшеп кала күрмәсен. Аңда баргач, акчагызны кесәгездә йөртмәгез! Бозыла торган ашамлыкларыгызны баштан ашагыз. Киптергән сохариларны аңда баргач, җитмәгәнгә кушып ашарсыз...

– Ярый, әни, – диде Гата, өстәл артыннан чыгып. – Мин киттем. Көтеп тора торганнардыр.

– И-и, бала, шул булдымы ашавың? Улым, аңда баргач карап, сакланып йөрегез! Бер-берегездән калмагыз. Пристаньда, пароходта, йоклап, әйберләрегезне алдыра күрмәгез! Чиратлап йоклагыз... – дип тезде Кәримә апа. Аннары, кичтән улына дип әзерләнгән ашамлыкларны биштәргә тутырып, авызын бәйләде дә, янында басып торган улына таба борылып, аны күкрәгенә кысты.

– Йә, улым, сау бул. Карап кына, тәртипле гена йөрегез. Урнаша алмасагыз, анда каңгырып йөрмәгез. Монда, Алпарда укырсыз...

– Йә инде, әни, елама, – диде Гата, әнисенең яшьле күзләренә карап.

Ул биштәрен алып җилкәсенә салды да ишеккә юнәлде. Аннары кинәт борылды да:

– Син, әни, тәрәзәдән генә карап кал, озата чыкма, – дип, ишектән чыгып йөгерде.

Ул килгәндә Илгизәр Ибраһим бабайлар турысында туктаган, күп итеп печән салган арбага биштәрен куеп кайнаша иде. Капкадан Ибраһим бабай килеп чыкты да:

– Җыелып бетәсезме, оланнар, кузгала башларга кирәк, соңга калабыз, – дип, капка баганасына бәйләнгән дилбегәне чишә башлады.

– Дәү абый, әле Рәфгать килмәгән. Аз гына көтик.

Ибраһим бабай Илгизәрнең әтисе белән бертуган абыйсы. Шуңа, әтисеннән олы булганга, ул аны «дәү абый» дип йөртә. Ибраһим бабай метр ярымнан аз гына калку, киң җилкәле, төптән утырган карт. Өстендә – бигүк яңа булмаган чиста киҗе-мамык костюм. Башында, төсе китсә дә, пөхтә күренгән соры төстәге фетр эшләпә. Авылда алар өч Ибраһим. Берсен, Төркиядә пленда булганы өчен, «Төрек Ибрай» дип йөртәләр. Икенчесен кушаматы белән «Кәҗә Ибрае» дип, Илгизәрнең дәү абыйсын «Мимеч Ибрае» диләр. Ул кушамат аңа кайчандыр, Идел буе немецларына барып батрак булып эшләп кайтканнан соң бирелгән булган. Ләкин авылда аның кушаматын әйтүче бөтенләй юк. Олы кеше булганга, Ибраһим бабай, Ибраһим абзый, дип эндәшәләр. Ибраһим бабай – йомшак, нечкә күңелле, ярдәмчел кеше. Олысына да, кечесенә дә, ачык йөз күрсәтеп, тәмле тел белән эндәшә. Бик нык ачуы килгәндә дә, күтәрелеп бәрелми. «Хәерсез», «ырыйстан», «шайтан төкергән» кебек сүзләр белән генә ачуланган була. Бервакыт кышкы каникулда, Илгизәр самокатта йөрергә өйрәнгәндә, звонок бирә алмыйча, дәү абыйсына арттан килеп бәрелгән иде. Шул чакта дәү абыйсы, егылып, сул кулын беләгеннән сындырган иде. Ләкин шунда да дәү абыйсы аңа авыз ачып бер сүз дә әйтмәде, хәтта кешегә дә сөйләмәде.

Шуның белән бергә, Ибраһим бабай моңлы-зарлы кеше дә. Бу моңлылык аңа ун-унбер яшьтән, кат-кат читкә китеп, байларга да хезмәтче булып, авыр тормыш нужасын тартудан да, егерме беренче елгы ачлык вакытында гаиләсе белән читкә китеп, ачлыктан, тиф белән авырып, ике малае, ике кызы, хатыны үлеп калып, берүзе буш нигезгә әйләнеп кайту хәсрәтеннән дә бирелгәндер инде. Ләкин шундый тормыш нужасы, читтән тыш авыр хәсрәтләр кичерүенә карамастан, Ибраһим бабай йөрәк януларын тәмәке белән дә бастырмаган, хәсрәтен аракы белән дә «юмаган». Тәмәке тартуны да, эчкән кешене дә ул яратмаган. Мишәрчә сөйләшсә дә, «ц» авазына артык басым ясамыйча сөйләгәнлектән, сөйләве ярыйсы гына матур килеп чыга.

– Әйдәгез, бара торыйк. Каршы оцырар әле, – дип, Ибраһим бабай дилбегәне тотып арбага менеп утырды. – Утырышыгыз, кузгалыйк!

Илгизәр дәү абыйсы янына – сул якка, Гата аның янына аякларын салындырып йомшак печән өстенә менеп утыру белән, Ибраһим бабай җирән алашасын борып алды.

– Әйдә, хайван, Аллага тапшырыйк! – дип, атны урам буйлап йөгертеп алып китте. Берничә йортны узуга, алда каршы йөгерүче Рәфгать күренде.

– Озак йоклыйсың, улым, – диде Ибраһим бабай, атын туктатып. – Караңгы белән кузгалырга тиешле кешеләр, кай вакыт җитте. Утыр, әнә, артка. Безгә әле сиксән чакырым артыгы белән барасы бар. Пароходка өлгермәсәк, су буенда, затонда кунарга туры киләсе...

– Кунарбыз, – диде Рәфгать, бер дә исе китмичә. – Безнең Ташкент поездын өчәр көн көткән бар.

– Минем шул затонда кунасым килми. Ул шпана оясында атыңны алып китәргә дә күп алмаслар. Сезгә дә анда кунарга язмасын... Әйдә, хайван, н-а-а! – диде Ибраһим бабай, дилбегәсен кагып. – Ишәк түгелсең лә!

Авылны чыгып бетүгә, юл үргә менә башлый. Ибраһим бабай атны, ара-тирә генә чаптыргалап, күбесенчә адымга гына алып барды. «Чаптырыр юллар алда әле», – дип уйлады ул, барасы ерак юлны күз алдына

китереп. Ничәнче мәртәбә чыгуы инде аның бу ерак юлга үз гомерендә. Санасаң бик күпкә җыелыр иде. Тик аны кем санаган... Шулай да аеруча күңелгә уелып калганнары гына берничәгә җыела...

Иң беренче мәртәбә шул юлдан Хәбибрахман исемле кешегә ияреп, Самара ягына чыгып киткәне күз алдына килде. Ул вакытта ун яшь тулган гына иде. Бу малайлар кадәр да юк идем. Алар өчәү. Бер-беренә иптәш. Ә мин берүзем, Самара ягыннан кайткан бер абыйга ияреп, ачтан үлмәс өчен, тамагыма эшләргә, кыш чыгарга дип киткән идем. Сагынсам да, һәркөн әр-хур күреп, кыш чыкмыйча кайта алмаган идем, дип уйланды ул. Әр-хур, кыен күреп елаган көннәре исенә төште дә талгын гына көйләп бара башлады.

*Уралның таулары ай биек,*
*Йөри икән арыслан кебек*
*Китмәсен лә кеше чит җирләргә,*
*Йөрер өчен ай янып-көеп...*

Менә юл уңга таба борылды да үргә яны белән бара башлады. Ибраһим бабай атын бераз әкрен генә элдертеп алып барды да, аякларын салындырып, авыл ягына карап утырганнан соң, түбәнгә, бөтен буе белән күренеп торган авыл урамына карап сүз башлады:

– Әнә, туган авылыгыз, карагыз! Саубуллашыгыз! Сагынырсыз әле, – дип, атын туктатты.

Малайлар бер-берсенә карап елмаешып алдылар да Ибраһим бабай карап торган якка күз салдылар.

– Әнә бит нинди матур урыннар: кечкенә генә каенлык. Аның каршысында тәбәнәк тау башында сузылып киткән туп-туры авыл урамы. Урамның теге башында – кызыл кирпечтән биек завод морҗасы. Аның артында – бакча. Уңда-сулда – Чирмешән болыннары, авыллар. Карап туйгысыз урыннар.

– Әнә безнең өй, безнең тирәкләр. Сезнең өйне безнең тирәкләр каплый, Гата, – диде Илгизәр.

– Карагыз әле, завод морҗасы нинди кечкенә күренә, – диде Гата. – Каенлыкта...

– Әнә, бу башта безгә арты белән торганы безнең өй... – диде Рәфгать, озак кына карап торганнан соң. – Әнә тау итәгендәге алмагач та күренә әле...

– Йә, күрдегезме инде авылны? Әле монда килеп караганыгыз булмагандыр? – диде Ибраһим бабай, атын әйдәп. – Анда бу болыннар, бу сахралар булмас. Сагынырсыз әле...



– Булмас, дип, монда нәрсәсе бар соң ул хәтле? – дип көлде Рәфгать. – Имеш, урман, Чирмешән, завод морҗасы?.. Казанда завод морҗасы дисәң, буа буарлык. Өйләр анда ничәшәр катлы. Салам башлы түгел. Идел дисәң, йөз Чирмешен хәтле бардыр...

– Сиңа шулай, – дип сузды Ибраһим бабай. – Синең булмаган җирең юк. Менә бу малайларның читкә беренче чыгулары. Алар шул җирдә туып үскәннәр. Шул болыннарда чапканнар. Шул Чирмешәндә коенганнар, балык тотканнар. Алар сагыныр, дип әйтүем. Синең дә әти-әниең монда кала. Син дә сагынырсың әле...

– Юк, сагынмыйбыз, дәү абый, – диде Илгизәр, Ибраһим бабайны бүлдереп, – әнә бит, Алпарда кыш буе торып укыдык. Бер дә кайтасы килмәде. Интернатта рәхәт иде, кызык. Ашарга китермәсәләр генә кайта идек...

– Әйе шул, – дип дәвам итте Гата. – Без бит шәһәргә барабыз. Пароход, трамвайда йөрүе, шәһәр күрүе үзе дә ни тора. Авылның нәрсәсен сагынасың?

– Менә, энем, үзең дә әйттең: «Ашарга китермәсәләр генә кайтасы килә», – дип. Шәһәрдә мондагы кебек атна саен кайтып йөри алмассыз. Монда әле сез атна саен кайтып, мунча кереп, әниләрегез пешергән тәм-томны капкалап, сөтен-катыгын, дигәндәй, ашап, әниләрегез юган чиста киемнәр киеп китә идегез. Тишек-тошыкларыгызны, өзелгән сәдәфләрегезне дә әниләрегез ямый, әниләрегез тегә иде. Анда бит аларның берсе дә булмасын сез беләсезме соң? Сез яшьләр шул әле. Менә анда барып, Лаеш шулпасы эчә башлагач, Ибраһим бабагыз әйткәннәр исегезгә төшәр әле. Мин үзем дә сезнең кебек вакытта шулайрак уйлый идем, Самара ягына китеп адаштым да туган якның нинди хикмәткә ия икәнен шунда гына белдем. Туган җир, туган авыл, туган ил әти-әни кебек якын ул, оланнар. Шуны белеп торыгыз!

– Дәү абый, син барган Самара ягы кайда ул?

– Шуны да белмисеңме? – диде Рәфгать, – мин Самара аша әллә ничә мәртәбә уздым. Ташкентка барганда, поезд шуннан уза...

– Жигули таулары янында ул, энем, Идел буенда. Мин ул якка китеп күргәннәрне сезгә төшегездә дә күрергә язмасын, оланнар. Моннан илле еллар элек булды ул хәл. Сездән яшьрәк малай чагым иде. Слабутный хөррият чыкканчы. Ул елны иген булмады. Безнең гаилә зур – алты җан. Мин – иң зурысы. Әтинең бер имана җире. Беркөнне әти, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, янына чакырып китерде дә:

– Улым, әллә кыш чыгарга берәр икмәкле якка китәсеңме? Болай булса, без кыш чыкканчы барыбыз да ачка үлеп бетәчәкбез, – диде. –

Әнә Хәбибрахман Самара ягыннан кайткан. Барсаң, сине дә алып барам, ди. Тамагыңа булса да ярар. Анда Хәмзә муллага йомышчы малай кирәк икән, бар, улым, ичмаса син ач булмассың, дигәч, бик теләп риза булдым. Монда, авылда да, берни юк, мин әйтәм... Дөнья күреп кайтырмын, дип, шатлана-шатлана киттем.

Хәбибрахман абый белән Спаска баручы атларга иярдек тә, җәяүләп, елга аша чыгып киттек. Әти юлга илле тиен көмеш бирде. Биш ун тиенлек. Капчыгымда яртыдан күбрәк ипи. Әле менә сезнең капчыкларга карыйм да, сөбханалла. Ике-өч атналык азыгыгыз бар.

– Н-а-а әле, алаша! Түбән таба элдертеп алыйк әле! – дип, Ибраһим бабай атны йөгертә башлады.

– Шуннан, дәү абый? Капчыгыңда яртыдан артыграк ипи?

– Әйе, капчыгымда – ипи, кесәмдә – биш ун тиенлек көмеш. Спаска төнлә килеп җиттек. Килсәк, Спас Затонында халык мәш итә. Пароход иртәгә генә була, диләр. Билет сата торган урын кечкенә. Утырып торырга түгел, басып торырга да урын юк. Хәбибрахман абзый: «Әйдә, Ибраһим, яр читенә чыгып утырабыз, монда усрак исе иснәп, төнне аягүрә үткәреп булмас», – ди. Яр читенә чыгып утырган идек, арылган, шунда ук йокыга киткәнмен. Бер заман бер өтек шпана капчыгымны тартып алды да читкә чапты. Әле ярый Хәбибрахман абзый йокламаган булган. Артыннан куып җитә башлагач, капчыгымны ташлап качкан, ырыйстан. Ул заманда Спас Затоны шундый иде. Хәзер дә әллә нәстәсе юк та, алай да билет сата торган, көтеп торган җирләре бар. Шпаналары юктыр, дип ышандыра алмыйм.

Н-а-а әле, алаша! Әллә син дә мине тыңлап барасың инде? Әйдә! Болай барсак, син безне ике көн алып барырсың! – дип, атны куалап алганнан соң, ул яңадан сүз башлады:

– Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, диләр, сез инде, оланнар, бер-берегезне ташламагыз! Син, энем Рәфгать, дөнья күргән малай, иптәшләреңне ташлама!

– Юк, Ибраһим бабай, ташламыйм. Без укырга да бергә керәбез. Торырга да бергә урнашабыз. Шулай бит, малайлар?

– Шулай, шулай, – диде Гата. – Әгәр укырга беребезне генә алсалар?

– Ничек беребезне генә? Әгәр мине генә алам дисәләр, мәсәлән, мин өчебезне дә алыгыз, диям.

– Сез соң, оланнар, кем булырга барасыз?

– Безме? Без столяр булырга укырга телибез, әгәр алсалар.

– Бик яхшы, бик күркәм эш. Анда матур шкафлар, өстәлләр ясарга, өйләрнең йөзләренә матур-матур бизәкләр ясарга өйрәнеп кайтыгыз! Колхозда столярный ачып җибәрербез. Матур-матур әйберләр ясап, авылдашларыгызны кинәндерерсез.

Малайлар, шатланышып, бер-берсенә карадылар, елмаешып, тирә-якны күзәтеп бара башладылар.

– Бәхетлеләр инде сез, оланнар, – дип дәвам итте карт. – Совет хөкүмәте сезгә юлны ачты. Безнең заманда гына булмады андый бәхетләр. Мин үзем әти мәрхүм күрсәткән белән хәреф танырга гына өйрәнеп калдым. Әнә, минем энем, Илгизәрнең әтисе, зиһенле булып чыкты. Сигез яшендә авыл буе хат язарга күтәреп йөртәләр иде үзен. Мин сезнең кебек вакыттан башлап, башта – Самара ягы байларына, аннары Идел буе мимечләренә эшләп тамак туйдырдым...

– Дәү абый, син бит әле безгә Самара ягында нишләгәнеңне сөйләмәдең?

– Мин күргәннәрне, энем, сөйләп бетерерлек түгел. Бер китапка да сыя торган түгел мин күргән нужалар, хәсрәтләр...

– Сөйлә инде, дәү абый.

– Сөйлә, юл озын, Ибраһим бабай! Юл тизрәк үтәр, – диештеләр малайлар.

– Ярар алайса, мин инде Хәбибрахман атлы кешегә ияреп киткәнемне әйткән идем. Ул абый мине Сарытау ягы баена тамак хакына эшләргә сөйләште дә, мин, Ибраһим, сине килеп алырмын әле, дип китеп барды. Кая киткәнен дә белми калдым. Шуннан бшланды инде минем михнәтләр.

Мине хезмәтче ярдәмчесе итеп алып калган Гали байның ике кибете, дүрт аты бар, тайлары белән алты баш була. Өч баш сыеры, таналары, бозаулары белән сигез баш, бер көтү сарыгы бар. Шул йортка – бер хезмәтче белән мин. Йортта – бәрәннәр, бозаулар, өйнең бер почмагында Галләм абзый белән без икәү торабыз.

Ибраһим бабай кинәт тукталып калды да тирән итеп көрсенеп куйды. Күрәсең, моннан ярты гасыр элек малайлыкта күргән, кичергән авыр көннәрне искә алу да аның күңеленә авыр тәэсир итә иде.

– Мин һәркөн, таңнан торып, хуҗаның мичләрен ягам. Сыерларга, бозауларга су җылытам. Кухняга, өйдәге мичләргә утын кертәм, су ташыйм. Көненә өч мәртәбә байбикәгә савыт-саба юарга булышам. Йомышка йөрим. Йомышка җибәрсәләр, кинәнеп бара идем. Анда азмы-күпме үз иркеңдә буласың. Кайвакытта: «Өйдә юк иделәр, көтеп тордым», – дип алдарга да җае чыга. Әй шул иртән өчтә торулары, туң агач башмак белән утын кертүләре. Салкын, караңгы, ә мин, эттән дә иртә

торып, утын ташыйм. Үзәкләргә үтә иде шул. Кичтән генә ташып калдырыр идем, бай рөхсәт итми. Мичләргә утын тутырып ут куям, аннан – бозаулар эчерергә, бәрәннәр имезергә, мичләрне уздырып томаларга. Ис чыкса да, мин гаепле. Күп ягарга да, аз ягарга да ярамый. Бай, чыгып, утын пүләннәренә кадәр санап йөри. Бер якшәмбедә байга мунча ягам. Анда да мунча кызу да булсын, утынны да күп якма. Исле дә булмасын. «Мунча исле!» – дип бервакыт башыма йодрыгы белән төйде комсыз. Шулай итеп, тамак хакына көнгә егерме сәгать эшлим. Ашарга нәрсә диярсез әле. Эт-мәче ялаган шикелле, савыт-саба юганда калган аш, ипи сыныклары. Кайчакта ипи калдыклары да эләкми. Калса шунда, бер савыт аш. Хуҗабикә шундый саран, кыш көне кар сорап ала алмассың. Кунак-фәлән булганда гына бераз тамак ялгарлык ризык кала иде. И-и, оланнар, бар иде ул заманалар.

*Бай байлар бал эчә,*
*Урта байлар сыра эчә.*
*Ярлы халык – ярлы мескен,*
*Ярга ятып су эчә, –*

дигән җыр шул вакытлардан калды инде. Эш шундый авыр, шундый арыта, кич, кыйнап ташлагандай, бәрәннәр өенә, биләнке булып кереп авабыз да, салам мендәргә башны кую белән, изрәп китәбез. Ә иртә торулары, дисеңме? Иртә торулары тагын да авыр була. Күзләремне ачу белән үземнең кайда икәнем, эшлисе эшләрем исемә төшә дә, йөрәк жу-у итеп куя. Куллар, җилкә башлары сызлый. Торып, кузгалып китә алмыйча торам да, ничек көнне үткәрим дип, юк алай гына түгел, ичмасам, йортка чыгып егылыйм да, кеше күз алдында үләрмен, дип сәкедән төшәм. Стенага тотына-тотына, бәрәннәр арасыннан йортка чыгам. Йортка, саф һавага чыгу белән, башлап эшли торган эшләрем исемә төшә дә, бай күреп өскә җикеренә башлаганчы дип, бөтен сызлануларны онытып, эшкә тотынам.

Беркөнне шулай, кыш көне булды бу хәл, иртә белән бик каты башым авыртып уяндым. Йортка чыгыйм, мондагы сасы ис башыма тигәндер дип кузгалган идем, башым әйләнеп китте дә, идәнгә – бәрәннәр арасына егылдым. Торып, көчкә кире сәкегә менеп яткан идем, Галләм абый керде дә: «Ибраһим, тор, канәт! Бай күргәнче, казан астына ут куй. Терлекләр эчерер вакыт җитә!» – дип яныма килде. Галләм абзый, тора алмыйм. Торган идем дә башым әйләнеп аудым, дим. Галләм абзый башымны тотып карады да: «Авырыйсың бит син, атакай, сырхавың зур. Башың ут кебек. Ят алайса, наный, суны үзем җылытырмын», – дип чыгып китте...

– На-а әле, хайван, әйдә! Түбән таба элдертеп алыйк! Менә шулай...



– Шуннан ни булды, Ибраһим бабай? Бир, атны үзем тотып барам.

– Юк, олан, син утырып кына бар. Мин үзем кайда ничек барасын беләм. Шуннан ни булды, дисеңме? Күп тә үтмәде, акырып, илереп Гали бай килеп керде. «Ах, көчек баласы, әрәмтамак! Нишләп шул вакытка кадәр су җылытмадың?!» – дип, аягымнан эләктереп, сәкедән сөрәп төшерде дә типкәләргә тотынды. Мин, эчемә типмәсен дип, бөгәрләнеп еларга керештем. Ул: «Кычкырма, көчек баласы», – дип, авызыма суга башлады. Мин, кем дә булса ишетсен дип, ул суккан саен кычкырып елыйм. Ярый әле Галләм абзый килеп керде. Югыйсә тагын типкәләргә тотынган иде.

«Бай, бу нишләвең бу?! Атай, кабәм, үтерәсең бит! Адәм баласы бит ул, көчек баласы түгел!» – дип, ике арага керде. Аннары идәннән алып сәкегә салды. Бай: «Нишләп ята ул әрәмтамак, килмешәк!» – дип, тагын өскә килә башлады. «Сырхау ул, бай, хаста! Күрмисеңме, бөтен тәне ут кебек яна! Суны үзем җылытам, тимә балага!» – дигәч кенә, туктапып, Галләм абзыйны сүгәргә тотынды: «Сез барыгыз да дармоедлар, бушка тыгынып ятасыз! Нишләп бу вакытка кадәр су җылытмадың?! Азыкны исраф итәсез! Җыен хөрәсән минем йортка җыелган!» – дип, сүгенеп чыгып китте.

И-и ул кышны миңа эләккән кыен, әр-хур. Мин түккән күз яшьләре... Кулы белән генә булса бер хәл иде, кулына ни туры килсә шуның белән тондыра. Утын пүләнәме, кучарка, чыбыркы сабымы – барысын да татыды минем бу аркалар. Теге, мине адаштырып киткән Хәбибрахман абзый килеп чыкмасмы, дип көн дә көтәм. Күзләрем гел ул чыгып киткән капкада. Килсә, аңардан калмам, дип өмет итәм... Ә ул, хәерсез, килми генә. Көтеп-көтеп тә килмәгәч, бер читкә китәм дә елыйм. Кайвакытта елаганымны Галләм абзый сизеп ала да: «Ибраһим, наный, тагын еладыңмыни? – дип, яныма килеп, җилкәмә кулын сала. – Ела, наный, ела. Еласаң, уңай була ул. Иленне сагынасыңдыр?» – дип сорый. Сагынам шул, Галләм абый, бик сагынам, дим. Бер көн, бер сәгать тә тормас идем, юлда катып үлүдән генә куркам, дип әйтүем була, тагын күңелем тулып, кычкырып елап җибәрәм...

Ибраһим бабай, тирән сулап, көрсенеп куйды да сүзен дәвам итте:

– И-и, оланнар, адәм баласы туган җиреннән аерылмасын иде. Туган җирендә ачка үлү дә чит-ят җирләрдә эт баласы кебек үлүдән хәерлерәк. Шундый әр-хур, кыенга түзеп, кыш чыгарга туры килде миңа, оланнар. Сезгә карап торам да, сез бәхетле заманда үсәсез. Кадерен генә белегез дә, дөньялар гына тыныч булсын...

– Нигә качып китмәдең соң, дәү абый? Качып китәргә иде.

– И-и, энем, син үз башыңа төшмәгәч, белмисең шул әле. Качып кая барган булыр идем соң мин ул заманда? Ул заманда хәзерге кебек приютлар юк иде бит. Ул хәзер генә, Совет чыккач кына, ярдәмчесез балаларны приютларга җыеп карый башладылар. Ленин бабагыз гына шулай эшләде. Ул заманда мин байдан качып китсәм дә, катып кына үлгән булыр идем. Чуен юлы ерак. Пароходлар йөри торган вакыт түгел. Сәләмә бишмәт белән авылдан чыгуга, туңып үләсең.

Кайбер көннәрне, эшләрдән бушаган арада, бәрәннәр өенә кереп утырабыз да, Галләм абзый, чабаталарын да салмыйча, сәкегә сузылып ята да: «Ходайның тагын бер көнен үткәреп җибәрдек бит, Ибраһим. Бу айның да фәлән көне үтте. Бай хезмәт хакын арттырмаса, апрельдә мин китәм», – дия торган иде. Мине дә алып кит, Галләм абзый. Пароходка утыртып җибәрсәң, мин бик риза, дия торган идем. «Ярый, наный, мин сине калдырмам, китәрбез. Кышны гына үткәрик», – дип, мине шатландыра иде. Галләм абзыйның һәрвакыт җырлый торган җыры бар иде. Тавышы шундый матур, шундый моңлы. Ул җырлый башласа, ирексездән минем күзләр яшь белән тула иде. Аннары мин дә анарга кушылып җырлый башладым.

*Самара ла дигән ай каланың,*
*Трамвайларында йөрмәдем.*
*Бәхетле лә бала илдә яши,*
*Ташламый ла туган җирләрен.*

Шул җырны җырлап бетерер иде дә: «Әй бу дөнья, буялган йонга. Йоны да мамык, дөньясы да тәмуг», – дип, тирән сулап, уфтанып куя. Аннары: «Йә, наный, йоклыйк. Иртә тора алмабыз», – дип, икенче якка борылып ята иде.

– Ул абый сине пароходка утыртып җибәрдеме соң, Ибраһим бабай?

– Галләм абзыйны әйтәсеңме? Юк, ул әле миннән соң да анда калды. Минем бәхеткә, теге мине калдырып киткән Хәбибрахман абзый килеп, мине үзе эшли торган икенче авылга алып китте. Анда мине Хәмзә атлы муллага йомышчы малай итеп бирде. Мулла абзый Гали бай кебек комсыз, усал булмады. Мин йорт арасындагы эшкә булышчы булып йөрдем. Мулланың миннән өч яшькә кечерәк Нургали атлы малае бар иде. Без Нургали белән бик тиз дуслашып киттек. Шул дуслык мине күп вакытта авыр эшләрдән коткарып кала иде. Нургали бик шук, уйнарга ярата. Хәмзә мулланың берданбер баласы. Тау шуарга булса да, уенга булса да, әтисеннән сорап, мине алып китә. Дөресрәге, мулла абзый чакырып



ала да: «Ибраһим, бар әле шул малайны тау шуарга алып бар! Кайчан үзе генә йөри башлар инде... Карап уйнат инде анда. Юньсез балаларга иярмәсен!» – дия торган иде. Ә малае Нургали шундый хәйләкәр, капкадан чыкканда чанага утырып миннән тарттырып чыга да, капкадан чыгу белән, чанадан төшеп, шаярырга тотына. Көндә икешәр, өчәр сәгать уйнап йөрибез. Минем өстә – юка, сәләмә бишмәт. Әзрәк шуабыз да: «Әйдә, кайтабыз, мин өшим!» – дисәм: «Әз генә шуыйк инде», – дип, тагын шаярырга караша. Икәүләп чанага утырабыз да биек таудан тагын төшеп китәбез. Төшеп җитәрәк Нургали мине кочаклап ала да юри чанадан егып төшерә. Икәүләп мәтәлеп калабыз. Чана әллә кая китеп бара...

Беркөнне мулла абзый чакырып алды да: «Мә әле шушы тунны киеп кара!» – дип, Нургалинең иске тунын бирде. Кечкенәрәк булса да, ярап куйды. Минем сәләмә бишмәт түгел. Рәхәтләндем шул тунга. Ул тунны да Нургали әтисеннән: «Әти, минем иске тунны бирик әле Ибраһимга... Барып та җитмибез, ул өши башлый. Уйнарга тотынуга: «Әйдә кайтабыз, мин өшим, дип кайтырга борыла», – дип зарланган.

Беркөнне Нургали урамнан йөгереп кайтты да: «Әти, Нургалине җибәр әле? Мин аңа бер кызык күрсәтергә алып барам», – дип, әтисеннән мине җибәрүне сорады. Мулла абзый малаен ярата иде. «Ярар алайса, бар. Йортны иртә белән җыештырып бетерерсең!» – дип, миңа китәргә рөхсәт итте...

Йә, хайван! Әйдә, түбән таба элдертик әле! Н-а-а, менә шулай!

Җирән алаша түбән таба еракка киткән тигез юлдан матур гына йөгертеп бара башлады. Рәфгать түземе бетеп:

– Йә, Ибраһим бабай, шуннан, кайда, нинди кызык күрсәтергә алып барды Нургали? – диде.

– Капкадан чыгу белән Нургалига, кая барабыз, дим. «Әйдә тизрәк, соңга калабыз!» – ди Нургали. Үзе кая барганны әйтми. Кая барабыз соң, дим. «Баргач күрерсең. Әйдә, йөгердек», – ди ул, минем җиңнән тотып. Бер йорт аша гына, тыкрык буенда, урядникнең мунчасы бар. Каршысында таллар үсеп утыра. Тыкрыктан барып, мунча ишегалдына кердек. Нургали миңа әйтә: «Мунчага керәбез дә ләүкә астына төшәбез. Хәзер урядник яшь бикәче белән мунча керергә килә... Мин шул бакаларны урядникнең аркасына тондырам. Әй, кызык булачак», – ди...

Кызык та күрәсем килә. Бөтен тирә-якның өнен алып торган урядниктән дә куркам. Ул урядник беренче күрүемдә үк котымны алган иде: Хәмзә мулла хатыны Хәдичә абыстай мине аларга гөбе сорарга керткән иде. Әле беренче килгән көннәр. Капканы ачып керүем булды,

зур мыекларын бөтереп, Карахмәттәй таза үрәдник басып тора. Капканы ябып, ишек алды ишегенә таба бара башлаган идем, үрәдник миңа күзләрен әйләндереп карады да: «Кая керәсең, көчек баласы! Пошёл моннан!» – дип, өнемне алып, кычкырып җибәрде. Мин аптырап калдым. Шулай да бөтен көчемне җыеп, йомышка керәм, дигән идем: «Бирермен мин сиңа йомыш, пошёл!» – дип, өстемә килде дә, эләктереп алып, мәче баласы кебек култык астына кыстырып: «Әйдә әле мин сине каталашкага ябып куям!» – дип, келәт эченә ыргытты. Аннан рәшәткә ишеген ябып куйды. Мин еларга керештем: Хәмзә мулла хатыны Хәдичә абыстай гөбе сорарга җибәрде, дим.

Ә ул һаман: «Алдыйсың, көчек баласы, мулланың үз малае бар!» – ди.

Нургали өйдә юу-ук, дим. Шуннан өйдән кемнедер чакырып чыгарды да: «Танылсыңмы бу көчекне?!» – дип кычкырды. «Ай алла, – диде теге хатын. – Ул бит Хәмзә муллаларда тора торган малай. Хәзрәт ишетсә, яхшы түгел. Нишләп анда яптың аны?» – дигәч кенә, ишекне ачып, мине чыгарды. Шуннан мин, ул үрәдниктән куркып, дошман күреп йөри башлаган идем. Монда ишегалдына кергәч, Нургали минем курыкканымны сизеп: «Син аңардан курыкма. Хәзер тими инде ул сиңа. Үрәдник ул үзе дә әтидән шикләнә», – дигәч, риза булдым. Аннары теге вакытта кыерсытканы өчен үзеннән үч тә аласы килә иде. Шуннан минем дә башка бер уй килде. Юк, мин әйтәм, Нургали, ләүкә астына төшмибез. Потому что үрәдник, ләүкә астыннан безне мәче баласы кебек эләктереп кенә алачак. Тотып алыр да бәреп үтерер. Мин аның кулын бер татыдым инде, дим. «Нишлибез соң?» – ди Нургали. Без болай итәбез, мәйтәм. Бакаларны кайнар суына салабыз да, ишеген тутырып ачып куеп, ташына бер чиләк салкын су тондырабыз. И тизрәк моннан таябыз. Һәм шулай эшләдек тә. Ну, безнең бер ялгышбыз булды, китеп ычкына алмадык. Яшь бикәче белән үрәдник килеп керде. Бетте баш, мин әйтәм... «Нишлисез монда, мулла көчекләре?! – дип, баштан Нургалине эләктереп алды да чәпелдәтте тегенең арт санына.

«Ник мунчаны суыттыгыз?! Кем кушты?!» Нургали, мескен, илереп елый-елый: «Без җылынырга гына кергән идек. Без түгел... Без килгәндә ачык иде-е!» – дип елавы елау. Мин куркудан нишләргә белмичә мунча ишеге артына төртелгән идем. Нургалине карга чыгарып атты да: «Кайда теге хәерче көчеге?» – дип, мине эләктереп алды. Билемнән култык астына кыстырды да калак кадәр куллары белән йомшак җиремә эләктерә генә, тун итәген кайтарып. Аннары тышка алып чыгып, мунча каршысындагы талга тунымның билдәмәсеннән элеп куйды. Өзеп алырдай итеп борынымнан кысты да: «Тыныңны чыгарасы булма! Балык кебек кипкәнче шунда эленеп тор!» – дип, мунчага кереп китте. Ул арада Хәмидә апа китеп барган. Нургали дә, артына да карамыйча, өйләренә чапкан. Үрәдник мунчадан күзләрен акайтып, сүгенеп чыкты да: «Кем мунчаны суытты?! Сезнең эшме?!» – дип, колагымнан бора башлады. Өзеп ала дип торам. Кысылган кәҗә кебек, ай-яй-й дип акыра башлаган идем: «Кычкырма чучка кебек! Әйт, кем суытты мунчаны?» – ди. Үзе колакны җибәрми. Без җылынырга кергән идек. Ачык иде-е, дим. «Кем шулай эшләгән? Әйт!» – ди. Белм-и-и-м, без күр-м-ә-дек, дим, елап. «Кычкырма!» – дип, авызыма сукты да, авыз-борынымнан кан китте. «Кычкырма! Тыныңны чыгарасы булсаң, каталашкага ябып куям!» – дип, сүгенеп китеп барды. Минем борыннан кан китте дә, пәт-пәт тамып тора башлады. Колагымны өзеп алганмы әллә, дип тотып карыйм. Юк, колак урынында. Тик авыртуына гына чама юк.

Мин шунда, аяк-кулларым белән асылынган килеш, түбән карап, тал ботагында эленеп калдым. Инде нишләргә? Тегеләй дә, болай да итеп карыйм, юк, талдан ычкынып булмый. Нургали дә юк. Сынып төшмәсме дип, тирбәлеп та карыйм, сынмый каһәр. Сиртмә кебек тирбәлеп кенә тора. Бик озак азаплангач, башка бер уй килде. Тунның бауларын чиштем дә, тунны агачта калдырып, кар өстенә лап итеп килеп төштем. Аннары, мунча алдындагы көянтә белән тунны алып, өйгә йөгердем.

Бу эшкә Нургалине Хәмидә апаны яратып йөргән бер егет котырткан булган икән. Үрәдник аркасына ташларга дип, бакаларны да ул биргән. Бу турыда без икебез дә берәүгә дә сөйләмәскә булсак та, үрәдник икенче көнне үк безнең турыда хәзрәткә җиткергән. «Малаеңны үзең өйрәт, ә теге хәерче көчеген бер атнага каравыл өенә илтеп яп!» – дигән. Шул ук көнне хәзрәт кайтты да, кулына чыбык алып, Нургалине үз янына дәшеп алды: «Төнәген Ибраһимны нинди кызык карарга алып киттең? Кем котыртты, әйт дөресен?!» – диде. «Беркем дә котыртмады», – ди Нургали, каушап калып. «Кем котыртты, каһәр суккан малай, шайтанмы?! Шайтан котырттымы?!» «Әйе, – диде Нургали, тагын да куркуга төшеп. – Шайтан...» «Кил әле монда, шайтаннарыңны куыйм әле мин синең!» – дип, Хәмзә мулла Нургалине эләктереп алды да, тал чыбыгы белән шап-шоп китереп, улын кыйный башлады. Нургали, мескен, иркә генә үскән, тотынды кычкырырга, еларга. Мин түзмәдем, йөгереп бардым да, ике арага кереп, Нургалине кочаклап алдым. Ул арада миңа да эләкте. Ну, шулай да, минем Нургалине яклап ташлануым хәзрәтнең ачуын кайтарды. Тук-

тады бит кыйнаудан. «Моннан ары актыгы булсын! Минем абруемны төшереп, алай йөрисе булсагыз, икегезгә дә яхшы булмас. Шуны ишетсен колагыгыз!» – дип кисәтте.

Шул ук көнне мине каравыл өенә яптылар. Ярый әле Нургали килгәләп хәлемне белеп йөрде. Көненә бер телем ипи белән судан кала әйбер бирмәделәр. Нургали китергәләмәсә, бар атнада балык кебек кипкән булыр идем...

Шулай итеп яз җитте. Аннары Хәмзә мулла мине сабан сукасына алып китте. Иртән, таң белән уята да, үзе белән арбага утыртып, кырга алып китә иде. Атларны җигеп, сабанны көйләгәч, җирен башлап бер әйләнә дә: «Менә шулай сукала. Кичкә килеп алырмын», – дип, үзе китеп бара. Мин көне буе бер ялгызым хәзрәтнең җирен сукалыйм. Кич, кояш баеганда гына, килә дә башта дәшми-тынмый җирне карап чыга. Аннары, аз сукалагансың, дип мыгырдый. Арыдым хәзрәт, ат та арыды, дим. Дөрестән дә мин аягымны да кузгата, телемне дә әйләндерә алмаслык, шунда ятып калырдай арыган булам. Ә ул: «Кил әле, атлар ничек арыган икән?» – дип, тагын сукалатырга керешә. Кыш, яз көннәрендә болай ярыйсы гына кеше кебек иде. Сукага төшү белән бөтенләй комсызлана. «Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың», – дигән була. Минем хәзрәт өчен бер дә сайрашасым килми. Язгы чәчү беткәнче, буразнада ятып үләм, дип торам. Аннан, бер атна да үтмәде, пар җирләрен сукаларга алып китте. Әти-әнине, авылны сагынуымның чамасы юк. Хәзрәткә көн дә ялынам, көн дә елыйм. Баштан: «Пар сукаланып беткәч», – дип йөрде. Пар бетте дә: «Печәннәрне җыеп алыйк инде. Аннары юлыңа акча биреп, пароходка озаттырырмын», – дия башлады. Кайтасы килүгә чама ак. Көн дә күз яше. Нургали генә янымда угаланып йөри. «Елама, әти белән үзем сөйләшәм», – дип, беркөнне минем янга әнисен – абыстайны алып килде. «Ник елыйсың, наный?» – ди абыстай. Әниләрне, өйне сагындым, хәзрәт җибәрми, дим. Үзем тыела алмый елыйм.

Шуннан аркамнан каккан булды да: «Елама, хәзрәт белән үзем сөйләшермен, җибәрер. Җибәрми булмас», – дип ышандырып китте.

Шуннан бер атна үттеме икән, ун олаулап зур кибән куйгач, Идел пристанена баручы бер олаучыга утыртып җибәрде үземне. Унике яшь тулган көнне өйгә кайтып егылдым.

Менә шулай, оланнар. Күрде инде минем башлар. Шуннан, гомергә беркая да чыкмам, дигән идем дә, солдаттан калгач, тагын чыгып китәргә туры килде. Бу юлы инде Сарытау ягына ук барып җиттем. Анда Идел буе немецлары бар. Шунда бер немецта хезмәтче булып кыш чыктым.



Өйләнергә иде исәбем. Акча эшләргә дип барган идем. Аңда немецлар яхшы түлиләр, дип ишеткән идем. Карап торсаң, без булмаган җирдә генә яхшы икән. Байлар барысы да бер тиен өчен чукына торган сараннар икән. Ун ай эшләгәч, расчёт ала башлаган идем: «Бер пар – күн итек, бер кием киез итек туздырдың, чалбар алып бирдем. Сәнәгемне сындырдың, балтамны югалтып кайттың», – дип, биш сум акчамны тотып калды. Егерме сум урынына унбиш тәңкә акча тотып кайтып киттем.

Ибраһим бабай кинәт башын күтәреп алга карады да, нидер исенә төшкән кеше шикелле, юлның түбән таба киткәнен күреп, дилбегәне тарткалап атны чаптыра башлады:

– Әйдә әле, малкай, әйдә! Менә шулай! Әнә Салманга җитәбез, – диде ул, малайларга карап. – Салманда атны эчереп чыгарбыз. Аннары, бераз ял биреп, ашатып алырбыз. Тоташ куаласак, барып җитә алмас.

Спаска килеп җиткәндә, кичке алтылар булып килә иде. Ибраһим бабай, әкрен генә көйләп, моңаеп барган җиреннән, атны сул якка борып алды да зиратка бара торган урам белән йөгертә башлады. Бераз барганнан соң, янына утырган Илгизәргә:

– Әйдәгез әле, энем, мин сезгә Исмәгыйль абыегызның каберен күрсәтим, – диде. – Сез аны белергә тиеш. Бигрәк тә син, энем. Мондый җай әллә туры килә, әллә юк.

– Нәрсәгә? – диде Гата, сүзгә кушылып.

– Хәтерегездә саклансын өчен, оланнар. Андый кешеләрне без онытмаска тиешбез.

– Кем соң ул? Кем иде Исмәгыйль абый?

– Исмәгыйль – минем энем. Илгизәрнең әтисенә дә эне...

– Нигә соң аны монда күмгәннәр. Авыл зиратында түгел?

– Исмәгыйль авылда беренче булып кызыл гвардиягә язылган. Ярлылар комитеты оештырып, унсигезенче елның язында куелган бәядән авыл ярлыларына кулаклардан икмәк алып бирүдә катнашкан кеше. Чехословаклар фетнәсе вакытында авыл байлары аны чехлар комендантына тотып бирәләр. «Кызыллар шпионын тоттык», – дип, аклар аны атып үтерә. Аның гомере менә шулай Спаста өзелә. Исмәгыйль безнең власть өчен башын салган кеше. Сез аны белергә, хәтерегездә сакларга тиешсез. Вакытым бик тар булса да, мин аның каберен сезгә күрсәтмичә китә алмыйм. Сез үсеп җиткәч, үз балаларыгызга күрсәтерсез. Андый кешеләр, хәтер булып, телдән-телгә күчеп яшәргә тиеш...

Зират капкасыннан кереп, уңга борылганнан соң, Ибраһим бабай артыннан ияргән өч малай, рәшәткәләр арасыннан үтә-үтә, еллар үтү белән

ярыйсы искергән чардуган каршысына килеп туктадылар. Ибраһим бабай, башыннан эшләпәсен салып, рәшәткәгә якын ук килеп басып, башын иде. Малайлар да аңардан калышмадылар. Алар башларын игән хәлдә тын басып тордылар.

– Үтә гомер, – диде Ибраһим бабай, кабер өстенә карап. – Безнең чәчләр, сакал-мыеклар агарды. Ә син, энем Исмәгыйль, хәзер дә чатнап торган егет булып күз алдында торасың. Егерме бер яшеңдә, өйләнергә да өлгерә алмый китеп бардың. Харап иттеләр үзеңне, туганкаем. Харап кына иттеләр...

Ибраһим бабай бераз тын алмыйча торды да яңадан башлап китте:

– Урта буйлы, кара чәчле, кара күзле, бик үткен егет иде. Герман сугышыннан кайткач, ярлыларны оештырып, хөррият өчен янып-көеп йөргән иде мәрхүм. Авыл байлары башына җитте.

Ул бер мизгел, онытылмасын, хәтердә ныграк калсын дигән шикелле, кабер өстенә карап торды да малайларга эндәште:

– Әйдәгез, оланнар, кузгалыйк. Пароходка соңга кала башларбыз. Мин монда кунам әле, иртән килеп, кабер, чардуганны карап китәрмен әле... – дип, тиз-тиз атлап, ат янына ашыкты. Ләкин энесе турындагы уйларыннан арына алмады.

Идел буе таллыклары арасыннан барган бормалы-бормалы ат юлы белән затонга килеп чыкканда, кояш баеп килә иде. Илгизәр белән Гатаның Иделне беренче күрүләре булганга, исләре китеп, киң Иделгә, аның аргы ягында сөрем эчендә күренеп торган биек тауларга карап тордылар. Аннан күзләре яр астындагы зур дебаркадерга төште.

– Ай-яй зур пароход! – диде Гата. – Шуңарга утырып барабызмы без?

– Морҗасы юк бит моның, – диде Илгизәр.

– Пароход туктый торган урын гына ул, җүләр, – дип көлде Рәфгать. – Пароход моннан зуррак, ак була, бу яшел.

– Йәгез, оланнар, әйберләрегезне алыгыз да әнә шунда төшегез. Билет сата торганы да, көтеп тора торган җир дә шунда. Казанга пароход килмәгән икән әле, – диде Ибраһим бабай. – Мин китәрмен инде. Монда кунарга калмам. Үзегез генә билетлар алырсыз бит?

– Мин беләм, Ибраһим бабай, – диде Рәфгать. – Бар син, кайт. Билетларны да алырбыз. Утырып та китәрбез.

– Йәгез, оланнар, сау булыгыз! Карап кына, тәртипле генә йөрегез!

– Сау бул, дәү абый.

– Сау бул, Ибраһим бабай. Әниләргә пароходка утыртып җибәрдем, диярсең, – диде Гата ни өчендер.



Ибраһим бабай, аякларын салындырып, арба читенә утырды да, кайту ягына бер дә кыстатмыйча йөгергән җирән алашасын әйдәкләп, чаптырып китеп барды. Икесе бертигез, берсе бер башка биек өч малай, биштәләрен тоткан килеш, бер рәттә басып калдылар. Гата белән Илгизәрнең йөзләренә моңсулык йөгерде. Бераз киткәч, карт борылып карады да кул изәде. Малайлар да кул болгадылар.

* * *

...Идел буенда өч малай басып тора. Берсе – Рәфгатъ Атнабаев, иптәшләреннән бер башка биегрәк. Матур, озынчарак ак йөзле, саргылт чәчле, зәңгәр күзле үсмер. Башында – козырёгы күтәреп киелгән килешле кепка. Ак күлмәк өстеннән ярым сукнодан тегелгән бер катлы пинжәк. Өстендәге киеме үзенә килешеп тора. Матур, йомшак тел белән сөйләшә. Кайвакыт «йә» урынына «җә» дип җибәргәли. Һәрвакыт шат. Төрле кызыклар оештырырга хирыс. Яхшы укый. Рәсем ясарга осталыгы бар. Читтә шактый йөргәнлектән, күп белә.

Гата белән Илгизәр буйга икесе дә бертигез. Икесе дә бераз шадралар. Бит төзелешләре белән да охшашлар. Тик Гата кара чәчле, кара күзле. Илгизәр соры чәчле, соры күзле. Гатаның өстендә – ак күлмәк, чалбар балаклары кыскарак булганлыктан, аягындагы йон оекбашы күренеп тора. Илгизәрнең өстендә – билдәмәле гимнастёрка. Кепкасының козырёгы зур булганлыктан, җыелеп, ямьшәеп тора.

– Әйдәгез, малайлар, пристаньга төшик, билет сата башларлар, – диде Рәфгать, баскан җиреннән кузгалып.

Пароход килү белән, Рәфгать, өч билетны да үзе алып, иптәшләрен ияртеп, пароходка алдан керде. Трапны үтүгә, сулга борылып, палубада тезеп куелган мичкәләр өстенә күрсәтте:

– Шунда урнашыгыз, малайлар! – дип, кара кыршаулы ак мичкәләр өстенә биштәрен куйды.

– Дүртенче класс дигәне кайда соң? – диде Илгизәр, як-ягына каранып.

– Шушы инде дүртенче дигәне, – диде Рәфгать, – монда ошамаса, әнә койрыкка чыгарга була. Тик анда төнлә салкынча...

– Ярар, күченеп йөрмик инде. Шунда урнашабыз да йокларга ятабыз.

– Озак йоклый алмабыз әле. Пароход төнге икедә Казанда була.

Бераздан малайлар тирәсендәге буш урыннар капчыклы,биштәрле, төенле кешеләр белән тулды.

Илгизәр белән Гатаның пароходкаа беренче утырулары. Андагы тәртипләрне белмиләр.

– Әйдә, – диде Рәфгать, кружкасын алып. – Кайдан су алырга икәнен күреп килерсең, – дип, Илгизәргә карады. – Син, Гата, әйберләрне кара.

«Кипяток» дип язылган җирне карап, су алып килгәннән соң, алар чәй эчәргә утырдылар.

– Идел суы тәмсез икән, – диде Илгизәр, борынын җыерып. – Әллә нинди дару исе килә.

– Пароход казаны исе ул, – диде Гата, белдеклеләнеп.

– Хлор исе ул, – диде Рәфгать. – Идел суын даруламыйча эчәргә ярамый. Бөтенесенең тәрәте шунда.

Чәйдән соң малайлар пароходны карап, танышып йөрделәр. Пароход алдындагы палубага чыгып, каршы килгән пароходларны, баржаларны күзләп, озатып бардылар. Соңыннан мичкәләр өстенә урнашып, тәмле генә йоклап барганда Рәфгать:

– Малайлар, Казанга җитәбез! Халык кузгалды, – дип кычкырып җибәрде. Шул тавышка иләс-миләсләнеп сикереп торган малайлар, биштәрләрен алып, Рәфгать артыннан кузгалдылар. Уң якта, кешеләр төркеме арасыннан, күктәге йолдызлар шикелле җемелдәшкән шәһәр утлары күренде.

– Казанга җиттек, малайлар!

Яр буена туктаган зур-зур баржалар, буксир пароходлар яныннан уза-уза пароход алга барды да ике янәшә туктаган пароход борынына өченче булып килеп туктады.

Халык төркеменә кушылып, малайлар ике пароход һәм дебаркадер аша Идел ярына чыгып бастылар.

– Кая барырга? – диде Гата, як-ягына каранып.

– Трамвай кайда, шунда барырга, – диде Илгизәр, әтисе өйрәткәнне хәтерләп. – Кольцога кадәр трамвай белән барасы.

Бераздан халык төркеме:

– Трамвай килә! – дип, ишелеп, алга кузгалды. Халык төркеме арасыннан, чың-чың иткән, колакны яра, тешкә тия торган әллә ничә төрле тавыш чыгарып, трамвай килгәне күренде. Төнлә трамвай йөрмәгәнлектән, шактый күп җыелган халык, бер-берсен этә-төртә, трамвай килгән якка агылды. Малайлар беренче трамвайның түбәсен генә күреп калдылар. Бер-берсен югалтып, адашып калудан курыккан малайлар, үзара сыенышып, берничә трамвайны үткәреп җибәргәннән соң гына Рәфгать:



– Монысына утырабыз, миннән калмагыз! – дип, алга ташланды. Аның артыннан ияргән Илгизәр белән бергә вагонга эләктеләр. Гата исә ике-өч олы кеше арасында кысылып калды.

– Каласың бит, Гата, тизрәк!

– Без сине Кольцода көтәрбез! – дип кычкырды Рәфгать. Ләкин Гата боларның берсен дә ишетмәде. Ике олы кеше арасыннан башын сузып:

– Китмәгез! Китмәгез! – дип, үрсәләнеп кычкырды. Аның бу кычкыруының файдасы тиде. Теге кешеләр, читкә кагылып, аңа юл бирделәр. Гата куркынган кыяфәттә, ашыгып, вагон ишегенә килеп асылынды. Рәфгать аны шунда ук эләктереп алды да эчкә тартып кертте.

Трамвай кузгалып китте дә, тимер шалтыраган, дөбердәгән, чучка чинаган тавышлар чыгарып борылганнан соң, алга йөгертә башлады. Шулвакыт Илгизәр Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасының трамвай турында язылган юлларны исенә төшерде. Трамвай турында ул инде укыган иде. Ә трамвайның үзен «Туган тел» китабындагы рәсемдә күрде. Менә бүген алар Казанда, дөбер-шатыр китереп, дию пәриен өстерәп барган трамвайда баралар.

Шәһәргә җитәрәк, трамвайда халык кими төште. Ул арада төн караңгылыгы бетеп, тирә-юньгә яктылык иңде. Малайлар тирә-якны карап бара башладылар. Алда, бераз сулдарак Кремльнең ак стеналары артыннан, ялтырап торган зур-зур чиркәү гөмбәзләре арасыннан киртләчләнеп торган Сөембикә манарасы күренде.

Илгизәр:

– Әнә Кремль, әнә Сөембикә манарасы! – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. Малайларның йөзләре яктырып китте. Ниһаять, моңа кадәр рәсемнәрдә генә күргән, укытучы апалары сөйләгән буенча гына белгән Казан Кремлен, Сөембикә манарасын үз күзләре белән күрделәр.

Әле көннең башы гына, кояш та чакмаган. Казан урамнары буш. Шәһәр әле уянмаган. Урамнарда сирәк-мирәк урам себерүчеләр генә күренгәли.

Мәктәпне тапканнан соң, малайлар бик озак ишек төбендә көтеп утырдылар. Тәмам аптырап, инде булмады дип өметсезләнә башлаганда гына, төш тирәләрендә аларны директорга керттеләр.

– Ни йомыш? – диде директор, ишек төбендә капчыкларын күтәреп басып торган өч авыл малаена карап.

– Абый, без укырга керергә дип килгән идек, – диде Рәфгать.

– Кайдан килдегез, ерактанмы?

– Әлки районыннан, Алпар ТБУМның дүртенче классын бетердек.

– Ерак икән шул. Сезгә ничә яшь соң?

– Миңа – ундүрт, боларга унике тулды.

– Бераз үсәсегез бар икән шул әле. Менә сине хәзерлек бүлегенә алырга була, – диде директор, Рәфгатькә карап.

– Без шул, абый, өчебез бергә керергә дип килгән идек.

– Шулаймыни? – диде директор, елмаеп. – Яшегез җитеп бетми шул. Аннары тулай торакта да урын юк. Әгәр дә сезгә барактан урын бирсәм, каласызмы? Ул вакытта мин сезне хәзерлек бүлегенә ала алам.

– Калабыз, абый, – диде Илгизәр.

– Алайса, язуларыгызны бирегез. Хәзергә болай гына укып йөрерсез. Яңа елдан яшьләрегез дә арта. Бәлки... (директор, китүчеләр булса, диярргә теләгән иде дә, тукталып калды) тулай торакта урыннар бушар.

– Ярар, абый, без риза, – диде Рәфгать. Ләкин алар директорның баракның бик еракта, шәһәр читендә урнашкан булуын әйтмичә калдыруын белми иде әле. Директор малайларның язуларын алып карады да:

– Яхшы. Яхшы укыгансыз икән, – дип, өстәл тартмасына салып куйды. Аннары хуҗалык эшләре буенча ярдәмчесен чакырып алды да малайларны ашханәгә учетка кертергә, ашатканнан соң, өчесен бергә баракка илтеп урнаштырырга кушты.

Ашханәдән чыкканнан соң, әлеге абый, малайларны Болак буйлап Кольцога таба алып китте. Бутлеров урамына менә торган җирдә трамвайга утырдылар. Биек матур йортлар күренгән саен малайлар: «Әллә шул йорттамы икән?» – дип өметләнеп барсалар да, теге абый һаман трамвайдан төшү турында сүз кузгатмады. Шулай өметләнеп, көтеп бара торгач, кондуктор: «Конечная!» – дип игълан итте. Трамвайда берничә кеше генә калган иде, теге абый:

– Әйдәгез, малайлар! – дип, урыныннан кузгалды.

Җәяүләп киттеләр. Алда өйләр бетте. Урам башында, тирән чокыр төбендә тимер юл полотносы күренде. Тар сукмактан шул чокырга төшеп киттеләр. Тимер юлны үтеп, чокырның теге ягына чыкканнан соң, тагын киң үзәнле тирән чокыр күренде. Ул чокыр үзәне чүп-чар белән тулган. Тегендә дә, монда да ком, балчык алынган чокырлар. Сукмактан читтә камышлы үлән үскән.

Малайлар, шикләнеп, бер-берсенә карап алдылар.

– Ай-яй, бу чокырлар аша ничек йөрербез? – диде Илгизәр.

– Бигрәк ерак. Җәһәннәм артында икән!



– Ерак икәнен директор әйтмәдеме? – диде озата килүче абый. – Хәзер ярый әле. Көзге пычракларда, караңгыда, кышкы бураннарда ничек йөрербез, диген...

Малайлар бер сүз дәшмәде. Алар үзләренең начар хәлдә калуларына аптырашканнар иде. Гата белән Илгизәр, син ни уйлыйсың, дигәндәй Рәфгатькә карадылар. Рәфгать үзе дә, ни диярргә дә белмичә, аптырашта калган иде.

Чокырны чыгып өскә күтәрелгәч, йөз илле метрлап алдарак берничә барак күренде. Алты койка куелган зур бүлмә малайларның торак урыны булып китте. Бүлмә ачкычын кесәдә калдырасын әйткәннән соң, озата килгән абый иртәнге җидедә – ашханәдә, сигездә мәктәптә булырга кирәклеген кисәтеп китеп барды.

Иртәгесен алтыда торып, өйдән алып килгән ашамлыкларыннан берәр кисәк ипи алдылар да кичтән килгән сукмак белән трамвай тукталышына йөгерделәр. Көненә – дүрт сәгать уку. Беренче көннәрне малайлар бөтен нәрсә белән кызыксынып, мавыгып йөрделәр. Барганда-кайтканда шәһәрне карыйлар. Тирә-якта алар өчен яңа күренешләр, бар да үзгә. Кичләрен баракка кайтканнан соң гына, күңелсез булып кала. Чыгып йөрер җир юк. Өстәвенә, алар кичке аштан мәхрүм. Сәгать дүрттә эшләре бетә дә кайтып китәләр. Салкын су белән ашханәдән алып кайткан ипиләрен ашыйлар. Җитмәгәненә өйдән килгән сохарилар бар.

Икенче кичне үк Гата авылны искә алды. Кружкасы белән су алып кергәндә: «Көтү кайткандыр инде. Әни сыер саварга җыенадыр... Хәзер алар да чәйгә утыра торганнардыр... Монда безгә генә, салкын судан кала, бер әйбер юк», – дип уйланды. Шулай да ул турыда иптәшләренә әйтергә яхшысынмады. Әйтермен дә, килеп җитмәдең, өйне сөйли башладың, дип көлүләреннән шикләнде.

Шулай да, чишмә суыннан әни куйган чәйләр юк инде монда дип, кружкасын өстәлгә куйды. Дүрт көн шулай авыл, өй, әни турында сөйлиселәре килсә дә, Гата белән Илгизәр, Рәфгатьтән яхшысынмыйча, эчтән генә тынып, эчтән генә уйланып йөрделәр. Бишенче көнне Гатаның түземе бетте. Трамвайдан төшеп, баракка кайта торган сукмакка чыгуга:

– Алпарда укысак, хәзер балык тотып кайтыр идек, – дип башлады.

– Кармагыңны алып киләләр аны, – дип көлде Рәфгать. – Монда да тотар идең...

– Монда кайда тотасың? Идел җәһәннәм артында. Анда без Чирмешән буйлап, болыннар аша, карлыган сазы буйлап йөри идек. Теләсәң – җиләк җыеп аша, теләсәң – карлыган, юа, какы, гөлҗимеш, шомырт, дисеңме...

– Йә, җитте! – диде Рифгать. – Булмаганны иске төшереп...

Илгизәрнең дә Гатага кушылып китәргә исәбе бар иде дә, Рәфгать җитте дигәч, тукталып калды. Йә тагын, мәми авызлар, килеп җитмәдегез, әниләрегезне сагына башладыгыз, дип көлә башлар дип уйлады.

Тимер юл чокырын чыгып, беренче тирән чокырга төшеп киләләр иде, түбәндә бер төркем малайлар күренде. Икесе болардан зурлар, өчесе Рәфгать чамасындагылар, икесе Илгизәрләр чамасындагы җиде малай чокыр уртасында каршы төштеләр. Алга чыккан чандыр малай:

– Тартырга бармы, салагалар? – дип, Рәфгатьнең каршысына ук килеп басты.

– Без тартмыйбыз.

– Алайса, акчаңны чыгар!

– Нинди акча, без укудан кайтабыз.

– Обыскать! – диде чандыр. Сукбайлар яшен тизлеге белән өч авыл малаен чолгап алдылар да тенти башладылар. Малайларда, ипидән кала, бер әйбер дә юк иде. Чандыр анда да:

– Сойдёт, заберите хлеб! – диде дә читкә китеп басты.

Ул көнне авыл малайлары, ике йөз грамм ипиләреннән дә коры калып, баракка бернәрсәсез кайтып керделер.

– Бу эш түгел, – диде Гата, ишекне ачып кергәч. – Иртәгә дә шулай каршы алсалар? Әле ярый өйдән килгән сохарилар бар.

– Нишләргә иде соң синеңчә? Алар җидәү, без өчәү. Икесе әнә нинди. Көтмәгәндә сугышкан булсак та, эш чыгара алмас идек.

– Әй, аның ише салам торхан. Буе гына бит аның...

– Йәгез, туйдан соң дөмбергә дигәндәй, хәзер әтәчләнеп торудан ни файда. Иртәгесе турында уйларга кирәк. Дүрт-биш кенә булсалар, бирешмәс идек.

– Дөрес, без алар кебек төпчек җыеп, төпчек суырып үсмәгән, – диде Гата. – Эшләгән беләктә, май булмаса да, көч бар.

– Шулай да бит, шәһәргә килеп сугышып йөрү дә пионер эше түгел.

– Син, Илгизәр, бигрәк тә әдәпле инде. Пионер эше түгел дип, үзебезне хурга калдырып, деревенская салага, дип ипиләребезне талап алганнарын карап торыргамы? Бүгенге кебек.

– Иртәгә да каршы чыксалар, бирмәскә, малайлар! Каушап калмаска!

Икенче көнне дә малайлар торакларына тыныч кына кайтып керә алмадылар. Чокыр төбендә аларны дүрт сукбай каршы алды:

– Кайтасызмы, салагалар? – Бу кичәге чандыр иде. – Акчаларыгызны, ипиләрегезне чыгарыгыз да, рәхим итеп үтегез!



– Китегез юлдан! – диде Рәфгать, саллы таягын күрсәтеп.

– Берни дә бирмибез. Менә сезгә! – дип, Гата йодрыгын йомарлап күрсәтте.

– Китегез юлдан. Бездә, ипидән кала, бер әйбер дә юк.

– Безгә ипи дә ярый, – дип авыз ерды чандыры.

– Тешеңне ырҗайтма! Син әрәмтамакны сыйлар өчен дүрт сәгать эшләмәдем мин, – диде Илгизәр. – Ашыйсың килсә, эшләп аша. Әнә буең нинди!

– Буй гына бит аңарда. Аның эче тәмәке төпчеге белән тулган. Черек... Эшләргә хәле юк аның, төрттең исә ава.

– Йә, телеңә салынма!

– Хак сүз күңеленә ярамыймыни? Әйдәгез, малайлар, – диде Рәфгать. – Әйдәгез. Якын киләсе булмагыз!

Илгизәр белән Гата чандырны әйләнеп уздылар да ары атладылар.

– Ладно, я вам покажу! – диде чандыр, бармагы белән янап.

...Шулай бер атна үтеп китте. Малайлар көн саен, иртән торып, трамвай тукталышына йөгерәләр. Дүрт сәгать укыганнан соң, практик эш дип, аларны класстан алып чыгалар. Практик эш дигәч тә, төрле кораллар белән эшләргә өйрәнәбез дип шатланып чыксалар да, юкка гына булды. Инде икенче атна укып йөриләр, әле мастерскойның, столярныйның кайда икәнен да белмиләр. Кай көнне балта тоттыралар да ботак юндыралар, бүрәнәнең кабыгын чистарттыралар, чүп җыйдыралар. Группада унҗиде-унсигез яшьлек егетләр – алар арасында бу авыл малайларын бар дип тә белмиләр. Башкалар столярныйга киткәндә, алар өчәү агач чистартырга, чүп җыярга чыгалар.

Ял көне җитте. Ерак булганлыктан, малайлар иртә торып ашханәгә бармадылар. Озак кына йокладылар да төшке ашка киттеләр.

– Әйдәгез, малайлар, ашап чыгабыз да Ленин бабай укыган җирләрне, Кремльне карап кайтабыз, – диде Илгизәр. Бу тәкъдим барысына да ошады. Ашханәдән чыгу белән, Бауман урамына юл тоттылар, аннан университет урамы буенча күтәрелеп, медицина институтын үткәннән соң, мәһабәт баганалары белән әллә кайдан күренеп торган Казан университетына килеп чыктылар. Университет бинасына сокланып, шактый озак карап торганнан соң, урам буйлап Кремльгә таба атладылар. Һәр бинаны җирдән алып түбәсенә кадәр карап, элмә язуларны укып, кайбер кибетләргә дә кереп бара торгач, Кремльгә җиттеләр. Капкасыннан эчкә үтеп, Кремльне карый-карый, Сөембикә манарасына килеп чыктылар... Ул көнне алар бик нык арып, торакларына соң гына кайтып кергәндә, кояш баеган иде инде.

Илгизәрнең авылны сагынуы көннән-көн арта барса да, сиздермәде. Ерык авыз Рәфгать: «Мәми авызлар, петәй имәсегез киләме?» – дип көлә башлар дип курка иде ул.

Ә менә Гатаның ул көнне шеше тулган иде. Капчыгыннан сохарилар алып, тәрәзә янына барып басты да, авыл ягына карап, уйга калды. Аннары тирән сулап куйды да:

– Эх, малайлар, авылда булсаң иде. Хәзер кичке уенга чыга торганнардыр. Ә без... – диде дә, тамагына килеп тыгылган төерне йота алмыйча, тукталып калды.

– Нәрсә, ә без? – диде Рәфгать. – Ә без бүген Ленин бабай укыган университетны, Кремльне, Сөембикә манарасын, шәһәрне карадык.

Гата дәшмәде. Ул, тәрәзәгә караган булып, бер ноктага текәлде дә: «Өйдә хәзер кайнар аш, йомшак ипи белән чәйләп, сыйланып утыра торганнардыр. Сөт тә, катык та бардыр», – дип, кулындагы каты сохариларына карады.

Аны күзәтеп торган Рәфгать исә:

– Син нәрсә, Гата, ашаудан калдың? Әллә сагына да башладыңмы, – дип елмаеп куйды. Гата дәшмәде. Дустына күз төшереп алды да, аның авыз ерып көләргә әзер торганын күреп, башын түбән иде.

– Һи, егетләр, әле бит килгәнебезгә сигезенче генә көн. Утырмага килгән кечкенә кызлар шикелле... Мин тагын сезне чын малайлар дип торам...

– Без нәрсә? Синеңчә чын малайлар түгелме? – диде Илгизәр. – Әллә теге шпаналар янында сине ташлап качтыкмы?

– Малайлар да бит, бик тиз изрәдегез әле, – дип, Рәфгать Гатага таба баш изәде. – Син дә сагына торгансыңдыр әле?

– Сагынам, дип... Сагынсам, ни булган? Без бит синең кебек...

– Нәрсә, минем кебек? Әйтеп бетер.

– Синең кебек Азия якларында йөреп үсмәдек.

Рәфгать дәшмәде. Дуслары авылны сагынып сөйләгәндә алардан көлгән булса да, авыллары турындагы татлы уйлар үзенең күңелендә дә көннән-көн күбрәк урын ала бара иде. Теге көнне Гата Карлыган сазы җимешләрен искә төшереп саный башлагач, бик тиз хискә бирелеп китүдән куркып, «Йә, җитәр, булмаганны», – дип, Гатаны туктаткан иде. Шул чакта үзе дә: «Булмаганны искә төшереп, йөрәкне яндырма әле», – дияргә уйлаган иде дә тыелып кына калды, чөнки Казанга укырга барырга малайларны ул котырткан иде. Инде Казанга килеп, яңа елга кадәр запас укучы булып, тулай торакта урын бушаганны көтеп, «җәһәннәм чокыры» артыннан йөрергә калгач, Рәфгатьнең үзенең дә күңеле төшкән иде. Әйтә калса, Илгизәр дә, Гата да, үзең котыртып алып килдең, инде китәргә җыенасыңмы, дип үпкәләрләр дип, бу турыда иптәшләренә сөйләргә шикләнде.



Малайлар капчыкларындагы соңгы кисәк сохариларын шешә төбендә калган май тамчылары белән чылатып тамак ялгадылар да, урыннарын җәеп, ятарга җыена башладылар. Беренче булып одеял астына кергән Илгизәр:

– Амин-амин айланды, авыз-борын майланды. Күз күренде, тамак туймады. Алай да йөрәк ялганды, – дип, әтисеннән ишеткән такмакны тезеп китте... Аннары: – Әй, малайлар, хәзер мәктәп интернатында булсак, ике тәлинкә кайнар токмачны әйләндереп каплар идек тә, корсакларны барабан кебек ясап, менеп ятар идек, – дип, авылда укыган вакытларын искә алды.

– Тулай торакка урнашып укый башласак, монда да җайланыр әле, – диде Рәфгать.

– Яңа елга кадәр әле башламаган биш ай бар, – диде Гата, одеял астына кереп. – Һавадагы сомса, авызыңа килеп кунса, дигәндәй, әллә була, әллә юк.

Алар тагын тын калды. Рәфгать үзе дә тулай торакның буласына ышанмаганлыктан, Гатага каршы төшмәде. Илгизәр авылда интернатта торып укыган вакытларын искә төшерде дә андагыча җырлап җибәрәсе килеп китте. Аның тавышы матур. Әтисе скрипка сузганда, ул җырлаган моңлы көйләрне дә күп белә. Ул юлда килгәндә дәү абыйсы җырлаган җырны исенә төшерде дә шул җырны башлап җибәрде.

*Урал таулары ай биек лә...*

Авылда җырлаганда малайлар аны тын да алмыйча тыңлап яталар иде. Тик Рәфгать кенә кайвакытта, берәр төрле көлке оештырып, җырны бүлә иде. Бүген Илгизәр юлда дәү абыйсы сузган җырны җырлый башлагач, Рәфгать тә тын да алмый тыңлап ятты.

*Китмәсен лә кеше чит җирләргә...*

«Бу нинди көй соң әле, бик моңлы?» – дип уйланды Рәфгать. Аннары юлда Ибраһим бабайның җырлаганы хәтеренә килде. Ул вакытта җырга әһәмият бирмәгән иде. Хәзер шул җырны Илгизәр җырлый башлагач, уйга калды.

Кара әле, аның Илгизәр дусты да бик моңлы җырлый икән бит. Әллә аның тавышы матурлана төшкәнме? Үткән ел болай ук моңлы җырламый иде шикелле...

Ә Гата Илгизәр җырлаганда, бөтен дөньясын онытып, авылда укыган чакларын, интернат тормышын, Чирмешәндә су коенып, балык тотып йөргән вакытларын уйлап ятты. «Китмәсен лә кеше ят җирләргә...» Ирексездән аның күзләре яшь белән тулды.

Илгизәр җырлады да җырлады. Күптән инде аның болай моңланып, болай бирелеп җырлаганы юк иде. Җырлаган саен күңелендә, йөрәк түрендә тулган, әле үзе дә аңлап бетерми торган нindидер хисләр кими барды. Бушанып калган кебек булды. Менә ул яңа җыр башлады:

*Гөлбакчага керәмсең лә...*
*Өзелә үзәк исләргә төшкәндә.*

Малайларның бу җырны элек тә күп мәртәбәләр ишеткәннәре бар иде. Интернатта Илгизәр еш җырлый иде. Шулай да Илгизәрнең бүгенге җыры, күңелнең әллә кай җирләренә үтеп кереп, йөрәкне телеп ала, үзәкләрне өзә.

Менә Илгизәр җырлаудан туктады да, бүлмәдә урнашкан тынлыкка исе китеп торганнан соң, әйтеп куйды:

– Йоклыйк, малайлар, иртәгә безне уятырга әниләр юк.

– Йоклап калырбыз дип куркасызмы әллә? – диде Гата. – Курыкмагыз, үзем уятырмын.

– Сиңа ышансаң, төш җитәр, – дип көлде Рәфгать. – Авылда әниең, өчәр мәртәбә уятам, дия торган иде.

– Ул бит авылда, монда өч көннән бирле яктыра башлауга, уянам да шуннан йоклый алмыйм. Башка төрле уйлар килә. Беләсезме, малайлар, хәзер авылда урак вакыты. Ындырда, кырда халык мәш килә торгандыр. Кемнәр ат куа, кемнәр көлтә ташый, салам тарттыра. Төш җиттеме, Чирмешәндә чумып-чумып коеналар. Хәзер барысы да кичке уенда. Әй, хәзер кайтып төшәсе иде...

– Минем Шаригым сикерә-сикерә каршы алыр иде. Йолдыз Кашка нишли икән. Хәзер тазаргандыр инде...

– Нишләсен, эшсез тайлар-атлар янында үлән ашап йөри торгандыр... – дип бүлдерде Рәфгать. – Әйдәгез, йоклыйк инде.

– Йоклыйбыз. Хәзер безнең уятучыбыз бар...

Гата төне буе төш күреп йоклады. Имеш, Казан урамында адашкан да кая барырга икәнен исенә төшерә алмый. Нindидер тирән чокырда беренче көнне ипиләрен алып калган чандыр килеп чыкты да: «Әһә, эләктеңме? Бүген үзең генәме?» – дип, ыржаеп басып тора икән. Кинәт кайдандыр Илгизәр белән Гата килеп чыктылар да, теге чандыр шундук юкка чыкты. «Без сине югалткан идек, – ди, имеш, Илгизәр. – Мәктәпкә



соңга калабыз». Менә алар Илгизәрләр тыкрыгыннан төшеп киттеләр. Тирә-якта каеннар, таллар, яшел үлән... Алар шунда ял итәргә яттылар. Чү, асларында чирәм түгел, нindидер шыгыр-шыгыр килә торган карават икән. Менә Гатаның әнисе килеп чыкты. Чәчәкле алъяпкычын япкан. Кулларын маңгаена куеп, чокырның теге ягында кемнедер эзли. Гата: «Мин монда-а, әни-и, мин монда-а!» – дип кычкыра. Тавышы чыкмый, имеш. Кычкыра-кычкыра, тавышы һич кенә дә чыкмый бит. Тәмам аптырап бетте. Ахырдан бик нык кычкырып җибәргән иде, үз тавышына үзе уянып китте дә, әнисе юкка чыкты.

Гата, уңайсызланып, икенче якка борылып ятты да йокыга китте. Бераздан күз алдында тагын әнисе пәйда булды. Кәримә апа аның янына килеп баскан да: «Улым, сезне монда җәһәннәм чокыры артында тоталармы? Кыш көне нишләрсез? Әйдә, тор, кайтабыз! Алпарда укырсың», – дип төрткәли...

– Тор! Үзең безне уятырга тиеш идең, – дигән тавышка күзләрен ачып җибәрсә, янында Рәфгать басып тора.

– Тор, уятучы! Сиңа ышанып соңга кала язганбыз!

– Әле бик тәмләп төш күреп ята идем. Бүлдердең, – диде Гата, үпкәләп...

– Нинди төш иде ул кадәр тәмле?

– Әни килгән иде. «Әйдә, тор, Алпарда укырсың», – ди, имеш.

– Мин төшемдә Мәсфия апаны күрдем, – диде Илгизәр. – Без авылда да, монда да кебек. Мәсфия апа безне бишенче класска алырга килгән. «Интернатта ремонт бетте. Нигә миңа әйтмичә киттегез?» – ди, имеш.

– Мин дә төш күрдем, – диде Рәфгать. – Тик миңа әни дә, әти дә күренмәде. Теге сукбай малайлар төнлә капчыкларны урлаганнар, имеш. Иртәгә кичкә нәрсә ашыйбыз инде, дип куркып уянып киттем дә, сикереп торып, капчыкларны карадым. Капчыклар урынында икәнен күргәч кенә тынычландым. Карасам, кояш күтәрелеп килә. Торыр вакыт җиткән. Ярый әле төшләнеп уяндым. Югыйсә Гатаның үзен көчкә уяттым.

Малайлар барак коридорындагы юынгычта битләрен чылаттылар да, тиз генә җыенып, таныш сукмактан, чокырлар аша, трамвай тукталышына йөгерделәр.

Шулай тагын берничә көн үтеп китте. Малайларның туган авылларын, әти-әниләрен сагынулары көннән-көн арта барса да, кичләрен Илгизәр җырлаганда күзләренә тулган яшьләр мендәргә агып төшсә дә, берсе дә: «Әйдәгез, кайтып китәбез!» – димәде. Һәр көнне авылларын телдән төшермәсәләр дә, Сабанчының очраган бер карачкысының муенына

ташланырга торган өч малайның берсе дә: «Авылны, өйне сагындым», – дип, башлап әйтергә теләмәде. Югыйсә бер-берсенең авылны сагынуын да белеп торалар бит.

Соңгы вакытта ерык авыз Рәфгать тә дусларын үртәп маташмый. Юк, алай гына да түгел. Илгизәр белән Гатаның авыл турында берәр нәрсә сөйләгәннәрен теләп тора. Кайвакытта алар авыл турында сөйләмичәрәк торсалар, әллә инде күнәләр, авылны оныта башладылармы, дип куркып куя. Ләкин һәр нәрсәнең ахыры булган кебек, малайларда түземлекнең дә чиге бар иде. «Әйдәгез, малайлар, кайтып китәбез», – дигән сүзне кем дә булса әйтергә тиеш иде.

Ике көн күренми торганнан соң, сукбайлар башлыгы чандыр, дүрт иптәшен ияртеп, чокыр уртасында тагын малайларны каршы алды.

– Киләсезме, авыл гыйбатлары? – диде ул, кулларын кесәсенә тыгып, аякларын аерып, сукмак уртасына баскан килеш.

– Сез шәһәр гыйбатларымы?

– Киләбезме, кайтабызмы... Сезнең ни эшегез бар? – дип өстәде Гата.

– Бу җирләр минем биләмә! – диде чандыр, горур гына тирә-якны күрсәтеп. – Без моннан пошлина алмыйча үткәрмибез! Нәрсәгез бар? Давай, выкладывай!

– Менә сезгә!

– Ә-ә, сез әле шулаймы? Обыскать! – диде чандыр, уң кулын малайларга таба сузып.

Малайлар, каршылык күрсәтергә әзерләнеп, өчесе бергә килеп бастылар да:

– Якын киләсе булмагыз! – дип кычкырдылар.

Сукбайлар шикләнеп калды.

– Обыскать! – дип кабатлады чандыр каты тон белән.

Сукбайларның малайларга ташлануы булды, Рәфгать, үзенә таба килгән кара сукбайның эченә йодрыгы белән шундый итеп тондырды ки, теге эһ тә итә алмыйча бөгелеп төште. Ул арада Гата үзен тентергә килгән озын чәчле малайның күз төбенә менеп төште.

Илгизәргә ташланган шадра малай, хәйләкәррәк булып чыкты. Үзенә сугарга ирек бирмичә, Илгизәрне кинәт үзенә таба тартып, башы белән аның аяк астына бирмәкче булды. Илгизәр дә каушап калмады. Кинәт яны белән борылды да, тегене җиргә әйләндереп салып, өстенә менеп утырды.

– Менә сиңа, – диде ул, сукбайның ике кулына басып. – Тагын бәйләнәсеңме?!



Сукбай дәшмәде. Илгизәр астыннан чыгарга теләп, төрлечә талпынып карады да, ычкына алмагач, тезләре белән аркасына бәрергә теләп азапланды. Алай да булдыра алмагач, гарьлегеннән Илгизәрнең битенә төкереп карады.

Нәкъ шул вакытта Рәфгать ике сукбай белән чәпәшкән җиреннән, чандырның күкрәгенә китереп тондырган иде, арты белән Илгизәргә якын ук торган чандыр, аңа абынып, якындагы ком ала торган чокырга әйләнеп барып төште...

Ул арада Гатаны ике сукбай урап алган да, берсе аны арттан килеп муеныннан беләге белән кысып маташа. Икенчесе сугарга тора. Гата:

– Илгизәр, булыш! – дип кычкырып җибәрүе булды, Илгизәр, җирдә яткан шадра малай өстеннән сикереп торды да, дустына сугып кайнашканын, аяк чалып, җиргә алып бәрде. Аннары Гатаны муеныннан алганын дөмбәсли башлады. Тегесе, ычкындырып, читкә качарга мәҗбүр булды.

Чандырны чокырга бәреп төшергәннән соң, бергә бер калган Рәфгать кара чутыр сукбайны ике куллап – уңлап-суллап дөмбәсли башлаган иде, тегесе, берүзе калганын күреп, читкә чапты.

– Ну как, обыскали?! Ещё будете обыскать?! – диде Рәфгать, төрлесе төрле якта торган сукбайларга карап.

– Ладно, замолчи! – диде чандыр, чокырдан чыгып баскач.

– Әйдәгез, киттек! – диде Гата, колак артын кашып. – Ничу болар белән...

Яр башына күтәрелгәч, малайлар артларына борылып карадылар. Чандыр, уң аягына аксый-аксый, иптәшләрен ияртеп, тимер юл чокырына таба китеп бара иде.

– Теге сары чәчлесенең кирәген бирдем, – диде Гата. – Син Илгизәр шадраның өстенә утыргансың да, монда миңа икәүләп ябыштылар.

– Булыш, дигәнеңне ишеткәч, алып бәрдем бит. Икенчесенә дә төште, колак төбенә биргән идем, кулымны авырттырдым...

– Чандыр эләктерде, – диде Рәфгать, иренен капшап. – Ну үзенә дә шәп эләкте. Әнә, күрәсезме, ничек аксап качты.

– Бу эш түгел – көн дә сукбайлар белән сугышып йөрү. Иртәгә баргач, директорга әйтергә кирәк...

– Исләре китә дип беләсеңме? – диде Рәфгать. – Теге көнне әйтеп карадым бит. Ак та димәде, кара да.

Тагын шимбә көн килеп җитте. Мәктәп йортында дүрт сәгать буена бүрәнә чистартып, аларны такта яра торган җиргә тәгәрәтеп, чүпләрен җыеп, арыганчы эшләделәр дә, ипиләрен алырга дип, ашханәгә керделәр.

Иртәгә ял көне булганлыктан, иртән сәгать алтыдан торып килмәс өчен, иртәнге чәйгә дигән ипиләрен дә сорап карадылар. Тик малайларның хәленә керүче генә булмады. Ашханәдән малайларның күңелләре төшеп, гарьләнеп чыктылар. Нишләсеннәр, иртәгә алтыдан торып килергә туры киләчәк. Капчыкларындагы сохарилары беткәнгә өч көн.

Болак буеннан килеп Кольцога чыкканнар иде, Илгизәр үзләренең укытучылары Мәсфия Гариповнаны күреп алды да кычкырып җибәрде:

– Малайлар, әнә безнең укытучы апабыз – Мәсфия Гариповна! – дип читкә ташланды.

– Илгизәр! – диде укытучы. – Син ничек монда?

– Без, апа, бирегә укырга дип килгән идек.

– Исәнмесез, Мәсфия Гариповна! – дип, Гата белән Рәфгать тә килеп җиттеләр.

– Исәнмесез, укучылар. Кайда укыйсыз соң сез? – диде укытучы, малайларны баштанаяк карап чыгып.

– Без, апа, столярныйга килгән идек.

– Алмадылармы?

– Алдылар да, өйрәнчеккә, запас итеп кенә. Тулай торак та юк.

– Сезгә соң, укучылар, бер дә акыллы киңәш бирүче булмадымы? Анда бит 16-18 яшьтәгеләр генә укыйлар. Сезгә 12–14 яшь. Шул дүрт класс белем белән калырга телисезме? Һич югында җидене бетерергә кирәк. Ул чагында сез теләсә нинди техникумга бара алыр идегез. Ялгышасыз, балалар. Аннан, җиде классны бетерү мәҗбүри икәнен да онытмагыз. Мин сезне бишенче класска киләсез дип, исемлеккә кертеп куйган идем. Ул вакытта нигә сез миңа әйтмәдегез? Минем белән киңәшеп тә тормагансыз. Юк, укучылар, әле соң түгел. Уйлап карагыз. Сезгә җидене бетерергә кирәк!

– Ярар, Мәсфия апа, без үзебез дә кайтып китәргә уйлап тора идек, – диде Гата, барысы өчен да җавап биреп.

– Шулаймы? Дөрес эшлисез. Кайтыгыз, җидене бетергәч килерсез!

Яраткан укытучыларын очрату малайлар өчен бик зур, көтелмәгән шатлык булды. «Кайтыгыз, җидене бетергәч килерсез!» – дигән киңәшен ишеткәч, шатлыклары эчләренә сыймаслык зур иде. Бу тылсымлы сүзләр хәзер үк, шул ук минутта авылларына чыгып чабарга әзер торган малайларны канатландырып җибәрде.

– Кайчан кайтабыз, малайлар? – диде Гата, Мәсфия Гариповна китеп барганнан соң.



– Ничек, кайчан? – диде Илгизәр. – Хәзер баракка кайтабыз да, элдерт моннан, пристаньга.

– Юк, малайлар. Иртәгә иртә белән кузгалырбыз, – диде Рәфгать. – Пристаньга төшеп кунудан файда юк. Пароходлар да иртә белән генә була дип ишеткән идем.

– Ярар, иртә белән төшәрбез. Иртә утырсак, иртәдән арыга Спаста булабыз, – дип сикергәләде Илгизәр белән Гата. Әйтерсең лә, инде пароходта кайтып баралар.

Трамвайдан төшеп, тимер юл чокырына җитә башлагач, малайларның башына яңа уй төште. Алдагы чокыр төбендә аларны дүрт сукбай көтеп тора иде.

– Әнә, безне көтәләр инде, – диде Рәфгать. – Нык торыгыз! Шәбрәк төшерсәк, икенче бәйләнмәсләр...

– Иртәгә без булмыйсыз инде. Бусы соңгысы булыр...

– Кайтабызмы, авыл килмешәкләре? – диде чандыр һәм, алгарак чыгып, малайларга каршы төште. – Әйдәгез, танышабыз?

– Баштан ук танышырга иде. Хәзер соң инде, – диде Рәфгать. – Баштан ук сугышырга түгел иде!

– Отказываемся? Смотри какой гордый?

– Син ул гордый. Без сезгә каршы чykканыбыз юк әле. Сез безне салагалар дип каршы аласыз.

– Ә син танышырга теләсәң, бармак янама! – диде Илгизәр. – Исәбең башкадыр әле? Танышабыз дип, берәр хәйлә корып маташасыңдыр?

– Чуешь? Салага деревенская!

– Без салага булсак, син саламандр!

– Что? Что ты сказал?!

– Без салага булсак, син саламандр! Җир-су кәлтәсе! – Малайлар көлешеп алдылар. Чандыр кызарып чыкты да:

– Ладно, моны исеңдә тот! Я ещё покажу вам! – дип янап читкә китте.

Баракка кайтып керү белән, малайлар юлга җыена башладылар. Капчык төпләрендә сохари валчыклары гына калган иде.

– Малайлар, әйдәгез, ипиләрне иртәгегә калдырабыз! Иртән яктыра башлауга торып, юлга чыгабыз. Чиратлап йокларбыз, – диде Рәфгать, урынга ятарга әзерләнеп.

Ләкин ул төнне малайлар берсе дә юньләп йокламады. Таң беленер алдыннан өчесе дә уянган иде инде. Тышта яктыра башлап, каршы як барак күренүгә, малайлар, капчыкларын кулларына тотып, ишеккә юнәлделәр. Гата, ишекне бикләде дә, ачкычны вахтёр апага илтеп

тапшырганнан соң, ишеккә йөгерде. Берничә минуттан алар инде трамвай тукталышында иде. Пристаньга төшкәннән соң гына, билет алырга акча кирәклеге исләренә төште. Өчесенең дә кесә төпләрен какканнан соң, бары бер билет алырлык кына акча җыелды.

– Нишлибез инде, малайлар, бер билет белән ничек кайтабыз?

– Кайгырмагыз, малайлар, җайлыйбыз аны, – диде Рәфгать, иптәшләрен тынычландырып. – Без болай итәбез: мин билетсыз гына керәм. Син, Илгизәр, өчебезнең дә капчыкларын бер итеп, билет белән керерсең, аннары мин билетны Гатага чыгарып бирәм, кепкамны салам да...

– Синең кепкаң кайда соң?

– Һәй, минем кепка баракта калган, малайлар, – диде Рәфгать, капчыгын капшап. – Менә сиңа мә!

Малайлар шаркылдап көлә башладылар. Китү шатлыгы белән Рәфгать кепкасын онытып калдырган. Гатаның салфеты, Илгизәрнең кружкасы калганны бу минутта белмиләр иде әле алар.

– Ярар, хәерле каза булсын, – диде Рәфгать. – Мин билет алырга киттем...

Пароход төштән соң гына килде. Алдан сөйләшкән буенча, малайлар пароходка берәмләп кереп беттеләр. Тикшерүче, билет сораучы булмады. Пароход кузгалып китте. Малайларның шатлыкларының чиге юк. Кайту шатлыгы белән хәтта ашыйсы килгән дә онытылып торды. Бераздан пароходтагы кешелар, ашамлыкларын таратып, ашарга-эчәргә утыргач кына малайларга бик уңайсыз булып китте. Кичәдән бирле ашамаган ач тамак белән, кешеләр ашаганны карап, алар капканны йотып утырудан да авыр хәл юк икәнен малайлар шунда ук аңладылар. Аннары, кеше авызына карап утырганчы дип, Рәфгать аларны пароход палубасына ияртеп алып чыгып китте.

Караңгы төшә башлаганда гына эчкә кереп, машина залы буендагы коридорга урнаштылар да, бер-берсенә елмаеп, йокларга яттылар. Ләкин ач тамакны йокы да тиз генә алмады. Бервакыт:

– Малайлар, торыгыз! – дигән тавышка күзләрен ачып җибәрсәләр, каршыларында өч селёдка тотып Рәфгать басып тора.

– Каян алдың? – диде Гата, торып утыргач.

– Әнә, шул абый бирде, – диде Рәфгать, күптән кырынмаганга сакал-мыек баскан, кисмәк өстендә балык ашап утыручы урта яшьләрдәге кешегә күрсәтеп. – Илгизәр, тор! Балык ашыйбыз.

Өч малай шатлана-шатлана балык ашадылар. Тамаклары туеп киткән кебек булды. Хәзер аларның эчәселәре генә килә башлады. Рәфгать,



кружкасын алып, «Кипяток» дип язылган җиргә су алырга китте. Шулвакыт Гата теге кисмәк өстендәге кешегә күз салган иде, аның кисмәктән балык алганын күрде.

– Илгизәр, кара әле теге абыйны, безгә нинди балык биргән?

Илгизәр шул якка карады һәм теге кешенең кисмәктән селёдканы сумкасына тутырганын күреп алды.

– Белмәдем, – диде ул. – Белсәм, ашамаган булыр идем.

– Мәгез эчегез! – диде Рәфгать, алып килгән сулы кружкасын Илгизәргә сузып.

– Син, малай, нинди балык ашаттың безгә?

– Селёдка, – диде Рәфгать. – Селёдка ашаттым.

– Урланган балык булган бит ул синең?

– Миңа әнә теге абый бирде. Ашыйсыңмы балык, диде дә, мин, ашыйм, дидем.

– Ә ул аны әнә теге кисмәктән чәлдергән. Үзем күрдем, әллә никадәр балыкны сумкасына төяде.

– Капитанга әйтергә кирәк, – диде Илгизәр.

– Үзебез ашагач, яхшы түгел инде...

– Нәрсәсе яхшы түгел? – диде Гата һәм шунда ук теге кеше каршысына барып басты.

– Зачем рыбу украл?

– Чего, чего?! – диде теге кеше, күзләрен әйләндереп карап.

– Зачем рыбу крадешь?

– Ах ты, татарчонок! Сам рыбу кушал, теперь на меня валишь?!

Теге кеше Гатага шундый итеп карады, малай бер адым артка чигенергә мәҗбүр булды. Илгизәр сикереп торды да теге кешенең каршысына барып басты.

– Мин – пионер, балык алганыңны үзем күрдем. Алдый алмассың! – диде һәм, югары палубадан капитан ярдәмчесенең төшеп килгәнен күреп, шунда ук аңа каршы йөгерде:

– Дяденька, вон этот человек рыбу украл! – дип, мичкәләр ягына күрсәтте. Капитан ярдәмчесе ашыкмыйча гына килде дә, мичкә өстендәге кешене төшереп, савытны карады.

– Синең эшме бу?

– Юк, мин тимәдем, ачык иде...

– Сумкаңны күрсәт әле!

– Бу минем сумка түгел.

– Кем сумкасы?

– Белмим, – диде балык урлаучы.

– Кем сумкасы? – диде капитан ярдәмчесе, малайларга карап.

– Бу абый балыкны шул сумкага тутырды, – диделәр малайлар бертавыштан.

– Бу бит дәүләт милке, товар, – диде капитан ярдәмчесе. – Син, ватып, аннан балык урлыйсың? Документларыңны күрсәт әле?

Теге кеше боргалана башлаган иде дә, капитан ярдәмчесе, аңа сумкасын тоттырып, үзе белән алып китте.

Балык урлаучы артына борылып:

– Мин сезгә күрсәтермен әле. Ботыңнан тотып суга... – дип ысылдады.

Шуннан малайларның йокылары качты. Теге кешене җибәрсәләр, безгә берәр хәл эшләр дип, Кама Тамагына кадәр куркып кайттылар.

– Әйтмәскә кирәк булган, – диде Рәфгать. – Хәзер менә чыгып кирәкне бирер...

– Пионер башым белән каракны яшеримме? Кибеткә кайта торган балык бит ул...

Кама Тамагы пристаненда ул кешене милициягә тапшырып калдырдылар. Шуннан соң гына малайлар иркен сулап куйдылар.

Яктырыр алдыннан гына пароход Спас Затонына килеп туктады. Малайлар өч капчыкны бер иттелер. Башта билет белән Гата, бераздан Илгизәр белән Рәфгать чыктылар.

Пароходтан төшкәч, малайлар авылларына кайтып җиткән кешеләр кебек шатландылар. Туган авылларына кайтып җитәр өчен әле сиксән чакрым тузанлы юлдан атлыйсылары булса да, монда инде, билет сорамасалар ярар иде, пароходтан төшереп калдыра күрмәсеннәр, дип куркып кайтасы түгел. Бераз яктыра төшкәнне көттеләр дә, Идел болыннары буйлап, бормалы юлдан Спаска ашыктылар.

Бар өметләре Сабанчыдан Спаска ипи китерә торган олауларны очрату иде. Ләкин, ни хикмәттер, хәтта күрше авыллардан да атлылар очрамады. «Спасскига кайткач, Спасны карарбыз, атлылар туры килмәсә, көтеп торырбыз», – дип хыялланып кайткан малайлар, Затоннан унбиш чакрымны йөгерә-йөгерә атлап кайттылар да, кесә төпләрендә калган тиеннәрне җыеп, өчесенә ике аш һәм дүрт кисәк ипи алып, тамак ялгаган булдылар.

– Ашыйсы килгәнем печтик тә бетмәде, – диде Гата, ашханәдән чыккач.

– Минем дә, минем дә, – диештеләр Илгизәр белән Рәфгать.



Аннан алар, уңга-сулга борылмыйча, туган көннәреннән үк бәйләнгән авылларына, мәктәпкә йөри башлаганчы ук уйнап үскән, какысын, юасын, карлыганын, җиләген җыеп ашаган Чирмешән төбәгенә ашыктылар.

Кояш иртәдән үк рәхимсез кыздыра. Рәфгатьнең башында кепкасы да юк. Аңа тагын да читенрәк. Олы юл тузаны кием өстенә, биткә, башка утыра. Тир белән агып төшеп, күзләргә тула.

Малайлар баралар да баралар. Кураловоны үттеләр. Катериновка да янда калды. Аяклар кыек-мыек атлый башлады. Ямбахтыны чыкканда бер коедан су алып эчтеләр дә яңадан киттеләр. Өч малайның берсе дә: «Әллә туктап ял итәбезме?» – димәде. Аякларының кыек-мыек атлавын, хәлләренең бетә барганын күреп, тоеп торсалар да, бүген кичкә кайтып җитеп булмасмы дип, алга атларга тырыштылар. Моңа кадәр аларның берсенең дә мондый юлны бер көндә түгел, өч көндә дә үткәне булдымы икән? Шулай булса да, туган төбәкләре шундый көч белән үзенә тарта ки, хәтта аяклары атламас хәлгә килсә дә, алар үрмәләп кайтырга да риза иде. Менә алда Салман күренде. Бу аларның ярты юлны үтүләрен аңлата. Бик авырлык белән авылны чыктылар да, юл читенә чыгып, чирәмгә аудылар. Капчык төпләрендә калган сохари валчыкларын кагып җыйдылар. Аны тигезләп өч өемгә аердылар. Ахырдан, кружкалары бер генә булганлыктан, чиратлап, су белән изеп эчтеләр. Шундый «туклыклы» су эчкәннән соң, яңадан кузгалдылар.

Баллы Күлне үтеп, Матакка җиткәндә аларның аяклары тәмам атламас булды. Хәзер инде бүген туган авылларына кайтып егылу өмете юклыгы көн кебек ачык иде. Шулай да берәү дә Матакка кереп кунарга теләмәде. Бервакыт көн сүрелгән кебек булып китте. Битләрен йомшак җиләс җил сыйпап алды. «Матак ерак калдымы?» – дип артларына борылып карасалар, кояшның зур алсу түгәрәге үр артына төшеп капланып килә.

– Малайлар, әйдәгез, ашыгырга кирәк! – диде Илгизәр, иң арттан барган килеш. – Караңгы төшкәнче, Үргәагарга җитәсе иде. Караңгыда берәү дә кертмәс!

– Әйдәгез соң, ашыгыйк, – диде Гата.

Ләкин телләре белән ашыгу турысында сөйләсәләр дә, аяклары тыңламады. Ничек тә алда күренеп торган авылга җитеп, берәрсенә квартирга керү турында хыялланган малайларның күзләренә инде өйләреннән киткәннән бирле күрмәгән кайнар чәй, бер телем ипи белән бәрәңге күренә башлады.

Караңгы төшә-төшә авылга килеп керделәр дә, берничә өйне узу белән, квартирга кертүне сорый башладылар. Берничә йортка кагылдылар. Ләкин берәү дә керегез дигән тылсымлы сүзне әйтмәде. Ахырдан берсе: «Әнә, авыл советына барыгыз!» – дип, аларны борып чыгарды. Ул арада төн булды. Авыл советында җыештыручы апа, ипи юклыктан зарлана-зарлана булса да, аларга берничә бәрәңге пешереп чәй эчерде.

Иртә белән малайларны көтүдән алда уяттылар. Авылны чыгып, өч чакрымнар киткәч, чирәмле тирән үзәнлекләрнең тау астына төшеп, чишмәдән су эчтеләр дә, икенче якка чыгып, куаклар арасында калгалаган кипкән җиләкне чүпләштереп йөрделәр. Инде кайтырга дип юлга чыкканнар иде, бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына дигәндәй, юлдан читтәрәк алмагачларны күреп алдылар. Алмалары шундый күп, агачлары иелеп төшкән. Малайлар шатлыктан нишләргә белмәделәр. Капчыкларын чирәмгә атып бәрделәр дә алмагачларга ташландылар.

– Анысы тәмле түгел, монысы тәмле! – дип, берсеннән икенчесенә күчә-күчә, алма ашарга керештеләр. Бу яшел алмалар малайларга шулкадәр тәмле булып тоелды. Ач тамакка алма ашый-ашый тешләре камашты. Эчләре барабан кебек катып китте.

– Әй, малайлар, шартламагыз тагын! – дип, беренче булып Гата чирәм өстенә ауды. Аннары:

– Малайлар, җитәрегез! Бу ашауның ахыры яхшы булмас! Эчем катты, үләм! – дип, чирәм өстендә аунаган булды.

– Нәрсә булды? – дип, Илгизәр дусты янына йөгереп килде.

– Берни булмады. Килегез монда! Ятып хәл җыярбыз. Югыйсә ачлык вакытындагы кешеләр кебек әче алма ашап үләрбез!

Алар, алмагач астынарак кереп, ышыкка яттылар.

– Бу алмалар без киткәндә дә булгандыр. Без ничек күрмәдек аларны?

– Без анда калага бару шатлыгыннан, дәү абыйның Самара якларында күргән нужаларын тыңлап бара-бара, берни дә күрмәгәнбез, ахры.

– Мин бу куаклыкны үткәнне дә хәтерләмим, – диде Гата.

– Уйлап карасаң, дәү абый аларны юкка гына сөйләмәгән икән. Хәтерегездәме? Ул бер җыр да җырлаган иде әле. Ничек башлана иде әле?

– Син бит инде ул җырны әллә ничә җырладың. Тагын нинди җыр?

– Юк, ул түгел. Самара дип башлана ул... Ә-ә, исемә төште:

*Самарада дигән ай каланың,*
*Трамвайларында йөрмәдем.*
*Бәхетле лә бала илдә яши,*
*Ташлап китми туган җирләрен.*



Дәү абыйсы җырлаган җырның моңы Илгизәрнең бөтен барлыгын биләп алды. Күңеленең үтә дә нечкәреп китүен сизеп, әкрен генә көйне башлап җибәрде. Әлегә кадәр Илгизәр моңлы көй җырлаганда тыңлап ятарга гына күнеккән Гата белән Рәфгать тә җырга кушылдылар.

*Самара ла дигән каланың...*

Әйе, кушылып җырлый башладылар. Икесенең дә тавышлары тигез. Әйтерсең лә, алар Илгизәр белән шулай күптәннән җырлап күнегеп беткәннәр. Тик алар икесе дә сак кына, Илгизәр ачуланмасын дигәндәй, әкрен генә җырлыйлар. Алмагач яфракларына һәм термәч-термәч алмалар арасыннан күренеп торган ак болытларга карап, өч малай җыр суза. Җырлаган саен күңелләренең әллә кай җирләрендә куера барган авылларын сагыну хисләреннән һәм кайтып җитү шатлыгыннан туган таныш моңнар агышын тоеп, тәннәренең рәхәт сулкылдап куюын, күзләренә ачы да, татлы да яшьләр тулып ага башлавын сизми дә калдылар.

Бу дулкынлану шундый көчле, шундый рәхәт иде. Күзләрдән агып төшкән яшь тамчыларын берәү дә сөртеп кайнашмый. Яңак буйлап колак артларына агып төшкән җылымса яшь тамчылары ниндидер сабыйларча рәхәтлек бирә шикелле. Җырның икенче өлешен үзләре дә сизмәстән икенче кат җырладылар.

*...Бәхетле лә бала илдә яши,*
*Ташламый ла туган җирләрен.*

Илгизәр җырдан туктады да торып басты:

– Әйдәгез, малайлар, киттек! – дип, баш очына салган ярымбуш капчыгын тотып, юлга чыгып басты. Гата белән Рәфгать тә сикеренеп тордылар да юлга чыгып алдан киткән Илгизәр артыннан ашыктылар. Әйтерсең лә, алар җиңеләеп, ниндидер авыр йөктән бушанып калганнар. Куаклык эчендәге атлы юлыннан зур-зур атлап авыллары ягына кайта башладылар.

– Авылга ничә чакрым бар әле? – диде Гата, иптәшен куып җитеп.

– Уннан артык әле...

– Төшкә кайтып җитәсе иде.

– Белмим шул, – диде Рәфгать. – Хәзер халык төшкә кайта башлар инде...

– Төшкә кайтып җитмәсәк, төштән соңга кайтып җитәрбез. Әнә, Вольное Муллино күренә. Әнә Яңа Чаллы ягында, ындыр табагында, ашлык суктыралар, ахрысы? Тузан болыты күтәрелгән...

– Әнә тегендә, тегендә дә ургычлар белән урдыралар, – дип, Гата да алга таба карады. – Бу Муллино кырыдыр инде?

Кызык, кичә малайлар көне буе җитмеш километрга якын юл үтеп, бернәрсәгә дә игътибар итмичә, тирә-юньдәге бернәрсәне дә күрмичә кайтканнар иде. Бүген, авылларына якынлашкан саен, таныш кырлар, җанга якын урманнар, үзәннәр, куаклар – барысы да аларны үзенә тарта. Барысы да якын, барысы да кадерле. Хәзер менә революциягә кадәр Вольное һәм Крепостное Муллино дип аталган ике авылны үтәләр дә, үргә күтәрелүгә, күз алларына бөтен барлыгы белән аларның туган авыллары – Сабанчы, аның каршындагы кечкенә каенлыкның, авылның теге башындагы завод морҗасы, бакча, бөтен куаклыклары, елгалары, болыннары белән Чирмешән үзәннәре пәйда булачак.

Илгизәр никадәр ашыгып кайтса да, Гатага аның адымнары әкрен тоелды. Ул йөгереп алга чыкты.

– Авылга иң алдан үзем кайтып керәм! – диде дә, тиз-тиз атлап, алдан китте.

– Юк! – диде Рәфгать. – Иң алдан мин кайтып керәм. Аннары Илгизәр, иң ахырдан – син.

– Ни өчен иң ахырдан мин?

– Чөнки синең өең иң еракта. Алмагач тавына җиттекме, мин өйдә булам. Аннан әле сез чишмәгә төшәсез дә су эчәсез. Аннан Илгизәр кайтып җитә...

– Ә-ә, менә үзең дә әйттең... Чишмә суын без башлап эчәбез. Иң кадерлесе – чишмә суын эчү...

– Алайса, мин дә башта чишмәгә төшәм, аннан өйгә борылам.

– Беләсе иде, Тузик мине танырмы икән?

– Танымыйча, таныр. Тик синнән шәһәр исе килә, ипиең дә юк икән, дип читкә китеп барыр, – диде Рәфгать, көлеп. – Өч атнадан бирле юынмаган, негр кебек катып беткән. Карагыз әле Илгизәргә! Морҗадан чыккан диярсең?

– И-и, ертык тишектән көлә, ди, үзеңне кара!

Малайлар, бер-берсенә карап, көлешә башладылар.

– Эт түгел, әниең да танымас әле, – дип көлде Гата.

– Син үзеңне, үзеңне кара! – диде Илгизәр, Гатага бармагы белән төртә-төртә. Алар яңадан бер-берсенә төртеп күрсәтә-күрсәтә көлешә башладылар. Гатаның ак күлмәге көрән төскә кергән иде. Чәч араларыннан агып төшкән тирдән муены юл-юл булып аклы-каралы тора. Рәфгать белән Илгизәрнең дә битләре, муеннары, тузан, тир белән катып, кырып алырлык булган.



– Әйдәгез, малайлар, Мулла авылы елгасына төшеп юынабыз, – диде Илгизәр. – Болай кайтып керсәк, әниләрнең исе китәр.

Тирән елгага төшеп күлмәкләрен-ыштаннарын кагып юынганнан соң, юлга чыгып, үрне менеп җиттеләр дә, менә хәзер, менә хәзер күренә башлый, дип алга ашыктылар.

Менә Чирмешәннең теге ягындагы Дугыз урманы, Ак чиркәве белән Николай Чирмешән болыннары эчендәге Карлыган сазы, зур тирәкләре, карамалары белән Латра елгасы күренә башлады. Сулда – Гоголиха, Чиркәүле, Абалдуевка, Биләр кырлары... Еракта сөремләнеп торганы – Хуҗалар тавы...

– Малайлар, әнә завод морҗасы! Сабанчы күренә башлады! – дип кычкырып җибәрде Гата. – Ур-р-р-ра! Кайтып җитәбез!

– Авыл күренә, авыл, – дип сикерә башлады малайлар.

– Исәнме, авылым!

– Исәнме, Сабанчым!– дип кычкырып җибәрде Илгизәр.

– Ә-ә-н-ә безнең тирәкләр!

Кинәт аңа әнисе, урамга чыгып, маңгаена кулын куеп, карап тора кебек тоелып китте. «Балакаем, кайтасыңмыни? Көтә-көтә арып беттем. Нигә бу көнгә кадәр бер хәбәр дә бирмәдегез? Нигә болай озак бер хат та язмадыгыз?» – дип такмаклый-такмаклый, каршы килер кебек тоелды. Шулвакыт әнисенең, тәрәзәгә килеп, озак итеп Биләр ягына карап торганнан соң җырлаган җыры исенә төште:

*...Шул балалар исемә төшсә,*
*Җырламыйча түзә алмыйм.*

Ул вакытта абыйсы кайдадыр Ярославль ягында, апасы Чистайда укый иде.

– Нигә соң әле без, малайлар, хат язмадык?! – диде ул, иптәшләренә таба борылып. Малайлар: «Нәрсә әле син, иске авыздан яңа сүз», – дигәндәй, Илгизәргә карап алдылар. Бераздан Рәфгать:

– Язмадык инде... Кайтып китәсе булгач, – дип куйды.

– Ничек? Кайтып китәсеңне белдеңме син?

– Белдем, тулай торак булмагач, шәһәр артыннан йөреп, бу киемнәр белән укып булмыйсы билгеле инде...

– Нигә соң баштан ук шулай димәдең? – диде Гата. – Сразы кайтып киткән булыр идек.

– Сез әйтерсез дип көттем. Сез әйтмәдегез.

– Мин син әйткәнне көттем, – диде Гата.

– Мин дә!

Кинәт малайлар, бер-берсе белән кочаклашып, көлешә башладылар. Бер-берсен төртешә-төртешә, күзләреннән яшьләр чыкканчы көлделәр.

– Ярый, малайлар, минемчә, шунда ук кайтып китмәвебез дә ярады әле, – диде Гата. – Болай әле столярныйга җидене бетергәч бару яхшы икәнен белеп, шәһәр күреп кайтабыз.

– Әйе шул, дәү абый әйтмешли, Лаеш шулпасы эчеп, ничә көн сукбайлар белән сугышып йөрсәк тә, сохарилар, акчалар бетмичә, тәки кайтмадык.

– Казанны күрдек. Ленин бабай укыган җирләрне, Сөембикә манарасын, Кремльне. Трамвайда йөрдек, – диде Гата. – Кайткач, малайларга сөйләрлек нәрсәләр күп...

Шат күңел белән сөйләшә-сөйләшә өч малай, авылларына, авыл каршысындагы каенлыкка, авылның теге башындагы Чирмешән буена сузылган, алар көн саен уйнарга чыга торган бакчага, аннан уңдарак зур канатларын җәеп утырган җил тегермәненә карый-карый, алга атладылар. Кайсына карасалар да, алар киткәндәгегә караганда якынрак, матуррак булып, ниндидер яңа төсләргә буялгандай, кадерле булып күренделәр. Әйтерсең лә, алар өч атна түгел, ә өч ай юк булдылар. Алай гына да түгел, еллар буе торып кайтып киләләр. Һәрберсе – авыл каршысындагы каенлык та, Чирмешән болыннары да, озын билбудай боргаланып аккан Чирмешән елгасы да – барысы да үзгәргән, яңа төсләргә буялган булып күренәләр. Менә аларның күзләре Латра болынына төште... Кара инде, алар киткәндә әле анда чабылмаган болын җәелеп ята иде. Әле карасалар, анда зур-зур печән кибәннәре үсеп чыккан. Борчак җирләренә күзләре төшкән иде, исләре китте. Менә сиңа мә! Борчак ашап кайтырбыз дип килсәләр, күзләре дүрт булды. Әллә алар адашып килеп чыктылармы? Алай дисәң, шул юлдан киткәннәр иде. Борчак җирен сукалап ук куйганнар. Юкка гына аларга калада бик озак торган кебек тоелмаган икән. Әнә бит авылдашлары күпме эш башкарган... Күпме үзгәреш...

– Малайлар, – дип кычкырып җибәрде Илгизәр. – Ә-н-ә тегендә, күрәсезме?! Тирән Чокыр артында көлтә ташыйлар!

– Әйе шул, өч олау белән кайтып киләләр. Ә тегендә – Тирән Чокыр артында ничә олауга көлтә төйиләр, – диде Гата, очып төшәрдәй булып. – Беләсе иде, кемнәр ташый икән?

– Әнә, ындыр табагында ашлык сугалар!

– Иртәгә мин көлтә ташырга чыгам, – диде Рәфгать. – Сез дә чыгыгыз.



– Сөйләштек, кичтән бригадирны күреп калабыз да иртәгә өчебез дә көлтә ташырга чыгабыз.

Туган җирләренә, туган авылларына кайтып җитүдән чиктән тыш шатланган бәхетле өч малай йөгерә-атлый, сыйса, бөтенесен берьюлы кочаклап алырдай булып, үзләренең кечкенә генә, ләкин чиктән тыш кадерле Сабанчыларына ташланды. Иң башлап, йөгерә-йөгерә төшеп, шәһәрнең квасыннан да тәмле тоелган чишмә суын йотлыга-йотлыга эчтеләр.

Бу өч малай өчен туган авыл, туган җир тудырып, тәрбияләп үстергән әнкәйләре кебек гомергә газиз, гомергә якын, гомергә кадерле булып калды.

Шул ук көнне малайлар, кичке уенга чыккач, иптәшләре алдында, моннан соң бервакытта да авылларын ташламаска сүз бирделәр.

# ЯЛГЫШЛАР ҺӘМ ЯЗМЫШЛАР

Пристаньның кассалары залына чиста ак йөзле, шомырт кара күзле, калын толымнарын чак кына калку күкрәге өстенә салган яшь кыз килеп керде. Аның өстендә сыек зәңгәр төстәге күлмәк, кулында кирза сумка. Кыз стенадагы расписание янында басып торган бер ападан Казанга кайчан пароход буласын сорашты да рәшәткәле диванга утырып уйга калды:

«Казанга пароход килергә өч сәгатьләр бар икән әле. Билетларны пароход килер алдыннан гына сатачаклар икән. Ничек билет алырмын да, ничек утырырмын? Кайдан утырталар икән? Ичмаса, Казанга баручы таныш кеше дә күренми...»

Хәятнең әле дөньяга беренче чыгуы. Чистаен да, пристанен дә беренче күрүе. Пароходын да рәсемдә генә күргәне бар. Авылларында җидене бетергәннән соң ике ел колхозда эшләде, әнисенә булышты. Инде менә Казанга китеп барышы.

«Әле пароход килергә вакыт бар, әллә чыгып әйләнеп керергәме? Кайдан утырталар икән? Су өстендә тирбәлеп тора торган пароход шикеллесе бар, шулдыр инде?..» Кыз урыныннан торып китәргә өлгермәде, залга әле генә килеп кергән, урта буйлы, ачык зәңгәр күзле, соры чәчле егетнең үзенә игътибар иткәнен күреп, Казанга баручы укучы, ахыры, дип өметләнеп, егеткә карады. Егет тә кызның игътибар итүен күрде бугай, шунда ук Хәятнең каршысына килеп басты.

– Гафу итегез, бирегә утырырга мөмкиндер бит?

Кыз алдына килеп баскан егетне баштанаяк күздән кичерде дә:

– Утырыгыз, – дип, сумкасын кулына алып, читкәрәк тартылды.

Егет, чемоданын аяк очына куеп, урындыкка утырды. Чалбар кесәсеннән кульяулык алып, тирләгән битләрен, муенын сөртеп алды да, чак кына борылып, кызга эндәште:

– Гафу итегез, мин сезне кайдадыр күргән кебек булам, сез Әлмәттән түгелдер бит?

– Әйе, Әлмәттән мин, абый, кайдан беләсез? – диде кыз, читләтеп кенә егеткә күз салып.

– Мин Сабанчыдан Нурмөхәммәт Мәрданов булам, таныш булыйк, – диде егет, ачыла төшеп, – мин сезнең авылга апам янына бара идем. Минем апам Әкълимә Мәрдәнованы белә торгансыз бит?

– Әкълимә апанымы? – диде кыз, кояштай яктырып. – Минем беренче укытучым бит ул, абый. Ул сезнең туганыгызмы?

– Минем олы апам ул...

– Бик ярата идек без Әкълимә апаны.

Хәят беренче укытучысының туганын очратуына шатланып, аның турында шатланып сөйләп китте.

– Җырлар, биюләр өйрәтә иде ул безгә. Классыбыз белән концертлар куя торган идек. Ике ел укыткач, Әкълимә апаны районга комсомол эшенә алдылар. Бөтен классыбыз белән елап калган идек. Кайда ул хәзер?

– Шөгер районында укыта ул хәзер. Институттан шунда җибәрделәр.

– Шулаймыни? – диде кыз, уңайсызланып. – Кызганыч, Казанда булса, барып күрергә иде исәбем. Әкълимә апага миннән бик күп сәлам тапшырыгыз, абый, Садриева Хәяттән, диярсез. Мине онытмагандыр әле. Сез дә, абый, Казанга барасызмы?

– Минем Алабугага укырга барышым. Сез Казанга юл тоттыгызмы? Мин тагын сезне ни өчендер Алабугага барасыз дип уйлаган идем.

– Мин, киресенчә, сезне Казанга баручы студент дип, миңа иптәш булды, дип шатланган идем, – диде кыз, уңайсызланып. – Минем Казанга беренче баруым. Ничек барып, кайда төшәргә икәнен дә белмим.

– Укырга баруыгызмы?

– Әле үзем дә белмим, абый. Бер таныш апа чакырды. Шул апаларга барам. Ул: «Үземә кил. Укырга да, эшкә дә урнаштыра алам», – дип чакырып китте.

– Нинди апа соң ул? Ышанычлы кешеме?
– Үзе болай бик ышандырып сөйләде. Әни белә ул апаны.
– Бик нык ышанма син ул шәһәр хатыннарына. Авыл кызы, берни белми дип, бер юньсезенә димләп куймасын, – диде Нурмөхәммәт.
Безнең авылда бер апа шулай синдәй чибәр кызны эшкә урнаштырам дип иртеп китте дә, анда баргач, кызны үзенең бер хатын аерган исерек туганына биргән, дияргә уйлаган иде дә, ни өчендер әйтмәс булды.
– Мин яшь бит әле, абый. Уналты тулды гына.
– Юк, мин сезгә сак булыгыз дип кенә әйтүем. Синдәйләргә күзе төшүчеләр күп булыр. Билет алдыгызмы соң әле?
– Юк әле, абый, билетны пароход килер алдыннан гына саталар икән. Әле Казанга беренче пароход килергә өч сәгатьтән дә артык, диләр.
– Сез, Хәят, әйберләр янында торыгыз. Мин хәзер кассага чиратка басам. Икебезгә дә алырмын. Сезгә кайсы класска алырга?
– Мин белмим дә инде, абый, иң арзанына алыгыз, – диде кыз, кирза сумкасыннан кульяулыкка төргән акчасын алып. – Билет бәясен дә белмим.
– Ярар, алай булгач, мин билетларны алып килим, – диде егет, кызның үзенә ышаныч белән караган сөйкемле йөзенә карап.
Нурмөхәммәт кассада озак торып килде. Хәят инде борчыла да башлаган иде: «Нишләп озак тора икән? Әллә ничә кеше Казанга дип билет алып килде. Әллә билет ала алмыймы?» – дип торганда, кулына билетлар тотып үзенә таба килүче егетне күреп, тынычланып калды.
– Икебезгә дә алдым, – диде ул, бер билетны кызга сузып. – Ике кат чиратта торырга туры килде. Башта Казанга гына сатты. Аннары – Алабугага. Миңа пароход соң гына булачак. Мин әле сезне озатып калачак кеше.
– Рәхмәт инде, Нурмөхәммәт абый, – диде кыз, билетны кулына алып. – Ничек билет алырмын дип, куркып утыра идем. Ничәнче класска?
– Өченче класска алдым, Хәят. Синдәй чибәрләргә балык кисмәкләре арасында бару килешеп бетмәс. Тиздән пароход буласы, ди. Әйдә төшә башлыйк, мин сине пароходка утыртып, озатып калырмын.
– Әйдә, – диде кыз, шатланып урыныннан торып. Алар касса залыннан чыктылар да Кама өстендә тирбәлеп торган ак дебаркадерга таба төшеп киттеләр.
– Сезнең Казанда булганыгыз бармы, абый? – диде кыз, кыйгач кашлары астыннан гына егетне күзәтеп.



– Бар, – диде егет, кызга якынрак килеп. – Мин анда ике ай укыдым да әле. Аннары безне Алабугага күчерделәр.
– Сез дә Казанга барсагыз, миңа нинди уңайлы булыр иде, – кыз егеткә тагын бер тутырып карап алды. – Свердлов урамына ничек барырга икәнен беләсезме?
– Свердлов урамына бару бик җиңел ул, Хәят. Пароходтан төшү белән, шәһәргә бара торган трамвайга утырасың да Кольцога кадәр барасың. Свердлов урамы Кольцодан башланып китә. Анда җәяү генә дә үзеңә кирәкле йортны табарга була.
Нурмөхәммәт Хәятне пароходка кертеп, Казанга баручы олы абыйлар янында урын табып урнаштырды.
– Йә, Хәят, сау бул! Хәерле юл сиңа!
Кыз оялып кына кулын сузды, егетнең сөйкемле карашын тоеп, йомшак җылы кулын тартып алырга ашыкмады. Бу мизгелдә икесенә дә рәхәт һәм моңсу иде. Икесе дә күңелләрдә нindидер әйтелми калган, әле үзләре дә яхшылап аңлап бетермәгән хисләр дөньясында йөзәләр. Тагын нидер әйтергә кирәк булып та, әйтә алмаудан аптырап калганнар иде.
Ул арада пароход, өченче кат гудок биреп, егетне сискәндереп җибәрде. Ул кызның кулын каты итеп кысты да:
– Сау бул, Хәят! – дип, чыгып китәргә ашыкты.

* * *

Нурмөхәммәт чыгып киткәч кенә, Хәят үзенә күңелсез булып калганын сизде. Җанына нидер җитми башлады, йөрәгенең кайсыдыр җире сыкраган шикелле булып китте. Нурмөхәммәт үзенең йомшак сөйләшүе, ихлас күңелдән булышып озатып йөрүе белән Хәятнең күңелен үзенә җәлеп итәргә өлгергән иде инде. Пароходта да, Казанга баргач та, кыз егетне еш хәтеренә алды. «Хәерле юл сиңа, Хәят, сау бул» дип, озак итеп кулын кысып торган кадерле минутларны ул күңеленнән чыгармаска тырышты.
Нурмөхәммәт пароходтан көчкә чыгып өлгерде. Ярый әле ашыкты. Ул килгәндә киң җилкәле юан матрос трапның икенче яртысын алып маташа иде. Ул йөгереп килгән уңайга дебаркадерга менеп басты да палуба буйлап пароходның өченче классы турысына килде. Исәбе ничек булса да бу сылу һәм сөйкемле кызны тагын бер кат күреп, кул болгап калу иде. Ләкин кыз күренмәде. Ничек болай килеп чыкты соң әле? Егет пристаньның кассалар залына килеп кергән минутларны күз алдыннан ки-

черде. Диваннарга утырган юлчылар каршысыннан үтеп барганда ниндидер көч аны тукталып калырга мәҗбүр итте. Күзләре белән күргәнче үк, җылы нур сибеп өлгергән газиз җан иясен күреп, ирексездән туктап калды. Гади авыл кызы әнә ничек бераз уйланыбрак, тыйнак кына утырып тора. Кайсы җире беләндер Сәлимәгә охшаган түгелме? Юк, моның толымнары әнә нинди, бөтен күкрәген каплап тора, кара кашлар, чиста ак йөз, шомырт кара күзләр. Бу Алабугага фельдшерлар мәктәбенә баручы түгелме икән?.. Әйе, әйе, аннары ул кыз үзе миңа туры карап тора башлады... Шуннан мин аның яныннан урын сорадым...

Нурмөхәммәтнең ике ел йөргән кызы авылда калды. Әле үткән төнне генә ул Сәлимәсе белән бергә үткәрде. Киләсе җәйгә, егет мәктәпне бетереп кайткач, бергә булырга сүз куештылар...

Әле менә нинди хәл: уйламаганда, көтмәгәндә, егетнең теләгәне, уй-планнарына каршы килеп, Сәлимә белән ике арага Хәят шәүләсе кереп басмакчы түгелме? Юк, бу болай гына дип уйланды ул. Андый гына танышулар, аралашулар булырга тиеш инде ул. Аннары, ничек инде, кызның ярдәмгә мохтаҗ булуын күрә торып булышмыйсың, ди? Кеше һәрвакыт хисләрдән өстен, ярдәмчел булырга тиеш...

Нурмөхәммәт Мәрдәнов, Алабугадагы Республика политик агарту мәктәбенең икенче курсын бетереп, җәйге ялга кайткан иде, шунда китеп барышы.

Ак пароход, Кама Иделе өстендәге рәшә дулкыннарына күмелеп, күренми башлагач, сүнеп бара торган «Беломорканал»ын суга ташлады да пристаньның касса залына күтәрелә башлады. Аның уйлары яңадан авылда калган Сәлимә белән әле кичә генә булган кадерле минутларга күчте.

Сәлимә бөтенләй изрәп төшкән иде, дип уйланды ул, әллә үзе шулай булуын теләдеме икән? Мин, җүләр, шуны да аңламадыммы? Ни өчен соң әле мин читкә тайпылдым? Сәлимәне кызгандыммы? Юк, алай ярамый, минемчә. Үзең өчен үстергән матур чәчәкне вакытсыз өзмиләр... Без бит киләсе җәйгә бергә булырга сөйләштек. Аның укырга барасы бар. Унны бетерәсе... Эх, нинди исерткеч минутлар...

Ай ярым Нурмөхәммәт авылда булды. Сәлимә белән һәркөн күрештеләр. Көндезләрен болында печән җыйганда, печән ташыганда да еш кына очрашалар иде. Кичләрен бакчада төрле уеннар уйнап, җырлап-биеп күңел ачтылар. Соңыннан карлыган, чия куаклары төпләрендә сөйләшеп утырдылар. Кайсыбер көннәрдә таң әтәчләре кычкырганда гына таралышалар иде. Нурмөхәммәт, Сәлимәне бүген үзенеке итәргә теләсә, кызның риза икәнен сизенеп тора иде. Тик егет үзенчә итәргә тырышты. Көне, сәгате җиткәнне көтәргә, сабыр итәргә. Әдәп сакларга тырышты. Кызның биленә кул салудан да тартынды. Барысына да Сәлимә үземнеке булгач кына ярый торган эш итеп карады. Әлегә кадәр ике арада кайчан өйләнешү турында сүз чыкканы юк иде. Беркөнне, егет иртәгә укырга китәсе кичне, кыз үзе егеттән сорап куйды.

– Син, Нурмөхәммәт, кайчанга укып бетерәсең инде?

– Киләсе җәйдә, – диде егет, кызга сораулы карап. – Син бит ул турыда беләсең? Киләсе җәйдә туйларбыз, дип уйлап торам мин, Сәлимә. Син шуңа ризасыңдыр бит? – Ул кулын кызның җилкәсенә салды.

– Мин бүген үк риза, җаным, – кызның тавышы шундый назлы иде. Ул, иркәләнеп, егетнең күкрәгенә капланды. Егет кызның тыгыз күкрәкләрен, кайнар тәнен тоюдан хисләнеп, көчле куллары белән кысып алды.

Үзе дә белмәстән, ике кулын кызның аркасында шуыртып йөртә башлады. Сәлимәнең кайнар тыгыз тәнен, калак сөякләрен, бил батынкылыгын тойды. Кыз дәшмәде, ниндидер рәхәтлеккә чумып, бөтен тәне белән Нурмөхәммәткә сыена барды. Назга, иркәләүгә сусаган кызның сулышы, тәне кайнарланды. Үз-үзен тыярлыктан узган кыз, егет кенә ишетерлек итеп, җаным, мин бүген үк риза, дип кабатлады. Аның майлы, нурга күмелгән күзләре, йә инде, нигә тилмертәсең, шуны да аңламыйсыңмы, дип ялвара шикелле иде. Егет исә, юк-юк, болай ярамый дип, ничек тә бу халәткә чик куярга аптырап торганда, ниндидер рәхәт тылсым көткән кыз аны муеныннан кочаклап алды да, чирәм өстенә авып, Нурмөхәммәтне үз өстенә егып, егетне шашынып үбәргә тотынды. Сөлек кебек иреннәренә ябышты... Хисләре ташудан егет сулышы ешайганын, йөрәгенең читлектән чыгардай булып ярсуын, бөтен тәненең үзе дә белмәгән тансык бер тылсымга омтылуын тойды. Шунда ул үз-үзен тыеп тора алмаслык хәлдә икәнен тагын бер кат аңлады. Моңа кадәр үземә буласы кызга көне, сәгате җитмичә кагылмам, дип йөргән вакытлары исенә төште. Күңеле иләс-миләс килеп, башында ике уй көрәште, ике фикер тартышты: «Әллә... югыйсә? Барыбер минеке буласы бит?..», «Ничек була инде, хатын итеп алганчы ук, балага узса?..», «Чү, нишләмәкче буласың син? Юк, ярамый, акылсызланма...». Нурмөхәммәт, бар акыл көчен җыеп, үзен-үзе белмичә хис исереклегенә бирелгән кыздан кулларын алып, читкә тартылды, чирәмгә яткан килеш югарыга, йолдызларга карап тын алды. «Күктә күпме йолдыз карап тора икән бит безне...»

– Ялгышып куймыйк, Сәлимә, – диде ул, кызга таба башын борып.

Бары тик Сәлимәгә генә ишетелерлек итеп әйтелгән бу сүзләрне кыз әллә ишетте, әллә юк. Ул дәшмичә генә күктәге йолдызларга карап ята иде.

– Ә-ә?..

– Сабыр итик, Сәлимә, дим, ямен җибәрмик.

– ...

– Син унны бетер, мин дә бетереп кайтыйм да, шәп итеп туйлар ясап бергә, гомергә бергә булырбыз, – диде егет, кызга якынрак борылып. – Син мине көтәрсең бит, Сәлимә?

– Көтәм, җаным, көтәм, – диде кыз, егетне яңадан муеныннан алып. – Тик син анда шәһәр кызлары белән йөреп, мине оныта күрмә. Аннары мин синсез акылдан язармын. Хатларыңны гына ешрак яз.

– Миннән калмас, Сәлимә. Атна саен язарга да риза. Син, кызый, бу соңгы вакытта үзең хәрәмли башладың. Соңгы хатларыма җавап булмады...

– Имтиханнар вакыты иде бит, Нурмөхәммәт. Аннан тиздән кайтасы идең бит...

– Шул гына булса ярый да...

– Шул гына, – диде кыз, нидер әйтеп бетермичә.

Ләкин чын сәбәбенең ике арага бик төче телле, таш астыннан чыккан керәшен егете керә башлаганын егет белми иде әле. Ул шулай, Сәлимәнең көтәм, җаным, көтәм дигән вәгъдәсенә ышанып, китеп барган иде.

* * *

Сәлимә йокысыннан торганда кояш югары ук күтәрелгән иде. Ул, чиләк-көянтә алды да, «Яңа дөнья»га укырга киткәнче, әнигә чишмә суы кайтарып калдырыйм дип, урамга чыкты. Чиләкләрен чак кына чайкалдырып урам буена, чишмәгә таба китте. Бер-ике йорт үтүгә, үзе дә уйламастан, Нурмөхәммәтләр ягына чыкты. Алар турысына җиткәч, тәрәзәләренә, ишегалларына карый-карый, биек үскән өянкеләр ышыгыннан үтте. Киткән, ахры, диде ул, артык әһәмият бирмичә генә. Берәү дә күренми. Кызның күңелендә үзенә дә аңлашылмый торган бушлык кына иде. Бер кызык та калмады, кайтырга да, «Яңа дөнья»га барырга әзерләнергә кирәк дип, кыз адымнарын тизләтте.

Кайтканда ул Нурмөхәммәтләр ягыннан кайтмады. Ул якка күз дә салмады. Күңеле аны тегендә – «Яңа дөнья» мәктәбенә ашыктыра иде.



Сәлимә күңел биреп, тырышып укымады. Тугызынчыга да Нурмөхәммәт белән танышкач, аның киңәшен тыңлап кына барган иде. Әле дә ул «Яңа дөнья» мәктәбенә укырга теләге зур булудан ашкынмый иде. Беренче сентябрьдә кызлар-егетләр, аның яшьтәшләре, барысы да укырга китеп баралар. Берүзе авылда калмас өчен Сәлимә, әллә ни укыйсы килмәсә дә, башкаларга иярергә булды. Ни дисәң дә, зур мәктәптә, шунда торып укулары кыш буе өйдә ятудан күңеллерәк. Төрле авыллардан җыелган кызлар-малайлар бер түбә астында торып укыйлар. Төрле түгәрәкләр эшли. Уеннар оештыралар. Буш вакытларда бакчага, урамга чыгарга була. Ял көннәрендә берәр кыз белән башка авылга барырга да була.

Элекке вакытларда алпавыт утары булган, хәзер Сәлимәләр укый торган «Яңа дөнья» мәктәбе табигатьнең бик матур җирендә урнашкан. Кечкенә булса да, күле бар. Тирә-якта – урман-куаклыклар. Алмагачлы бакчасы бар. Тирә-яктагы сигез-тугыз татар авылыннан җыелган укучылар шунда торып укыйлар...

Сәлимә судан кайтты да, тал чыбыгыннан үреп эшләнгән бикләүле кәрзинен алып, әйберләрен тутыра башлады. Алмашка кия торган ике күлмәген, ак алъяпкычын, сөлге-сабын алып, кәрзиннең уң як читенә урнаштырды. Аннан китап-дәфтәрләрен куйды да, тагын нәрсә калды дип, як-ягына каранды. Әһә, яулыгым белән косынкам кала икән. Алыйм әле, Розаларга барсам кирәк булыр дип, бәйләгән кофтасын да алып кәрзингә салды, шуннан соң уйга калды. Кинәт Нурмөхәммәт исенә төште аның: «Юлда микән әле, әллә барып та җиттеме? Тормады бит шунда бер-ике көн... Азрак кичексә дә берни булмас иде әле... Китте дә барды. Үзе мине яратам дип, ике елдан бирле башымны әйләндерә. Үзе һаман суза. Башта тугызны бетер, дигән иде. Инде унны бетер, имеш... Әллә инде минем белән вакыт үткәрер өчен генә йөри. Яратуы шулай гынамы? Бәлки, аның анда шәһәр кызлары бардыр? Минем белән каникул вакытында гынадыр? Югыйсә әнисе быел өйләндерәм дип тора иде. Бу һаман киләсе җәйгә дип, тагын китеп барды. Ярый ла сүзендә торса... Көтеп-көтеп тә булмаса? Никифор белән араны өзмәскә кирәк миңа. Ул әнә беренче күрүдә үк: «Нигә мин сине хәзергә кадәр күрмәдем?» – дип танышты. Хәзер әнә, Сәлимәкәй, алтыным минем, дип кенә тора. Ике көн укыгач ял көне буласы. Роза белән аларга барырга кирәк тә, күрешергә... Тагын нәрсәләр аласы соң әле? Сәлимә почмакка кереп китте дә, аннан бербөтен ипи алып, шакмаклы ашъяулыкка куйды. «Әһә, әни бавырсаклар да пешердем дигән иде», – дип, салфет белән каплап куйган агач табактан

кызарып пешкән бавырсакларны ашъяулыкка бушатып, төенләп, түр яктагы кәрзине янына чыгарып куйды. «Тагын нәрсәмне алмадым икән?» – дип, як-ягына каранганнан соң, киртәгә элгән кич киеп ята торган күлмәген күреп, аны кәрзиненә урнаштырды да, кәрзинне ябып, урамга чыкты. Кайчанрак китәбез икән дип тора иде, классташ кызы Фәниянең үзләренә таба килгәнен күрде.

– Җыенып беттеңме, Сәлимә? Хәзер китәбез! – диде Фәния килә-килешкә, – әйберләрне алып, тыкрыкка чыгып торырга куштылар.

– Җыендым. Синең әйберләрең кайда соң, кызый? – диде Сәлимә, дустын каршы алып.

– Мин Нияз арбасына куеп калдырдым, сеңлем анда калды...

– Нишләп, Нияз укырга бармый микәнни?

– Ул ялдан соң гына барам, ди, ике көн укыгач ял бит.

– Мин дә ялдан соң гына барырмын дип тора идем дә, барырга булдым инде. Монда берүзем калып нишлим...

– Нурмиең киттемени? – диде Фәния, Сәлимәгә сораулы карап.

– Китте, соңга калам, дигән була...

– Кичә бик озак саубуллаштыгыз, ахры? Иртән озатырга да чыкмадың.

– Каян беләсең? Әллә син озатып калдыңмы?

– Көтүдән соң китеп бара иде, күреп калдым. Кул изәп: «Сәлам!» – дип узып китте безнең турыдан.

– Соң яткан идем шул. Ул алайса ятып та тормагандыр. Алай иртә киткәч.

– Ничек соң араларыгыз? – диде Фәния, Сәлимәгә сынаулы карап. – Мин инде сезне бергә буласыз, син укырга бармыйсың, дип уйлаган идем.

– Әй, аны аңламассың. Укуны бетерик дигән була... – Сәлимә, бу турыда сөйләшмәс өчен, урам буена карады. – Атлар килә башлар, әйберләремне алып чыгыйм әле, – дип, өйгә кереп китте. Аннан кәрзине белән төен тотып чыкты да:

– Әйдә, Фәния, тыкрыкка бара торыйк, – дип, урам буена китте. – Синең рәхәт, егетең янында, – диде ул, бераз баргач туктала төшеп.

– Янымда булмаса, бәлки, яхшырак булыр иде...

– Нигә алай дисең?

– Соң нәрсә диим инде? Бер малайга да туры карарга шикләнеп торасың...

– Нигә, көнлиме әллә?

– Шулайрак итенә шул.



– Яратадыр.

– Ярата дип, хатыны булмаган килеш мин аның күзенә генә карап торыйммы? Яз көне ике мәртәбә синең белән Баранга барган идем, ай буе сөйләшми йөрде. Анда нәрсәң калган, керәшен егетләрен күзләп йөрисеңдер әле, ди. Синең рәхәт. Нурмиең янында булмагач, рәхәтләнеп йөрисең.

– Әйдә, бу ялда Розаларга барабыз. Нияз ялдан соң гына бара, дисең түгелме соң?

– Белмим шул...

– Нәрсәсен белмисең, әйдә. Муеныңа тагылмаган бит Нияз. Белми дә калыр әле. Берәүгә дә әйтми китәрбез.

– Ярар, анда барыйк әле, – диде Фәния, уйга калып. – Араны бозмыйсы иде дә...

– Арагызны бозма. Яхшылап сөйләш. Сине генә сөям, диген. Җаным, дип, үбеп ал. Эреп китә ул...

– Нияз килә, – диде Фәния, урамнан чаптырып килгән атны күреп. Алар туктап атны көтә башладылар.

– Сәлам җанкисәкләргә! – диде Нияз, чаптырып килгән атыннан төшеп. – Кайда, бирегез әйберләрегезне!

Егет кәрзин белән Фәния кулындагы төенне алып арбага урнаштырды да кызларга елмаеп борылды.

– Фәния, син менә монда утыр, – диде ул, кызга үзе янынннан урын күрсәтеп. – Сәлимә синең янга утырыр. Сез, малайлар, менә мондарак күчегез!

Сәлимәнең әнисе ындыр табагыннан кайтып килә иде.

– Кызым, әйберләреңне алдыңмы? Анда почмакта бавырсаклар пешереп куйган идем, – дип, арба янына килде.

– Алдым, әни, алдым, – диде кыз.

– Анда тәртипле генә йөрегез! – диде ана, кызына карап, – ялда бәрәңге алышырга кайта торгансыздыр бит? Кайтыгыз!

– Бу ялда түгел, әни, киләсе ялда кайтабыз.

– Кайтабыз, Галимә апа, үзем барысын да алып кайтам! – дип кычкырды Нияз, атын йөгертә башлап.

* * *

Нурмөхәммәт, Кокшанга барып төшү белән, җиң сызганып эшкә тотынды. Берничә көн завод клубында эшләрне җайландыруга иреште. Алдагы совет утырышында авыл советы территориясендәге клублар-

ның һәм кызылпочмаклы китапханәнең эшен тикшерүне оештырды. Авыл советы һәм завод идарәсе белән сөйләшеп, завод клубына гармун, мандолина, берничә шахмат, радиоалгыч һәм унбиш метр комач алуга иреште. Ел ахырына кадәр эш планы төзеп, клубның эшен план нигезендә алып бара башладылар. Октябрь бәйрәме көннәрендә куярга бер спектакль, бер концерт әзерләделәр. Атнага ике мәртәбә кино китерүгә ирешелде. Комсомол оешмасы, мәктәп белән сөйләшеп, клубның эшен җанландыру турында киңәшмә үткәрде. Драмтүгәрәктән тыш, җыр-бию, музыка, кул эшләре һәм шахмат түгәрәкләре оештырылды. Аларга укытучылар арасыннан җитәкчеләр сайланды. Партоешма, мәктәп дирекциясе белән сөйләшеп, халыкара һәм башка темаларга әңгәмәләр, докладлар үткәрү планы төзелеп, аларны үткәрү өчен кешеләр билгеләнде...

Шулай, кызу эш белән, бер ай сизелми дә калды.

Авыл советыннан һәм партия оешмасы, заводтан Мәрдәновка мактау сүзләре язылган бик әйбәт характеристикалар биреп җибәрделәр.

Командировка срогын тутырып, техникумга кайтканда Нурмөхәммәт, Сәлимәдән, артык булмаса, кимендә ике хат көтә торгандыр, дип канатланып кайтты.

Кайтты да күңелсезләнеп уйга калды. Сәлимәдән ник бер уч кисәге кадәр хат булсын. Техникум канцеляриясенә кереп кат-кат сорашты... Вәгъдәсендә тормаган өчен Сәлимәгә ачуы чыкса да, булгандыр, сәбәбе килеп чыккандыр дип, үзен тынычландырырга тырышты. «Син анда, Нурмөхәммәт, шәһәр кызлары белән чуалып, мине онытма! Мин синсез шашармын!» – дип калган Сәлимәгә ничек инде бер дә белмичә үпкәлисең. Бәлки, язган хатлары югалгандыр. Йә булмаса, кайда да булса почтада адашып ятадыр дип, үзен тынычландырырга тырышты. Менә бүген, менә иртәгә Сәлимәнең хатлары килеп төшәр, дип көтә торгач, тагын бер ай үтеп китте дигәндә, кыздан кыска гына хат килеп төште. Хатның башы да Сәлимәнең үткән елларда язган хатларга бер генә дә охшамаган: «Нурмөхәммәт, менә бер кисәк буш вакыт таптым да сиңа хат язарга утырдым. Без шулай кызу гына укып йөрибез. Унынчы класс дип, баш күтәрергә дә ирек бирмиләр. Көздән мәктәп бакчасында эшләдек. Бәрәңге алдык. Алмагач төпләре йомшарттык. Мәктәптә әллә ни үзгәрешләр юк. Ял көннәрендә авылга кайтабыз. Мине үткән елда Роза Игнатьева үзләренә кунакка алып киткән иде. Клубка чыктык, бик күңелле булды. Киләсе атнада да авылга кайтмассың, үзебезгә генә кайтырбыз, ди. Авылга кайтасы да килми, бердән, җәяү йөрергә ерак. Кайтсаң, кич чыгарга урын юк. Розалар авылында клуб гөрләп тора... Сине практикага җибәрәләр, дигәнсең. Син гел читтә, гел чит кешеләр янында. Чит кешеләр белән аралашу кызык икән ул. Розалар авылына кайткач, минем дә күңелем күтәрелеп китте. Керәшеннәр кичләрен бик кызык үткәрәләр икән. Роза каникулда бер атнага алып китәм, дип тора. Алып китсә, мин каршы түгел. Ярый, мин шуның белән бетерәм. Без быел бер бүлмәдә гел өлкән класслар гына торабыз. Хатларыңны ешрак яз. Сәлимә».

Хатны укып чыкты да Нурмөхәммәт уйга калды: элеккеге хатларда язылa торган «кадерлем, Нурмөхәммәт», «кайчан кайтырсың, кайчан синең нурлы йөзеңә карап сөйләшеп утырырбыз икән?», «күрешер көннәрне түземсезлек белән көтәм», «сагынычлы хат башы, яз каршы», «сагынып, сәлам белән» дигән сүзләрнең ник берсе булсын. Бу хатны Сәлимә язмагандыр дияр идем – аның кулы. Тик сүзләре аныкына охшамаганнар.

Хатларыңны ешрак яз, имеш. Үзе минем өч хатыма бер уч хат кисәге җибәргән... Нидер булган бу кызга. Алыштырып куйган төсле. Шулай да практикада кайда булганнарын,ниләр эшләгәннәрен, рус авылында татар егетенә беренче практика үтүе җиңел булмаганын бәйнә-бәйнә сөйләп, озын итеп хат язды. Соңыннан гына үзенең шикләнүләрен белдереп: «Сәлимә, син, кадерлем, мин белгән Сәлимәгә охшамаган хат язгансың. Әллә синең кулың белән башка берәү яздымы ул хатны? Әллә үзең шулай ике ай эчендә танымаслык үзгәрдеңме? Ачыклап яз әле. Мин синең өчен, Сәлимә, бик борчылам. Синнән түземсезлек бнлән хат көтәм. Өзелеп сагынып, синең Нурмөхәммәтең», – дип, дүртенче хатын язды.

Шуннан айлар үтте, Сәлимәдән хат килмәде... Башта бик өзгәләнеп хат көтсә дә, мартта дәүләт экзаменнарына хәзерлек көннән-көн үзен сиздереп тора башлагач, Нурмөхәммәт, хәзер бер-беребезне гаепләшеп тора торган вакыт түгел, икебезгә дә укуны уңышлы тәмамлау турында уйларга кирәк дип, җәй күрешкәч аңлашырга өметләнде.

* * *

Чемоданын район үзәгендә калдырып, кечкенә сумка гына тотып кайтып килүче Нурмөхәммәт, авыл ягына карый-карый, адымнарын тизләтте. Авыл өстеннән калкып торган биек-биек өянкеләр, канатларын җәеп торган җил тегермәне, Чирмешән үзәнендәге болыннар уртасындагы каенлык каршысына утырган кечкенә авыл рәшәле җәйнең эссе һавасында изрәп утыра.

Юл Чирмешәннән километр ярымнар читтән, иген кырлары эченнән, көньякка таба бара. Шул юл белән елганың теге ягындагы авыл

турысын үтеп киткәнче барасың да, кинәт уңга борылып, тегермән буасына төшәсең. Сабанчыга тегермән буасы аша әйләнеп йөриләр.

Болын читендә, калкурак урында, зур-зур печән кибәннәре калкып чыккан. Әйе, быел алдатмаганнар, дип куйды Нурмөхәммәт, әле берничә ел гына элек язгы ташу алып киткән ярты кибән печәнне хәтерләп.

Аннан ул Чирмешәннең аргы ягындагы үзе таптаган, җиләк җыйган болынга күз салды. Болын чуп-чуар, халык белән тулы. Печән җыялар, печән өяләр. Атлар белән кибәннәргә ташыйлар. Кайчандыр Нурмөхәммәт үзе дә печән ташыган, тирләп-пешеп кибәнгә печән ыргыткан вакытларын исенә төшереп, талпынып куйды. Сәлимәләр, Ниязлар, Фәридәләр шунда гөр килә торганнардыр. Әллә иртәгә үземә дә чыгаргамы? Егетләр-кызларның бергә килеп эшләп йөрүе кызык бит, ифрат күңелле.

Әрәмәлекләрне үтте дә Нурмөхәммәт тегермән буасына килеп чыкты. Буаны күптән буганнар икән. Чирмешән тулып, суы кавызга җитеп килә. Ул киң итеп өелгән буа өстенә керде дә, уртага җиткәч, мөлдерәп торган Чирмешән өстенә карап торды. Аннан, артына борылып, тирән тобалы, карасу зәңгәр сулы буа артына карады. Су өстендә агымга каршы хәрәкәтсез торган беләк буйлы кызылканатларны күреп, буа читенә якынрак килде. Элек монда җәен балыгы бар, дип сөйлиләр иде. Уникe яшьләрендә вакытта ул җәен балыгын үзе дә күреп куркуга калганы исенә төште: төш вакыты иде, тирә-юньдә бер җан иясе дә юк. Шундый бер тынлыкта Нурмөхәммәт ялгыз гына буа өстенә керде дә, озын саплы кармагын суалчан куеп, буа артына төшерде. Суда балык шулкадәр күп, кармагыңны бер җимсез килеш балык арасына төшерсәң дә, балык эләгеп чыгарлык. Су өстендә әкрен генә селкенгәләп, мыж итеп торган вак балыклар арасына эре балык килеп чыга да, тегеләре, кирпеч ташлап су чәчрәгән шикелле, як-якка сибеләләр. Шул күренешне карап, әй, әнә шул кызылканат килеп капсын иде дип торганда, кинәт астан чучка башы кебек зур җәен башы күренеп китте. Шул минутта тирә-юньдәге барлык башка балыклар читкә сибелделәр. Зур балык көрәктәй койрыгы белән суны шапылдатып алды да тирәнгә китеп югалды. «Әнекәем, җәен балыгы...», – дип, өне алынып төсе киткән Нурми хәле китеп чигенде дә, лап итеп, артына утырды. Аңына килеп кармагын ала башлаган иде, кармакка эләккән беләк буйлы кызылканат, шапыр-шопыр килеп, судан килеп чыкты да... «Әнекәем, җепне өзеп төшерә бит!» – Нурминың куркуы тагын да артты. Ашыгып, кармак җебен кулына алды да тиз-тиз үзенә тартырга кереште. Түбәннән күтәрелеп җитү белән, балыкны кочагына алып, тиз-тиз артка чигенде. Кочагыннан атылып төшкән балыкны, кармагыннан да ычкындырып тормыйча, бишмәтенә төрде дә, алдына-артына карамыйча, буа өстеннән читкә ташланды...

Егет үзенең малай чактагы шул куркуыннан елмаеп куйды. Ә бит ул көнне тагын да тотарга була иде... Ул исә өенә чапты. Җүләр булынган инде. Хәер, әнисе мактаган иде үзен шул балык өчен.

Нурмөхәммәт, кавыз өстеннән салынган кечкенә күпер аша чыгып, текә яр буена килеп басты. Бу берәр атнадан кавызга керәсе икән, яңгырлар булса, алай да тормас, дип уйлады ул. Ул Чирмешән борылышыннан күренеп торган бакчага карады. «Без малай чакларда бу бакчада алма күп була иде. Әти карап тора иде шул ул вакытларда. Хәзер, хуҗасыз калгач, алмагачлары юкка чыгып беткән... Велосипед алгач, шул бакча аллеясында беренче мәртәбә самоходта йөрергә өйрәнгән идем. «Самоход», кызык, ул вакытта әти «самоход» дип йөртә иде. Хәзер «велосипед»ка әйләнде. «Самоход» дигәне русча инде аның, «велосипед»ы кемчә була икән инде? Йөрергә өйрәнгәч, Сәлимәне алдыма утыртып йөрткән идем. Сәлимә ничек каршы алыр икән? Әллә Нурмөхәммәт турында бөтенләй уйламый дамы, онытты мы икән кызый? Яңа елдан соң бер хат та язмады бит. Кинәттән хат язмас булды. Әллә үпкәләдеме? Юк, үпкәләргә урын юк. Мин аңа җылы хатларымны язып тордым бит. Димәк, үзе белән ни дә булса булган. Апрельдән соң үзем дә язмадым, анысы. Имтихан вакытлары. Бәлки, ул да шулайдыр? Бәлки, ул бөтенләй мине оныткандыр? Ни булды икән ул кызга, шуны беләсе иде. Әллә башка берәү белән мәхәббәт сатамы? Алай булса, әйләнеп тә карыйсым юк. Йөрәктән чыгардым да ташладым булыр. Ике куян артыннан кумасын. Чү, нигә әле мин белер-белмәс карар чыгарам? Нигә дип Нияз дуска хат язмадым? Татар акылы төштән соңмы? И-и, башсыз да инде мин. Ниязның Фәниясе белән Сәлимә дус бит. Ниязга язган булсам, әллә кайчан хат алган булыр идем. Нияз барысын да белеп тора бит. Бер класста укыйлар, бер түбә астында интернатта торалар... Нәрсә соң әле мин, Сәлимә дә Сәлимә дип, баш ватам? Кайттым бит. Үзен күреп сөйләшермен. Әгәр ык-мык килсә, сау бул, син миңа иш түгел. Син Нәгыймә булсаң, мин сиңа Куян Хаҗибе түгел, диярмен дә, вәссәләм. Куян Хаҗибенең хатыны янына гармунчы Хаҗип йөрде бит...

Куянның хатыны дөньяда бер чибәр. Төсе-буе, дисеңме... Койган да куйган. Күкрәкләре, биле, дисеңме... Йөзе тулган ай кебек балкып тора. Башын күтәреп, горур атлап йөрүләре, дисеңме... Гармунчы Хаҗипне иясләштерде бит... Хаҗип абый көр тавышлы «вараксинын» уйнап турыларыннан узып китү белән, Нәгыймә апа: «Хаҗип җаным, шул

гармунчыны чакырып керик әле, бигрәк үзәкләрне өздерә, җырлашып, сөйләшеп утырыр идек», – ди икән. «Соң, алай булгач, чакыр, бергә-бергә кызык булыр». Хатынга шул гына кирәк, тиз генә җыенып чыгып китә дә озак кына йөреп кайтып керә, икән. «Җаным, тапмадым адашыңны. Бар әле, үзең эзлә. Әллә кемгә керде дә батты. Бар инде, җаным, мин монда аны-моны карый торам», – дип, ирен чыгара икән. Куян Хаҗибе чыгып ун минут та үтми, гармунчы атлар йортыннан килеп чыга.

– Адаш, кайда булдың, сәгатьтән артык сине эзлибез. Әйдә әле, гармун уйнап, сөйләшеп утырырбыз, – дип, адашны алып керә. Алар кергәндә, өстәлгә шешә дә менеп утырган була. Берәрне кабып алгач, гармунчы кыстатмыйча уйнап җибәрә. Нәгыймә апа «Хәмдия»не сорый. Ире янына килеп утыра да, аны кочаклап, җырлап җибәрә:

*Хәмдиянең ак калфагы, яңа каралган чагы,*
*Нәгыймәгә сүз әйтмәгез – зиһене таралган чагы, –*

дип җырлый икән дә, аннары боегып утырмагыз әле дип, үземнеке үзәктә дип, Куянга бер стакан тутырып, адаш Хаҗипкә яртыны гына салып алларына куя. Куян Хаҗибе, ябык кына кеше, икенче стаканнан ук изрәп төшә дә, «Хәмдия»не тыңлый-тыңлый, йокыга да китеп бара. Бераздан Нәгыймә: «Менә бит минем ирем нинди акыллы, исерсә, тавышланып, бәйләнеп тормый», – дип, мактый-мактый чишендерә дә урынга илтеп сала. Үзе: «Бар инде, Хаҗип, син дә кайт, вакыт соң, минем әле он илисем бар», – дип, күз кысып, гармунчы егетне чыгарып җибәргән була. Аннан киенеп, иләк алып, «он иләргә» үзе чыга икән. Җәйгә чыккач, Куян абый хатынының хәйләсен сизеп алган. Тик бер алдалаган хатын барыбер туктамады. Кичке якта киенеп-ясанып бакчага, гармунчы Хаҗип янына узганын Нурмөхәммәт үзе дә әллә ничә күрде. Шуның аркасында Хаҗибулла өйләнә алмый йөрде. Авыл кызлары килмәделәр аңа. Соңыннан башка авылга барып кына үзенә хатын алып кайтты... Юк, мин Куян Хаҗибе булмам. Кулыннан тоттым, артына типтем булыр. Яратам, дип тормам...

Тегермән өе янынннан үткәч, Нурмөхәммәт җил тегермәненә күз салды. Тегермән ишеге бикле. Тарттырырга юкмы, әллә халык су тегермәне туктаганчы он ясатып калганмы? Шулайдыр әле. Булмаган җилне көтеп торганчы... Мондый су тегермәне тирә-якта юк бит. Тирә-як авыллардан дистәләрчә олау белән киләләр дә берничә сәгатьтән он капчыклары тутырып китеп тә баралар. Өч таш гөрләп эшләп тора. Шуның өстенә кыш буена тула бастыра торган эшли... Шул тегермәннән Сабанчы колхозы дәүләткә биш йөз потлап керәк салымы түли. Аннан тыш, колхозчыларга хезмәт көненә дә бирәләр. Теге елны мин буа буудда эшләгән өчен генә дә ике капчык он алган идек... Башка авылларда хезмәт көненә граммлап кына биргәндә дә, безнең колхоз килолап бүлә. Мул тегермән файдасыдыр инде... Язгы чәчүгә берәр эре терлек чалалар да, чәчүдә эшләүчеләргә ашханә ясап, яртышар кило ап-ак бодай күмәче бирәләр. Тегермән буасын буганда да, печән чапканда да шулай...»

Җил тегермәнен узгач, юл үзәнлектән бара. Биредә Чирмешән «г» хәрефе сыман борылыш ясый. Үзәнлек икегә аерылып, бер тармагы Тәре сазына, икенче – киң тармагы – авыл каршындагы урманга таба сузыла. Чирмешән ташып боз киткәндә кайбер бозлар шул үзәнгә кереп китәләр дә, Тәре сазына кадәр барып җитә язып, сай җиргә утырып калалар. Бөтен үзәнлекләр, су астында калып, диңгез кебек була. Кайбер елларда су ташуы шундый зур була, каенлыкка кереп, авылның аргы башындагы чишмәгә кадәр җитә. Чирмешән буендагы бакча каршына утырган өйләргә су керә. Нурмөхәммәт белгәндә генә дә шундый көчле ташу ике тапкыр булды. Тимерче Иглаллар белән тегермәнче Вазыйх абзыйларның сыерларын йөздереп алып чыкканны, сарыкларын төне буе көймә белән ташыганны Нурмөхәммәт әле дә онытмый. Яз көне иң кызыгы Чирмешәндә боз киткәнне карау булса, икенчесе сазлыкларга кереп калган чуртаннарны тоту иде: озын саплы сәнәк тотасың да, аякка итек киеп, түмгәкләр арасындагы суга кереп, чуртан күзлисең. Алар түмгәк төбенә борынын төртеп торган чакны ялт сәнәк белән...

Нурмөхәммәт каенлыктан килә торган елга аша салынган күпергә килеп керде. Сәрби куаклары, өйләр өстеннән калкып торган биек морҗага, аның янындагы яртылаш сүтелеп беткән биналарга карады да, исе китте. Морҗа янындагы кызыл кирпеч биналар бөтенләй күренми. Әле кайчан гына, Нурмөхәммәт ун яшьлек малай чагында, шул биналарга кереп адашып йөргән иде. Ул вакытта завод бөтенләй исән иде. Инде әнә шул заводтан биек морҗа гына утырып калып бара. Әтисе Нурмөхәммәткә бу заводның эшләгән чакларын сөйләгән иде: князь Оболенский төзеткән бу спирт заводы өч кенә ел эшләп калган. Революциядән соң завод әле берничә ел исән торган. Аннан хуҗасызлыктан файдаланып, Гоголиха поселогы руслары, төннәрен килеп, калай, такта сүтеп ала башлаган. Каравылчылар шул авылныкы булган. Биләр исполкомында бер дә юньле адәм булмаган, күрәмсең. Нинди заводны җимерергә юл куйганнар... Әнә бит Төрнәстә шундый ук завод эшләп тора. Анда җимермәгәннәр. Кемдер хуҗа була белгән. Ә безнең Биләр тирәсендә ничәмә-ничә алпавыт утары булган, берсе дә калмаган. Нинди таш һәм агач биналар юкка чыкканнар. Бакчаларын әйтмим дә инде... Ярый әле «Яна дөнья» мәктәбе

исән калган. Югыйсә, кайда укырлар иде бу тирәдәге унлап татар авылы балалары?

Күперне чыккач ул, завод ягыннан әйләнмичә, турыга китте. Бакчасы буеннан үткәндә күзе гел шул якта булды. «Әллә кереп чыгаргамы, югыйсә? Кыяр өлгердеме икән соң әле? Юк, кермим әле, кыяр-суган үзебездә дә булыр. Кыяры өлгермәсә дә, әнинең суганы чалу кебек тезгә җитәрлек булып үсеп утырадыр».

Яшелчә бакчасын үтеп, үзәннән күтәрелгәч, Нурмөхәммәт, элеккеге атлар йорты эчендә урман кебек булып үскән киндерләрне күреп хәйран калды. Эченә кереп басып, кулны күтәрсәң дә, очына җитәрлек түгел. Бармак калынлыгы булып үскән. Вәт киндер дисәң дә киндер. Исе китеп карап бара торгач ул, юлдан чыгып, аяк астында бүкән-бүкән аунап яткан кызыл кирпеч ватыкларына абынып егыла язды. Бетон белән берегеп каткан әллә ничәшәр кирпечне аерып ала алмаганлыктан, аларны шулай ташлап калдырганнар. Князь Оболенскийның биредә атлар йорты булган...

Нурмөхәммәтнең әле дә хәтерендә. Иңе-буе бишәр йөз метр тирәсендәге, биеклеге ике-өч метрлы кызыл кирпеч койма белән әйләндереп алынган галәмәт зур йорт иде. Койма тирәли әллә ничәшәр бүлектән торган конюшнялар. Идәннәре бетонланган, тирес, сыеклык агызу өчен каналлар ясалган. Шул сыеклыклар агып төшәр өчен читтә кечкенә күл казылган иде. Күле хәзер дә бар. Үрдәкләр быкырдап ята шунда. Нинди атлар йортын әрәм иттеләр бит! Тагын өч-дүрт ел гына торган булса да, Сабанчы колхозына мәңгелек атлар йорты булып кала иде. Баш булмау, хуҗасызлык бәласе инде бу. Алпавыт, князьләрне бетерәбез дигәч тә, шулай бар корылмаларны ишәргә идемени? Шулай буладыр инде. Беркемнеке дә булмагач, рус әйтмешли, ничейный була бит инде. Раз ничейный – хуҗасыз. Ватарга, җимерергә, һәркем үзенә нәрсә булса да әләктереп калырга ашыккан.

Революция корбансыз булмый, диләр. Бу завод та революция корбаны буламыни инде? Юк, болай дөрес түгел. Революция ясарга иде. Анысы кирәк булгандыр. Тик заводны, аның корылмаларын, биналарны, эш коралларын тартып алганнан соң, шул хуҗаларга биреп. Эшне контрольгә куярга булган. Ул вакытта бу завод та, гаҗәеп яхшы биналар да исән калыр иде. Карап торсаң, бу заводны князь мәңгелек булсын дип, җиде буынга калсын дип төзеткән.

Минем әтием бу заводны төзешкән бит. Түбәләр ябуда калайчы булып эшләгән. Шунда эшләгән эш хакы исәбенә безнең өйнең түбәсенә калайны шуннан алган. Өйнең түбәсендә әле дә шул калай утыра...



Князьнең йөз башлап биясе бар иде, дия иде әти. Шул бияләрне саудырып нишләгән, кымыз ясаткан, дип беләсезме? Тот сиңа, кымыз эчмичә тор әле. Бия сөте кушып, кирпеч измәсе әзерләткән Оболенский, шуңа аның кирпечләре дә тимер кебек. Кәйлә дә, лом да алмый, дия иде.

Шул уңайдан сезгә Нурмөхәммәт белми торган бер вакыйганы язып китим әле: кайсы елдадыр, анысын төгәл хәтерләмим, Түбән Әлки МТС директоры Камил Хөснетдинов шул завод морҗасын сүтеп алып, оешмасы кирәгенә файдалану турында хыяллана. Кырык-илле метрлы морҗаның очына менеп сүтү – хәтәр эш. Аннан сүтеп алган кирпечне дә төшерү мәшәкате бар. Камил бер бригада оештыра да, ике машина, ике «НАТИ» тракторы һәм бик озын трос табып, морҗаны аударып сүтәргә килә. Планы яхшы: җиргә тартып аударабыз да рәхәтләнеп сүтеп ташыйбыз. Килеп төшәләр дә, озын тросның бер очын морҗаның түбәсенә бәйләп, «НАТИ»ларга тагып, тарттыра башлыйлар. Ике трактор, иләмсез үкереп, кузгалып китә. Трос скрипканың нечкә кылы шикелле зеңгелдәп тартыла. Директор тракторчыларга кычкыра:

– Ава башласа, тракторыгызны тизрәк алып китегез!

Янәсе, морҗа авып, кирпечләре өстегезгә очмасын. Яңадан команда бирә:

– Поехали!

Тракторлар, иләмсез үкереп, кара төтен чыгарып кузгалалар. Ике-өч метр көчкә-көчкә генә үрмәлиләр дә, тал чыбыгы кебек бөгелеп килгән морҗа тракторларны, җире-ние белән сыдырып, кире элеккеге урыннарына тартып китерә. Директор тагын команда бирә:

– Алга!

Тракторлар үкерә-үкерә тагын алга тырмаша башлый. Морҗа тагын бөгелеп килә дә, бер урында тырмашып үкергән тракторларны тагын кире тартып, элеккеге хәленә кайта. Тегеләр берничә сәгать азапланалар да, бер эш чыгара алмыйча, кире китеп баралар. Бәлки, аударган да булырлар иде, тагын берничә трактор булса. Тик авыл картлары, аударып кына китәсез сез моннан, бер генә бөтен кирпеч ала алмаячаксыз, дип кисәткәч, ташларга булалар. Менә нинди була икән ул бия сөте кушып яндырылган кирпеч.

Шуннан бирле морҗага кул күтәрүче юк.

– Кешеләр, аңлы булыгыз, вату-җимерү муллык та, рәхәт тормыш та китерми! – дип кисәткән сыман, яраксызга калган морҗа, хуҗасызлыкка тарихи истәлек булып, һаман авыл өстеннән калкып тора.

Нурмөхәммәт киндер җирен әйләнеп үтте дә аны янәшә диярлек салынган бура янына килеп чыкты. Авыл үсә. Уң яктагысын үткән ел ук умартачы Габдулла абзый сала башлаган иде. Бу түбәсе дә япмаган бура кемнеке икән? Яңа күтәргәннәр, ахрысы. Әнә бит мүкләре да кәҗә сакалы шикелле салынып тора...

Ул берничә йортны узып, сул якта Кечкенә Хафиз өе каршысындагы кое турысына килеп җитте. Кое тирәсендә дә кеше юк. Ул өйгә карый-карый үтте. Бу өйдә алар, ничә мәртәбә аулак өй ясап, кызлар пешергән бәлешләр белән сыйланып, кич утырганнар иде. «Йөзек салыш», «Сукыр тәкә», тагын әллә нинди уеннар уйнап, җырлап-биеп үткәргәннәре булды. Кечкенә Хафиз – бик оста мич чыгаручы, йозак төзәтүче, ачкыч ясаучы. Тирә-як авылларга бер чыгып китсә, атналап кайтмый. Хатыны, кызлар ит, май, сөт, он китерсәләр, көн дә аулак өй ясарга риза. Нурмөхәммәт беренче мәртәбә шунда «Сукыр тәкә» уйнаганда, почмакка кысып, «ялгыш» кына Сәлимәне кочаклап алган иде. Аларның бер-берсенә тартылулары шуннан башланды бугай. Тагын ике йорт үтүгә, уң якта – Сәлимәләр йорты. Нурмөхәммәтнең аяклары ашыгамы, йөрәгеме – күзләр шул якка күчте. Җил капка аша йорт эче, бөтен нәрсә күренеп тора. Урам тәрәзәләрендә ак пәрдә корылган. Нишләп көпә-көндез корып куйдылар икән? Йортта да берәү дә юк. Бары тик тавыклар гына кыр-кырр килеп йөриләр. Сәлимә кайда булыр? Нигә ул тәрәзәләрен корып куйган? Менә кайдандыр килеп чыккан чуар әтәч капка киртәсенә очып менде дә, шапшап канатларын кагып, кычкыра башлады: «Кик-кри-кү-үк!» дип миңа кычкырасыңмы әллә? Кайттыңмы, диюеме? Әллә башка берәр хәбәр бирүеңме? Юк ла, нәрсә әле мин әтәч кычкырганга да юрап кайтам. Әтәч, әтәч инде ул... Әнә үзебезнең тыкрык, биек өянкеләр, сиреньнәр. Әллә өянкеләр тагын да җәелә төшкәннәр? Элек өч тәрәзә дә күренеп тора иде. Хәзер икесе генә. Әни бүген дә тәрәзәдән карап торамы икән? Үткән ел тәрәзәдән күреп, капка төбенә үк чыгып каршы алган иде. Бүген күренми. Әллә өйдә дә юкмы? Кече сеңелкәш Зәйнәп булса да өйдәдер әле. Кечкенә капканың келәсе төшми башлаганмы әллә? Кул тиюгә, ачылып китте. Капканы ябып эчкә керергә өлгермәде, өйдән Зәйнәп атылып чыкты:

– Абый кайтты! Абый кайтты! – Ул йөгереп килгән уңайга абыйсының муенына асылынды.

– Улым, бәгърем, кайттыңмы?

– Кайттым, әни, кайттым. Исән генә тордыгызмы?



– Аллага шөкер, улым. Әйдә өйгә керик але. Бик мактап йөрисең үзең. Әле чәйгә утырырга әзерләнә генә идек.

– Абый, бир сумкаңны, – дип, Зәйнәп, абыйсының сумкасын алып, өйгә алданрак кереп китте.

– Әйдә, улым, керик. Зәйнәп тәрәзәдән сине күреп алып, абый кайтты дигәч, ясый торган чәйләремне калдырып чыктым.

Өйгә керделәр. Фәридә апа, кашык-савыт алып, улына эндәште:

– Бар, улым, чыгып юынып кер дә, чәйгә утырырбыз. Мин базга гына төшеп менәм.

Нурмөхәммәт алып кайткан конфет-прәннекләрен алып куйды да, сөлге алып, юынырга чыгып китте. Ул юынып кергәндә Фәридә апа баздан каймаклы катык алып чыгып өстәлгә куйган иде.

Нурмөхәммәтне өстәл артына утыртып, Фәридә апа, каймак салып, чәй ясады.

– Улым, син кайтасыны сизенгән кебек, мич ашлары пешереп куйган идем, – дип, егет алдына бөккәннәр, җәймәләр куйды. Баздан алып чыккан каймаклы катыкны этәрде.

– Юлдан көеп кайткансың, көн бик эссе, менә, салкын катык капкала, улым.

– Ярар, әни, алдымда бит, – дип, Нурмөхәммәт чынаяктагы чәйне бүлеп чәй эчәргә керәште.

– Ничек соң, улым, бетереп кайттыңмы инде?

– Бетереп кайттым, әни. Экзаменнар биреп бетергәч, документлар, стипендия акчалары алганчы, тагын ике атна үтеп китте...

– Кая җибәрделәр соң, улым, еракка түгелдер бит?

– Үзебезнең районга җибәрделәр, әни. Менә бер ай ял итәм дә районга эшкә китәм. Кайтуынча ук райбашкармага кереп чыктым. Документларны күргәч, райбашкарма председателе Орлова дигән хатын бик шатланып каршы алды. Культура бүлегенә җитәкче кирәк, беренче августтан шул эшне кабул итәрсең, ди. Авылда нинди хәбәрләр бар соң, әни?

Фәридә апа улына каймак салып чәй агызды да дәвам итте:

– Авылдамы, улым? Чәчүләрне яхшы гына башкарып чыктылар. Чәчү бетү белән, бөтен авыл тегермән буасын буарга керәште. Ташу бик көчле булган иде. Буаның яртысыннан артыгын алып киткән. Бер диләнкә урман алып ташыдылар. Халык, төшкә дә кайтмыйча, кунып-төнеп шунда эшләделәр. Ашханә дә шунда булды....

– Күрдем, әни, күрдем, бик киң итеп буганнар. Инде суы да кавызга җитеп килә.

– Аннан, мин сиңа яздым микән? Председательне алыштырдылар. Илдар абзаң кыш көне туйдан кайтканда, адашып, Чаллы чокырына барып төшкән, шунда кулларын туңдырган иде. Бармаклары төште. Председательгә Сәлах Габделхагын куйдылар. Әле яхшы гына эшләп йөри. Районга барып, урак машинасы, печән чаба торган, аннан тагын печән җыйдырта торган ат тырмасы да алып кайткан. Әле тагын сугу машинасының да зурысын алабыз, ди икән. Галимә апаңның Хаҗибе Бибайдан өйләнде. Аннан килеп, Бәдретдин абзаңның олы малае летчик булырга укый икән. Онытып та җибәрә язганмын, кладовщиклыкка Төрек Ибраен куйдылар. Бригадир булып Кәрим Фәрдиен билгеләделәр.

Әнисе сөйләгәннәр Нурмөхәммәтнең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыга барды. Әнисе яңа җөмлә башлаган саен, егет менә хәзер Сәлимә турында ни дә булса әйтә, дип көтсә дә, ни хикмәттер, әнисе Сәлимәнең абыйсы өйләнгәнне әйтте, ә кыз турында ләм-мим. Әллә инде әнисе Сәлимәне яратмый башлаганмы? Үткән җәйне үк шул кызга өйләндерү ягында иде бит. Тукта әле, икенче яктан башлап карыйм:

– Габдулла ничек, әни, өйләнмәгәндер бит?

– Ул турыда мин сиңа язмадыммыни? Ул үткән көз үк өйләнде бит. Нәриманнан алып кайтты, – диде Фәридә апа, улының чынаягына сузылып. – Бир әле, улым, юлдан көеп кайткансың, тагын ясыйм.

– Җитте, әни, булды.

Нурмөхәммәт чынаягын эчкәрәк этеп куйды да, урыныннан торып, тәрәзәгә карады.

Бала-чаганың көтү каршыларга йөгерешкәнен күреп, ул да өй алдына чыкты. Чишмә очында шарт-шорт көтүченең чыбыркы шартлаткан, сарыклар, кәҗәләр кычкырган тавышлар ишетелеп тора.

Нурмөхәммәт, чоланга кереп, тузан басып бетергән тальянын алып чыкты да, сөрткәләп алганнан соң, уйнап карады. Гармун бик нык кипкән иде. Ул аны, бераз дымлана торсын дип, тиз генә кар базына төшереп куйды. Аннары, келәткә кереп, самокатын алып чыкты. Аның тузаннарын, майларын сөртеп, камераларына һава өрдерде. Ул арада караңгы төшә башлаган иде.

– Әни, мин яшьләр янына чыгарга җыенам, – диде егет, сөт сөзеп торган әнисе янына кереп.

– Бар, улым, чык. Бер сүзем юк, – диде ана, малаена бер карап алгач. – Җылы сөт эчеп җибәр, улым. Син бит җылы сөт ярата идең.

– Бир, әни, мин сөткә бер дә каршы түгел.



* * *

Гармунын култык астына кыстырып капка төбенә чыккач, Нурмөхәммәт, як-ягына каранып, урамны күзәтте. Урам тынып калган. Кичке эңгер-меңгер эчендә Чирмешән болынындагы күлләрдән бакалар сайрашканы ишетелеп тора. Чишмә тавы ягында этләр өрә. Егет урам буйлап китеп барды да Сәлимәләргә җитәрәк, тальянын алып, тартып җибәрде. «Минем кайтканны Сәлимә ишетеп, белеп калсын әле», – дип уйлады егет. Унике телле, биш планкалы «вараксин»ның көчле тавышы тын урамнар аша таралып, ачык тәрәзәләрдән өйләргә керде. Тәрәзә пыялаларына кагылып, Чирмешән болыннары аша күрше авылларга җитте. Сәлимәләр турысында егетнең күзләре йорт тәрәзәләрендә булса, куллары, бармаклары гармун тартты, гармун сайратты.

Тик, ни хикмәттер, тәрәзәдә берәү дә күренмәде. «Әллә Сәлимә өйдә юкмы? Әллә ул бакчада яшьләр янында Нурмөхәммәтне көтәме?» Егет, гармун уйнавыннан туктамыйча, адымнарын тизләтте. «Андадыр, бакчададыр, мин соңгарак калганмындыр», – дигән уйлар белән бакчага барып керде.

– Исәнме, исән кайттыңмы? – дип, аны яшьтәше Нияз каршы алды. Бакчада күпчелек алардан ике-өч яшькә кечерәк кызлар-егетләр җыелган. Күрешкәндә Нурмөхәммәтнең күзләренә шул чалынды. Күзләре белән Сәлимәне эзләде. Ул биредә дә юк иде. Сөйләшеп, тәмәке тартып торганда да, уеннар башлангач та, Сәлимә килмәде. Кызларны-егетләрне җырлатып, әйлән-бәйлән уйнаганда да, «Өченче артык», «Куып тотыш» уйнаганда да, кыз килмәде. Уеннар уйнап, бераз гармунга җырлатып-биетеп алганнан соң, Нурмөхәммәт, гармунын култык астына кыстырды да, яшьлек дусты Ниязны ияртеп, бакчаның аулак почмагына китеп барды.

Нурмөхәммәт җиденче классны Нияз белән бергә бетергән иде. Алар өч дус иделәр: Сәлим, Нияз, Нурмөхәммәт. Сәлим җидене бетерү белән, курска барып укыды да колхозда хисапчы ярдәмчесе булып эшли башлады. Өйләнде. Хатыны шундый булдымы, үзеннәнме – өйләнгәч, ул яшьләр янына чыкмый башлады. Нияз, җидене бетергәч, авырып, укый алмады. Аннары, икенче елны икмәк булмау сәбәпле, Ташкент ягына китеп бер кыш үткәргәннән соң, Сәлимә белән бер класста укый башлады.

Бакчаның ерак почмагындагы чиялек эчендәге ачыклыкка кереп чирәмгә утыргач, Нурмөхәммәт сүз башлады:

– Нинди планнар белән яшисең, Нияз, унынчыны ничек бетердең?

– Өчлеләрем чыкмады, – диде егет, дусты янына чирәм өстенә сузылып. – Көзгә агрономнар курсына китәргә исәп. Анда кадәр, бәлки, өйләнеп тә өлгерермен. Әнинең ялгыз каласы килми. Курска киткәнче өйләнеп кит дип, әни дә борчыла. Бер ялгызына тормыш алып баруы авырдыр инде, аны да гаепләп булмый. Солдатка алсалар, үзең кайтканчы тупырчык малаең булыр, миңа да күңелле булыр, ди.

– Фәния нәрсә ди соң, ризамы?

– Ул җилкуар булып чыкты бит, малай, аның белән ботка пешмәде минем, атна саен күрше авылга йөри башлагач, күңел сизде.

– Кемгә өйләнергә исәплисең соң?

– Үзем белән бергә укыган Әшнәк кызы Нурания белән йөрибез. Ярлы гаиләдә үскән, эшчән кыз. Көзгә бергә булырбыз, дип вәгъдәләштек. Фәния ул Сәлимә белән кыш буе керәшен егетләре янына йөрде...

– Сәлимә дигәннән, кайда ул, кызлар янында күренмәдеме? – диде Нурмөхәммәт, исеме чykканда сорашып калырга ашыгып.

– Сәлимә тиз генә күренмәс инде ул, Нурми дус. Аның көмәне бар, диләр.

– Ничек көмәне бар? Кемнән? – Нурмөхәммәтнең битенә кызыллык бәреп чыкты. Бөтен тәне буйлап салкын кырмыскалар йөгереп үтте дә, кинәт ут кебек кызыша башлады.

– Син, Нурми, аның белән хат алышмадыңмыни? Мин аңарга бервакыт: «Баранда кунып-төнеп йөрүләреңне Нурмөхәммәткә язам», – дигән идем, ул: «Куркытма, куркытма, Нурмөхәммәт белә ул турыда», – дип китеп барган иде.

– Көздән бер хатын алган идем, шуннан минем хатларга җавап язмады. Вәгъдәләшкән идек, шул булган икән вәгъдәсе...

Егетнең тавышы калтыранып, өзелеп калды. Аңа дусты каршында оят иде. Ярый әле төн караңгы, битләремнең уттай янганын күрми, дип уйлады ул. Тынлыкны Нияз бозды.

– Дус кызы Розаларга кунакка баргач, ул анда клуб мөдире Никифор белән таныша. Шуннан китте инде, дәрестән соң да, ял көннәрендә дә гел шунда чапты. Кайвакытта тегесе мәктәпкә килеп алып та китә иде. «Майда туй ясыйбыз», – дип, Сәлимәне алдаган Никифор. Эшләре бер генә булмаган, ахры. Чөнки апрельдә дәрестән соң һәркөнне диярлек урманга чыкканнарын күрә идем. Тегесе башта, майда туй итәбез, дип алдап йөрткән. Хәзер инде авыры булгач, күргәнем дә юк, мин болай сөйләшеп кенә йөрдем, Сабанчы егетләреннәндер аның авыры, дип әйтә, ди. Никифор янынннан соңгы вакытта Сәлимәнең берничә мәртәбә елап кайтканын күрделәр. Менә шулай, Нурми дус... Җете кызыл тиз уңа, диләр. Сәлимә синең белән вакыт үткәрер өчен генә йөргәнме икән? Җәйне тик үткәрмичә, егет куенында буласы килеп кенә синең белән йөргәндер әле.

Эх, Сәлимә, Сәлимә... Сине генә яратам, синсез мин шашармын, дип озатып калулары шул булдымы? Никифорның төче теленә ышанып, вәгъдәләреңә хыянәт итеп, үзеңне харап иттеңме, дип кычкырасы килде Нурмөхәммәтнең. Тик кычкыра алмады. Бугазына килеп терәлгән төергә төелеп, эх дип, туктап калды.

– Кызлар шулай алар, чын күңелдән яратып йөргәннәрнең кадерен белмиләр. Әз генә күзләреннән китеп тордыңмы, төче телле җилкуарларга сатылалар. Фәния дә шунда йөрде. Шуннан күңелем бизде минем аңардан. Күрәсем дә килми шундый тотнаксыз, җилбәзәк кызларны.

– Бәлки, кеше сүзе генәдер? – диде Нурмөхәммәт, бу авыр хәбәргә ышанасы килмичә.

– Кеше сүзе булырга? Бер класста укып шуны күрмәскә, сукыр түгел лә! Бу арада гына Сәлимәнең әнисе Никифорларга барып үзе сөйләшкән. Тегесе йортына да кертмәгән. Капка төбеннән генә:

– Күргәнем дә юк кызыңны. Әллә кемнәрдән булган авырын миңа такмакчы буласыңмы? Барып чыкмас! – дигән дә урам буйлап китеп барган.

– Хурлыгы ни тора, кеше көлкесе, – диде Нурмөхәммәт, авыр сулап. – Мин, җүләр, вәгъдәләшкән кызым дип, хатлар язып яттым.

– Ярар, кайгырма! Төкер син андыйларга. Ярый әле Ходай үзе аралаган аны синнән. Өйләнгән булсаң да, синең җаныңны тындырмаган булыр иде, – диде Нияз, дустының бу хәбәрне авыр кичерүен күреп. – Аннан тагын шуны да әйтим әле: бу арада Сәлимәнең әнисе Галимә апа сезгә бик еш килеп йөри икән. Аң булып тор. Никифордан булган баланы сиңа тагарга йөриме икән ул хатын? Әниең: «Нурмөхәммәт кайтсын гына, кайтуга өйләндерәм. Киткәндә үзе дә шулай ышандырып китте», – дип әйтә икән. Син әллә үткән ел әниеңә ышандырып киткән идеңме?

– Әйе, әни белән шундый сөйләшү булган иде. Өйләнеп кит, улым, миңа иптәш булыр, үзеңнең дә җаның тыныч булыр, дигән иде. Мин укуны бетерим, әни, Сәлимәнең дә унны бетерәсе бар, дигән идем.

– Ярар, үзеңә кара, – диде Нияз, дустының Сәлимәгә шул килеш тә өйләнергә исәбе бар дип уйлап. – Мәшәкатьләнәсе калмаган, авыры белән киләчәк...

– Син нәрсә, Нияз? – диде Нурмөхәммәт, кызарып чыгып. – Башыма тай типмәгән бит минем. Болай да хурлыгыннан авылдан чыгып качарлык.

– Хурлыгы Сәлимәгә аның, Нурми дус, сиңа түгел.

– Вәгъдәләшкән кызың шулай булса, син хурланмас идеңме, Нияз?

– Ярар, борчылма, Сәлимә борчылсын. Син оныт аны. Бәлки, әле ул синең бәхетеңә каршы булгандыр...

Нияз, алмагачның алмасы агачыннан ерак төшми, Сәлимәнең әнисе дә ире өстеннән йөреп бала тапкан, дияргә уйлаган иде дә, үзебез күрмәгәч, гайбәт сатмыйк дип, әйтмәс булды.

Чирмешән буендагы сукмакка чыгып, кайту ягына борылдылар. Мөлдерәп тулган Чирмешән елгасы өсте сыек ай яктысында күзгә кебек ялтырый. Шул тигезлекне бозып, анда-санда балык чиртеп тора.

– Тартып җибәр әле гармуныңны! – диде Нияз, янәшә атлап.

Бакчадагы сиреньнәрне, судагы балыкларны сискәндереп, тирә-якка тальян моңы таралды да, кинәт башланган моң, урамга чыгу белән, кинәт тукталып та калды.

– Әйдә, уйна әле!

– Ярты төн узгач, тавышланып йөрү килешмәс, – дип, Нурмөхәммәт гармунының каешларын каптырып аркасына асты.

– Хәерле төн! – Нияз үз якларына борылды.

– Тыныч йокы!

Төнге тынлыкны бозып, әле анда, әле монда әтәчләр кычкыра башлады. Нурмөхәммәтнең зиһенен Сәлимә турындагы уйлар бораулады: әнә ни өчен ул минем хатларыма җавап бирмәгән. Мин, җүләр, үземнеке буласы дип, ялгышып куймыйм дип, кагылырга да тартынып йөрдем... Сәлимә, әнә, сүз куешкан дип тормаган... Күрәсе иде үзен, ни дияр икән? Ялган, мин сине көттем, сине генә сөям, диярме? Әллә күзгә дә күренмәскә тырышырмы? Кеше күзенә күренерлеге калмаганлыгын белеп, шуның өчен кызлар янына чыкмыймы? Шулайдыр әле... Югыйсә кызлар янына, бакчага чыкмыйча кала торганнардан түгел иде...

Болытлар арасыннан караган ай нурында колхоз кәнсәләре тамбурында йортларына кайтмый калган кәҗәләр күренде. Кибет алдында да берничә баш сарык тонык лампа яктысында өелешеп яткан. Каенлык ягыннан, сыек томан белән бергә, салкынча саф һава җиле килеп бәрелде. Чишмә очында кайсыныңдыр эте үрсәләнеп өрде.

Кечкенә рәшәткә капканы ачып, келәсен шалтыратмый гына ишеккә таба килә башлаган иде, юл өстенә яткан казлар, борчып йөрмәсәң ярамаганмы, дигәндәй каңгылдашып алды. Ата каз, ысылдап, муенын сузды. Нурмөхәммәт ишеккә килде. Ишек бикләмәгән иде. Аяк очы белән генә басып үтим дигән иде, әнисе:



– Улым, синме? Кайттыңмы? Тамагың ачкан булса, өстәлгә сөт куйдым, шуны эчеп ят, – диде.

Бу әни нишләп йокламый икән, дип уйласа да, Нурмөхәммәт бер сүз дә дәшмичә гармунын өстәлгә куйды да, чоланга чыгып, чишенеп кереп ятты.

Нурмөхәммәт урынга яткач та, бик озак уйланды. Ни өчендер ул Сәлимәне кызганмады. Күтәрә алмаслык хыянәт дип, Сәлимәнең сиздерми генә авыры белән үзенә килеп сыланырга йөрүен ишеткәч, мәкерле кызга карата егетнең күңелендә бары тик нәфрәт хисләре генә дөрли башлады.

Иртә белән Нурмөхәммәт әнисенең кем беләндер әкрен генә мөлдер-мөлдер сөйләшкәнен ишетеп уянып китте. Чоланнан чыгып, ишек ярыгыннан күз салган иде, Галимә апаның капкага таба китеп барганын күреп калды. Нишләп йөри икән бу Галимә апа? Нәрсә турында сөйләштеләр икән? Әллә Сәлимә турында авылга таралган сүз ялган дип, кызын аклап йөриме икән? Ярар, чәй янында әнидән сорармын әле дип уйлады егет. Бәлки, үзе үк әйтер.

Ул майкасын салып юынырга җыенды. Кояш ярыйсы биек күтәрелгән иде. Өй ишеген ачып җибәргән иде, аннан борын тишекләрен кытыклап тәмле таба исе килеп бәрелде.

– Тордыңмы, улым? Юынып кер дә, чәйгә утырырбыз, – диде әнисе, – мичемне уздырып куйдым инде.

– Ярар, әни, мин хәзер, – дип, Нурмөхәммәт юынырга чыгып китте.

Ул кергәндә өстәлдә гөжләп кайнап торган самовар янында әнисе чәйләр агызып тора иде. Табага өеп куйган кайнар коймак авызга сулар китерде.

– Кил, улым, утыр, чәйләп алыйк та, мин сиңа эш кушармын, – диде Фәридә апа, Нурмөхәммәткә чәй ясап куйганнан соң. – Түбән бакчаның читәне ауган, шуны торгызып рәтләрсең әле, улым. Иртә-кич казлар кереп аптыраталар.

– Ярар, әни, тагын нинди эшләр бар? Миңа барын да сөйләп куй. Аннары мин үз тәртибем белән эшләрмен.

Нурмөхәммәт чынаякны алдына тартып куйды да, аны бүлеп тормастан, табадагы коймакка үрелде.

– Тагын дип, печән бүлгәнче утын әзерләп кала алсаң, бик тә әйбәт булыр иде, улым. Печән бүлсәләр, печәне дә кирәк бит аның. Кешеләр әнә каенлыктан каен төпчекләре кубарып җыялар. Үзе коры, кипкән, ташырга да якын...

– Шул гынамы, әни? Эшлибез аны, утынлы да, печәнле дә итмичә китмим әле мин эшкә. Аннан, эшли башлагач, районнан ял көннәрендә кайтып булышырмын. Биләр ерак түгел.

Нурмөхәммәт, кызу мичтә кетердәп торган, алланып пешкән кайнар коймакларны берсе артыннан икенчесен озатып ашаса да, әнисе Галимә апаның ни өчен килүен үзе әйтмәсме дип көтте. Аннары үзе сорарга булды:

– Әни, кем килгән иде безгә? – диде ул, үзе кем килгәнен белсә дә.

– Бүгенме, улым? Галимә апаң кереп чыкты. Хәл белергә дип кагылган. Сине сорашты, исән-сау кайтканмы, ди.

– Шул гынамы?

– Шул гына дип, ахры, сине дә күрергә исәбе бар иде дә, мин сине әле тормады, дидем. Хәзер чәй эчәбез дип чакырган идем дә, мичтә ипием бар дип, китеп барды.

Фәридә апа, почмакка барып, мич алдындагы табадан тагын бер дистәләгән әчегә изгән коймак алып килде.

– Менә, улым, болары әчегә изгән коймаклар. Бәлки, болары суынгандыр, боларын аша! – дип, малае алдына куйды. Чынаякларга чәй агызды. Шуннан соң тагын сүз башлады:

– Иртәгә бер ярканы алып калырмын әле, улым. Үзең суярсыңмы, әллә Галимулланы чакырыргамы?

– Ярка суярга өлгерербез әле, әни, – диде Нурмөхәммәт, әнисенең уйларын белмәстән.

– Ярар алайса, улым, кирәге чыкса, тавыкларым бар... Тавык суеп, тавык шулпасы ясармын... Кара әле, улым, былтыр укуны бетергәч, башлы-күзле булам, дигән идең. Үзең бер айдан районга китәм дисең, әллә алып кайтасыңмы, диюем?

Нурмөхәммәтнең ачуы килгәне йөзенә чыкты:

– Ничек инде, әни, кичә кайттым, бүген өйләним дәме? – диде ул, аптырап калып.

– Анысын үзең карарсың, диюем, улым. Хет бүген алып кайт, хет иртәгә, мин каршы түгел. Ике куллап каршы алырмын. Сөйләшегез дә озакка сузмыйча кушылыгыз. Аннары сиңа эшеңә китәргә вакыт килер. Бер сөйләшкән, сүз куешкан булгач, сузып торырга кирәкмәс диюем, улым.

Нурмөхәммәт, аптырап, әнисенә карап торды да, ак димәде, кара димәде, каршысындагы чынаякны алып, өреп-өреп чәй эчкән булды.



Ләкин Сәлимә турында белгәннәрен дә, аның белән ара өзек булуын да, гомерендә дә «приданлы» кызның янына бармаячагын да әйтергә ашыкмады. Сәлимәне алмыйм, үлсәм дә, дип әйтергә теләсә дә, әйтмәде, тыелды. Хәзер әйтәм икән, әни бүген үк Галимә апага җиткерәчәк. Берәр атна белмичә торсыннар әле, өмет итеп йөрсеннәр, дип уйлады егет. Бу аның үзенә күрә Сәлимәдән үч алуы иде.

Егет, кичкә кадәр каенлыкта утын әзерләп, арып кайтты да чәйдән соң яшьләр янына чыгарга әзерләнде. Чиста күлмәк, яңа чалбар алып киде. Базга төшеп гармунын алды да урамга чыгарга әзерләнгән иде, әнисе:

– Улым, Нурмөхәммәт, мин сезгә урынны келәткә җәярмен, – дип, егетне тагын бер кат аптыраштa калдырды. Егет бу юлы да бер сүз дәшмәде. Ишектән чыкканда гына борылып:

– Ярар, әни, – дип китеп барды, капкадан чыгып урам буена ерак китеп барырга өлгермәде, каршы яктан Мәрьям җиңгәсе кул изәп үзе янына чакырды:

– Кичке уенга чыгуыңмы, Нурмөхәммәт?

– Шулай дип чыгу, апа.

– Бер сүзем бар иде, – диде хатын, башка кеше ишетмәсен дигәндәй як-ягына карап.

Егет каршысына салмак кына атлап килеп баскач, сүз башлады.

– Син беләсеңме, бу көннәрдә Галимә апа сезгә бик еш йөри башлады. Нишләп йөри, дисәм, кызын көмәне белән сиңа тапшырырга ашыктырып йөри икән. Төштән соң иләк сорарга дип сезгә керә идем, Галимә апа белән әниең сөйләшеп торалар. Ишек төбендә, кермичә, тыңлап тордым. Галимә апа әйтә: «Нурмөхәммәт Сәлимә белән сүз куешкан булган, үзе сиңа әйтергә ояла икән. Тот та өйләндер малаеңны, без риза, каршы түгел, печәнгә кадәр бергә булсыннар», – дип сөйләгәнен ишетеп тордым. Әниең: «Мин аңа үткән җәй үк өйлән, дидем, укуны бетергәч өйләнәм, дигән иде. Ярар, бүген үк мин аның исенә төшерермен», – дип ышандырды. «Шулай ит, шулай ит, – ди тегесе. – Сузарга ярамый, йә тагын киләсе елга дип башларлар», – дигәнен үз колакларым белән тыңлап тордым. Мин кергәч, икесе дә тынып калдылар.

Бу хәбәр егетнең тагын да җен ачуларын чыгарды. Муен тамырларына кадәр кабарып чыкты. «Баран егетләре белән типтереп авырлы булган да, шул көмәнен миңа китереп сыламакчы булалармы. Әйтәм, әни кич чыкканда, мин сезгә урынны келәткә җәеп куям, дип калды. Эх, әни, әни, авылда торып, шул хәлләрне белмисең, күрмәсең, дип уйланды

егет. Галимә апаның, кеше-кара күргәнче, кара көчек өргәнче дип, кызын көмәне белән малаеңа тапшырырга ашыктырып йөрүен уеңа да китермисең, күрәмсең... Ярар, мин дә кызык итәм әле аларны. Ышанып йөрсеннәр әле миңа әниле-кызлы. Мин үз юлымда булыйм».

– Сәлимә белән араларыгыз ничек соң? – диде хатын, тынлыкны бозып.

– Берничек тә түгел, апа, тыныч бул. Мин барысын да беләм, – дип, егет гармунын кулына алды.

– Ярар, энем, гаепләмә, белеп тор дип әйтүем генә.

– Рәхмәт, апа.

Нурмөхәммәт ашыгып китеп барды. Берничә адым атлау белән, бөтен тирә-якка тальян моңын җәелдереп, «Урам көен» уйнап, Сәлимәләр турысына җиткәндә җыр башлады:

*Алмалары-хөрмәләре кызарып пешәр әле,*
*Бүген исеңә төшмәсә, иртәгә төшәр әле...*

Җырны җырлап бетергәннән соң, күзләренең чите белән генә Сәлимәләр өй артына караган иде, кызның култык астына төен кыстырып басып торганын күрде. Күрде дә, белмәгәнгә салышып, гармунын тарта төшеп уйный башлады. «Әһә, көтәсеңме? Минем белән сөйләштеңме соң, Сәлимә? Кара син аларны, миннән башка хәл итеп куйганнар түгелме соң? Эх, Сәлимә, Сәлимә, эшләр шулайга калдымыни инде? Җиде хатыма җавап бирмичә, Баран буенда типтереп йөргәндә уйларга иде ул турыда. Әллә шулай үтәр, дип уйладыңмы? Никифордан булачак баланы мыштым гына миңа сыларга булдыңмы? Сыламый гына тор әле. Мин лучше детдомнан алам. Аның исеме уйнаштан туган булмый ичмасам. Оят дигән, намус дигән нәрсә бөтенләй юк икән бит синдә, кызый. Мин сиңа ышанып йөрдем. Үз үлчәвеңдә үлчәргә ярамый икән һәр кешене. Мәхәббәт кешене сукырайта, диләр. Шулай булды инде бу. Мин аңа ышанып йөрим. Ә ул мыштым гына мине адәм рисваена калдырырга йөри икән... Шулай килермен дә, шуның белән эш бетәр, дип уйлыйсызмы икән? Әни булган кешесе дә, үзе уйнаштан бала табып иренә таккан кебек, кызын да шуңарга өйрәткән була инде. Ярый әле вакытында белеп алдым... Мондый тотнаксыз кызга өйләнсәм дә, өстемнән йөреп газап чиктерер иде. Ярар, мин дә сезне өйрәтим әле. Көн дә шулай төен тотып йөреп тор, мин белмәмешкә салынып йөргән итим».

Җиде көн шулай йөрде егет. Һәр көнне әнисенә ярар дигән булды. Һәр кичне, гармун уйнап, Сәлимәләр турысыннан Чирмешән буендагы бакчага узып китте. Алты көн Сәлимә, төен тотып, өй артында аны озатып калды...



Нурмөхәммәтнең әнисе көн саен иртән, көтүгә тору белән, келәтне барып карады. Сигезенче иртәдә Фәридә апа, торырга вакыт дип, улын уятырга килгәч түзмәде:

– Төртенеп кит инде, бүген дә алып кайтмаган, – дигән борчулы тавышын ишеткәннән соң гына Нурмөхәммәт, әни дә борчыла икән дип, барысын да сөйләп бирде.

– Әни, Сәлимә турында сиңа баштан ук әйтми йөрүем белән сине борчуым өчен гафу ит. Ләкин шуңа шатлан: уйнаштан туган кеше баласын караудан сине коткардым. Бер дә борчылма, озакламый киленең дә булыр. Үз оныкларыңны карарсың. Бәлки, әле яхшыгадыр бу хәлләр...

– Ярар, улым, ярар, – диде ана, улын тынычландырырга теләп. – Бер генә сүз дә әйтмим, улым. Үземнең дә соңга таба күңелем тартмый башлаган иде. Бу Галимә нишләп көн дә килеп ашыктырып йөри дип, шикләнә калган идем. Ул бит миңа бөтенләй башкача сөйләде. Тагын килсә, әйтермен инде үзенә. Башымны катырып йөрмәсен. Нурмөхәммәт, Сәлимә белән безнең аралар өзек, дип әйтә, диярмен. Хурлыксыз икәнен белә идем инде. Кызы да әнисенә охшар дип кем уйлаган. Инде, улым, нишләрсең икән? – диде ана борчылган кыяфәт белән. – Теге Чирмешән очы Габдулла Мәрьямы белән араларыгыз ничек? Бик инсафлы семья. Кыз да бик әдәпле...

– Кайгырма, әни, кызлар бетмәгән, Мәрьям булмаса, башкасы булыр. Әзерләгән утыннарымны алып кайтып бетерим дә, Шамил абзыйларга барып кайтырмын. Анда минем таныш, инсафлы кызларым бар...

– Кем кызлары икән соң алар, улым?

– Әкълимә апа торган Кәүсәр апаның Җәүһәриясе. Аннары үткән ел апада укыган бик инсафлы кыз белән танышкан идем...

– Шамил абзыеңның Камиле өйләнмәдеме икән, улым, ул Җәүһәриягә. Өченче ел Мәрфуга ахирәт шулай сөйләгән иде. Шамил абыеңнар бертуганнар кебек инде. Әтиеңнең бик якын дуслары. Башлап аларга төшәрсең.

– Ярар, әни, мин хәзер атка барам. Утыннарны китереп бетерә алсам, бүген үк кичке якта китеп барырмын.

* * *

...Нурмөхәммәт, авыл башындагы зират яныннан узып, түбәндәге яшелчә бакчасын әйләнеп үтте дә, тегермән буасы өстеннән Чирмешәнне чыгып, ак чиркәве күренеп торган рус авылына юл тотты. Аннан соң да

әле ун километрдан артык. Тегермән буасы өстеннән самоходыннан төшеп чыкты.

Аннан соң, сары балчык алган, кайчандыр кирпеч суккан тирән базларны үтеп, тигез юлга чыккач кына, самокатына менеп, күкрәккә җиткән арыш кыры эченнән бара торган юл белән элдертә башлады. Ике километр баргач, ул үргә табарак китте. Кояш түбәнгә төшеп барса да, әле ярыйсы эссе. Тигезсез юлдан педаль әйләндереп дырык-дырык бара торгач тирләп чыкты. Өстендәге костюмын салып, самокат артындагы сумкасына салды.

«Нишләп соң әле мин теге вакытта Хәятнең адресын алып калмадым. Үз адресымны да бирмәдем. Хат язып, хәбәрләшеп торган булсак, нинди әйбәт буласы иде бит. Әй бу татар акылы төштән соң булмаса... Бигрәк тә ошаган иде бит Хәят миңа. Матурлыгы, дисеңме, тыйнаклыгы, дисеңме... Бөтен яктан килгән. Саф күңелле изге җан икәне әллә кайдан күренеп тора иде. Хәят үзе дә миңа бик тутырып-тутырып карап алганы әле дә күз алдымда. Аерылышканда, мескенем ничек боегып калды. Ә мин шул изге җанга: «Сез миңа ошыйсыз, Хәят, хат язсам, җавап язарсызмы?» – дип, җылы сүз дә әйтә алмадым. Имеш, минем вәгъдәләшкән Сәлимәм бар, күңелне аздырмыйм. Менә шулай була ул. Сәлимә әнә, вәгъдә бирдем, дип тормаган...

Юк, Сәлимә шикелле булырга ярамый. Ул намуссызлык, җиңел күңеллелек. Кеше булган кеше, күбәләк шикелле, чәчәктән чәчәккә сикерергә тиеш түгел. Берне сайладыңмы, шуның белән мәңгегә бергә булырга кирәк. Әнә аккошлар ничек, бер-берсен иркәләшеп кенә торалар, ди. Э-эх, Сәлимә, мондый җилбәзәк күңелле булуыңны күреп бетерә алмадым шул. Шуның өстенә син әле оятсыз да булып чыктың. Оятың булса, ничек инде әллә кемнән алган авырыңны ике ел йөргән егетеңә сыларга җыенып, мәкерле уйлар белән йөрер идең?

Чү, нәрсә соң әле мин гел шул Сәлимә турында уйланам. Миннән бигрәк, ул үкенсен. Гомерлек үкенеч аның башына төшә. Уйнаштан бала тапкан исеме алса, хәзер кем аңа күз салсын да, күрә-белә торып, кем ышанып хатын итсен...

Хәят кайткан булса ярар иде. Барып төшүгә, Камил белән клубка чыгарга булыр. Кайтмаган булса, Хәятнең кайчан кайтасын белүчеләр бардыр. Кияүгә чыгып куймаган булса. Анда бит минем күргән-белгән кызлар бар. Әллә Ислам абзыйларга керергәме? Җәүһәрия өченче ел ук бик ачык булган иде. Кәүсәр апа да, килгәндә үзебезгә кер, дип тора. Юк, Камилләргә керим әле, аның белән клубка чыгарга да була, киңәшер өчен дә егет кеше».



Пар кыры аша үтә торган юлны аркылыга йөреп, сай гына кырдырып үткәннәр. Ярым сукаланган юлдан дырык-дырык килгән самокат өстендә килә торгач, Нурмөхәммәт авылга килеп җитте. Самокатыннан төшеп, кибеткә керде. Күчтәнәчкә бер такта чәй, прәннек, кәнфитләр алды. Аларны алып чыгып сумкасына салды да, бераз җилләнеп, тирләгәннәрен бастырганнан соң, костюмын киеп, түбән оч урамындагы таныш йортка юл тотты.

Капка төбенә җиткәч, самокатыннан төшеп, тирә-юньдәге тынлыкка игътибар итте. Өйдәләрме икән, дигән уй белән капка келәсен басып, әкрен генә эчкә үтеп, самокатын уң як койма буена терәп куя башлаган иде, болдыр өстендә Шамил карт күренде. Аның башында төсе киткән, ямьшәеп беткән фетр эшләпә. Кәҗә сакалы сыман сакал җибәргән. Карт, самокат янында кайнашкан егетне күрү белән, баскычтан ашыгып төшә башлады. Картның йөзе яктырып киткәндәй булды:

– Нурмөхәммәт, син түгелме соң бу?! Хуш киләсең, әйдә, әйдә, нишләп анда торасың? Исән-сау гына килеп җиттеңме? – дип, ике кулын алга сузып, егеткә таба күрешергә атлады. – Исәнме, энем, исән-сау гынамы?

– Әйбәт кенә әле, Шамил абзый. Үзегез исән-саулармы? Мәрфуга апа, Камил, ни эшләр бетереп ятасыз?

– Аллага шөкер әле, энем. Барыбыз да исән-имин. Әйдә, өйгә керик, анда җиләсрәк. Бу нәмәстән белән тирләп пешкәнсең. Әйдә, әйдә, өйгә керик.

Ишекне хуҗабикә ачты.

– Әйдә, кер, Нурмөхәммәт. Кем бар икән дип тәрәзәдән карасам, син икәнсең. Өйгә кер, түрдән уз, – дип, егетне ачык йөз белән каршы алды.

Боларга ни булган? Бервакытта да болай каршылаганнары юк иде дип, Нурмөхәммәт Шамил карт белән Мәрфуга апасының гадәттән тыш кунакчыл каршы алуларына шатланып куйды.

– Әйдә, түрдән уз. Сал өстеңне, тирләгәнсеңдер, – дип дәвам итте хуҗабикә. – Фәридә исән калдымы? Үзең күптән кайттыңмы?

– Әни исән-сау. Бик күп сәлам тапшырырга кушты, – диде егет, костюмын салып чөйгә элгәннән соң. – Үземнең кайтканыма да бер атнадан артып китте. Әнигә кышлык утын әзерләдем дә сезнең дә хәлләрне белеп китәргә булдым.

– Рәхмәт инде, энем Нурмөхәммәт. Бик рәхмәт, онытмыйча безне зурлап йөрүең өчен.

Карт белән карчык почмакка кереп киттеләр. Карт шунда борылып чыкты да:

– Мин монда гына чыгып керим әле. Син, энем, ял итеп тор, – дип чыгып китте. Мәрфуга карчык почмакта кайнашкан җиреннән Нурмөхәммәткә сораулар яудырды:

– Бетереп кайттыңмы, Нурмөхәммәт? Кайда эшләргә уйлыйсың? Башлы-күзле булмагансың бит әле? Нindирәк исәптә торасың? – дип тезде генә. Соңыннан, азмы-күпме җавап алганнан соң, үзе сөйли башлады:

– Өйләнергә иде сиңа, Нурмөхәммәт, тормыш корып җибәрергә. Яшең дә бик җиткән. Әниеңә дә берүзенә бик уңайсыздыр.

– Апа, менә шул күчтәнәчләрне кабул итеп ал әле, – диде Нурмөхәммәт. – Башка әйбер булмады инде, гаепләмәссез.

– Рәхмәт инде, Нурмөхәммәт, бик зур рәхмәт, – дип, хуҗабикә егет алып килгән күчтәнәчләрне шатланып кабул итте.

Ишектән Шамил абзый кайтып керде дә почмакка кереп китте. Аннан бер кечкенә акны өстәлгә китереп куйды. Хуҗабикә стаканнар китерде.

Чәйгә утырдылар.

– Монысы бер дә кирәкмәс иде инде, Шамил абзый. – диде егет, хуҗа шешәдәге акны стаканнарга бушата башлагач.

– Ни бит, энем, әз генә. Гаепләмәссең инде... Сөйләшеп утырырга яхшырак.

– Бөтенләй кирәкле әйбер түгел, Шамил абзый.

– Нәрсә, әллә ниме? Әйдә, тот. Синең исән-сау мәктәпне бетереп кайту хөрмәтенә булыр.

– Юк, Шамил абзый, кыстама. Үзең теләсәң нишлә, тик мине кыстама.

– Әйдә тот, бер дә тотмыйча килешми ул...

– Кара әле, син нәрсә дип яшь кешене ирексезлисең? Эчми икән, бик әйбәт. Шулай кирәк, эчмәсен. Үзең, карт тиле булгач та, кешене дә шулай итмәкче буласың. Эчмә, энем! Бик дөрес...

– Ярар алайса, баштан ук шулай диген. Моны бит болай калдырырга ярамый инде.

Ишектән Камил кайтып керде:

– Кунак бар икән, – диде ул, туры егеткә таба атлап. – Исән-сау килдеңме? – диде каралып беткән кулларына карап. – Болай күрешү килешми дә инде, ярар, гаепләмәссең.

Нурмөхәммәт, өстәл артыннан торып, аңа каршы атлады.

– Эштән кайттыңмы, Камил? Исәнме, саумы? – дип, Камилне кочаклап алды.



– Улым, бар юынып кил дә утыр. Кунак белән белән бергә чәйләрбез.

– Мин сукалый торган җир башыннан берәү самокат белән узып киткән иде. Ул син булгансың икән, Нурмөхәммәт.

– Әйе шул, мин идем, кайсы шулай юлны боздырып бетергән дип тиргәдем дә әле, – диде Нурмөхәммәт, көлеп. – Син икәнне белмәдем...

– Пар кыры бит, сукаламыйча калдырсаң, юл буенча чүп үләне үсәчәк, – диде Камил, почмакка керә торган аралыкта эш киемнәрен салып. – Йә, ничек соң, Нурмөхәммәт, укуларны бөтенләй тәмамлап кайттыңмы?

– Бетереп кайттым, Камил. Бер ай ял итәм дә, районга эшкә чакырдылар.

– Кем буласың инде син, энем, районда?

– Районда культура бүлеген җитәкләргә, диләр, Шамил абзый.

– Нәчәлник булгач, безнең авылга да килерсең әле, – диде Камил, – клубта эшләренең бер дә рәте юк. Октябрь, Май бәйрәмнәренә берәр нәрсә оештырган булалар да, шуның белән эшләре бетә. Библиотеканың да эше сәләмә. Ачкан көнне ача, ачмаса – юк. Кереп, гәзит-журнал карап чыгыйм дип барасың, анда йозак эленеп тора. Мин көндез ачам, дигән була. Көндез авыл халкы эштә була. Кем өчен ачадыр? Аның эш сәгатен икегә бүләргә кирәк. Дүрт сәгатен көндез, калганын кич ачсын.

– Дөрес әйтәсең, Камил. Аны иртәгә үк сөйләшергә булыр. Авыл советы, партоешма белән сөйләшербез дә...

Ишектән Фәүзия кайтып керде. Ул кунак белән исәнләшергә өлгермәде, әнисе, аңа каршы төшеп, тиз-тиз почмакка алып кереп китте. Бераздан алар икесе бергә түр якка чыктылар. Мәрфуга апа кызын үз урынына утыртты да: «Исәнләш абыең белән», – дип, аның артына басты. Фәүзиянең өстенә чуар чәчкәле күлмәк кигәнен, битләренә иннек-кершән сылаганын күреп, Нурмөхәммәт: «Бу апа кызын миңа күрсәтергә дип шулай буяп чыгаргандыр инде», – дигән уй белән тагын бер кызга карап алды. Кара инде, буяу белән уйнаган баламыни. Иннекне шулай сылыйлар, күрәмсең...

Хуҗабикәнең кызын шулай буяп чыгаруы, бала гына икән әле бу кыз, дигән тискәре уйлар гына уятты.

Чәйдән соң Камил кунак егетен үзе белән капка төбенә алып чыкты. Бераз гармун уйнап, сөйләшеп утырганнан соң, гармунсыз гына клубка юл тоттылар.

– Өйләнергә өлгермәдеңме? – дип сүз башлады Нурмөхәммәт.

– Көзгә, эшләр беткәч, дип торабыз.

– Кайдан, авылданмы?

– Юк, күрше авылдан. Призывка кадәр үк, тракторда эшләгәндә танышкан идек. Фәһимә исемле. Акыллы, тәртипле кыз. Эшкә дә батыр. Шул кыз белән сүз куешкан идек. Син ничек, нинди планда? – диде Камил, кунагына карап.

– Юк, өйләнмәдем әле. Шул исәп белән кайткан идем дә, – Нурмөхәммәт әйтимме икән, дип тукталып калды, – уңышсызлыкка очрадым әле, малай.

– Нәрсә, әллә киреләндеме? Теге, кем дигән идең әле?

– Сәлимәне әйтәсеңме? – диде Нурмөхәммәт, кызарып чыгып. – Юк, Камил, үземнең күңел бизде. Чит авыл егете белән чуалып, авырга калган. Хәзер үзебезнең авылдан өйләнмәскә булдым. Кызлары да юк, диярлек. Сездә күргән-белгән яшь кызлар бар иде, шуңа килдем.

– Кемнәр алар?

– Берсе Җәүһәрия, Әкълимә апа аларда торган иде. Хәзер унҗиде-унсигездә булырга тиеш.

– Чибәр, үткен кыз. Эшкә дә батыр, – диде Камил, кунагына карап. – Аның артыннан берәү йөри дә. Кыз үзе өнәми булырга охшый. Икенчесе кем?

– Садриева Хәят, монысы ниндирәк?

– Хәят? Беләм. Ул көздән Казанга киткән иде, кайттымы икән. Чибәр, акыллы, тыйнак кыз. Эшкә дә уңган, минемчә.

Алар мәчет бинасында урнашкан клубка килеп керделәр. Ишектән керүгә, зур өстәл өстендә берничә журнал, гәзит куелган. Шуның янында ук, икенче өстәлдә, шашка-домино уйнап утыралар. Аргы баштагы сәхнәдән алып ишек төбендәге өстәлләргә кадәр – бөтен залга эскәмияләр тезелгән. Сәхнәдә берничә кыз, ике егет басып тора. Репетиция бара. Нурмөхәммәтнең күзе сәхнә читенә баскан ак күлмәкле кызга төште. Кыз яны белән баскан. Залдагыларны күрми. Менә ак күлмәкле сылу, башын борып, залга карап алды. Нурмөхәммәткә шул җитә калды. Хәятне хәзер үк күрермен дип уена да китермәгән иде. Ак күлмәкле кыз Хәят иде. Нурмөхәммәт, янында Камил басып торганны да онытып, берничә эскәмия алга үтте дә, кыздан күзләрен алмый, сәхнәне күзәтә башлады.

Тәненә ятып торган җете ак күлмәк кигән, чак кына калкып торган күкрәкләре аша кара толымнарын алга салган сылу кыз нидер сөйли башлады.



– Таныйсыңмы? Хәят ул, – диде Камил, егетнең колагына үрелеп.

– Тс-с, – дип күрсәтте Нурмөхәммәт, бармагын иреннәренә куеп. – Хәят сөйли, тыңлыйк әле.

Нурмөхәммәт берничә адым алга узды да, бармагы белән изәп, Камилне янына чакырды. Кил, монда утыр дигәнне аңлап, Камил йомшак кына басып кунагы янына утырды.

– Нинди пьеса өйрәнәләр икән?

– Белмим шул, әллә барып сорап килимме? – диде Камил, урыныннан тора башлап.

– Бүлдереп йөрмә! – дип, Нурмөхәммәт аның җиңеннән тотты. – Тыныч кына карап утырыйк әле.

Егет кызның ягымлы тавышын ишетәсе килә иде. Ул, сәхнәдәге кыздан күзләрен алмыйча, дөньясын онытып тыңлады.

– Син алайса, Нурмөхәммәт, репетиция беткәнне көтеп утыр. Мин бераз журналлар карыйм да кайтып китәрмен. Иртәгә таңнан сменага барасы бар. Безгә урын ишегалдындагы чоланда булыр. Син үз вакытың белән кайтырсың, – дип, Камил өстәл янына күчте.

– Ярар, бар, минем өчен борчылма.

Егетнең бөтен игътибары сәхнәдәге ак күлмәкле кызга күчте.

Менә сәхнә артыннан кемдер кабаланып чыкты да, ашыгып килгән уңайга абынып киткән булып, мәтәлеп китте. Сәхнәдәгеләр көлешә башладылар. Хәят тә көлә. Аның тавышы Нурмөхәммәткә шундый килешле, шундый ягымлы тоелды. Әйтерсең лә, дистәләгән көмеш кыңгырау чыңлый.

Озак көтәргә туры килмәде. Сәхнәдәгеләр таралыша башлады. Хәят, сәхнәдән төшеп, ишеккә таба килә башлагач, Нурмөхәммәт торып басты. Кыз шунда ук аны күреп алды, шат елмайган хәлдә аңа якынлашты.

– Исәнмесез, Нурмөхәммәт абый, сез бит бу? – диде кыз, кояштай ялтырып. – Әйдә, күрешик.

Үткән көз беренче күрешүдә үк егетнең күңеленә якты нур сибеп калдырган газиз җан иясе аның алдында елмаеп басып тора.

– Исәнмесез, Хәят, – диде ул, кызның йомшак кайнар кулын кысып. – Тау белән тау гына очрашмый, диләр, менә тагын очраштык.

Ул кызга сокланып караган хәлдә, аның кулын озак кысып торды.

– Ничек килеп чыктыгыз, нинди җилләр ташлады, Нурмөхәммәт абый? – диде кыз, кыйгач кашлары астыннан сихри нур бөркеп торган шомырт кара күзләре белән сөйкемле карап.

– Килдем менә, – диде егет, Шамил абзыйларга, дип тә өстисе иде, тик: – Сезнең хәлләрне белергә, – диде. – Нишләп торасыз, Хәят, күптән кайттыгызмы? Репетиция ясап ятасыз, ахры?

– Әйе шул, кичә клубка кергән идем, шунда ук эләктереп алдылар үземне. Кайтканыма ике генә атна әле.

– Әйдәгез, урамга чыгабыз, – дип, егет ишеккә таба борылды.

– Әйдәгез. Кемнәрдә туктадыгыз, Нурмөхәммәт абый?

– Шамил абзыйларга килдем. Мин теге вакытта сөйләмәдемме сезгә? Алар безнең бик якын дуслар.

– Кайсы Шамил икән? Безнең авылда өч Шамил.

– Кайсы дип, фамилияләрен хәтерләмим. Гармунчы карт. Малае Камил. Хатыны Мәрфуга.

– Ә-ә, беләм, алар безнең арттагы урамда торалар. Шамил абзый балта остасы.

Куян койрыгыдай кыска җәйге төн. Алар клубтан чыкканда төн урталары җитеп килә иде. Тышта җылы, җиләс саф һава. Тирә-якта төнге тынлык. Клубтан китеп баручы кызлар-егетләр сөйләшкән тавышлар арасыннан авыл артындагы күлдә бакалар сайрашканы ишетелеп тора. Айсыз аяз күктә йолдызлар җемелди. Кемдер Югары оч ягында гармун сайратып җибәрде. Кыз тын калып тыңлап торды да, Нурмөхәммәтнең дә гармун тавышына игътибар иткәнен сизеп:

– Яратам да шул авыл кичләрендә уйнаган гармун тавышын, – дип куйды.

– Авылны сагынып кайтканга ул, Хәят. Миңа да шулай тоела баштагы көннәрдә. Аннары, гармун күтәреп, үзем уйнап йөри башлагач, алай түгел.

– Сез дә гармунчымыни, Нурмөхәммәт абый?

– Алай мактанырлык түгел дә, уйныйм...

– Соң алай булгач, нигә клубка гармун алып чыкмадыгыз? Җырлатып-биетеп утырыр идегез.

– Чит авылга килеп, алай йөрисем килми. Сезнең егетләр көнләшә башлар. Болай тыныч кына йөрсәм, берсе дә игътибар итмәс. Шуның өчен Камилгә дә гармунын алдырмадым. Көнләшә башларлар да, монда безнең авыл кызларын күзләп йөрмә дип, якалашырга тотынырлар.

– Кызлар теләгәнә алар киртә куя алмый инде анысы...

– Ничек кенә каршы төшәләр әле. Әгәр, мәсәлән, мин берегезне алып китә башласам...

– Шундый ниятегез дә бармыни, Нурмөхәммәт абый? – дип, кыз аңа серле караш ташлады.



– Бар, Хәят, бар. Дөресен әйтим, мин сезне беренче күрүдә үк ошатып калган идем. Шул чакта сезне озатып чыгуга, адресыгызны алмавым өчен үкендем. Вакыт-вакыт гел күз алдыма килә тордыгыз.

Кыз, башын түбән иеп, бераз кызарып, егетнең каршысында тын гына басып торды. «Казанда мин дә сезне еш искә алдым. Бигрәк тә Халимә апа энесе Сабирҗанга бирергә йөргән көннәрдә...», – дияргә уйласа да, кыз телен әйләндереп, мин дә, дия алмады.

Егет кызның кулларын үзенең учларына алды. Кыз кулларын тартып алмады. Каршысында басып торган бу изге җан иясенең күкрәкләре өстеннән салынып төшкән чәч толымнарының сулыш ритмы белән әкрен генә бер күтәрелеп, бер төшеп торуларын карап, егет күзләрен ала алмый торды. Кызның кара толымнарыннан килгән нindидер хуш ис аның күңелен айкады. Кинәт каршысында басып торган бу оялчан сылуны күкрәгенә кысып иркәлисе, сөясе, чәчләреннән сыйпыйсы килеп китте. Алар шулай тын калып, шактый басып тордылар. Тынлыкны Хәят бозды:

– Абый, мин сезне бөтенләй белмим бит әле, – диде ул, башын түбән игән килеш.

Нурмөхәммәт шунда гына кызның үзен кире кагарга җыенмавын, тик аңа үзе турында бик күп сөйләргә, таныштырырга тиешлеген аңлады. Кайдан башларга, дип уйланды ул. Үткән ел мин аңа үземнең кайда укуымны әйткән идем. Апа турында сөйләгән идем. Шул гынамы? Һәм ул үзе турында кызга никадәр күбрәк сөйләсәм, шулкадәр яхшы булыр дип, әкрен генә дәвам итте.

– Миңа егерме бер тулып килә, Хәят. Армиядән калуыма да озакламый өч ел була. Малай чагымда сугу машинасында ат куганда, ат тибеп, күкрәгемне, борынымны җимергән иде. Шуның зәхмәте аркасында армиягә алмадылар. Кайда укуымны беләсез инде. Менә күптән түгел, техникумны бетереп, районга эшләргә кайттым. Өйдә әнием белән кечкенә сеңелем бар. Ике апам укытучы. Абыем үз йорты белән тора. Үткән көз ашлыклар уңмаганлыктан, Азия ягына чыгып киткән иде. Әтием өч ел элек дөнья куйды. Безнең авыл Чирмешән буенда, бик матур урында урнашкан. Элек ул болыннар, урманнар князь Оболенский кулында булган. Олы апамны сез беләсез инде...

– Әкълимә Мәрдәновна һаман шул Шөгер ягындамы? – диде кыз, кашлары астыннан гына Нурмөхәммәткә карап.

– Юк, ул быел үзебезнең якка күчеп кайтырга уйлый.

– Әкълимә апага миннән бик күп сәлам тапшырыгыз, Нурмөхәммәт абый.

Төнге тынлыкны бозып, якындагы йортта әтәч кычкырып җибәрде.

– Тапшырырмын әманәтеңне, Хәят, онытмам, – диде егет, әтәч тавышын тыңлаган хәлдә. Башка йортларда да әтәчләр кычкыра башлады.

– Төн уртасы җиткән, – диде кыз, як-ягына каранып, – мин кайтыйм инде, Нурмөхәммәт абый, – дип, үзләре ягына борыла башлады. – Әни ачулана башлар. Иртә белән көтүгә торырсың, дигән иде.

– Әйдәгез, мин сезне озата барам, – дип, егет кызның уң кулыннан алды. Алар, янәшә атлап, тыкрыктан Хәятләргә таба киттеләр.

– Иртәгә нишлисез, Нурмөхәммәт абый, клубка чыгасызмы? Китми торгансыздыр бит әле?

– Торам әле, – диде егет, кызның кулын кыса төшеп. – Көндез ни эшлисез, Хәят? Бәлки, библиотекада очрашырбыз?

– Килегез, – диде Хәят, җәһәт кенә нурлы караш ташлап. – Сәгать икеләрдә ачыла ул. Мин анда булырмын.

Кыз туктап калды.

– Менә, безнең йорт шушы була инде.

Кыз йомшак кына капканы ачты да:

– Хушыгыз, абый! – дип, капканы ябып, үзе теге якта калды.

– Хуш, Хәят, тыныч йокы!

Егет күпмедер вакыт, кыз яңадан чыкмасмы дип, капка төбендә басып торды. Аннан соң ишегалды ишеге ачылып ябылганны ишетеп, әкрен генә, әле генә булып үткән татлы минутларны уйлый-уйлый кайтып китте.

Караңгы чоландагы урын аны күп уйлар белән көтеп торган.

Авыл әтәчләре, берсе артыннан берсе кычкырып, таң атканны хәбәр иткәндә дә, Нурмөхәммәт әле уй диңгезендә йөзә иде. Соңгы көннәрдәге борчулы уйларга калуын ул бары тик Сәлимәдән генә күрде. Югыйсә аның планнары гади иде: ялы беткәнче әнисенә булышырга, кыш өчен утын, печән әзерләргә. Кичләрен Сәлимә белән бакчада яшьләр янында үткәрергә. Көзгә, авылда эшләр беткәч, туй ясап, бу кышны авылга кайта-китә генә үткәреп, киләсе кышка квартира алып, Сәлимәне дә, әнисен дә үзе янына алырга уйлаган иде.

* * *

Хак сүз булган икән... Хәят нинди булыр икән? Юк, ул саф күңелле булырга охшый. Аның үз-үзен тотышы да, холкы-фигыле дә Сәлимәгә



капма-каршы. Аннан Камил дә Хәятне авылда алдынгы сафта тора торган яшь кыз, дип характерлады, эти-әниләре кемнәр икән?

Иртәнге чәйгә утырганда кояш югары ук күтәрелгән иде. Чәйгә алар Мәрфуга апа белән икәү генә утырдылар.

– Шамил абзый кайда соң әле? – дип сүз башлады Нурмөхәммәт. – Камил белән Фәүзия эшкә киткәннәрдер инде?

– Шамил абзаң печәнлекләрне карап кайтыйм, дип чыгып китте әле. Безнең бит, җәйгә чыксаң, печән мәсьәләсе бик авыр. Басу буйларыннан, чокыр-үзәннәрдән култыклап җыярга туры килә, – диде хуҗабикә.

– Тракторчыларга колхоздан бирмиләрме?

– Саламын ала инде шунда Камил. Печәннең исемен дә атаган кеше юк. Йә, ашап-эчеп утыр әле, Нурмөхәммәт, тартынып торма. Ни бары белән инде, гаеп итмәссең, – дип, хуҗабикә кунак егете алдына мич алдыннан иртә табадан төшкән коймаклар китереп куйды.

– Камил бүген көндәгедән дә иртәрәк китте. Тракторларының нәрсәсендер карыйсы бар диде, – дип дәвам итте Мәрфуга апа. – Фәүзиябезне бүген колхоз складына чакырдылар, амбарлар юаргамы, ди шунда. Кунак булган көнне бер генә көн өйдә калдырырга дигән идем дә, үзе ашкынып торгач, каршы килмәдем. Эшкә бик уңган Фәүзиябез. Өйгә кайтса, әни, нәрсә эшлим, дип кенә тора. Бригадир да мактый үзен. Ул өйдә булганда, минем кулыма бер эш тими. Үзем, әни, үзем, генә дип тора. Үзе гомерендә дә каршы сүз кушмас, шундый күндәм инде менә, түбәсендә казык очласаң да, сүз әйтә торган түгел. Кул эшен дә булдыра. Тегәргә, дисеңме, чигәргәме – һич эшләмәгән эше юк. Бик уңган. Сиңа да, Нурмөхәммәт, шундый кыз димләргә инде. Үзеңнең дә дөньяң тулы, җаның тыныч булыр, әниең дә шатланыр. Без, әниләр, киленнең уңган, күндәм булуын телибез. Хатын алсаң, үзеңнән дә уңган, кара-каршы тормыш алып бара торган булсын. Менә үзебез дә, Шамил абзаң белән, Камилебезне өйләндерергә, дибез. Авылда уңган кызлар да юк түгел, шуны ал, дип әйтеп тә караганыбыз бар, юк кына бит, миңа ошамый, минем үз дигәнем бар, ди. Миңа ошаган сезгә дә ошар, ди. Мин яратканны сез дә яратырсыз, аның белән миңа гомер итәсе, дип кенә куя...

– Дөресе шулай бит, Мәрфуга апа. Өйләнгән-өйләнгән гомер итәрдәйне алырга кирәк. Мин бит, мәсәлән, хатынны әнигә дип алмыйм, үземә дип алам. Мин яратканны әни дә яратырга, әни дә үз итәргә тиеш. Мин әнидән курыкмыйм, анысы. Ул минем әүлия кеше. Үземне якын күргән кебек, киленен дә якын күрәсенә ышанам. Ике арага кереп тә аптыратасы түгел.

– Менә үзебез дә куркып торабыз. Хәзер бит килен булып төшәләр дә, эти-әни дип олылау юк. Бер-ике ай торган булалар да малайны ата-анадан аерып китү ягын карыйлар. Ярый инде эти-әни дип санлап торырдай юньле бала булса. Камилебез ике елдан бирле күрше авылга йөри. Нинди баладыр, белмибез. Камил үзе, акыллы, уңган, дигән була. Чит авылдан булуы үзе бер яктан ярый да инде, анысы. Читтән өйләнгәннәр яхшырак торалар. Тырт итсә дә, пырт итсә дә, әнисенә чаба алмый. Авылдан өйләнгәннең аның шул ягы начар: иренә үпкәләсә дә, кайнанасы белән сүзгә килсә дә, тота да әниләренә кайтып китә. Ярый ла ата-анасы, юньле акыл биреп, бар, кемгә чыктың, шуның белән тор, дия белсә. Кайберләре, ир белән хатын арасына кереп, пыскып янган утка керосин гына сибә. Камилгә, кызыңны алып килеп бер күрсәт, ичмасам, күзебез күнегә торсын, безне булачак килен белән таныштыр, дим дә бит, ярар, дигән була. Кайчанга кадәрдер инде ул ярары.

Хуҗабикә, чынаягын алып, бер генә йотым чәй капты да кире куйды.

– Кара әле, Нурмөхәммәт, ашап утыр әле, аша, тартынма! – дип, тәлинкәне егет алдына куйды.

– Алдымда бит, апа, кыстама.

– Ниме, Нурмөхәммәт, – хуҗабикә егеткә якынрак тартылды, – нindирәк уйда торасың соң. Әниең үткән ел ук малаемны өйләндерәм, дигән иде. Авылыгызда күзең төшкәне юктыр бит?

– Бар иде дә, хәзер юк инде, апа, – диде егет, чынаяктан чәй эчә башлап.

Хуҗабикәнең йөзе тагын да яктыра төште. Утыргычын тарта төшеп, егетнең колагына ук үрелде:

– Менә безнең Фәүзия кебек бер яшь кызга өйләндерергә инде үзеңне.

Егет дәшмәде. Тагын шул Фәүзия, аның кай җиренә өйләнәсең, бала гына бит әле ул, кыз булып җитлекмәгән, дияргә бик теләсә дә, дәшмәде. Өйдә тынлык урнашты. Хуҗабикә, егетнең ризасызлыгы йөзенә чыкканны тоеп, почмак якка кереп китте дә анда нидер эшләгән булып йөргән җиреннән:

– Кичә Камил кая алып барды үзеңне? Клубкамы? Клуб буенда күңелеңне аздырып йөрисе түгел, – дип, яңадан эндәште. – Клубка юньле кыз-бала йөрми. Җыен азган-тузган кызлар гына йөри анда. Әнә безнең Фәүзия йөрми. Үзебез тыябыз. Анда вәсвәсә сатып йөрүдән мәгънә юк.



Тагын Фәүзия... Тәки шул балалыктан чыкмаган кызын мактый. Ләкин Мәрфуга апа үз кызын мактаган саен егетнең саруы кайнаганын арттыра гына барганын уйламый шул.

– Акыллы кыз-бала клуб буенда йөрми. Син дә акылыңда бул. Күңелеңне аздырып анда йөрмә. Алла теләсә, Шамил абыең белән үзебез менә дигән яшь кыз димләрбез. Әниең белән икәүләп киләләр аны. Ул да, күреп, ризалыгын бирер иде...

– Рәхмәт, апа, чәегез тәмле булды! – Нурмөхәммәт чынаягын каплап эчкәрәк этәрде дә, өстәл янынннан күчеп утырганнан соң, дәвам итте:

– Клубка йөргән кызлар турында фикерләрең белән килешә алмыйм, Мәрфуга апа. Сезнеңчә, клубка йөргән кызлар әдәпсезлеккә генә өйрәнә булып чыга. Клуб – аң-белем, культура үзәге ул. Анда яшьләр, сез уйлаганча, азып-тузып йөрми, культуралы ял итә. Радио, музыка тыңлый, күмәк уеннар уйный, кино, театр карый. Үзләре дә театрда, концертлар куюда катнаша. Гәзит-журналлар укый. Ул аулак өй түгел. Анда барысы да кеше күз алдында. Хәзер аулак өйләр юк. Һәркем күңел ачарга клубка бара. Уйнамагач та, көлмәгәч тә, ул нинди яшьлек була, ди? Тумас борын картаеп үскәч, ул бит мокыт булып чыга. Юк, апа, бу фикерең белән килешеп булмый. Мин үзем дә клубка йөреп үстем. Сез уйлаганча азмадым да, тузмадым да. Сез дә Фәүзияне клубка чыгармыйча ялгышасыз, шуның өчен ул боек күңелле, ябык. Сез аны клубка чыгармыйча, яшьлегеннән мәхрүм итәсез. Камил әнә бөтенләй башкача, ул да бит клубка йөреп үсте. Азмаган да, тузмаган да...

– Камил бит ул ир бала.

– Кыз бала булганы өчен Фәүзия өй тавыгы булып яшәргә тиешме? Тавык та бит, гел-гел өйдә торса, йонын коя, ябыга. Һич дөрес түгел, Мәрфуга апа, кыз бала булганы өчен сез аны, алты класстан ары укытмыйча, надан калдыргансыз.

Фәүзия дә Фәүзия дип, кызын мактаудан туктар, минем уналты да тулмаган кызына карашым нинди икәнне белеп торсын, дип уйланды Нурмөхәммәт. Хуҗабикәнең ачуы кабарганны гына күреп, кунак егет туктап калды. Ләкин үзенең фикерен әйтеп бетерә алуыннан ул канәгать иде.

Мәрфуга апа егеткә усал карап алды да, каты-каты басып, ишегалдына чыгып китте. Анда үз-үзенә сөйләнеп йөргәннән соң, табак тотып, почмакка керде.

– Надан дип, нишләп надан булсын ул? Шатырдатып укый, матур итеп яза. Кыз балага шул җиткән...

– Мәрфуга апа, авылыгызда ун класс ачтылар. Сез авылыгызда була торып, кызыгызны алты класс белем белән калдыргансыз. Мин моның белән килешә алмыйм...

Хуҗабикә дәшмәде.

* * *

...Нурмөхәммәт китапханәгә килеп кергәндә, Хәят озын өстәл артында гәзит-журналлар карап утыра иде.

– Исәнмесез, – диде егет, барьер артында бер өем китаплар актарып торган сары чәчле сипкелле кызга карап.

– Исәнмесез, үтегез, – диде кыз, зәңгәр күзләре белән егеткә текәлеп.

Егет өстәл артындагы эскәмиягә Хәяткә каршы килеп утырды.

– Хәерле көн, Хәят, журналлар карыйсызмы?

– Хәерле көн, Нурмөхәммәт абый, – дип елмайды кыз. – Кунак егете, озак йоклыйсыз.

– Кунакта рәхәт бит, печән чабасы да, утын әзерлисе дә юк. Ашыйсың-эчәсең дә, кич клубка чыгып, кызлар күзлисең.

– Кара аны, абый, безнең авыл егетләре көнчеләр, – дип шаяртты китапханәче кыз, китаплар арасыннан елмаеп. – Сизсәләр...

Нурмөхәммәт китапханәче кызның сүзләрен ишетмәмешкә салышты. Аның игътибары каршысында утырган кызда иде. Кичә ул аны лампа яктысында, төн караңгысында гына күргән иде. Бүген менә Хәят үзенең калын толымнарын калку күкрәге өстеннән салындырып, кыйгач кашлары, озын керфекләре астында яшеренгән шомырт кара күзләре белән егетнең каршысында сихерләп утыра. Хәят үткән елдагы шикелле үк чибәр. Иннек-кершән ягылмаган чиста ак йөз, җыйнак борын, алсу иреннәр, тыйнак, ягымлы... Юк, үзгәрмәгән Хәят. Тагын да матурлана гына төшкән...

– Ничек йокладыгыз, Хәят? Нинди төшләр күрдегез? – диде егет, кызга ягымлы карап.

– Рәхмәт, әйбәт йокладым. Төшләр күрергә вакыт тимәде. Көтүгә тордым, – дип елмайды Хәят. – Сез ничек йокладыгыз, кунакта йокы тәмле булгандыр?

Егет дөресен әйтергә булды:

– Узган кичтәге тәэсирләр белән тиз генә йоклый алмадым. Таң атканда гына йокыга кителгән. Хәтта Камилне уятканны да тоймаганмын. Кичә сездән сорарга онытканмын, – диде ул, кызга таба иелә төшеп, – үткән көз Казанга ничек бардыгыз? Теге апагыз ничек каршы алды?

– Баруым уңай булды. Ул апаларны да тиз таптым, – диде кыз, кайсыларын сөйлим икән, дигән уйга калып. – Баргач кына берәр ай бик читен булды. Теге апа тәки шундый булды бит, Нурмөхәммәт абый. Хәлимә апа мине ах итеп каршы алмады. Башта, тегендә бар, монда бар дип, төрле адреслар белән эшкә кертергә дип йөртте. Яшем җитмәгәнлектән эшкә алмасларын Хәлимә апа белеп тора икән. Хәлимә апа җибәрде дип барам, анда миннән көләләр генә. «Бар, сеңлем, әле үсәсең бар», – диләр. Аннары тегене эшлә, моны эшлә дип, төрле эшләр эшләтә башлады. Беркөнне, бу минем энем дип, бер егетне ияртеп килде, шуның белән таныштырган булды. Аны мактады, билетлар алып, шул егет белән бер-ике мәртәбә киногa да җибәрде. Аннан энесе Сабирҗанга кияүгә чыгарга димли башлады. Сабирҗан башта тыйнак кына кебек күренгән иде. Аннары апасы өйдә булмаган вакытта эчеп килеп, кулларын озынайта башлагач, кайтып китәргә булдым. Шул турыда Хәлимә апага әйткән идем, ул күгәреп-бүртеп чыкты да: «Ай буена ашап, сыйланып яттың да, шуның рәхмәте урынына качып китмәкче буласыңмы? Беркая бармыйсың! Башта шул ашап ятканнарың, квартира хакын түлә. Аннары китәрсең!» – дип кычкырына башлады. Үзе түләргә акчам юк икәнен белә иде. «Акчаң юк икән, әнә Сабирҗаннарга бар. Аңа өй җыештырып, ашарга әзерләп торырсың, ул сиңа акча түләр», – дип, мине шул исерек янына хезмәтче итеп җибәрмәкче булды. Анда барсам, ни буласын сизә идем. Аптыраштa калдым. Инде нихәл итим дип аптырап, беркөнне подъездга чыгып утырган идем, яныма бер апа килеп утырды. Сөйләшеп киттек. Мин үземнең хәлем турында сөйләп бирдем. Бу апа миңа: «Минем кызыма өйдә күз-колак булырга бер кеше кирәк иде. Риза булсаң, урнаштырам. Кызым Зәкия – зур врач, киявем Зиннур – заводта инженер, ике балалары. Берсе садикта. Берсе икенчедә укый. Риза бул, кызым, ашау-эчү бергә булыр, аена кырык сум түләрләр, дигәч, риза булдым. Ул мине Зәкия апаларга алып барып урнаштырды. Хәлимә апага утыз сумны Зәкия ападан бурычка алып илтеп бирдем. Шулай итеп, Зиннур Хәлиловичларда няня булып урнашып калдым. Бер айдан соң Зәкия апа үземне кичке мәктәпкә укырга урнаштырды. Бәхетем бар икән әле, Нурмөхәммәт абый. Ул вакытта кайгырганымны үзем генә беләм. Ул авыр көннәрдә сезне дә искә алгаладым. Минем бит бер яклаучым да юк иде.

– Казанга тагын китәсезме, Хәят? – Егет кыз ни әйтер икән дип, аңа иелә төште дә күзләренә карады.

– Белмим әле, абый, – диде кыз, башын түбән иеп. – Барсам да, кыш чыгарга гына барырмын, бәлки. Сез нинди киңәш итәр идегез? – Кыз Нурмөхәммәткә күз төшереп алды.

– Минем фикеремне сез беләсез дип уйлыйм, – диед егет, китапханәче кыз ягына күз ташлап.

Кыз да шул якка күз төшереп алды да, урыныннан кузгалып:

– Кайтырга кирәк, – диде һәм ишеккә таба юнәлде.

– Әйдәгез, мин дә чыгыйм әле, – дип, Нурмөхәммәт тә урыныннан торып чыга башлады. – Авыл советына барып киләсем бар әле минем.

Урамга чыккач, алар кичкә клубта очрашырга булып аерылдылар. Авыл советына барып китапханәне көндез – икедән дүрткә кадәр, кич җидедән унбергә кадәр ачу турында сөйләшеп чыкты. Авыл халкы көндез эштә булганга күрә, шулай эшләү кирәк, дип аңлатты.

Нурмөхәммәткә Хәятнең клубтан чыкканын озак көтәргә туры килде. Китапханәдән чыккач, кич клуб каршысында очрашырга сөйләшкәннәр иде. Ниһаять, клуб ишегендә кыз күренде. Тәненә сылашып торган сыек зәңгәр төстәге күлмәге кызны зифа буйлы сылу итеп күрсәтә. Уртадан ачып, ике калын толым итеп үрелгән чәчләре күкрәкләре өстендә адым саен талпынып куя. Менә ул кызлар төркеменнән аерылды да, ихлас күңелдән елмаеп, яктырып, бер читтәрәк ялгыз басып торган егет янына якынлашты. Карап, сокланып туймаслык иде Хәят бу мизгелдә.

Дөнья дигәнең шундый матур, шундый күңелле, бары тик чиксез зур шатлык алып килгән сөю белән мәхәббәттән генә тора. Күңеленең түренә язгы ташкындай өерелеп кергән шатлык хисләре егетне үзе дә белмәгән хыял дөньясына алып китте. Гомергә, мәңге-мәңге шулай булса иде икән...

– Озак көттердемме, Нурмөхәммәт абый?

– Юк, озак түгел.

Тик син минем өметемне генә өзмә, минеке генә бул дияргә уйлаган иде дә, әллә бу сүзләрне әйтергә иртәрәк дипме, әллә кыюлыгы җитмәдеме – туктап калды.

– Бүген дә репетиция була, дигәннәр иде дә, җыелмадылар, – дип кыз, клубтан шаулашып чыгып килгән яшьләрдән ераклашу өчен читкәрәк атлады. Шулвакыт, кичке тын урамнарны яңгыратып, клуб тирәсендәге сирень, сәрби агачларын сискәндереп, тальян тавышы яңгырады. Кемдер калын тавыш белән җыр башлады:



*Тальяныңны тартып уйна,*
*Җырлаучыга хут булсын.*
*Тыңлап торган яшь кызларның*
*Ике күзе ут булсын...*

Нурмөхәммәт кызның кулыннан алды. Алар кулга-кул тотынган килеш, Хәятләр тыкрыгына таба киттеләр. Кызның йомшак кайнар кулы егетнең көчле учларында эреде. Әкрен генә, сөйләшмичә генә атладылар. Әйтерсең лә, кайнар куллары аша бер-берсенең йөрәк тибешен, уй-фикерләрен аңлыйлар иде. Хәят, егеткә сиздермичә генә, кара кашлары астыннан күз сирпеп алды. Үзе белән янәшә атлаган егет аңа бик ошый иде. «Буе миннән бераз калкурак икән. Гади, яхшы күңелле булырга охшый. Акылы-фигыле ничек икән? Мин аны бик аз беләм шул... Ярый ла мин көткән өметләрне акласа. Җиңел карашлы, җилбәзәк күңелле булмаса... Юк, ул андый булырга охшамый». Хәятнең күз алдына үткән ел август ахырында Чистай пристанендә очрашкан минутлар килде. Нурмөхәммәт ул вакытта ук аның күңелендә җылы хисләр уятып киткән иде. «Әнә ничек кайгыртып, озатышып йөрде... Өйдә әнисе, сеңлесе бар бугай. Әнисе нindирәк кеше икән?»

Нурмөхәммәт, кулыннан тотып янәшә бару рәхәтеннән исереп, кызга күз төшергән саен, бу тыйнак, инсафлы кыз аңа кадерлерәк, якынрак булып тоелды. Ераклаша барган гармун моңнарына да игътибар итмичә, сүзне нидән башларга, кичәниләр сөйләшкәннәрен хәтеренә төшерергә теләү уйларыннан арынып, егет кинәт кенә тукталды да сорап куйды:

– Ничек яшисез, Хәят, кемнәрегез бар?

– Безнең тормышның сөйләрлеге юк, Нурмөхәммәт абый, – диде кыз, уңайсызланып кына сүз башлап. – Без өйдә өчәү генә яшибез – әнием, миннән биш яшькә кече энем дә мин. Тормышыбыз ярлы якта. Авылда әтиемнең энесе бар. Апам Нурлатта, үз тормышлары белән яшиләр. Ике балалары бар. Әтием... – Кыз кинәт, әйтергәме, юкмы, дип тукталып калды. – Әтиемне алты ел элек кулга алганнар иде. Шуннан кайтмады. Ике ел элек үлгән хәбәре килде... Без өч ятим авыр үстек, абый. Хәзер дә җиңел түгел. Үткән ел ашлыклар уңмаганлыктан, хезмәт көненә икешәр йөз грамм гына бирделәр. Ул икмәк белән генә өч җанны саклап чыгып булмас дип, әнием киңәше белән, Казанга киткәнемне беләсез инде. Әнием – Кадрия, әтием Хөсәен исемле иде...

– Гафу итегез, Хәят, авыр булса да, әтиегез турында да берәр сүз әйтә алмассызмы?

Кыз уңайсызлануыннан кызарып чыкты. Шулай да сиздермәскә тырышып, көттереп кенә сөйләп китте:

– Әтиемне кулга алганда, мин әле өченчедә генә укый идем. Яхшылап хәтерләмим. Ул колхозда хисапчы булып эшли иде. Яңа иген өлгергәч, ведомость төзеп, колхозчыларга аванс бирергә булганнар. Гаиләсенә, эшләүче кешеләр санына карап, кемгә бер пот, кемгә ике пот аванс ясаганнар. Колхоз рәисе ведомостька кул куйган да үзе районга киңәшмәгә киткәндә: «Мин киткәч, ведомостьны амбарга илтеп тапшыр» – дип кушып калдырган әтигә... Дәүләткә ашлык сату планын үтәмичә, колхозчыларга икмәк таратуда гаепләгәннәр әтиемне. Мин мәктәптә идем, әтине өйгә дә кайтармыйча алып киткәннәр. Ике көннән соң без әтине күрергә бардык. Шунда әти сөйләде: минем бер гаебем дә юк, тикшерерләр дә кайтарырлар, кайгырмагыз, диде. Ведомостьта рәиснең кулы бар, мин аның кушканын гына үтәдем, диде. Ә колхоз рәисе, мин кушмадым, имза минеке түгел, Садриев мин өйдә юк вакытта шулай мине гаепләр өчен эшләгән дип, бөтен гаепне әти өстенә аударган. Рәискә идарә акчасын әрәм-шәрәм итәргә юл куймый идем мин, диде әти. Шуның өчен ала инде ул миннән, диде. Артыннан әтинең энесе дә йөреп карады. Барыбер әтине акламадылар. Теге рәиснең районда дуслары күп. Шулар яклады, диләр. Шулай итеп, без әтисез калдык. Ул булмагач, әни берүзе очын-очка ялгый алмый аптырый. Авыр, ярлы яшибез без, Нурмөхәммәт абый.

Кыз тукталып калды да, егеткә карамыйча гына, башын аска иде. Егет Хәятне кызганып куйды. Аны юатасы, күңеленә хуш килердәй сүзләр әйтәсе килеп китте.

– Ярлылык хурлык түгел ул, Хәят, гариплек тә түгел. Исәнлек кирәк. Исәнлек – байлык, дигәннәр борынгылар. Әниегез Кадрия апа ни хәлдә?

Кыз тагын егеткә карап алды. Бу юлы аның карашы күңеллерәк иде.

– Әнием исән, авырып ятканы булмады. Ул гына алып бара да инде...

– Шулай булгач, бер дә борчыласы түгел. Вакыты белән бар да булыр. Минем әни шулай, ди. Мин үзем дә кешеләр белән байлыкка, барлыкка карап аралашмыйм. Тормыш иптәшемнең дә бай семьядан булуын теләмим. Саф күңелле хезмәт кешесен яратам мин... Үзем дә хезмәтне сөям. Бер-береңне хөрмәт итеп, бер-береңне тыңлап, тормышны тигез тартканда гына кеше бәхетле, тормыш күңелле була. Син тот та, мин тот, дип яшәргә калсаң, бу инде булмады дигән сүз. Кеше барлыклы булырга мөмкин. Әгәр аның холкы-фигыле начар, һавалы, башкаларны санга санамый торган булса, нишләрсең? Кешене байлык боза, ди минем әнием. Ярлы кешенең күңеле саф, күңеле бай була, ди. Аннан, тагын шунысын да әйтим әле: Хәят, сез инде мине интеллигент, аксөяк дип уйлый торгансыз. Хезмәтем буенча мин киләчәктә интеллигент булсам да, кул кушырып, кәнсәләрдә генә утырырга җыенмыйм. Үземә йорт-җир булдырырга, җимеш бакчасы үстерергә уйлыйм. Минем әти өйләнгәндә үзенең җимеш бакчасын булдырып өйләнгән. Минем әлегә җимеш бакчам юк-югын. Ләкин, исән булсам, ансыз яшәмәм, дип уйлыйм. Семьям, балаларым җиләк-җимеш, алмага рәхәтләнерлек булыр.

Нурмөхәммәт кызга карап алды да, аның бик игътибар белән тыңлаганын күреп, дәвам итте:

– Безнең татар халкында кат-кат өйләнү кебек начар гадәт бар. Хәзер ике хатын белән торучы булмаса да, кат-кат өйләнү әле дә бар. Мин үзем андый караштa түгел. Кеше гомерендә бер генә өйләнергә, бер генә мәртәбә кияүгә чыгарга тиеш, дип саныйм. Бер мәртәбә өйлән дә, йә булмаса, бер мәртәбә тормышка чык та, шул үзең сайлаган өлешеңә төшкән көмешең белән гомер ит. Аңа тугрылыклы бул. Үзеңнең тугрылыгың, бирелгәнлегең, хөрмәт итүең белән аның ихтирамын яула. Бер-береңне тыңлап, ихтирам итеп яшә. Нерваларыңа ирек бирмә... Берең әйткәндә, икенчең дәшми калу яхшырак. Әгәр инде ул әйтә дип, син дә калышмаска тырышасың икән, бу инде конфликтны, ризасызлыкны арттыруга гына ярдәм итәчәк. Безнең күршедә шундый бер семья яши. Хатыны шундый телдәр, шундый әче телле, хәтта русча сүзләр кыстырып ирен сүгәргә дә ул апага берни тормый. Ире мескен, юаш. Теге сүгенгәндә, ай алла, ай алла, дип кенә тора. Ир кешегә бернинди ихтирам юк, ә бит ул хатын үзе өйдә генә команда биреп ята. Беркайда эшләми, ир китергәнне сарыф итүче генә. Ярый ла ире эштән кайтканда ашарга әзерләп көтсә, анысы да һәрвакыт булмый. Балаларына да шулай ул апа. Аның балалары да бәхетсез. Алар да чүлмәкчедән кырмәкче дигәндәй, шундый усал телле, миһербансызлар. Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты соң? Өч малай үстергәннәр иде. Олысы өйләнде дә, аны икенче көнне үк әни кеше өеннән куып чыгарды. Икенче малаен өйләнгәнче үк куып чыгарган иде, анысы яшьли читкә китеп, шунда юкка чыкты. Карты, мәрхүм, вакытсыз гүргә керде. Кече малае үсеп җитеп, бурычка акча алып өйләнгәч, өч кенә көн тордылар да, әни кеше, бөтен авылга рисвай итеп, килен белән малайны куып чыгарды. Хәзер карчык яңа өйдә берүзе яши. Малай яшь хатыны белән кешедә квартирада тора, бурыч түли. Моның белән ни әйтергә теләгәнемне аңлагансыздыр инде... Тормышта хатын, әни кешедән бик күп нәрсә тора. Ул семьяны кеше дә итә ала, шулай ук юкка да чыгара ала. Ләкин тормыш өчен бу мин әйткәннәр барысы да түгел әле. Бер

үк вакытта ир кеше дә семья терәге, семья тоткасы булып тора. Ни өчен шулай таркалды бу семья?

Нурмөхәммәт кызга карап алды да яңадан сөйләп китте:

– Чөнки ул апа үзен генә дөнья тоткасы итеп санады. Ата кешенең бер тамчы да авторитеты булмады. Әни кеше балалар алдында да, кеше алдында да ирен хурлады. Аны булдыксыз мәхлук итеп күрсәтте. Өч ир бала шуны күреп, ямьсез телле булып үстеләр. Үсә төшкәч, әниләрен санга сукмый, кара-каршы кычкырыша башладылар. Әйтерсең лә, этиләре өчен әниләреннән үч алдылар. Бәлки, шулайрак та булгандыр. Чөнки этиләре белән алай итенгәннәрен күрмәдем. Халык, ни чәчсәң, шуны урырсың, ди. Ул апа хәзер үзе чәчкәнне күрә.

Тыкрыкка китереп актарган бүрәнә өеме янына җиткәч, Нурмөхәммәт шул җирдә туктап калды да:

– Әйдә, шунда утырабыз, – дип, Хәяткә карады. Аннан кесәсеннән гәзит кисәге алып, аны бүрәнә өстенә җәеп салды.

– Утырыгыз шунда, – дип, кызга урын күрсәтте.

Кыз гәзит өстенә сүзсез генә килеп утыргач, аның сул ягына үзе урнашты.

– Әйтергә теләгәнем шул, – дип дәвам итте ул, – тормышта бик күп нәрсә ир белән хатынның үзара мөнәсәбәтенә бәйләнгән. Ир белән хатын үзара бер-берсен ихтирам итеп, бер-берсен тиң күреп, кимсетмичә, тату яшиләр икән, балалар да шуны күреп, шуннан үрнәк алып үсәләр. Алмагачның алмасы ерак тәгәрәми, диләр бит. Ата-ана нинди була, бала да шундый була дигән сүз.

Егет, Хәяткә табанрак борылып, якынрак утырды да аның кулын алды.

– Мин үзем дә, Хәят, тугрылыклы ир булып, тормыш иптәшемне дә ихтирам итеп, аны да, үземне дә бәхетле итеп яшисем килә. Минем этием белән әнием дә бик матур, бик тату яшәделәр. Әтинең бер вакытта да, кул күтәрү түгел, яман сүз әйткәнен, ачулanganын хәтерләмим. Әти, мәрхүм, үзенә авыр булса да, безне укытырга, белемле итәргә тырышты. Безне эшкә, һөнәргә өйрәтте. Үзе дә һөнәрле кеше иде. Кулына ни тотса, шуны булдырды. Үз вакытына күрә укымышлы да иде. Әнием, укымышлы булмаса да, аш-су, киндер туку, кул эшләренә оста. Бик күп үләннәрнең дәвалау серен белә. Киң күңелле, йомшак характерлы, җанын ярып бирергә әзер тора торган кеше. Үткән елдан бирле мине өйләндерү ягында. «Улым, өйлән инде, исәнлегем бар вакытта оныкларымны карап үстерәсем килә», – дигән була. Мәктәпне бетереп кайтыйм инде, әни, дип



тордым. Әлегә кадәр ул да моңа каршы килмәде. Инде менә диплом алып эшкә кайткач, вакыт җиткәндер, дип уйлыйм. Авылда минем яшьтәгеләр бар да өйләнеп, кияүгә чыгып беттеләр. Яшь кызлар бар да, аларның әле бераз үсәселәре бар.

Нурмөхәммәт кинәт туктап калды да, Хәятнең ике кулын да алып, аның күзләренә карады. Аларның күз карашлары очрашты. Бу мизгелдә Хәятнең күзләреннән ниндидер якты нур сибелеп тора иде. Ул якты нур шундый назлы, шундый сөйкемле... Егет Хәятнең шул карашыннан күзләрен ала алмыйча карап торды. Шул ягымлы караш Нурмөхәммәткә ниндидер көч, кыюлык бирде. Ул һич икеләнмичә:

– Бер сүз әйтимме, Хәят? Ачуланмассыңмы? – дип сорап куйды да, кызның җилкәсеннән алып, яратып, үзенә якынрак китерде дә, кызның җавабын да көтмәстән, дәвам итте:

– Мин сине, Хәят, беренче мәртәбә Чистай пристанендә күргәндә үк ошаткан идем. Ул вакытта ук мине көткән газиз җан иясе шул түгел микән, дип үземә сорау куйган идем. Шуннан бирле син миңа көннән-көн якын була барасың. Әгәр мин синең кулыңны сорасам, син каршы килмәссеңме?

Кыз, башын аска иеп, тыңлаган җиреннән бераз уйлап торган булды да:

– Юк, каршы килмәм, – дип, егетнең күкрәгенә башын салды.

– Рәхмәт, – диде Нурмөхәммәт, шатлыгыннан ни эшләргә белмичә, кызны кочагына алды.

Шундый рәхәт, шундый иркен иде дөнья бу минутларда аларның икесенә дә.

...Болыт арасыннан килеп чыккан ай, аларны тәбрикләп, якты нурын сипте. Нурмөхәммәт шатлыгыннан ни дияргә, үзенең рәхмәтен кызга ничек аңлатырга белмичә, аны көчле куллары белән үзенә кысты. Аның чиядәй кызыл кайнар иреннәренә үрелде. Шулвакыт ул ай яктысында кызның йөзендә оялчан елмаю күрде. Аның карашлары назлы, йөзе мөлаем иде.

Белмим, алар шулай дөньяларын онытып күпме утырган булырлар иде, таң әтәчләре кычкыра башлап, икесен дә чынбарлыкка кайтарды:

– Кайтыйк, – диде кыз, егет куеныннан чыгып.

– Әйдә, мин сине озатып куям, җаным, – диде егет, Хәятнең кулыннан җитәкләп. Кыз дәшмәде. Аңа рәхәт иде.

Капка төбенә җиткәч кенә, Хәят әйтеп куйды:

– Иртәгә китмисеңдер бит әле?

– Юк, китмим.

– Мин сине китапханәдә көтәрмен.

Кыз, тиз генә үрелеп, егетнең битеннән үбеп алды да капка артына кереп югалды.

...Нурмөхәммәт бүген клубка көндездән үк килде. Болай иртә килүенең сәбәбе клубта эшнең торышы белән риза булмавында иде. Өч көн буе кунак егете булып күзәтеп йөри торгач, ул клубта яшьләр белән бернинди дә эш алып барылмаганын күреп, сыкранып куйды. Яшьләр һәркөнне бер-ике сәгать домино сугалар да, клуб каршысына чыгып, тәмәке тарталар, гармун тартып, җырлап таралышалар. Клубта бертөрле уен оештыру юк. Радиоалгычлары эшләми. Ындыр табагына барып концерт бирергә уйлаган булганнар, аны да оештыра алмаганнар. Клуб мөдире Җәләлов клубны ача да яба. Барлык эшне үз агымына куйган. Концерт бирергә теләп янып торган, шәһәрдән укудан кайткан яшьләр дә бар, югыйсә.

Нурмөхәммәт бу турыда партоешма белән сөйләшеп карарга уйлаган иде дә, башта клуб мөдиренең үзе белән сөйләшергә булды. Партоешма каршына барып сөйләшергә әлегә үзенең вәкаләте җитми дип уйлады. Ни дисәң дә, ул бит әле район культура бүлеген кабул итеп алмады. Беренче августка әле өч атнага якын вакыт бар.

Клуб мөдире егетнең үз эшләренә тыгылып йөрергә теләвен бик өнәмәде. Кашларын җыерып, ризасызлык белдерергә җыенган иде дә, егетнең ярдәм итәргә җыенуын күргәч, ачылып китеп, сөйләшә башлады.

Нурмөхәммәт үзе белән таныштырып, кем икәнен, ике атнадан кем булып эшли башлаячагын да белгәч, бөтенләй йомшарып, иптәш Мәрдәнов дип, Нурмөхәммәтнең киңәшләрен теләп кабул итте:

– Иптәш Җәләлов, колхозның радиоузелы бармы сездә? – диде ул клуб мөдиренә. – Булса, шуннан нигә файдаланмыйсыз?

– Ничек файдаланырга соң радиодан?

– Радио аша концертлар бирергә, әңгәмәләр үткәрергә. Яшьләрне клубка сөйләшүгә чакырырга мөмкин. Әйдә, бүген үк яшьләрне сөйләшүгә чакырабыз?

– Нәрсә сөйләшербез икән соң? – диде Җәләлов, аптырап.

– Авылыгызда яшьләр дә, җәйге каникулга кайткан укучылар да җитәрлек. Шуларны җыябыз да кичәләр, концертлар оештыру турында сөйләшәбез. Көндезләрен – ындыр табагына, кырга барып, кич, халык эштән кайткач, радио аша концерт бирергә була.

– Барып чыгар микән соң ул, килерләрме?

– Килерләр, килми нишләсеннәр. Чакырабызмы?



– Чакырып карыйм алайса. Тик яшьләр белән сез сөйләшерсез, – диде мөдир

– Кайгырмагыз, иптәш Җәләлов, мин шунда булам.

Нурмөхәммәт белән Камил клубка килгәндә анда утызлап егет һәм кыз җыелган иде. Клуб мөдире аларны шатланып каршы алды:

– Яшьләр җыелды, иптәш Мәрдәнов. Башлыйбызмы? – диде ул. – Камилне дә алып килгәнсез икән.

– Әйдә, ачып җибәр җыелышны. Аннары миңа сүз бирерсез.

Җәләлов, сәхнәдәге өстәлне уртага куйды да яшьләргә якынрак килеп утырырга кушты. «Нәрсә бар? Шул партияне генә уйнап бетерик», – дип каршы төшүче домино сугучылар да булды. Шулай да бераздан сәхнә алдындагы эскәмияләр яшьләр белән тулды.

– Иптәшләр! – дип сүз башлады клуб мөдире. – Тынычланыйк әле. Менә иптәш Мәрдәнов белән сөйләштек тә сезнең белән киңәшеп алырга булдык. Мин сүзне баштан ук аңарга бирәм. Ул районнан килгән вәкил.

Нурмөхәммәт, бер залдагы яшьләргә, бер клуб мөдиренә карап алды да, өстәл артыннан чыгып, сәхнә читенә килде.

– Дуслар, мин, иптәш Җәләлов әйткәнчә, районнан килгән вәкил түгел. Сезнең авылга кунакка килгән кеше генә. Өч көн инде мин сездә буталам. Клубыгызның эше бик аяныч булганын күреп йөри торгач, менә иптәш Җәләлов белән, сезне чакырып киңәшергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Күреп торасыз, клубыгызда кичләрен бер ямь юк. Ә яшьләр күп икән авылыгызда. Әле бирегә килмәгәннәре дә бардыр... Клубның эшен җайландырасы иде, иптәшләр. Кичләрен клуб гөрләп торсын. Төрле уеннар оештырырга, концертлар куярга мөмкин. Ягез, сөйләшик әле. Кемдә нинди тәкъдимнәр, сораулар бар?

– Миңа сүз бирегез әле, – дип, арттагы рәттән уртача буйлы, кара чәчле колхозчы егет торып басты. – Мин көн дә диярлек клубка киләм. Киләм дә, икенче килмәс булып, кайтып китәм. Нигә алай, диярсез. Берәр нәрсә булмасмы, дип киләсең, һаман шул домино да шашка. Казаннан бирә торган концертларны, татарча тапшыруларны тыңлар идек, радио эшләми. Кинокартиналар сирәк килә. Елына ике-өч концерт оештырган булалар да, шуның белән эш бетте. Әңгәмәләр, доклад кебекләре дә шулай. Бәйрәмнәрдә генә берәр нәрсә оештырган кебек булалар да, шуның белән бетте. Шуның өчен клубка киләсе дә килми. Клуб эшен без оештырырга тиешмени инде? Иптәш Җәләлов ни өчен соң? Чакырганда киләбез без.

– Мин дә берничә сүз әйтим әле! – дип, савымчы кыз торып басты. – Рәшит дөрес әйтте. Клубка киләсе дә килми. Менә мин фермада эшлим. Кич эштән соң бик арган булсам да, чыгасы, күңел ачасы килә. Клубка киләбез. Киләбез дә аптыраашта калабыз. Берәр төрле уен, җырлар оештырырга мөмкин бит. Җәләлов Фатих абый, үзе кырыктан узган кеше булгач, уеннар оештыруны кирәкми, дип саный. Кайчан килмә, зал тулы эскәмия. Бер читтә өстәл куеп, домино суктырудан башканы белми. Бу эскәмияләрне җыеп, яшьләргә уеннар, биюләр оештырырга мөмкиндер бит? Хәзер авылда укудан кайткан әллә никадәр яшьләр бар. Концертлар әзерләргә мөмкин. Әллә ничә гармунчы. Чакыручы, оештыручы булса, беребез дә каршы түгел, минемчә.

– Дөрес, Халисә, дөрес әйтәсең! – дип урыннан Камил кычкырды. – Чакырсалар, мин дә, башкалар да катнашабыз.

– Миндә бер сорау бар, – дип, җирән чәчле, киң җилкәле егет торып басты. – Ни өчен клубның радиоалгычы эшләми? Менә минем өйдә радио юк. Клубка килеп тыңлар идем. Мин үзем фермада эшлим. Анда да, җәйләүдә дә радио юк. Без анда савымчылар белән барыбыз унбишләп кеше. Концерт оештырып җәйләүгә барсалар, нинди күңелле булыр иде.

– Тагын кем нәрсә әйтергә тели? – диде Нурмөхәммәт. Ул инде үзен район культура бүлеге вәкиле сыманрак хис итә башлаган иде. – Иптәш Җәләлов, сез ни диярсез? Биредә сөйләгәннәрнең күбесе сездән тора.

Клуб мөдире урыныннан торып басты да, яртылаш пеләш җирән чәчен янга сыпыргандай иткәннән соң, сүз башлады:

– Монда сөйләүчеләр гел мине генә гаепләп чыктылар. Мин бит, иптәшләр, ни, кушканны эшләргә тырышам. Хәзер урак өсте, уру-сугу вакыты җитте, дип колхоз идарәсе клубны сәгать унбергә кадәр генә ачарга куша. Имам Харисович төн буе клуб янында йөрмәсеннәр, кышка биерләр, ди.

– Унбергә кадәр дә уеннар оештырырга була бит, Фатих абый! Клубта унбергә кадәр дә берни булганы юк, һаман шул домино! – дип кычкырды урыннан гына савымчы кыз. Аңарга кушылып, башкалар да шаулашып алды.

– Кыш көне дә бит берни юк бездә! Бертөрле түгәрәк тә эшләми!

– Иптәшләр, шаулашмагыз әле, – дип дәвам итте Җәләлов. – Кыш көннәрендә драма, хор түгәрәге эшләде. Анысын дөрес әйтмисең, Хәкимулла. Аннан, иптәшләр, мин үзем дә бит тик ятмыйм. Көне буе диярлек ындыр табагында булам. Аннан кайтам да тизрәк клубка йөгерәм. Бүгеннән соң эскәмияләрне җыеп куярмын. Килегез, биегез. Әле менә өч көннән бирле концерт оештырырга теләп йөрибез. Кичә дә репетиция ясый алмадык, кайбер иптәшләр килмәде. Радиоалгычның батареясы бетте. Иртәгә авыл советы районга бара, дип ишеттем, алып кайтырга әйтермен. Концерт оештыруга мин каршы түгел. Әйдәгез, әзерләнәбез дә ындыр табагында, җәйләүдә куябыз. Менә иптәш Мәрдәнов, колхоз радиосы аша да концерт бирергә мөмкин, ди.

Клуб мөдире сүзен бетереп, урынына утырды.

– Иптәш Җәләлов, кәгазь-каләм ал да, кемнәр нинди номер белән катнаша ала, хәзер үк сөйләшеп исемлеген төзергә кирәк, – диде Нурмөхәммәт, яшьләргә карап. – Ягез, иптәшләр, кем нинди номер белән чыгыш ясый ала?

Залда тынлык урнашты. Кайберләре башын аска иде. Икенче берәүләре, як-ягына каранып, үз тәкъдимен кертергә җыенды.

– Мине язygыз, – дип, Камил гармунын алып торып басты.

– Садриева Хәятне җырга язygыз!

– Халисәне язygыз, бик матур бии ул!

– Садыйков Хәкимне язygыз, гармунда да, мандолинада да уйный!

– Рәшит Галимовны җырга язygыз!

– Рәшит белән Хәятне парлап җырлатырга кирәк!

– Камил белән Хәкимне икесен бергә язygыз, берсе гармунда, икенчесе мандолинада уйнарга!

– Хәят белән Сәкинәне парлап җырларга язygыз!

– Концертта катнашырга теләүчеләр егермеләп кеше җыелды, – дип, Нурмөхәммәт урыныннан торып басты. – Бәлки әле җырлый, бии, уйный белүчеләр тагын бардыр? Тартынып торучылар? Әйдәгез, иптәшләр, тартынып тормагыз. Нәфис сүз, декламация белән дә катнашырга ярый.

– Асияне язарга кирәк, ул бик матур җырлый!

– Укытучы Шакир абыйны чакырырга кирәк!

– Әйе шул, Сәгадәт апаны да чакырыгыз! Киләләр алар!

– Иптәшләр, минем шундый тәкъдим бар: әйдәгез, хәзер үк репетиция ясыйбыз, – диде Нурмөхәммәт, яшьләргә мөрәҗәгать итеп. – Мин дә сезгә ярдәм итәрмен. Сез ничек уйлыйсыз?

– Әйдәгез, башлыйк алайса!

– Без каршы түгел, – дип, зал гөр килде. Яшьләрнең күңеле ачылып киткәне күренеп тора иде.

– Алайса башлыйбыз, иптәшләр. Кемнәр исемлеккә керделәр, сәхнәгә күтәрелегез. Калган иптәшләргә таралырга мөмкин.

Репетиция белән Җәләлов үзе җитәкчелек итте. Нурмөхәммәт катнашучыларга көйләр, җырлар сайлауда ярдәм итте. Ошамаган, килешсез урыннарда төзәтте, ничегрәк уйнарга, ничегрәк җырларга кирәген күрсәтте. Бу эштә аңа үзенең шәһәр радиосында концертка катнашып йөрүләре, техникумда алган белемнәре ярдәм итте. Репетиция беткәч, Җәләлов Нурмөхәммәтне иртәгә дә килегез, дип озатып калды.

Алар клубтан таралганда, төн уртасы җитеп килә иде. Яшьләр тарала төшкәнне көтеп, Нурмөхәммәт Хәятне клуб ишеге төбендә каршы алды. Кызга карый-карый, ул Хәят белән баскычтан янәшә төште дә, тышка чыгуга, аны кулыннан алып туры карады.

– Матур җырлыйсың икән, Хәят, моңың да, көең дә әйбәт, тик оялып, тартынып торырга кирәкми. Үзеңне иркен тот. Курыкма. Көең теләсә кемне җәлеп итәрлек.

– Нурмөхәммәт, син бераз торасыңмы әле? – Алар янына гармунын тоткан Камил килде.

– Мин торам әле, – диде егет Хәяткә караган килеш. – Син кайта тор.

Камил гармунын тартып җибәрде дә, уйный-уйный, әкрен генә өйләренә таба атлады. Аңа күрше кызлары иярде. Алар ераклаша төшкәч, Нурмөхәммәт, кызны култыклап, әкрен генә тыкрык буйлап атлый башлады.

– Озаккарак китте, – дип сүз башлады егет. – Ярты төн җитеп киләдер.

– Нигә? Бик әйбәт үтте. Яшьләр дә риза булып, күңелләре булып таралыштылар, – диде кыз, сиздермичә генә егеткә күз салып. – Иртәгә дә җыелабыз, диделәр.

– Иртәгә минсез генә үткәрерләр инде. Бер оешкач, таралмаслар, дип уйлыйм, – Нурмөхәммәт елмаеп караган хәлдә кызның беләгеннән кысып алды. – Әгәр син риза булсаң, мин иртәгә кайтып китәрмен, дип уйлыйм.

– Мин сине мәҗбүри тота алмыйм, – диде кыз, егеткә сораулы карап. Аның карашы: «Нигә китәргә булдың? Тор әле», – дип ялвара иде.

– Юк, Хәят, минем синең яныңнан китәсе килүдән түгел. Дүртне кундым бит инде мин монда. Әни борчылып тора торгандыр. Кайтып, әнине шатландырасым килә. Мин инде сине алырга ат белән килермен. Тик кайчанга киләсен генә ишетәсем килә синнән.

– Кайчанга дип, берсекөнгә ярыймы? – Кыз җитди төскә кергән иде.

– Мин бүген үк алып китәргә дә риза.

Нурмөхәммәт кызны күтәреп алды да, күкрәгенә кысып:



– Менә шулай күтәреп кенә, кадерләп кенә, – дип, аның оялчан йөзенә карады.

– Кирәкми, мин оялам, – диде кыз, егетнең кулларыннан шуып. Егет аны йомшак кына, аягың авыртмасын дигән сыман җиргә бастырды.

– Мин сине менә шул урында көтәрмен, – диде Хәят, бакча буендагы бүрәнәләрне күрсәтеп.

– Караңгы төшкәч, кибет ягыннан килеп керермен дә шунда көтәрмен. Бу аулак тыкрыкта берәү дә йөрми бугай?

– Юк, – диде кыз, – хәзер эш вакыты бит. Халык эштән арып кайта да ял итә. Урамда йөрергә вакыты юк.

– Кадерлем син минем, – диде егет, Хәятне беленнән алып. – Мин әле синең белән тагын бер нәрсә турында сөйләшмәдем. Без бу алдагы кышны ничек үткәрербез икән? Минем бит районда квартирам да юк. Квартирасын табарбыз инде аның, тик нинди квартира буласы билгесез. Әни мине ялгыз калдырма дисә, нишләрбез?

– Тора башлагач сөйләшербез әле. Мин бер кыш кына әниең белән чыгарга да риза. Син бит, Нурмөхәммәт (бу юлы кыз беренче мәртәбә «абый» сүзен төшереп калдырып эндәште), атна саен кайтырсың. Үзем дә синең янга баргалармын. Каршы килмисеңдер бит, яныңа баргаласам?

– Юк, ничек инде җанкисәгем яныма килгәнгә ачуланыйм, ди? Ике куллап каршы алырмын, Хәят. Бик, бик шатланып көтәрмен.

Хәят ике кулы белән дә егетнең беләгеннән кысып алды да, иркәләнеп, башын аның җилкәсенә салды. Егет, кыюланып китеп, кызны кочаклап алып иркәли, чәчләреннән, маңгаеннан үбә башлады. Алар тыкрык уртасында кара-каршы туктап калдылар. Егет кызны үзенә кысып алды. Кыз тыгыз күкрәкләре белән аның күкрәгенә терәлде. Икесе дә хыял диңгезендә йөзде. Гел-гел шулай булыр, гомергә бергә булырлар, гомергә бер-берсен сөеп яшәрләр төсле иде.

Ләкин алдагы көннең ни алып киләсен, иртәгә, берсекөнгә ни буласын, шатлыклы, бәхетле көннәрме, әллә гомер буена йөрәкне телгәләп газаплый торган үкенечме – икесенә дә билгесез иде шул әле. Билгесез иде. Белгән булсалар, мөгаен, алар бүген бер-берсеннән аерылмаган булырлар иде.

Тыкрык башында арба тавышы ишетелеп китте.

– Кайтыйк, Нурмөхәммәт, озат мине, – диде ниһаять уянып киткәндәй күзен ачкан кыз.

Капка төбенә кадәр алар сөйләшмичә генә, кулга-кул тотынып атладылар.

Хәят кинәт кенә егетнең битеннән үбеп алды да:

– Берсекөнне шунда көтәрмен, – дип, капка артына кереп югалды. Нурмөхәммәт «Хуш, тыныч йокы!» дигәндә, кыз инде капка артында иде. Җавап урынына кызның йомшак аяк тавышлары гына ишетелеп торды. Менә ул баскычтан менде, ишек ачылып ябылды.

Күңелсез, ямансу булып калды Нурмөхәммәткә бу минутларда. Йөрәге әрнеп куйды. Моңсу булып китте. Беравык нидер көткән шикелле капка төбендә торганнан соң, әкрен генә кайтып китте. Егет әкренләп тынычланды. Берсекөнгә килеп алам, дигән уй аны кирәгеннән артык тынычландырды бугай. Иртәгә кайтам да әнине берсекөнгә килен кайтасын әйтеп шатландырам. Өйләндерәм, өйләндерәм, дип борчылып йөрүеннән туктар. Кич, караңгы төшкәндә генә килеп, тыкрыкка туктыйсымны Камилгә әйтеп куярга кирәк. Авылны чыкканчы, ул озата барыр. Уйлар... Уйлар...

* * *

Ләкин Нурмөхәммәт Мәрфуга апасының Хәятне яманлап, үз кызын мактап, Фәүзиясенең яшен арттырып сөйләүләрен кызга сөйләмичә бик зур хата ясавы турында уйламады да. Әйе, Нурмөхәммәт, бу турыда сөйләсәм, кыз алдында үземнең дәрәҗәмне арттырырга тырышу була дип уйлап, бик зур хата ясаган иде шул...

Күзләрен ачып җибәрүгә, Нурмөхәммәт, озак йокланган, ахры, дип, кабаланып чалбарын кигәннән соң, чолан ишеген ачып, ишек алдына чыгып басты. Өйдә Мәрфуга апасының кем беләндер сөйләшкәне ишетелде. Ул нигәдер ярсыган иде.

– Фәүзияне димләргә кирәк үзенә. Өч-дүрт көннән бирле клуб янында тикмәгә генә йөрмидер. Авызыңны йомып торма, әйт! Яхшылап, ирләрчә әйтеп төшендер! Җиләк кебек кызыңа менә дигән кияү. Булмаса, Фәридәне чакыртырга кирәк. Әнисенең теләгенә каршы килә алмас.

– Кылларын тарткалап карармын.

Бу Шамил абзый тавышы иде.

– Тартып карармын, имеш, яхшылап сөйлә! Куркып торма! Әллә чит кешеме?

– Үзе теләмәсә, ни кыласың?

– И-и, җебегән, мәхлук булмасаң... Яхшылап сөйләш. Кызны макта! – дип ачуланды карчык.

Нурмөхәммәт түзмәде, ишекне ачты да:



– Хәерле иртә, Шамил абзый! – дип өйгә керде.

– Яхшы әле, энем, үзеңнең хәлең ничек? Яхшы йокладыңмы?

– И-и, Нурмөхәммәт, әйбәт кенә әле. Әллә йокыңнан уяттык инде? – дип, хуҗабикә егет янында юхаланырга тотынды. – Бар, юынып кер дә, самовар кайнаган, хәзер утырабыз, менә базга төшеп менәм дә... Син нәрсә карап торасың, юындыр кунакны, әнә сабын, әнә сөлге, – дип кабаланды карчык. Әйтерсең лә, үзен алыштырып куйдылар. Ну, артистлана белә дә соң, дип уйлап куйды Нурмөхәммәт һәм, сабын-сөлге алып, комган тотып, өй алдына юынырга чыгып китте. Нурмөхәммәт юынып кергәндә, карчык ни өчендер тагын картын тиргәп тора иде. Ишектә егетне күрү белән, кинәт аның йөзе үзгәреп китте:

– Әйдә, кил, Нурмөхәммәт, утыр. Бергә-бергә чәйләп алыйк әле, – диде ул. – Син чакыр кунакны! – дип, картына да кадалып алды.

– Менә монда, түр башына утыр. Тукта әле, астына мендәр салыйм, – дип, түрдәге агач кровать өстеннән мендәр алып куйды.

– Юк, Мәрфуга апа, мендәргә утырырга мин карт бабай түгел бит, – дип, егет каршы төшеп карады.

– Юк, юк, карт бабай булмасаң, син безгә иң якын кеше. Туганлашып та китәрбез әле, аллаһ боерса. Менә әниең, Фәридә ахирәтемне дә, алып килергә иде, бергә-бергә сөйләшеп, туганлашып куяр идек. Йә, тартынып торма, сузыл. Чәеңне сал. Менә каймак салып ясадым. Гаепләмәссең инде, үз кеше. Әллә ни кунак та итеп булмый үзеңне.

Хуҗабикә егет алдына бодай ипие телемнәре куйды, тәлинкә белән майны алдынарак шудырды, пешкән күкәйләр алып куйды.

– Син кыста кунакны! – диде ул картына. Тегесе бер карчыгына, бер Нурмөхәммәткә карап алды да, тамагын кыргалап, әкрен генә сүз башлады.

– Ниме, Нурмөхәммәт, башлы-күзле булу турында уйламыйсыңмы әле?

– Уйлый-уйлый, уйламаган кайда, син, карт тиле, шуны да чамаламыйсыңмы әллә? – дип, хуҗабикә картына ачуланып карады. – Көн дә клубта төн үткәреп бушка гына йөрми инде ул...

– Син, карчык, алай димә әле, ул бит клублар, китапханәләр башлыгы булырга укыган кеше. Үз эше белән йөри торгандыр, диюем.

– Шамил абзый дөрес әйтә, – диде егет. – Кичә яшьләр белән җыелыш үткәрдек. Клубның эшен җанландыру турында, уеннар оештыру, концертлар кую турында сөйләштек. Ахырдан репетиция ясап карадык. Авылыгызда яшьләр күп икән. Укудан кайтканнары да бар иде. Яшьләр

белән сөйләшә торгач, гармунчылар да, җырлаучылар да, биючеләр дә әллә никадәр җыелды. Камил дә катнашачак. Китапханә каршында тора торган Хәят исемле кызның тавышы бик матур. Әйбәт җырлар җырлады, – диде егет. Аннары читләтеп кенә Хәят турында сорау бирде:

– Кем кызы ул Миңнехәят? Казанда торып кайткан, диме шунда.

– Бик акыллы, бик уңган кыз. Әтисе дә, мәрхүм, бик булган кеше иде. Әнисе Кадрия дә уңган хатын. Ул кызны бик матур, акыллы диләр, – дип сөйләп китте карт. – Мин Камилгә шул кызны гына алыйк дигән идем дә, менә апаң, ярлы кеше баласы дип, бик өнәми.

– Өнәми дип, эш миндәмени әле? Әнә, малаең өченче ел чит авыл юлын таптый. Кодалашкач, туганлашкач, хәллерәк кеше баласы булса, яхшырак инде ул, карт. Кодаларга баргач, бер рәхәтләнеп утырырлык йорты-җире булуы хәерлерәк. Кадриянең нәрсәсе бар? Җаны чыкмаган сыеры да, ике баш сарыгы. Йорты-җире, өй җиһазы дисәң, ташка үлчим. Хәяте әле быел гына рәтләп киенеп кайткан, диләр. Алмашка күлмәге дә юк иде.

– Уңган, акыллы кыз, дисез, байлыктамыни эш? Ярлы кешенең анын көнеле бай була... Мин үзем кешене, дус-ишне байлыгына карап сайламыйм. Миңа ул кыз бик ошый. Тыйнак, матур...

– Тукта, тукта, әллә шул хәерчегә күзең төштеме? – Хуҗабикә, күзләрен зур ачып, Нурмөхәммәткә карады. – Тапкансың күз төшәр нәрсә, ул сиңа тиң түгел. Риза да буласы кыз түгел. Тәкәббер ул. Әнисе дә, кыз үзе дә риза булачак түгелләр.

– Әйе шул, бер дә белмичә, сорашмыйча, әллә шуңарга башкода җибәрмәкче буласыңмы? – дип, Шамил карт та сүзгә кушылды. – Юк, булмас, ул начар нәселдән. Башка теләсә кемгә башкода булып барам, Кадрия каршысына бармыйм. Аның ише ярлы, тәкәббер...

– Ул Хәятнең төсе-бите генә бит. Ирен ир итеп тора торган нәрсә түгел. Әни диясе дә юк. Шуның өчен мин аны Камилгә дә әйтеп куйдым. Теләсәң кемне алып кайт, Кадрия Хәяте генә булмасын, дидем.

– Син, Нурмөхәммәт энем, минем иң якын дустымның төпчек малае. Шуның өчен без сиңа яхшылык кына телибез. Ул сиңа тиң түгел. Сүз салсаң да, әллә нигә дә риза түгел, – дип, Шамил карт егетне үгетләүдә карчыгыннан калышырга теләмәде.

Нурмөхәммәт карт белән карчыкның кызны башта мактап, аннары бетереп яманлауларын тыңлап торды да, әйтергәме боларга Хәят белән вәгъдәләшкәнне, әллә белми калулары яхшымы дип, аптырап калды. Ахырда түзмәде, әйтеп ташлады:



– Мин Хәят белән сөйләштем инде, ул ризалыгын бирде.

– Әстәгъфирулла! – Мәрфуга карчык күзләрен зур ачып, ике кулы белән дә итәгенә сугып, сикереп үк торды. – Диваналандыңмы әллә? Сорамый, киңәшми! Сихерләгәндер ул сине! Киңәшәләр аны. Шамил абзаң, иң якын дустымның малае дип, ах итеп тора. Без синең бәхетле булуыңны гына телибез. Шул хәерче кызыннан кала авылда кыз беткәнмени? Ашарга ипиләре, ягарга утыннары юк. Тапкансың күз салыр кеше!..

– Юк, Нурмөхәммәт энем, без ул кызга өйләнергә киңәш бирмибез. Икебез дә каршы ул фикереңә. Әниең дә риза булмас. Кайтып әниең белән сөйләш. Шамил абыйлар шулай дип әйтәләр диген. Аннан әниең белән икәүләп килегез. Әниең, күрә торып, малаемны сез өйләндердегез дип, гомер буе безгә үпкәләп яшәр. Үзе килсен. Без сиңа яхшылык кына телибез. Ашыккансың бит, безнең белән киңәшергә иде баштан. Ул сиңа тиң була торган кыз түгел.

– Әйе шул, үзеңне дә санламас, әниеңә дә көн күрсәтмәс, – дип, хуҗабикә ирен бүлдереп сөйләп китте. – Без сиңа, Нурмөхәммәт, яхшылык кына телибез. Сиңа үзеңне дә, әниеңне дә санга санап, сезнең өчен җан атып тора торган, тормышны кара-каршы алып бара торган, эш ярата торган, әнә безнең Фәүзия кебек уңган кыз кирәк. Кай җире ким аның шул Казан буенда өстерәлеп кайткан Хәяттән? Төсе, буе, дисеңме? Уңганлыгы, дисеңме? Үзеңне кадерләп кенә торыр...

– Әйе шул, гомер буе үзебезгә рәхмәт укырсың, – дип, Шамил карт та өстәп куйды.

– Туктагыз әле, Шамил абзый, Мәрфуга апа, мин сезне аңламый башладым әле. Баштан Шамил абзый Хәятне мактады. Инде хәзер аңа төкереп ташлап, Фәүзиягә күчтегез. Хәят шәһәр буенда өстерәлгән дип, өстегезгә гөнаһ алмагыз. Ул анда эшләп укыган. Фәүзиягә килгәндә, яшь бит әле ул. Унбиш кенә. Кыз булып үсәсе бар...

– И-и, алла колы, унбиш тә тулмаган дип кем әйтте? Көзгә, алла теләсә, унҗиде тула, – хуҗабикә эчә торган чынаягын куеп, ашыгып сөйли башлады. – Менә минем үземне Шамил абзаңа уналты яшьтә биреп җибәрделәр. Үсәсе бар дип тормады. Куенына кергәч, хи-хи, үсәсең ул. Кызларның алды-арты егет кулы тигәч үсә. Бер дә кайгырма, куеныңа кергәч, тоткалый башлагач, хи-хи, үзең дә шатланырсың. Менә Шамил абзаңнан сора. Аннан килеп, Кадрия кызы турында Шамил абзаң белеп сөйләми ул. Яшь кызлар турында каян белсен ул. Аның сүзенә карасаң, Ул Камилне дә шул ялкауга өйләндерергә риза иде...

– Тукта әле, апа, Камил Хәят турында нинди уйда икәнен беләсеңме?

– Белеп торасы юк, ул кыз юньле булса, чит авылга йөрмәс иде.

– Юк шул менә, алай түгел, Камил миңа, минем яраткан кызым булмаса, үзем дә Хәятне сайлар идем, дип үз теле белән әйтте.

– И-и, кара инде бу яшьләргә, диванадыр, билләһи. Дивана булмасалар, шулай эшләрләр идеме? Шайтан саташтырган үзегезне. Шул гына. Шайтан бутаган.

Хуҗабикә, ачуланып, урыныннан ук торып китте. Нурмөхәммәт тә, сөйләшү беткәнгә санап, чынаягын эчкәрәк этәрде дә:

– Булды, рәхмәт! – дип, өстәл яныннан торып, утыргычын читкәрәк алып куйды. Бу юлы башка вакыттагы шикелле, кил әле, тагын ясыйм, аша-эч, оялып торма, дип кыстаучы булмады.

– Аш-су, хөрмәтегез өчен рәхмәт, Шамил абзый, Мәрфуга апа! Сезне борчыганым өчен гаепләмәгез. Кайтырга кирәк, – дип, Нурмөхәммәт юлга җыена башлады.

Хуҗабикә туп-туры басып почмактан чыкты. Аның йөзе кара янган, ачулы. Өстәл янына килеп, самоварны кулына алды да, егеткә усал карап алганнан соң:

– Ярар, бездән әйткән, үзеңә үпкәләрсең, – дип, туп-туры басып почмакка кереп китте. Аннан аның: «Кадер белмәс, кадер белмәс, кара ишәк», – дип сөйләнгәннәре ишетелде.

Нурмөхәммәт яхшы костюмы белән чалбарын сумкага куйды да, ак күлмәктән генә калып, самокаты янына чыкты. Аның арткы камерасына һава өрдерде. Сумкасын артка бәйләде дә яңадан өйгә керде. Ишек төбенә басып, яңадан рәхмәт әйткәннән соң, кире борылды. Хуҗабикә Мәрфуга апа почмактан да чыкмады. Аны Шамил абзый озата чыкты. Егет капкадан чыкканда баскыч өстеннән карап:

– Ярый, Нурмөхәммәт энем, гаепләп китмә! – дип калды.

* * *

– Кайттыңмы, улым? Инде бүген дә кайтмыйсың дип торам, – дип каршы алды Фәридә апа Нурмөхәммәтне. – Әллә ниләр уйлап бетердем.

– Кайттым, әни, миңа ни булсын, – диде егет, самокатын койма буена терәп куеп.

– И-и, улым, алай димә, дус бар, дошман бар. Нәрсә соң, Шамил абыеңнар, Мәрфуга апаңнар исәннәрме? Исән-сау калдылармы?



– Исән-саулар, тик сәлам әйтергә генә онытты лар, – диде егет, әнисенә алар турында сөйлисе килмичә.

– Нәрсә, әллә берәр хәл бармы?

– Бар, әни, бар, әзрәк тын алыйм да барын да сөйләрмен, – диде егет, баз өсте алдына куйган тулы чиләкне алып. – Бераз юынып, җилләнеп алыйм әле.

Фәридә апа малае күлмәген салып торган арада, өйгә кереп, чәй урыны әзерләде дә, тагын аның янына чыкты.

– Әйдә, улым, кер. Чәйләп алырбыз. Син кайтырсың дип, көн дә иртәнге чәемне эчмичә көттем үзеңне. Күңелем белән гел борчылып тордым. Нәрсә соң, улым, ул-бу булмагандыр бит?

Нурмөхәммәт бер чынаяк чәйне бушатып, әнисенә бирде дә, беркадәр эчәсе килгәне басылгач, барган көннән алып ниләр булганын сөйләп бирде.

– Ярар, улым, күңелеңә ошамаган икән, алар кыстый дип, мин дә аларга кушыла алмыйм. Үзеңә ошаганны, үз дигәнеңне алырсың... – дип, улын тынычландырырга тырышты ана.

– Минем анда таныш кызым бар иде, әни, Хәят исемле. Мин аны былтырдан бирле беләм. Хәят белән сүз куешып кайттым. Иртәгә алырга барам. Син ни диярсең?

– Кем соң ул, улым? Кем кызы?

– Бик акыллы, бик инсафлы кыз, әни, күрсәң, үзең дә каршы килмәссең. Сине дә, мине дә санга сугып, ихтирам итеп торырдай кыз. Ярлырак торалар. Әнисе дә, энесе бар. Әтиләре үлгән.

– Ярар, улым, сүз куешкансыз икән, Ходаем тәүфыйк биреп, бергә-бергә матур итеп яшәргә язсын. Иртәгә кай вакыттарак китәрсең икән? Идарәгә барып, ат турында үзем сөйләшеп кайтырмын.

– Кичкә генә барам әле мин, әни. Ул-бу булмаса, сәгать унберләрдән дә соңга калмый кайтып та җитәрбез, – диярга уйлаган иде дә, әни борчылып тормасын әле дип, ул фикерен әйтмәскә булды Нурмөхәммәт. – Син инде, әни, әллә ни әзерләнеп торма. Кешеләр дә чакырма. Кайткач, күз күрер...

– Иптәшкә берәр егет алып бармыйсыңмы соң, улым?

– Нигә, әни? Мин бит кыз урларга бармыйм. Сөйләшкән, вәгъдәләшкән, кирәксә, ярдәм итәргә Камил бар анда.

– Ярый, улым, үзең беләсеңдер инде. Сөйләшкән булгач. Исән-сау әйләнеп кенә кайтыгыз. Тавык суярмын, камыр ашлары пешерермен. Кирәксә, яркасын аннары суярбыз.

– Авылда нинди хәбәрләр бар соң, әни?

– Хәбәрләр дип, мин кая чыгам соң? Кичә Мәрьям җиңгәң генә сөйләп торды, син киткәннең икенче көнендә таң белән Галимә, кызы Сәлимәне ияртеп, күрше авылга Гайшә карчыкка киткәнен күреп калганнар. Галимә икенче көнне генә кайткан. Кызы әле дә кайтмаган икән. Баласын төшертергә алып барганнардыр инде. Акыллы гына кыз кебек иде. Авылда булмаганны эшләп куйды.

– Акыллы булмаган шул, әни, без генә синең белән аны таный белмәгәнбез. Үзе эзләп алган бәла, – диде Нурмөхәммәт, эчә торган чынаягын куеп.

– Шулай да бит, кыз бала кызганыч әле...

– Кызганыч дип, әллә шуны килен итәргә дә ризамы син, әни, хурланмыйча?

– Юк, болай гына әйтүем инде, улым, – диде ана, малаеның йөзендә ризасызлык очкыннары күреп. – Әнисенә охшады, күрәсең, балакай.

– Әнисенә карап кызын коч, әтисенә карап улын коч, дигәннәр бит, Сәлимә дә шулай булып чыкты инде, әни. Галимә апа турында ишеткәнем бар иде шул...

– Кешенең эчен ярып карап булмый шул, улым, карбыз түгел.

Фәридә апа малаена карап алды да тагын сорап куйды.

– Бу Хәят дигәнең ниндирәк кыз соң, улым? Азып-тузып йөргән нәрсә түгелме, сораштыңмы? Ни өчен Шамил абзаң, Мәрфуга апаңнар аңа каршы?

– Әйттем бит инде, әни, үзләренең чебеш кебек Фәүзияләрен биреп җибәрергә телиләр дип. Бер дә азган-тузган түгел, бик оялчан, инсафлы кыз. Әле унсигез дә тулмаган.

– Ярар, улым, ярар. Үзең беләсеңдер инде. Сиңа гомер итәргә бит.

Нурмөхәммәткә бер тәүлек бер елдан озын булды. Бигрәк тә кичне җиткерә алмый аптырады. Кичке алтыларда кара айгырны җигеп кайтып, юлга җыена башлаган гына иде, төньяк-көнчыгыштан кара болыт килеп чыкты да, ул барасы юл ягыннан җилләп-яшенләп яңгыр явып үтте. Яңгыр явып узганны көтеп торырга туры килүе егетнең кәефен бөтенләй төшерде. Юлга чыгар алдыннан яңгыр явуны Нрмөхәммәт бөтенләй начарга юрады. Болай да борчулы йөрәгенә шомлы уйлар кереп урнашты. «Булмады инде бу. Әллә бөтенләй бармаска дамы?» – дип, яңгыр үткәнне көтсә дә, яңгыр үтеп киткәч, күңелендәге шикләрне җиңәргә тырышып, үз-үзен ирексезләп юлга чыкты.



Авылга караңгы төшкәндә генә барып керермен дип, пычрак юлдан атны адымга гына алып барды. Егетнең йөрәгенә юл буена шомлы уйлар кимерде. Аның исәпләве буенча, Хәятнең бер сүзендә дә, бер хәрәкәтендә дә шик юк иде. Хәят чын күңеленнән аның белән сөйләште. Чын күңеленнән яратып йөрде. Тамчы да икеләнмичә ризалык бирде. Көнен дә, тартып-сузып тормыйча, үзе билгеләде. Юк, юкка гына борчылам, юкка гына шикләнеп барам. Хәят андый кыз түгел, дип үз-үзен тынычландырырга тырышты. Әйе, Нурмөхәммәтнең Хәяттән шикләнергә бер сәбәбе дә юк иде. Тик егет Мәрфуга апасының ул китәргә җыенганда ук дулап, ачуланып калуын нигә дә санамады. Мәрфуга апасының үз кызын бирү өчен теләсә нинди дуңгызлык эшләргә әзер булуы ихтималын уена да китермәде.

Караңгы төшеп, эңгер-меңгер бер вакытта айгырын адымга гына атлатып, кибет турысыннан узды да, тыкрыкка кереп, билгеләнгән урынга туктады.

Менә хәзер Хәят караңгыдан йөгереп килеп арбага утырыр да, айгырны чаптырып китеп тә барырлар. Ләкин ни булган? Хәят һаман юк. Йөрәге дөп-дөп тибә. Секундлар, минутлар шундый әкрен узалар, әйтерсең лә, вакыт тукталган. Егет чиктән тыш борчылган хәлдә, атын киртәгә бәйләп, әйләнеп тә килде. Юк, кыз бер җирдә дә күренми. Шулай алдап китердеме икән? Юк, юк, тагын бер кат юк. Хәят андый әшәкелекне эшли алмый. Нидер булган. Әллә әнисе белеп алып кызны чыгармадымы? Өйләренә керергәме әллә? Юк, ярамый. Ничек белергә соң?

Нурмөхәммәт тагын Хәятләргә таба кузгалган иде, Камил килеп чыкты.

– Хәят клубта юк, – диде ул. – Әйдә, мин хәзер аны клубка репетициягә дип чакырып чыгарам.

Тагын тынлык, тагын билгесез көтү. Бераздан Камил борылып килде.

– Хәят иртә таңнан апаларына киткән булган, кайтып җитмәгән, – диде Камил. – Иртәгә кайтыр әле. Әйдә, кайтабыз, – дип, дилбегәне кулына алды.

Нурмөхәммәтнең Мәрфуга апасы каршына бер дә барасы килми иде. Ләкин башка чара юк. Хәят кайтып җитәрмен, дип киткәндер дә, кайта алмагандыр, ерак бит дип, егет кызны иртәгә кичкә кадәр көтәргә булды.

Камил, капканы ачып, атны йортка кертү белән, баскыч өстенә баскан әнисе егетләрне тиргәп каршы алды:

– Диваналар, акылдан язган нәрсәләр, кызы кеше төсле булса ярар иде, бер хәерче артыннан йөрисез. Кайда кызыгыз? Алдап йөртә ул сезне! Кадер белмәс кара ишәк булгач...

– Әни, җитте сиңа, тукта, – диде Камил. – Тавышланма, күршеләрне уятасың. Кешедә синең ни эшең бар?

– Шауламам мена, хурлыксызлар! – дип дәвам итте карчык. – Кара инде бу булдыксызларга, шул хәерче кызы артыннан яхшы айгыр белән килгән бит. Хурланып үләрсең...

– Нәрсә тавышланасың, яхшы түгел, – дип, Шамил карт дулаган хатынын өйгә алып кереп китте.

Нурмөхәммәт көне буе кибет, библиотека тирәсеннән китмичә, кызны көтте. Көне буе өметле һәм шикле уйлар, берсен берсе алыштырып, егетнең күңелен теткәләде. Кич якынлашкан саен Нурмөхәммәтнең борчылуы да арта, өмете кими барды. Баштарак кайтып җитәрмен дип киткәндер дә, кайтып җитә алмагандыр дип, соңга табарак берәр хәл булгандыр, югыйсә болай озак тормас иде. Ни булды икән? Әллә авырып киттеме? Әллә артыннан барыйммы икән? Мин анда барсам, ул кайтып киткән булса? Барып та таба алмыйча кайтырга туры килер, мин анда кемне беләм? Шундый уйлар егетне көне буе җәфалады. Кич булды, көтү кайтты. Кешеләр эштән кайттылар. Урамнар тынып калды.

Хәят икенче көнне дә кайтмады. Күңел түрендә кыз минем белән шаярткан гына, алдаган дигән шик үсә барды. Кич, караңгы төшкәч, алар Камил белән икәүләп Хәятләргә киттеләр. Нурмөхәммәт капка төбендә калды. Камил, өйгә кереп, Хәятне клубка репетициягә чакырган булды. Ләкин ишекне ачмыйча гына:

– Хәят Нурлатка апаларына киткән иде, әле кайтмады, – дигән җавап ишетелде.

– Кайчан кайтасын әйтмәдеме, Кадрия апа?

– Озак тормам, дигән иде. Апасы җибәрмәгәндер, – диде тәрәзә артындагы тавыш. Шул җавапка риза булып, егетләр сөйләшмичә генә тыкрыкка борылдылар.

– Инде нишлисең? – дип, тынлыкны Камил бозды.

– Кайтып китәрмен инде, айгырны бит бер кичкә генә сораган идем, – диде Нурмөхәммәт. – Иртәгә болай гына килергә булыр.

Капка төбендә аларны Камилнең әнисе каршы алды:

– Нәрсә, әллә Хәят өйдә юкмы? Алдап йөртә ул сезне. Йөрисез шунда. Юньле кыз булса, алай хурлап йөрер идеме? Хурлыксызлар. Алдап китергән дә үзе качкан. Сез шул алдакчы артыннан айгыр җигеп йөрисез.



Нурмөхәммәт тә, Камил дә Хәятнең болай кинәт югалуының сәбәбенә төшенә алмадылар. Камил әнисенең соңгы сүзләре егетләрдә Хәят безне алдап йөрткән дигән фикерне ныгыта гына төште.

Ә бер көн элек, Нурмөхәммәт кайтып киткәч, мондый хәл булып узган иде. Алдырыр – көн яздырыр, диләр бит. Нурмөхәммәт белән дә ул көнне шулай булды. Кайтып китәргә ашыкты. Тагын ярты гына сәгать торырга иде. Ярты гына сәгать. Барысы да тәртиптә була иде.

Нурмөхәммәт кыр-капкадан да чыкмаган иде әле. Хәят ашыгып өйләреннән чыкты да, егет күренмәсме дип, кибеткә таба үтте. Киткәнче бу яктан әйләнеп китәр әле Нурмөхәммәт дип, аны күрергә өметләнеп, кибет каршысында басып торды. Кибеткә кереп, бераз әйләнгәләде дә, аннан тагын урамга чыкты. Көтеп-көтеп тә күренмәгәч, урамда очрамасмы дип, кире китте. Арт урамга чыккач, әкрен генә барды. Киткәнче безнең яктан әйләнеп чык, дип кичтән әйтә алмавы өчен үзен тиргәде. Гармунчы Шамилләргә якынлашкан саен, кызның адымнары кыюсызлана, әкренәя барды. Нурмөхәммәт абый киттеме әллә дип, бер дә булмаган йортка барып керергә оялды. Шикләнүләре артты. Барыргамы, керергәме-юкмы дип, капка төбендә тукталып икеләнеп тора иде, урамнан килгәндә үк күреп алган Мәрфуга карчык, бирим дигән колына чыгарып куя юлына дип, ашыгып капка төбенә чыкты.

– Миңнехәят, балакаем, син түгелме соң бу? Әйдә, кер. Нишләп капка төбендә торасың? Әйдә, кер. Сөбханалла, күз тимәсен үзеңә, – дип, кызның зифа буена, моңсу, тыйнак карашына игътибар итте. Капканы ябып, эчке якта калу белән:

– Әйдә, кер, әле ничек итеп үзеңне күрим, әллә Кадрия янына үзем барыйммы дип, аптырап тора идем, – дип, такмаклый-такмаклый кызны өйләренә алып керде.

Кыз берни дә аңламастан тирә-якка каранды. Аның күзләре Нурмөхәммәтне эзли иде. Егетнең өйдә дә юклыгын күргәч, киткән дип борчылып куйды.

Хуҗабикә почмактагы самоварын кайнатырга куйды.

Хәят ул арада исенә килеп:

– Мәрфуга апа, теге районнан килгән абый кайда? Аны клубка чакырырга килгән идем, – дип, килүенең сәбәбен дә табып өлгерде.

– Кемне әйтәсең? – дигән булды мәкерле карчык.

– Нурмөхәммәт абыйны, клубка чакырганнар иде.

– Китеп барды шул ул, юньсез җан. Дүрт көн кунак булды, рәхмәт тә әйтмичә чыгып китте. – Мәрфуга йомшак кына басып почмактан чыкты да кызның каршысына ук килеп утырды.

– Ниме, Миңнехәят, кайдан беләсең син ул ирне?

– Нишләп, ул өйләнгәнмени, Мәрфуга апа? – диде кыз, аптырап, карчыкка караган килеш.

Карчыкка шул гына кирәк иде. Ул кызның күңеленә бик тиз шик сала алды.

– Әле тегендә, укыган җирендә, марҗасы да бар түгелме икән? Килгән көнне эчеп исергәч, Шамил абзаңа шулай дип мактанып торды. Син соң, балакай, шул мактанчыкка ышанган идеңме?

Кыз телен әйләндереп бер сүз дә әйтә алмады. Аның бөтен йөзе, муеннарына кадәр кызарып чыккан иде. Ул бары тик, «әйе» дип, башын гына кага алды.

– И-и, бала-бала, кем дип алдады соң ул үзен? Йә, оялып торма! Шәт, әле мин андый, мин мондый дип мактангандыр? Кем баласы дип сөйләде соң ул сиңа?

Хәят ни белгәннәрен сөйләп бирде. Аннары өстәп куйды:

– Ул үзен Әкълимә Мәрдәновнаның энесе дип таныштырды. Өйдә әнием дә, өченче класста укый торган сеңлем бар, диде...

– Син шуңарга ышандың инде? Алдый ул. Ирләр алар кайда барсалар да, үзләрен егет дип йөриләр. Укытучы Әкълимәне мин бик беләм. Ул безгә килеп, аралашып йөри иде. Үткен, эшчән... Бу егет аның чыбык очы гына булыр. Йә әле фамилияләре генә бердер. Аның әнисе янында да өч кияүгә чыкмаган апасы бар. Канынны эчәрләр. Әнисе дә аждаһа кебек нәрсә. Юк, ул сиңа бер ягы белән дә килми. Аннары шунысын да әйтим әле: ул укыган кеше, районда нәчәлник булам дип мактанган булды. Укыган кеше – чукынган кеше, диләр бит. Ул сиңа тиң түгел...

– Апа, мин бит аны ышандырып җибәргән идем, – диде кыз, аптырашта калып. – Ул иртәгә мине алырга килә. Нишлим икән?

– Киңәшми-нитми шулай эшлиләрме инде, балакаем? Әниеңә дә әйтмәдеңме?

– Әйтмәдем шул. Мин бит Нурмөхәммәт абыйга бик ышанган идем...

– Менә инде, дивана дими, ни диярgә сезне? Егетләр күрәсез дә дөньягызны онытасыз, – диде карчык, үзенең ялгыш «егет» дип әйтүен сизми дә калып. – Аның төче теленә ышанырга ярыймы соң? Сине алырга киләсен сизенгән идем шул. Әле ике ат белән, егетләр төяп килергә җыена түгелме? Исәпләре, син риза булмасаң, урлап китү, ахрысы. Сак бул. Йә берәр җиргә китеп тор. Атна-ун көн китеп торырга кирәк сиңа. Менә минем киңәшем шул. Кара аны, харап була күрмә, шул буең, шул чибәрлегең белән...

Кызның бу кадәр көтелмәгән хәлдән башы әйләнгән иде. Ничек ышанмыйсың. Ышанды Хәят. Сыналмаган мәхәббәт сыек тал кебек, бик тиз бөгелеп төште кыз. «Мин бит аны үзенең сөйләве аша гына беләм, ә ул мине шулай алдаган. Кем уйлаган шулай буласын...», – дип, үкенеп тә куйды.

Кызның аптырашта калганын күргәч, Мәрфуга тагын да дәвам итте:

– Кайгырып торма. Апаң Нурлатта түгелме соң? Тот та, шунда китеп бар. Кайда киткәнеңне әниең генә белсен. Берәүгә дә сөйләмә. Килеп эзләп йөрерләр дә китеп барырлар.

Хәят, елар дәрәҗәгә җитеп, урыныннан торып басты. «Нишләргә? Әллә өйдә генә торыргамы, беркая да китмәскәме? Килсә, күренмәскә. Әллә үзен күреп сөйләшергәме?»

– Нишлисең инде, кызым? Бүген үк китеп барсаң, хәерлерәк булыр, – диде карчык, кызның икеләнеп торганын күреп.

– Бәлки, беркая да китмәскәдер? – диде кыз аптырап. – Өйдән чыгып йөрмәсәм, берни булмас.

– Дивана, өйдән чыкмыйча тора аласыңмы? Син бит яшь бала түгел. Ишектән чыгуың булыр, үзеңне эләктереп алырлар да алып китәрләр. Юк, бүген үк апаларыңа китеп бар. Югыйсә, мин әниең белән барып сөйләшәм.

– Юк, юк, апа, зинһар әнигә әйтеп аны борчый күрмәгез. Белми калуы хәерлерәк әнинең. Ярар, алайса мин хәзер кайтып, әни белән сөйләшәм дә иртәгә таң белән апаларга китеп барам.

– Шулай ит, кызым, шулай эшләсәң, ышанычлырак булыр, – диде карчык, кайтырга дип кузгалган кызны озата чыгып. – Алай-болай безгә килсәләр, мин белермен аларга нәрсә әйтергә. Оятсыз, ир башы белән җиләктәй кызларны алдап йөрмәсен!..

Теләгемә ирештем, дип тантана итте карчык.

* * *

– Айгырны җигәбез, – диде Нурмөхәммәт, капкадан керү белән. – Син арбаны чыгар, Камил!

Камил лапас астыннан арбаны тәртеп чыгарды. Нурмөхәммәт айгырны җитәкләп чыкты да, камыт кигезеп, тәртә арасына кертте.

Мәрфуга апа:

– Фәридәгә сәлам тапшыр, кунакка килсен, – диде дә, өйгә кереп китте. Егетләр, икәү генә калып, ат җиктеләр. Нурмөхәммәт дилбегә тотып арбага утыргач, Камил капканы ачуы булды, ял иткән айгыр капкадан йөгертеп алып чыгып китте.

Эх, аты нинди... Кызы гына юк, дигән уй егетнең йөрәген өтеп алды. Килеп туган хәлдән егетнең зиһене чуалган иде. «Нигә болай килеп чыкты соң әле? Кай җирдә ялгыштым?»

Хәят алдап йөрткән дигән фикер белән аның әле дә килешәсе килми иде. «Монда нидер бар», – дип уйланды. Ләкин үзен белгәннән бирле кунакка йөрешкән ахирәт дус Мәрфуга апасыннан шикләнергә уена да килмәде. Югыйсә Мәрфуга апасының үз кызын мактап, клубка йөргән Хәятне яманлап ташлавыннан ук нәтиҗә ясарга тиеш иде егет. Тик ул үз үлчәве белән үлчәде һәр кешене. Үзе кешегә яхшылыктан кала берни дә теләмичә, үзенә уңайсызга, үзенә авырга килсә дә, башкаларга яхшылык кына эшләргә өйрәнеп үскән булганлыктан, үзенә карата да шулай булырлар дип ышана иде. Ул һәркемгә ышанып карады. Әти-әнисе дә шундый кешеләр. Барлык кешеләр дә шулай булырга тиеш кебек иде аңа. Шуның өчен кече яшьтән үк әти-әнисе белән дус булып, аралашып яшәгәннәрен күреп үскән Нурмөхәммәт бу очракта да Мәрфуга апасына ышанып карады. Аның үз кызын тагып җибәрү өчен шундый дуңгызлык эшләве ихтималын башына да китермәде.

«Инде нишләргә? Иртәгә үк барыргамы? Иртәгә дә кайтмаса? Әнисе бит, апасы җибәрмәгәндер, дип җавап бирде. Юк, бер-ике көн торырга кирәк... Әни дә борчылып беткәндер инде». Кичке унда әйләнеп кайтырга дип киткән кеше, бер тәүлек торып, буш кайтамы. Ярый әле көндез түгел. Кыз алырга китеп, буш кайтуымны күрүче булмас. Каршы чыгып, кайда кызың дисәләр, хурлыгы ни тора...

* * *

Тәрәзәдән күзләрен алмыйча, төрле шомлы уйларга чумып, чиктән тыш борчылып малаен көткән ана, Нурмөхәммәт капкадан кергәнче үк, йөгереп каршы чыкты. Аның төсе киткән иде.

– Улым, бәбкәм, исән-сау кайттыңмы? – дип, Фәридә апа малаеның күзләренә текәлде. – Атың кайда?

– Борчылма, әни, ат исән-сау, дворга тапшырып кайттым. Әйдә, өйгә керик, – дип, Нурмөхәммәт әнисен җитәкләп алды.



Алар сөйләшмичә генә өйгә керделәр. Өйгә кергәч тә, ана малаена туры-туры карап алса да, ни булды, улым, кызың кире булганмы әллә дип, бер авыз сүз дәшмәде. Чәйгә утыргач, үзе сөйләр әле дип, сабыр итте. Чәй урыны әзерләде. Килен кайтса, дип пешереп куйган мич ашларын өстәлгә куйды. Чәй ясады. Нурмөхәммәт юынып керү белән аны чәйгә чакырды.

– Бусы күкәй белән суган кушып, бусы җиләк кыстырып пешергән, – дип, малае алдына кызарып пешкән пәрәмәчләр куйды. – Ачыгып беткәнсең инде, улым, аша! – дип, тамактан калган малаен кыстады. Нурмөхәммәт бер-ике чынаяк чәй эчеп сусавын басканнан соң кына сүз башлады:

– Син дә борчылып беткәнсеңдер инде, әни, юлым уңмады шул, – диде егет, өченче чынаяк чәйне бүлә башлап. – Хәятне алып кайта алмадым. Юлга чыгар алдыннан яңгыр явып киткәч үк күңелем шикләнде. Яхшыга юрамаган идем мин ул яшенле яңгырны. Хәят кичә иртә үк апаларына Нурлатка киткән булган. Нишләптер бүген дә кайтмады. Әллә инде апасы кирегә булганмы? Болай үзе бик риза булып, килү вакытын да үзе әйтеп калган иде. Ни булгандыр. Атны да кирәксенерләр, син дә борчылып торырсың дип, кыз кайтканны көтмәс булдым...

– Ярар, улым, кайгырма, – диде Фәридә апа, улының борчулы йөзенә карап. – Кызлар алар күлдәге камыш кебек, кайдан җил исә, шул якка авалар. Әнә Куртай Хәмитенең кызы кичтән Хәкимҗанга ышандырган, ә үзе төнлә күрше авыл егетенә ябышып чыккан. Сезнең дә шулай булганмы, улым? Бер дә борчылма. Дөнья кысыр түгел. Әле яшең дә аллага шөкер. Үз дигәнең, күңелеңә ошаганы килеп чыгар әле. Тынычлан, сабыр ит...

– Бер-ике көннән барып кайтырмын әле, әни. Бәлки, берәр сәбәп килеп чыгып, кайта алмый калгандыр, – диде малай, әнисен бүлдереп.

Фәридә апа:

– Шулай инде ул, бер уңмагач... Сәлимә дип йөрдең, анысы алай булды. Инде Хәят дигәнең болай булган. Бер булмаса, гел булмый, – дияргә уйлаган иде дә, баламның күңелен төшермим, җан биргәнгә җүн бирер, дип тукталып калды.

* * *

Җанын кайда куярга белмичә ике көнне көчкә уздырды Нурмөхәммәт. Ни эшләсә дә, уенда гел Хәят булды. Кулы эшкә бармады. Ике елдай тоелган ике көнне көчкә үткәргәннән соң, самокатын алды да тагын

Әлмәткә юл тотты. Бу килүендә ул туп-туры Хәятләргә килеп туктады да, самокатын капка төбенә сөяп куйганнан соң, капканы ачып кергән иде, ишекнең йозакта икәнен күрде. Күңелсезләнеп, кире капка төбенә чыкты. Бераз тирә-якка карап басып торган иде, бер үсмернең үзенә таба килгәнен күрде.

– Абый, сезгә кем кирәк? – диде малай, бер егеткә, бер аның самокатына карап.

– Син, энем, шул йорттанмы? – диде егет бу Хәятнең энесе булырга ошый дигән уй белән.

– Әйе, шул йорттан, – диде малай, Нурмөхәммәткә караган килеш.

– Хәятне күреп чыгыйм, дип килгән идем. Кайттымы апаң? – дип, егет ике күзе белән малайга текәлде.

– Ул Казанга китте, абый.

Нурмөхәммәтнең башына тукмак белән суктылармыни. Күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Ул көчкә:

– Кайчан? – дия алды.

– Өченче көн кич апалардан кайтты да кичә иртә белән...

Малайның соңгы сүзләрен әллә ишетте, әллә юк.

– Эх, – дип куйды ул, үз-үзен тыя алмыйча, – кичә киләсем калган. Әрнү, үкенү газабы белән самокатын алды да урыныннан ук чаптырып китеп барды. Малай бу нинди абый булды дип уйлап өлгергәнче, ул инде тыкрыкка кереп югалган иде. Нигә соң мин кичә, өченче көн килмәдем, дип үкенде ул.

«Ул мине яратмаган. Яратса, кеше сүзе белән миннән шулай качып йөрмәс иде. Үземне күреп аңлашырга да мөмкин иде бит. Миңа берсекөнгә кил дип җибәрде дә, үзе әллә кайда качып киткән. Мин, җүләр, кыз алырга барам дип, колхозның нәсел айгырын җигеп чаптым. Э-э-х, Хәят, Хәят, мине ничек хурлаганыңны беләсең микән?» Егетнең күңелендә кинәт ачу хисләре кайный башлады. «Әни дөрес әйтә шул, кызлар күлдәге камыш кебек, кайдан җил исә, шул якка авалар, дип. Вәгъдәләшкән кызым бар, дип кайткан идем, Сәлимәсе алай булып куйган... Җитмәсә тагын нindидер Никифордан булган авырын мыштым гына миңа тагарга йөрде. Ярый әле Нияз дус күзне ачып өлгерде... Инде Хәяте ышандырды да үзе качып китеп барды. Бу нинди хәл соң? Нигә язмыш минем белән шулай шаяра?»

Кинәт аңа бик эссе булып китте. Үзе дә сизмәстән, самокатын уң якка борып алды да Түбән очка, су буена төшеп китте. Урам башындагы елга буена килеп туктады да, самокатын чирәм өстенә яткызып, костюмын салып куйды. Башындыгы кепкасын салып, җилләнә-җилләнә яр читенә килеп басты. Кай тирәдәрәк коеналар икән дип, бераз тир басылганчы яр читенә аякларын салындырып утырды. Уң яктарак суда чупырдашкан казларга карап тора иде, артта чиләк чылтыраган тавыш килде. Аяк тавышлары якынлашканын ишетеп, Нурмөхәммәт артына борылып карады.

Түгәрәк ак йөзле, биленә алъяпкыч япкан кыз, уң кулын көянтә өстенә салып, суга килә иде. Килеп җитәрәк ул бераз сулдарак торган басмага таба борылды да, егеткә карый-карый, сакланып кына яр астына төшә башлады. Төшеп җиткәч, басмага керер алдыннан, тагын бер кат яр читендә утырган егеткә карап алды.

Бу Җәүһәрия иде. Бирим дигән колына – чыгарып куя юлына. Нурмөхәммәт, кызны танып, ашыгып урыныннан торды да, йөгереп төшеп, басма янына басты.

– Исәнмесез, Җәүһәрия! Әллә танымадыгыз инде?!

Кыз, басма өстенә куйган бер чиләген кулына алып, егеткә таба борылды. Сөбханалла, Җәүһәрия тагын да чибәрләнгән, җиләктәй өлгергән, ләбаса дип, егет, сихерләнгән кеше шикелле кыздан күзләрен ала алмыйча, карап тора башлады.

– Исәнмесез, Нурмөхәммәт абый! – диде кыз, төпсез күк йөзе шикелле күзләре белән сөйкемле карап, – танымаган идем дә, инде таныдым. Нишләп монда утырасыз? – диде кыз, «утырасыз» сүзен елмаеп һәм сузыбрак әйтеп.

– Бик нык тирләгән идем, Җәүһәрия, әллә су коенып чыгаргамы дип торам, – диде егет, елмаеп торган кыздан күзләрен алмыйча. – Менә сезне дә күрергә насыйп булган икән. Югыйсә ничә килеп күрә алмаган идем.

– Мин берничә көн өйдә булмадым шул, абый. – Кыз аз гына су алып, чиләген чайкап түкте. – Нигә үзебезгә кермәдегез соң?

Кыз шундый серле итеп, үз итеп карады. Әйтерсең лә, алар күптәнге танышлар.

– Мин Шамил абзыйларга төшкән идем. Сезгә, әллә ничек, яхшысынмадым. Ислам абзый, Кәүсәр апа нишләп торалар, исән-саулармы?

– Исән-саулар, әле кичә генә әни сезне искә алып торган иде. Нурмөхәммәт килгән булган икән. Нишләптер хәзер безгә керми башлады. Әкълимә апасын сорашырмын дигән идем, ди, кереп чыгыгыз, абый...

Нурмөхәммәт Әкълимә апасы биредә укытканда берничә мәртәбә апасы янына килгән иде. Ул вакытта Әкълимә апасы Ислам абзыйлар-

да квартирада тора иде. Апасы моннан киткәч тә, бер мәртәбә булды ул Җәүһәрияләрдә. Өченче ел Әкълимә апасы элеккеге квартира хуҗасына кечкенә генә бүләк җибәргән иде. Шуны кертеп чыккан иде Нурмөхәммәт ул җәйне. Җәүһәрия әле ул вакытта уналты яшьләрдә генә булгандыр. Хәзер әнә җиләктәй пешеп җиткән, сокландыргыч чибәр кыз булган. Ул елны ук Нурмөхәммәт Җәүһәриядә үзенә ошый торган күркәм сыйфатлар барын күреп, ярый торган кыз буласы бу дип, күңеленә беркетеп киткән иде.

– Турыгыздан узган саен күңелем белән сезне күрәсем килеп үтсәм дә, кереп чыгарга яхшысынмадым, Җәүһәрия, – диде егет, басма өстендә буш чиләк тотып басып торган кыздан күзләрен алмыйча...

Кыз икенче чиләгенә дә су чумырып басма өстенә куйды. Чиләкләрен көянтәгә элеп, җилкәсенә алды. Басмадан чыгып берничә адым атлаганнан соң, егет янында тукталып калды. Ул, егеттән бераз тәбәнәгрәк булса да, тау өстендәрәк булганлыктан алар тигезләштеләр. Җәүһәрия ике кулын як-якка көянтә өстенә салып баскан килеш кыйгач кашлары астыннан Нурмөхәммәткә күз салды. Шунда аларның карашлары очрашты. Егет керфекләр астындагы нур балкып торган бу күзләрдә тылсымлы сөйкемлелек, нindiдер эчкерсез якын күрү, ярату билгеләре күреп алды. Җәүһәриянең шул сөйкемле күз карашы егеткә кыюлык өстәде.

– Кереп чыгыгыз, Нурмөхәммәт абый. Хәзер кайтам да чәй куям. Чәй эчеп, ял итеп китәрсез. Әни дә шатланыр.

– Ярар, Җәүһәрия, керермен. Менә бераз коенып алам да керәм, – диде егет, мөмкин кадәр ягымлы, игътибарлы булырга тырышып.

Кызның күз карашында канәгатьлек билгеләре сирпелеп китте. Ул ашыкмыйча гына яр өстенә менде дә, бөтен гәүдәсе белән борылып басканнан соң:

– Керегез, абый, көтәрбез! – дип, тагын бер нур сибеп алганнан соң, егетнең йөрәгенә ут салып, бөгелә-сыгыла китеп барды.

Нурмөхәммәтне үзе дә аңламаган яңа тойгы биләп алды. Кызның үз итүе, сөйкемле карашы күз алдыннан китмәде. Күңел түрендә якын күрү, ярату билгеләре уянган кебек булды. Килгән вакытларда туганыдай каршы алган Кәүсәр апасының кызы булуы егетнең күңелендә Җәүһәриягә карата булган якынлык хисләрен тагын да көчәйтеп җибәрде. Кызның матурлыгы өстенә, үткенлеге Нурмөхәммәткә тагын да ошый төште. Ул үзенең баштан ук Ислам абзыйларына төшмәгәненә үкенеп тә куйды бу минутларда.



* * *

Капка төбендә Нурмөхәммәтне Җәүһәрия каршы алды.

– Әйдәгез, абый, керегез. Инде кермичә китеп баргансыз дип чыккан идем, – диде кыз, шат күңел белән капка ачып.

– Менә инде, бер ышандыргач кермичә китәргә, мин ул кадәр вәгъдәсез кеше түгел.

Егет самокатны эчке якка, капка буена сөяп куйды да сумкасын чишеп ала башлады. Баскыч өстендә Кәүсәр апа күренде.

– Исәнмесез, Кәүсәр апа!

– Әйбәт кенә әле, Нурмөхәммәт, үзең исән-сау йөрисеңме? Әниең, апаларың ни хәлдә? Әйдә, өйгә кер, Нурмөхәммәт. Кызым, чакыр абыеңны! Мин хәзер, базга гына төшеп менәм, – дип, хуҗабикә, баскычтан төшеп, кар базына таба китте.

– Әйдәгез, абый, өйгә керәбез.

Җәүһәрия, баскычтан менеп, ишек алды ишеген ачты да, елмаеп, егетнең баскычка менгәнен көтте. Аннан соң җитез генә алга үтеп, өй ишеген ачты. Алар өйгә керделәр.

– Узыгыз, абый, утырыгыз, – диде кыз, кунакка урындык тәкъдим итеп. – Тирләгән булсагыз, костюмыгызны салыгыз. Бирегез кепкагызны, – дип, Җәүһәрия утыргычта утырган егетнең башындагы кепкасын алырга үрелде. Кызның калын толымнары талпынып егетнең борын төбенә үк килеп бәрелә язган мизгелдә Нурмөхәммәт хушны алырдай татлы истән кызны кочып алырдай булып ымсынып китте.

Кәүсәр апа баздан алып чыккан әйберләрен өстәлгә китереп куйды. Почмактан самовар күтәреп Җәүһәрия чыкты. Берничә минут эчендә өстәл әзер булды. Чәйгә чакырдылар. Җәүһәрия Нурмөхәммәткә түрдә урын күрсәтте. Егет белән янәшә урын алып, үзе чәйләр ясый башлады. Хуҗабикә, өстәлнең икенче башына утырып, кызым, тегеләй ит, болай ит, абыең алдына тегене куй, моны куй, дип торды. «Нурмөхәммәт, тартынып торма, аша, маена, кортына сузыл. Кызым, кыста кунак абыеңны!» – дип өстәде. Җәүһәрия егеткә күз салып алган саен, аның үзенә карата игътибар иткәнен сизеп:

– Абый, ашагыз! Бирегез, чәегезне яңартам, – дип торды.

Кәүсәр апа егеттән энисе Фәридәне, олы апасы Әкълимәне сорашты. Нурмөхәммәтнең үзе белән дә кызыксынды. Әкълимә апасының киң күңелле, бик булдыклы, тырыш укытучы булуларын исенә төшереп сөйләде. Бер-ике чынаяк чәй эчеп, сорашып, сөйләшеп утырганнан соң, хуҗабикә урыныннан торды да:

– Кызым, син кунак егетен кара, ашат, эчерт! Минем күршедә йомышым бар иде, – дип чыгып китте.

Кыз белән егет икәү генә калдылар. Кәүсәр апасының чыгып китүен Нурмөхәммәт, яшьләрнең сүзләре булса, сөйләшсеннәр, мин комачауламыйм дип, үзләренә ирек бирү теләге белән шулай иткәнен аңлап алды.

Әнисе чыгып китүдән, кыз уңайсызланып калмады. Әнисенең капка ябып чыгып китүен күрү белән, егеткә бер күз төшереп алды да:

– Абый, юлдан сусап килгәнсез, менә каймаклы катык, сусауны бастыра, – дип, катык савытын егетнең алдына ук күчереп куйды. Янында ук чын күңелдән кыстап утырган бу чибәр җан иясе Нурмөхәммәткә торган саен ошый бара иде. Ул сокланып карап торганда, кыз шул игътибарлы карашны тоеп башын түбән ия. Йә булмаса, карашын читкә ала да аннан тагын кыйгач кашлар, сылу керфекләр артына яшеренгән күк йөзедәй серле зәңгәр күзләре белән бер нур сибеп ала. Кайвакытта аларның карашлары очраша. Егет кызның нурлы күзләрендә сөйкемле, нindидер өметле, үз итеп нур сибелеп торганын тоя. Шунда ул янында ук, терсәкләре бер-беренә тиярдәй булып торган кыздан күзләрен ала алмый, ашаудан калып тора.

– Абый, нигә ашамыйсыз? Чәегез суынып бетте. Катыгын да капмыйсыз, – дип, кыз сул кулы белән егет алдына корт белән майны этәрә башлаган иде, егет:

– Мин, Җәүһәрия, сине күреп кенә дә туйдым инде. Рәхмәт, кыстама, – дип, уң кулы белән кызның сул кулын тотып алды. Кыз кулын тартып алмады. – Күргәнче болай ук түгел кебек иде, Җәүһәрия.

Кыз башын күтәреп егеткә карады.

– Күрдем дә, исем китте. Үскәнсең, матурлангансың, әллә, мин әйтәм, өлешемә тигән көмешем шулмы икән? – диде егет, бөтен кыюлыгын җыеп.

– И, абый, әллә кемнәрең бардыр әле, – диде кыз, егеткә елмаеп.

– Әллә кемнәрем юк шул, Җәүһәрия. Дөресрәге, бар иде, инде юк.

– Нигә, абый, ачуланыштыгызмы?

– Ачуланыштык, ул башкага алданган.

– Шулай укмыни? – Кыз, гаҗәпләнеп, егетнең күзләренә карады.

– Шулай ук, Җәүһәрия. Синең ничек, бармы берәр күзең төшкән егетең? – диде Нурмөхәммәт, кызга ягымлы караш ташлап.

– Юк дисәм дә ярый, – диде кыз, башын түбән иеп. – Җиденчедә укыганда бер малайга күзем төшеп, ошатып йөргән идем, ул читкә китте дә, шунда бер украин кызынамы өйләнгән, ди.



Җәүһәриянең битләре алланып чыкты.

– Әгәр мин сиңа тәкъдим ясап, гомергә бергә булыйк, Җәүһәрия, дисәм, ни диярсең? – Егет кызның кулын кыса төшеп, үзенең аны якын күргәнлеген аңлатырга тырышты.

Җәүһәрия, башын күтәреп, егеткә бер карап алды да:

– Белмим шул, кинәт кенә? – дип куйды.

– Соратып алыйммы әллә? Ышан миңа, Җәүһәрия, мин сине бәхетле итәр өчен бөтен тырышлыгымны куярмын...

– Юк, абый, сорату кирәкмәс. Әтинең исәбе мине авылда берәүгә бирү. Мин ул мокытны яратмыйм. Ошамый ул миңа. Әни дә ул егеткә каршы. Уйлашыйм әле.

– Шулаймы, Җәүһәрия? – Егет, кызны кочып алырдай булып, ике кулыннан үзенә таба тарта төште дә аның күзләренә карады. – Димәк, риза?

Кыз башын түбән иеп Нурмөхәммәтнең күкрәгенә салды.

– Риза, – диде ул, йөрәк түреннән чыккан тавышын Нурмөхәммәт кенә ишетерлек итеп. – Кичкә, урамга чыккач, соңгы сүземне әйтермен.

Кыз бер мизгел сүзсез генә егетнең йөрәк тибешен тыңлагандай булды да:

– Хәзер барыгыз, абый, чыгыгыз. Әти кайта башлар, – дип, торып басты. – Әни дә өйдә юк, яхшы түгел. Кич без бүрәнәләр өстенә җыелабыз, – дип, почмакка кереп китте.

Егет костюмын киеп китәргә җыена башлады.

– Рәхмәт, Җәүһәрия, сый-хөрмәтегез өчен, Кәүсәр апага да рәхмәтемне тапшыр, – дип, өйдән чыгарга җыенганда, кыз дулкынлануын җиңеп, кояштай яктырып, Нурмөхәммәтне озата чыкты. Капканы ачып, егетне чыгарганда:

– Кемнәрдә кунасыз, абый? – дип, тагын бер нур сибеп алды.

– Камилләрдә кунармын дип торам, – диде егет, – йә, сау булып тор, кич күрәм, Җәүһәрия.

Кыз, урам ягына чыгып, як-ягына карады да Нурмөхәммәтнең самокатка утырып киткәнен карап торды. Аннары капкадан кереп югалды...

* * *

Нурмөхәммәт көтү кайтканда ук Камилләр капка төбенә чыгып утырды. Көтүләр кереп, урамнар бушый башлаганда гына Камил, эштән кайтып, аның янына утырды. Бер-берсенең хәлләрен сорашканнан соң, Камил кереп китте. Нурмөхәммәт кичке чәйдән баш тартып, капка төбендәге

эскәмиядә калды. Кичке тынлыкны тыңлап, як-ягына карангалап көтеп утырулары аңа ләззәтле дә, озак та булып тоелды. Хәят турында уйламаска тырышты. Егет үзенең чынлап торып кабынып җитмәгән Хәятне сөю хисе, ах итеп, Нурмөхәммәт абый дип, янында бөтерелеп йөргән Җәүһәриянең үткенлеге, нур чәчеп торган карашлары артына кереп югала башлаганын сизде. Миңа дигән асыл зат шул үзедер инде дип, өйләнү турындагы уеның уңышлы килеп чыгарына егет беркадәр куанып та куйды. Үз авылларындагы аңа өмет баглап йөргән кызларга игътибар итми, чит авылдагы таныш кызлары янына йөрүне, кыз алырга дип, колхозның нәсел айгырын җигеп киткәнен белеп калган кешеләрнең, Нурмөхәммәт кызны алып кайта алмаган, буш кайткан, кызы борынына чиртеп җибәргән, имеш, дип сөйләүләргә чик куеласына ышана башлаган иде. Кинәт аның күз алдына, өстәл янында үзен сыйлап, тылсымлы нур чәчеп торган карашлары белән шатландырып утырган Җәүһәрия килеп басты. Караңгы иңә башлау белән, үзе көтеп утырган асыл кошның тизрәк килеп чыгуын көтте.

Менә Җәүһәрияләр ягында капка ачылган тавыш килде. Бераздан кемнәрнеңдер мөлдер-мөлдер сөйләшкәннәре ишетелеп китте. Шуның артыннан ук эңгер-меңгер эченнән бире таба килгән аяк тавышлары ишетелгәндәй булды. Дистәләгән көмеш кыңгыраулар чылтырады диярсең, егетнең җанын эретердәй кызлар көлешкәне ишетелде. Җәүһәрияләр килә дип, егет каршы ашыкты.

– Исәнмесез, кызлар! – диде ул, аларга якынлашып. – Кайда юл тоттыгыз?

– Исәнмесез, Нурмөхәммәт абый, – дип, Җәүһәрия җавап бирде... – Әйдәгез безнең белән, без биредә бүрәнәләр өстендә генә утырабыз.

– Клубка бармыйсызмыни? – диде егет, алар белән янәшә атлап.

– Клуб ерак, анда кадәр барырга куркабыз, – дип шаяртты Җәүһәрия.

– Әйдәгез, үзем алып барам. Курыкмагыз...

– Без монда гына утырабыз, абый, – дип, кызлар бүрәнәләр өстенә таба борыла башладылар.

– Алайса мине клубка озатыгыз, – диде Нурмөхәммәт, Җәүһәриягә якын килеп. Кыз егетнең хәйләсен сизеп алды. Тик җавап бирмәде. Икенче кыз:

– Абый кеше, үзегез генә барыгыз инде, безгә монда гына да ярый, – дип шаярткан булды.

– Кызлар, мин Нурмөхәммәт абыйга клуб юлын күрсәтим әле, – дип, Җәүһәрия кызлардан аерылды. – Әйдә, абый, кунак кешене ялгыз йөртү яхшы түгел, – дип, Нурмөхәммәт каршысына килеп басты.



– Рәхмәт! – дигән булды егет, кыз белән янәшә атлап. Алар сөйләшмичә генә кызлардан ераклаштылар. Нурмөхәммәт кызның кулыннан алды да:

– Клубка ук бармабыз инде, Җәүһәрия, – дип, кызга карады.

– Абый җаным, – диде кыз, егеткә якын ук килеп, – әйдә, Түбән очка төшәбез.

– Әйдә, – диде егет, кинәт кире якка таба борылып. – Су буена төшеп утырсак та ярый.

– Әйе шул, теге син утырып торган җиргә!

Алар, бер-берсенә якын ук килеп, ашыкмыйча гына, тын гына түбән очка таба атладылар. Тынлыкны Җәүһәрия бозды:

– Беләсеңме, Нурмөхәммәт абый, ни өчен мин клуб ягына таба барасым килмәде? Анда теге мин әйткән егет очравы мөмкин. Минем аны күрәсем килми. Шуның өчен клубка да бармый башладым...

– Кем соң ул?

– Курста укып кайтты. Хәзер колхозда агротехник. Әти шуңарга чык, дип аптырата. Мин аны бөтенләй яратмыйм. Яныма килеп утыра да пуш-пуш тәмәке суыруны гына белә. Үзеннән кәҗә тәкәсе исе килә шикелле. Әни дә яратмый аны. Абый җаным, аңарга чыкмас өчен генә миңа ризалык бирә дип уйламагыз. Хәзер иске заман түгел. Ирексез беркем дә кияүгә чыкмый. Әти дә әйтер-әйтер дә туктар. Син бөтенләй башка. Мин сине теге вакыттан ук күңелем белән ошатып йөри идем...

– Мин дә шулай идем бит, Җәүһәрия, – дип, егет кызны җилкәсеннән үзенә таба кысып алды. – Тик менә килү белән сезгә кермичә генә ялгышканмын...

– Мин сине су буенда очратмаган булсам, кайтып китә идеңме?

– Китә идем, Җәүһәрия. Бәлки, башка килмәгән дә булыр идем.

– Димәк, мин сине үзем эзләп таптым? – Кыз, егеткә нур сибеп торган күзләре белән текәлеп, елмаеп алды да башын аның күкрәгенә куйды... – Минем сиңа әйтәсе дә, сорыйсы да сүзләрем бар, абый.

Нурмөхәммәт, Җәүһәрия миннән Хәят турында сорарга җыена, ахры, дип шикләнеп тә куйды. Сораша башласа, ни булганын дөрес итеп сөйләп бирергә дә риза иде. Хәтта соңыннан, син дә шулай Хәят шикелле сүз биреп, иртәгә кил, шул җирдә көтәрмен, дип алдап китереп, соңыннан качып китмәссеңме соң, дип сорарга да җыенган иде. Ләкин кыз ул турыда сүз кузгатырга уйламады да. Ул хәтта Нурмөхәммәтнең Хәят белән уңышсызлыкка очравының сәбәбен дә, әнисеннән ишетеп, азмы-күпме белә иде. Тик Мәрфуга карчыкның Хәятне котыртып җибәрүен

Нурмөхәммәткә бервакытта да әйтмәскә, дигән уйда тора иде. Әйтермен дә, Нурмөхәммәт абый Хәятне бик нык ярата торган булып артыннан китеп барыр, дип шикләнә иде Җәүһәрия. Нурмөхәммәт бу минутта Хәят турында түгел, башын үзенең күкрәгенә куеп, өтеп алырдай эчкерсез назлы карашлары, абый җаным дип, таш күңелне дә йомшартырдай ягымлы эндәшүләре белән бөтен барлыгын биләп алган Җәүһәрия турында гына уйлый иде.

Алда көзгә кебек тыныч су өсте күренде.

– Менә килеп тә җиттек, – диде егет. – Әйдә шунда, яр читенә утырабыз.

Ул яр читенә аякларын түбән җибәреп утырды да, кесәсеннән кульъяулыгын чыгарып, чирәмгә җәйде.

– Утыр шунда, Җәүһәрия, – дип, үзе янына урын күрсәтте.

– Абый җаным, кульъяулыгың...

– Утыр, утыр. Каз тизәге булып, күлмәгең пычранмасын. Кульъяулык ул кечкенә әйбер, – дип, Нурмөхәммәт кызның кулыннан алды.

Кыз, бераз тартыла төшеп, сүзсез генә ак яулык өстенә утырды. Егет кызның кулларыннан алды да, аңа иелә төшеп, сүз башлады:

– Йә, сөеклем, утларын да син кабыздың, суларын да син инде, дип җырлыйлармы әле? Соңгы сүзеңне әйт инде, көтәм.

– И-и, абый җаным, – дип, Җәүһәрия ике кулы белән егетнең беләгеннән алды. – Әйттем бит инде. Ышанмыйсыңмы? – Кыз нур чәчеп торган күзләре белән егеткә текәлде. Ул карашлар, мин синеке инде, синеке, ышан, дип ялваралар кебек булып китте егеткә. Аның күзләренә туры карады.

– Чынмы, сөеклем, вәгъдәме?

– Чын, абый җаным, вәгъдә, – дип пышылдаганда, кыз бөтен тәне белән Нурмөхәммәтнең куенына сеңгән иде.

Алар шулай бөтен барлыкларын биләп алган шатлыктан, дөньяларын онытып, тын калдылар. Кызның кайнар тәне, урталай ярып үргән толымнарыннан килеп торган тылсымлы ис, тыгыз күкрәкләренең беләгенә төртеп торуларыннан егет хыял дөньясында йөзә иде. Күктәге йолдызлар җемелдәве дә, авыл уртасындагы клуб янында гармун тавышы да, су өстендәге казларның гайгылдашып алулары да аларга кагылмады.

– Җәүһәрия, сөеклем.

– Әү, абый җаным? – Ул башын күтәреп егеткә карады.

– Кил әле, – дип, егет аның алсу иреннәренә үрелә башлады, – вәгъдәң билгесе булыр, бер үбим...



Кыз башын читкә борды.

– Абый җаным, кирәкми, сабыр ит. Бөтенләй үземнеке булгач, ярыймы?

Егет дәшмәде. Җәүһәрия аның моңсу күзләрен күреп тынычландырырга ашыкты:

– Кил, битләреңнән генә үзем үбеп алам.

Җәүһәриянең өтеп ала торган ягымлы карашлары астында кайнар иреннәре белән чуп-чуп үбеп алган минутларда дөньяда Нурмөхәммәттән дә бәхетле кеше булмагандыр, мөгаен.

– Абый җаным, – диде кыз, нурлы күзләре белән егеткә карап, – мин сиңа тугрылыклы хатын булырмын. Тик син минем ышанычымны гына аяк астына салып таптама. Мин сине беләм дә, белмим дә. Бер уйлыйм да, сиңа бик ышанасым килә. Икенче уйлыйм да, икеләнеп куям. Чәчәктән чәчәккә куна торган күбәләк күңелле булмассыңмы, дим. Шулай да вәгъдәмдә торырмын. Язмышымны сиңа ышанып тапшырырга булдым.

Җәүһәрия моңсу карашлары белән Нурмөхәммәтнең күзләренә текәлде. Әйтерсең лә, кыз шул мизгелдә егетнең күзләреннән аның уйларын, фикерләрен укый иде. Егетнең эчкерсез күз карашын күреп, ул тынычланды бугай. Кыз җылы эзләгән бала шикелле егетнең куенына сеңә төште.

– Абый җаным, мин синең гомерлек яр булуыңны телим, – дип пышылдап, туктап калды.

Кыз чиктән тыш дулкынланудан бөтен эче белән калтыранган кебек булып китте Нурмөхәммәткә. Ул аны тынычландырырга ашыкты:

– Ышан, кадерлем, мин дә шуны гына телим. Бер-беребезне ихтирам итеп, тыңлап, бәхетле, матур тормыш корып яшисем, балалар үстерәсем килә минем. Ничә бала бүләк итәрсең, анысы синең эш. Өчтән дә ким булмасын иде. Алар да безне ихтирам итеп, акыллы булып үссеннәр, эшчән булсыннар иде. Матур, тату яшәрбез, сөеклем, үкенмәссең.

Нурмөхәммәт кызны күкрәгенә кысып, аның маңгаеннан, хуш ис бөркеп торган чәчләреннән үпте. Кыз дәшмәде, аңа рәхәт иде. Шат иде ул бу минутларда.

– Җәүһәрия, кадерлем, – егет туктап кызга карады.

– Әү, абый җаным? – диде кыз «абый җаным» дип әйтүне үзенчә бик ярата, ошата иде. Хәзергә шулай әйтим әле, аннары зөфаф киченнән соң Нурмөхәммәт, дип эндәшә башлармын. Минем әни шикелле «син» дип әйтү килешми, дип уйлады. Хәтта ничек була икән дип, күңеленнән генә

кат-кат «Нурмөхәммәт, Нурмөхәммәт» дип, төрлечә әйтеп тә карады. Аннары матур исем дигән нәтиҗәгә килде.

– Мин бит синнән башка авылга кайтып китмәскә булдым, нишләрбез икән?

– Нигә, абый җаным? Әллә куркасыңмы?

Нурмөхәммәт, бер мәртәбә авызым пеште инде минем, икенче кат алдатасы килми дияргә уйлаган иде дә, үзен фаш итүдән куркып:

– Тимерне кызуында суксаң яхшырак, – дип, кызга карады.

– Кайчанга, дисең соң?

– Иртәгә үк, дип уйлыйм. Әни борчылып торадыр.

– Ярар, – диде кыз, Нурмөхәммәтнең муеныннан кочып алып. – Ничегрәк китәрбез икән соң, абый җаным?

– Эңгер-меңгер булуга, син кызлар янына чыгасың. Мин сине Камилләр капкасы төбендә көтеп торам. Алар йортыннан арт бакчага чыгабыз да, киттек була. Камил безне бераз озата барыр. Ризамы шуңа?

– Риза, – диде кыз, егетнең муеныннан кочаклап.

– Өйдә безне әни көтеп алыр. Әнине бераз беләсең инде. Чебенне дә рәнҗетә торган кеше түгел, әүлия. Үз баласы кебек якын күреп, кызым гына дип торыр үзеңә. Ул яктан да күңелең тыныч булсын.

Йортларда әтәчләр кычкырганы ишетелә башлады.

– Абый җаным, әйдә кайтыйк, – дип, Җәүһәрия урыныннан торды.

Тын урамнан егет белән кыз кулга-кул тотынып кайтканда күктәге йолдызлар елмаеп калдылар. Таң әтәчләре: «Кикрикүк, яктыра башлады, ашыгыгыз!» – дип кычкыралар иде кебек.

Капка төбендә Җәүһәрия Нурмөхәммәт кенә ишетелерлек итеп:

– Абый җаным, сау бул! Төштән соң үзебезгә кер. Әти икедә эшкә китә. Бергә-бергә чәй эчәрбез, – дип пышылдады да, чуп иттереп үбеп, егетнең күңеленә ут салып, капкадан кереп югалды.

– Хәерле төн, тәмле йокы, Җәүһәрия!

* * *

Икенче көн инде Фәридә апа тәрәзәдән күзләрен алмыйча малаен көтә. Самоварын кайнатып чыгарып, өстәл көйләде дә капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырды. Караңгы төшеп килә торган эңгер-меңгер вакытлар. Урамның каршы ягында кемнәрнеңдер сөйләшеп килүен шәйләп, әллә инде Нурмөхәммәтем кайта дип, урыныннан ук торып басты. Сөйләшеп килүчеләр чишмә очыннан Нәгыймә белән Нәҗип булып



чыктылар. Фәридә апа: «И-и, тиле дә инде мин, Нурмөхәммәт булса, ул яктан кайтыр идеме?» – дип, үз-үзен тиргәп, яңадан урынына утырды. Чирмешән ягыннан килгән һәр кыштырдаганны ишетергә тырышып, шактый озак борчылып утырырга туры килде аңа. Баш өстендәге өянке яфраклары кыштырдавына еракта уйнаган гармун тавышы килеп кушылды. Күпмедер вакыттан ул да тынып калды. Бүген дә кайтмавы булды инде дип, кереп китәргә генә җыенган иде, аяк тавышлары килгән кебек булып китте. Төн караңгылыгы эченнән:

– Кайтып җиттек, Җәүһәрия, бу биек өянкеләр безнең йорт, – дигән тавышны ишетеп, Фәридә апа, урыныннан сикереп торып, каршы атлады. Нурмөхәммәт самокатыннан төшү белән, аның алдыннан кыз җиргә төшеп басты.

– Кайттыгызмы, улым? – диде ана, каршы атлап.

– Без кайттык, әни.

– Бигрәкләр дә яхшы булган, улым. Әйдә, кызым, әйдә, – дип, Фәридә апа шатлыгыннан ни эшләргә белми, кызны кочаклап ук алды. – Ул-бу булмадымы, армадыңмы, кызым?

– Юк, әни, армадым, – диде кыз, кайнана буласы хатынның үзенә бик игътибар белән караганыннан тартынып.

– Әни, таныш булыгыз, Җәүһәрия булыр бу, – диде егет, килен белән кайнана янына килеп.

– Җәүһәрия? – диде ана, улына сораулы карап.

Фәридә апа, син бит, улым, Хәят дип сөйләгән идең, дияргә уйлаган иде дә тукталып калды. Нурмөхәммәт, әнисенең карашыннан ук аңлап, ачыклык кертергә ашыкты:

– Әни, хәтерлисеңме, Җәүһәрия безгә Әкълимә апа белән бер килгән иде?

– Кәүсәр кызымы? – диде ана, ачылып китеп. – Беләм, беләм, әйдә, кызым, әйдә, төкле аягың белән, бәхетең белән! – дип, капканы ачып, башта килен белән малайны йортка үткәрде. Аннары үзе кереп, алдан ишеккә йөгерде. Баскыч төбенә җиткәч, яшьләргә шунда туктарга кушып, тиз генә тун алып җәйде дә:

– Басыгыз шунда, – дип, өйгә йөгереп кереп китте. Аннан тәлинкә белән бер йомарлам май алып чыгып, яшьләр каршысына басты.

– Кабыгыз, балакайларым! Тормышыгыз майдай тәмле, балдай татлы булсын!

Нурмөхәммәт кашык белән батырып май алды да башта Җәүһәриягә каптырды, аннан калганын үзе капты.

– Әйдә, кызым, кер, төкле аягың, бәхетең белән! – Фәридә апа яшьләргә юл биреп, аларны алдан кертеп җибәрде. Үзе алар артыннан тунны алып, теләк теләде:

– Илаһи Раббым, бәхетегез, тәүфыйгыгыз белән булсын! Бергә-бергә гомер итәргә язсын! Исән-имин балалар үстерегез!

Ул яшьләр артыннан ишекне ябып өйгә керде.

Ул көнне йортта таңга кадәр ут сүнмәде.

Берничә минуттан чакырылган яшьләр килеп җитте. Чәйдән соң Нурмөхәммәт тальянын алып утырды, җырладылар, биеделәр. Җәүһәрия биегәндә, Нурмөхәммәт түзмәде, гармунын тотып чыкты да, кәләшенә каршы биеп китте. Кыз да, шат елмаеп, аның тирәли бөтерелеп-бөтерелеп биеде.

Аннан тагын җырлашып утырдылар. Таң беленә башлаганда гына кызлар-егетләр, кияү белән кәләшне алар өчен урын көйләнгән келәткә озатканнан соң, өйләренә кайтып киттеләр.

* * *

Менә ничәнче көн инде Хәят апаларында үзен үзе кая куярга да белми йөри. Хәдичә апасы белән Кондырча болынына печән җыешырга да барды. Станциягә чыгып, вокзал тирәсендә дә йөрде. Тик күңелендәге каршылыклы уйларыннан аерыла алмады. Яраткан бит ул Нурмөхәммәтне, яраткан. Бәлки ул карчык сөйләгәннәр дөрес тә булмагандыр? «Нигә ашыгып китеп бардым соң мин? Сабыр итәргә иде. Бәлки, Нурмөхәммәтнең үзен күреп аңлашырга кирәк булгандыр? Ул бит икенче көнне дә мине көтеп торган. Ичмаса, кич чыгып, Камилне генә күреп булса да сораша белмәдем. Кайттым да, иртән торып, тагын китеп бардым. Уйлар, уйлар. Ниндидер аңлашылмаган шикле билгесезлек. Әллә үзенә хат язаргамы? Гафу итәрме икән? Алар авылыннан берәрсен очратып, сорашасы иде. Ир-ат булса ничек сүз катасың?»

Хәят апасына бер көянтә су алып кайтты да:

– Апа, мин станциягә барып килим әле, Казан поезды кай тирәгәрәк килә икән, билет турында да белешермен, – дип, тагын чыгып китте.

Үзе дә аңлап, аралап бетерә алмаган борчулы уйлар белән тирә-юньдәге бернәрсәгә дә игътибар итмичә бара иде, вокзал ягыннан килеп чыккан бер бабайга барып төртелде. Уянып киткән кеше шикелле аңына килеп читкә тартылган иде, тимер юл рельсына абынды. Бу күренештән аптырап калган карт:



– Күзең чыкканмы әллә? Өскә килмәсәң?! – дип, ачуланып карады да, – болай поезд астына килеп керергә дә ерак йөрмәс, карап йөр! – дип, кызның артыннан кычкырып калды.

Хәят, вокзалга кереп, поездлар расписаниесен карады. Касса янында әллә иртәгегә билет алыргамы дип басып торды да, Уфа – Казан поезды килә дигән игъланны ишетеп, вокзал каршысына чыгып басты.

Поезд килеп туктау белән, нәкъ вокзал ишеге каршысына туктаган вагоннан пассажирлар төшә башлады. Зур төен, кәрзин тотып төшеп килүче яшь ир артыннан төшкән хатын аңа таныш булып китте. Аның алдыннан төшкән ир бу хатынның кулындагы чемоданын алды да, алар әйберләрен бер читкә алып килеп урнаштырдылар. Хәяткә арты белән баскан әлеге хатын:

– Ислам, бар әле, безнең якка кайтучы булмасмы, карап кил, – дигән иде, Хәят шунда ук йөгереп барып хатын каршысына басты.

– Әкълимә Мәрдәновна, исәнмесез! Танымый да торам! – дип, беренче укытучысын кочаклап алды, – Әкълимә апа, әллә танымыйсызмы? Мин Садриева Хәят булам. Сез мине ике ел укыткан идегез, – диде кыз, аптырап калган укытучысына карап.

– Хәят Садриева? – диде хатын, кызны баштанаяк күздән кичереп. – Үзең әйтмәсәң, танымас та идем, кара инде, искитәрлек. Бөтенләй җиткән кыз булгансың бит! Ничә ел булды соң әле минем сездән киткәнгә?

– Җиде ел булды инде, апа, сез районга киткәндә миңа ун яшь иде. Елашып озаткан идек без сезне, Әкълимә апа. Кайдан кайтып киләсез, апа?

– Шөгердән кайтып киләбез, Хәят. Иптәшем Ислам армиядән кайтты да, үзебезнең якка күчәргә булдык. Әнигә якынрак булырга телибез. Син, Хәят, ничек монда? – диде укытучы, кызга сораулы караш ташлап. Ул Хәятнең икегә аерып үргән толымнарына кагылып алды. – Кара инде, бөтенләй кәләш булып җиткәнсең бит.

Кызның колакларына кадәр кызарып чыкты. Кинәт Нурмөхәммәтнең: «Әкълимә минем олы апам, Шөгер районында укыта. Быел үзебезнең якка кайтырга уйлыйлар», – дип сөйләгәннәре исенә төште дә, йөрәге жу итеп, бөтен тәне буйлап кайнар тир йөгерде. Әгәр шул дөрес булса? Мәрфуга апа алай димәде бит? Әллә ул дөрес сөйләмәгәнме миңа, дип шикләнүдән йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Шулай да, сиздермәскә тырышып, үзен кулга алды да:

– Хәдичә апа белән иртәгә Казанга барырга уйлаган идек. Билет турында белешергә килдем, – дип җавап бирде.

– Казанда укыйсыңмы әллә, Хәят?

– Эшләп, кичкедә сигезне бетердем, апа, – диде кыз, уңайсызланып башын түбән иеп. Ничек итеп Нурмөхәммәтне сорашырга соң, дигән уй аның бөтен барлыгын биләп алган иде.

– Әкълимә апа, ничек кайтасыз инде, каршы алырга энегезне чакырмадыгызмы? Әйберләрегез күп бит, – дип, укытучы апасына карады.

– Энем Алабугада укый иде. Июль башларында районга эшкә кайтам дип язган иде, әллә кайткан, әллә юк. Өйдә әнием белән кечкенә сеңелем генә. Әнине борчыйсыбыз килмәде инде. Шуның өчен телеграмма биреп тормадык. Берәр җае чыгар әле, дидек.

– Энегез Нурмөхәммәт абыймы? – диде кыз, бик кызыксынып. – Ул кайткан, Әкълимә апа.

– Шулаймыни? Кайдан беләсең?

– Безнең авылга килгән иде, шул булса.

Кызның битенә тагын ут кабынды.

– Ничек шул булса? Нурмөхәммәт безнең авылда бер генә. Син соң аның үзен күрдеңме? Әллә кешедән генә ишеттеңме? – диде укытучы, кызның нидер әйтеп бетермәгәнен сизеп.

– Гармунчы Шамил абзый карчыгы Мәрфуга апа сөйләде. Нурмөхәммәт Әкълиманең энесе түгел, фамилияләре генә бер, ди. Өйләнеп хатын аерган ир, аның кияүгә чыкмаган өч апасы бар, диде...

– Тукта, тукта, – диде укытучы, кызны бүлдереп. – Син, Хәят, нидер бутыйсың, ахры. Нурмөхәммәтнең үзен күрдеңме, нindiрәк ул?

– Күрдем, апакаем, Җәләлов абый белән клубта яшьләр җыелышы үткәрделәр. Районда культура бүлегенә эшкә кайттым, диде. Репетиция ясаганда өйрәтеп торды. Гармунда да уйнады. Самокат белән килгән. Мәрфуга апаларга тукталдым, диде. Нурмөхәммәт Мәрдәнов...

– Шул, шул үзе. Минем энем ул Нурмөхәммәт Мәрдәнов. Димәк, укып бетереп эшкә кайткан. Тик аның беркайчан да өйләнгәне юк. Апалары да без икәү генә...

Хәят коелып төште дә, гарьләнү, әрнү, үкенү хәсрәтеннән яшенә төелеп, укытучы апасының күкрәгенә капланып, үксеп-үксеп еларга тотынды.

Көтелмәгән бу хәлдән аптырап калган укытучы, берни аңламастан:

– Нәрсә булды, Хәят? Нигә елыйсың? – дип, кызның башын кочаклап алды. – Ни булды? Аңламыйм, бернәрсә дә аңламыйм. Әйт әле, Хәят, әллә Нурмөхәммәт алдадымы үзеңне?

– Юк-юк, апа бәгърем, ул гаепле түгел, мин алдадым, ул гаепле түгел, – дип өзгәләнде кыз.



– Берни дә аңламыйм, Хәят, ничек инде син алдадың?

– Мин, – диде кыз, сулкылдап елавыннан тыела алмый, – мин алдадым Нурмөхәммәт абыйны. Сүз куешкан идек. Ул мине алырга киләсе көнне мин качып киттем.

– Нигә качтың соң, балакай? Яратмадыңмы?

– Мәрфуга апа, хатын аерган ир, тегендә марҗасы да бар, бүген үк качып кит, китмәсәң, әниеңә барып әйтәм, дип куркытты... Яратам мин Нурмөхәммәт абыйны... Апа җаным, нишлим инде?

– Юкка елама, кайт та гафу үтенеп хат яз. Кил, көтәм, дип чакыр.

– Бер атнадан артты бит инде, Әкълимә апа. Минем хат кайчан барып җитә? Бәлки, сез сөйләп аңлатырсыз? Бәлки, гафу итәр?

– Бер дә борчылып торма, акыллым. Кайтуга...

– Әкълимә! Мин үзебезнең якка кайтучы бер олаучы таптым, бер сәгатьтән китә, – диде Ислам, хатыны янына якынлашып. Аннары аның каршысында яшьләрен сөртеп торучы кызны күреп, аптырап калды.

– Монда килеп алырга дип, әйтәсе идең.

– Сөйләштем, Әкълимә, бер сәгатьләп ат ашата да үзе килеп ала.

– Бу кыз миндә укыган иде, Әлмәттә беренче-икенче класста. Гомер үтә, яшьләр үсә. Беләсеңме, кеп-кечкенә балалар иделәр. Хәзер җиткән кыз булган.

– Әкълимә апа, мин кайтыйм әле, – диде кыз, китәргә ашыгып.

– Ярый, бар, кайт, акыллым. Тыныч бул, – дип калды укытучы, Хәятне озатып.

* * *

Хәят ашыгып апаларына кайтты да, бер минут та тормастан, авылларына кайтып китте. Хәдичә апасы: «Бу нишләвең инде, ике арада киләп салып йөрисең. Үзең иртәгә Казанга китәм дигән идең», – дип, сеңлесенең яшьле күзләрен күреп аптырап калды. Кыз берни аңлатмыйча, кайтыйм әле, соңыннан сөйләрмен дип, җәяүләп юлга кузгалды. Әкълимә Мәрдәновна белән дә кайтырга исәбе юк түгел иде дә, янындагы ире Исламның үзенә бик кызыксынып карап торганын күреп, Әкълимә апа минем турында әйтер дип, шикләнеп китеп барды.

Нурлатны чыккач, аягыннан салып ташлады да йөгерә-атлый яланаяк элдертте. Уенда, фикерендә гел Нурмөхәммәт булды: «Гафу итәрме? Ничек кабул итәр? Кичерерме мине?»

Караңгы төшеп, утлар алгач, Хәят өйләренә кайтып керде. Битен-башын юып, чәй эчкәннән соң, ашыгып клубка чыкты. Клубка да туры барып кермәде, ишектән Камилне карады. Камилне күрмәгәч, кире урамга чыкты. «Нишләргә? Әллә өйләренә барыргамы? Юк, ул убырлы карчык каршысына гомеремдә барасым юк. Ничек тә Камилне генә күрергә кирәк», – дип уйланып тора иде, Камил үзе килеп чыкты.

– Хәят? – диде ул аптырап. – Кайда югалдың син, кызый? Шулай ярыймы? Нәрсә дип алдап китердең кешене?

Кыз дәшмәде, башын аска иеп, телдән язып басып торды.

– Исәбең булмагач, кешене алай йөртмиләр...

– Камил абый, мин гаепле түгел, – дип пышылдады кыз.

– Кем соң Нурмөхәммәткә, берсекөнгә кил, дип ышандырып җибәрде, мин түгел бит?

– Әниең, әниең, – диде кыз, – әниең гаепле. Кайткач, әниеңнән сора. Ул мине хатын аерган иргә чыкмасаң, беткәнме, әниеңә әйтәм, дип котыртып качарга өйрәтте. Мин аның сүзен тыңлап...

– Әни? – дип аптырап калды Камил. – Әйтәм аны...

– Нурмөхәммәт абый тагын килмиме, Камил абый? – диде кыз әкрен генә.

– Нурмөхәммәтме? – дип тукталып калды егет, әйтергәме моңа, әллә юкмы дигәндәй. – Син кайтмассыңмы дип, дүрт мәртәбә килде Нурмөхәммәт. Инде бүтән килмәс. Килмәс дип әйтүем дөрес тә түгел әле, хәзер кияү булып, Ислам абзыйларга килсәләр генә. Кичә ул Җәүһәрияне алып китте.

– Җәүһәрияне? – диде кыз, күзләрен зур ачып, Хәятнең башына суктылармыни, башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте:

– Кайчан? Алдыйсыңдыр?..

– Үзем озатыштым, – диде егет. – Син әллә дөньяда үзең генә дип белдеңме?

Камил тагын ни әйткәнне кыз ишеттеме, юкмы, үзе дә белмәде. Ул гарьләнүдән, йөрәге әрнүдән, ике кулы белән битен каплады да, кычкырып елап, өйләренә йөгерде. Капка төпләренә җитәрәк авызын томалап сулкылдады. Аннары, әнисе ишетмәсен өчен сыер абзарына кереп, үкереп-үкереп елады. Ул шулкадәр тыела алмыйча, бәргәләнеп елады ки, мөгаен, әнисе ишетеп чыкса да, туктала алмас иде. Елап арып урынына кереп ятканда, Хәятнең тавышы беткән иде. Урынга яткач та, тавышсыз гына күз яшьләре агызып ятты әле ул. Таң атканда башы авыртудан изрәп йоклап киткәндә, кызның мендәр тышы сыгып алырдай юешләнгән иде.



Иртә белән Хәят авырып уянды. Тавышы юк, тәне ут булып яна.

Кадрия апа кызның башын тотып карады да:

– Юлда тирләп, салкын су эчкәнсең, кызым, – дип, фельдшерга барырга кушты.

Мәхәббәт газабы, гарьләнү, үкенүләр тиз генә үтеп китмәде. Тавышы ачыла төшеп, бераз уңайлана төшкәч, Хәят Казанга китеп барды. Киткән вакытта яшьлегенең иң кадерле минутларын үткәргән сукмакларына моннан соң бервакытта да кайтмаска дип карар кылды. Казанда да бик озак уңайлана алмый йөрде.

Вакыт үткәч, мәхәббәт газаплары, үкенүләр беркадәр тынган кебек тоелса да, сугыш башланасы елны тормышка чыгып, кияве белән авылга кайткач, алар яңарып киткәндәй булып, Хәятнең йөрәген өтеп алды. Теге вакыттагы адымы өчен гафу үтенү уе белән Нурмөхәммәтне күреп чыгыйм дип, районга да кагылган иде. Тик урамда Җәүһәрияне очратып, аларның матур тормышлары турында ишеткәч, күңеле тартмады. Тормышларын бозармын дип, кире китеп барды.

Шуннан кайтып, Казанга китәргә дә өлгермәделәр, бөтен илне тетрәндергән сугыш хәбәре килде.

* * *

...Июнь урталары иде. Чистай пристанена Казан – Уфа пароходы килеп туктады. Аннан ашыга-ашыга чемоданнар, сумкалар күтәргән кешеләр төшә башлады. Төшүчеләр күп иде. Траптан күтәрелүче халык төркеме арасында кулына чемодан тоткан, янында үзе кебек үк кара чәчле, тугыз-ун яшьләрдәге малай иярткән чибәр хатын күренде. Ак йөзле хатынның кара чәчләре кыскартып киселгән. Ханым кара юбка өстеннән зәвык белән тегелгән киң якалы ак кофта кигән. Траптан үтеп, шәһәргә менә торган юлга чыккач, хатын малаеның кулыннан тоткан килеш туктап калды. Як-ягына каранып, кемнедер эзләде. Аннары малаена:

– Әйдә әле, улым, монда да кереп чыгыйк, – дип, юл аша чыгып баскычтан өскә күтәрелә башлады.

Сугыш беткәннең икенче елы иде. Хәят, авылларына кайткач, очраклы рәвештә Җәүһәрияне туры китерде. Шунда ул Нурмөхәммәтнең сугыштан исән кайтуын, бик нык яраланып, инвалид булуын, һәр елны июнь уртасында Чистайга комиссиягә баруын ишеткән иде. Шуннан бирле Хәятнең тынычлыгы югалды. Өч ел хәбәрсез югалып торган Нурмөхәммәтнең исәнлеге хәбәре хатынны шатландырса, яшьлектә ясаган

хатасы өчен, онытылып бара торган әрнүләрен яңартып җибәрде. Үзенең тол хатын булып, ялгыз яшәргә мәҗбүр булуын, кайчандыр яшьлектә ясаган хатасының нәтиҗәсе дип саный башлады. «Әгәр ул вакытта, шул явыз карчык сүзенә ышанып, качып китмәгән булсам, бүген миннән дә бәхетле кеше булмас иде. Яраткан кешем янымда булыр иде. Нурмөхәммәт каршында алдакчы булып калдым. Хәзер шуның җәзасын күрәм», – дип уйланган вакытлары күп булды Хәятнең. Җәүһәрияне очратып, Нурмөхәммәтнең исән кайтуын ишеткәннән бирле, аны күрергә омтылу теләге хатынны бер дә ташламады. Күреп, аның каршына басып, гафу үтенсә, күңеле тынычланыр кебек иде. Шуның өчен хатын Чистай пристанена кайтып төшүгә, тынычлыгын җуя. Баштан ук пассажирлар залына керә. Беренче мәртәбә ул Нурмөхәммәтне шунда очраткан иде. Аннан шәһәргә күтәрелә – кибетләрне, базарны әйләнеп чыга. Шуннан соң гына тегермән янына, олы юл янына, машина көтә торган җиргә чыга.

Күңеле белән Нурмөхәммәт кайдадыр шунда гына йөридер кебек аңа. «Күрәсе иде, сорашасы иде, ничек яшиләр, яралары ничек, бик борчымыймы, кай җирләре яраланган, кайда эшли икән, бәхетлеме ул – очратасы иде дә, барысын да бәйнә-бәйнә сорашасы иде...»

Хәят, малаен ияртеп, тиргә батып, тегермән янына менгәндә төш авышкан иде. Ул кулындагы чемоданын җиргә куйды да, кечкенә сумкасыннан кульяулыгын алып, тирләрен сөрткәләп алды. Аннан тирә-яктагы машина килеп чыкканны көтеп торучы юлчыларга күз йөртеп чыкты. Юл буенда басып торучылар да, эссе кояштан качып тегермән шәүләсе артына яшеренүчеләр дә, чирәм өстендә утыручылар да бар.

Кинәт Хәятнең күзләре бер читтәрәк сумкасы өстенә таягын куеп чирәмгә утырган кешегә төште. Яны белән утырган бу кешене ул шунда ук танып алды да, ашыгып, аның каршысына барып басты.

– Нурмөхәммәт абый, сез бит бу? Исәнмесез!

Ир кеше күтәрелеп карады да, каршында басып торган хатынны танып, таягын кулына алып, ашыгып торып басты.

– Исәнме, саумы, Хәят! – Ул кайчандыр бик тә кадерле булган йомшак кулларны ике кулы белән кысып селкеп тора башлады. – Сине дә күрер көннәрем бар икән әле, Хәят. Тау белән тау гына очрашмый, исән кешеләр кайчан да бер очрашалар икән, – диде ул, Хәяттән күзләрен ала алмыйча. «Хәят бераз калыная төшкән. Шул ук якты йөз. Шомырт күзләре элеккедәй ягымлы карый. Сылулыгы, матурлыгы сүрелмәгән. Толымнары гына киселгән».



Хатынның күзләре Нурмөхәммәттә иде: «Чигәләренә кырау төшкән. Сугыш, каһәр суккан сугыш мескенне нишләткән», – дип уйланды хатын, Нурмөхәммәтнең сул аягы кыскарып калудан җилкәсенең түбән салынып, таякка таянып басып торганын күреп. «Кечерәеп калган, нинди мәһабәт егет иде».

– Нинди җилләр ташлады үзеңне, Хәят?

– Менә авылга кайтып барабыз, Нурмөхәммәт абый. Сез ничек монда?

– Комиссиягә килгән идем мин, Хәят, – диде Нурмөхәммәт, хатыннан күзләрен ала алмыйча. – Менә сугыштан шулай булып кайттым да, ел саен комиссиягә йөртәләр. Бу аяк яңадан үсәр дип беләләрме икән, ел да чакырып карамасалар?

Хатынның үзенә кызганып карап торганын күреп, Нурмөхәммәт сүзне икенче якка борырга ашыкты:

–Үзең ничек соң, Хәят, тормышың, дим?

Хатын күптәннән, бик күптәннән әйтергә теләп тә әйтә алмый калган үтенечен әйтергә ашыкты:

– Нурмөхәммәт абый, теге вакыттагы качып китүемне гафу итә алыр идегезме?

– Хәзер, еллар үткәч, аның нинди әһәмияте бар, Хәят?

– Мин бик нык ялгыштым, Нурмөхәммәт абый.

– Сине алырга барып, көтеп-көтеп тә буш кайтып киткәндә генә, яратмаган, алдады, дип рәнҗегән идем, Хәят. Хәзер мин сине гаепләмим инде. Язмышларыбыз шулай булгандыр...

– Соң булса да, кичерегез мине, – дип дәвам итте Хәят, моңсу күзләре белән Нурмөхәммәткә карап... – Шуны гына булса да әйтеп чыгыйм дип, өч елдан соң эшли торган җирегезгә кереп чыгарга булып, районга кагылган идем. Урамда Җәүһәрияне очратып сөйләштем дә, сезнең матур яшәвегезне белгәч, кермичә китеп бардым...

– Кирәргә булган, Хәят.

– Тормышыгызны бозармын, дип курыктым. Ул вакытта Җәүһәрия икенчегә авырлы иде бит.

– Мин сине күптән кичердем дип сана, Хәят. Бәхетле булуыңны телим мин синең...

– Үз бәхетемнән үзем качкач... – Хатын, тамак төбенә утырган төерне йотып, дәвам итте. – Миңа бәхет елмаймас инде, Нурмөхәммәт абый. Карт кыз булып калмыйм дип, берәүгә чыккан идем. Каһәр суккан сугыш аны да миннән алды. Улым туганда этисенең хәбәре килгән иде. Этисе

исеме белән Зөфәр дип куштым. Өченчене бетерә инде Зөфәрем. Үзем заводта эшлим.

Хәят Нурмөхәммәтнең таягына карап алды да сорап куйды:

– Үзегез ничек соң, Нурмөхәммәт абый? Кайда эшлисез? Җәүһәрия ничек? Бик чая кыз иде бит ул.

– Җәүһәрия, дисең? Дөресен әйтим, әйбәт, тату яшибез. Бер малай, ике кыз үстерәбез, – ул кулындагы таягын күрсәтеп, дәвам итте. – Сугыштан болай булып кайткач, укытучылыкка күчтем.

– Мин бик шат, Нурмөхәммәт абый, синең өчен...

– Әни, әни! Безнең авыл машинасы килә!

– Менә минем бердәнбер куанычым шул инде, Нурмөхәммәт абый, – диде хатын, китәргә ашыгып. – Хуш, исән булыгыз, Нурмөхәммәт абый! Казанга барып чыксагыз, үземә керегез!

Хатын шомырт кара күзләре белән шундый итеп өтеп алды, ул карашлар, үзе киткәч тә, Нурмөхәммәтнең күз алдыннан китмәде.

– Җәүһәриягә сәлам тапшырыгыз.

Хәят тиз-тиз атлап китеп барды да, кинәт борылып, кул изәде.

– Хуш, сау бул, Нурмөхәммәт абый!

«Онытмаган, ярата икән әле». Нурмөхәммәт хатынның кузовка утырганын, аннан кул изәп китеп барганын күздән югалганчы карап торганда, еракта калган яшьлек хатирәләре тагын бер кат күңелен тырнап алгандай булды. Тик ул хисләргә ирек бирмәскә тырышты. Туең узган, туның тузган, өйдә хатының, өч балаң дип, Нурмөхәммәт шәһәр ягыннан менгән машинага кул күтәрде.

* * *

Чаптырып килгән такта кабиналы «Урал ЗИС» машинасы җәһәт кенә туктады да, кабинада шофер янындагы кеше ишекне ачып:

– Кемгә Аксубайга? – дип кычкыруы булды, иртәдән бирле машина көтеп кояшта пешкән юлчылар, бүре куркыткан сарык көтүе кебек, берсен-берсе этә-төртә, машинага ташланды.

– Эх, безнең якка булмады, – дип, Нурмөхәммәт таягын туп иттереп җиргә ташлады да сумкасы янына утырды. Ул арада машина бер кузов кеше төяп китеп тә барды. Вакыт үтә торды. Киткән юлчылар урынына тегермән тирәсенә тагын халык җыелды. Тагын төялешеп китеп бардылар. Биләр ягына һаман машина килмәде. Ике көн әле Нурмөхәммәт нефтеразведка машинасына утырып килгән иде. Алар да күренмәделәр.



Вахтага кадәр булса да утырасы калган дип, ул үкенә дә башлады. Кояш кызуында утырып машина көтә торгач, төш тә узып китте. Шулай кичкә кадәр утырырга туры килерме икән дип торганда, кемдер, ике машина килә дип, сикереп торган иде, шунда ук:

– Биләргә! Биләр машиналары! – дип кычкырып җибәрделәр.

Нурмөхәммәт сумкасын алды да, аксый-туксый, алдагы машинага йөгерде. Шофердан сорап та тормастан, ашыгып, кузовка менә башлады. Кузовтагы ябык кына хатын, аның таягын, сумкасын алып, менәргә булышты. Кабина артында утырган ике ир бала яныннан урын бирде. Ул арада машина кузгалып китте. Нурмөхәммәт идәндә яткан таягын сузылып алды да бер кулы белән кузов читенә тотынып чүгәләгән, үзенә менәргә булышкан хатынга карады. Карады да, исе китте. Аның каршында кузов төбенә чүгәләп торучы Сәлимә иде. Элеккеге вакытлардагы кебек шатланмады ул Сәлимәне күргәч. Шулай да кызыксынып карады: кеше үзгәрсә дә үзгәрә икән. Һич танырга юк үзен. Ябыккан. Йөзеннән нур качкан. «Күзләрем ялгыш күрми торгандыр бит? Кайдан килеп чыкты соң әле?» Ул Сәлимәнең сугышка кадәр Мәүләшә егетенә чыгып Мәскәүгә киткәнен, егетнең, син кыз түгел идең дип, аны аерып җибәргәнен, шуннан соң, Ташкент ягына китеп, бер үзбәккә тормышка чыкканын ишеткәне бар иде. Нурмөхәммәт сул ягына утырган ике малайга карап алды. «Ябыклар, кара йөзлеләр үзләре. Үзбәктәндер инде...» – дип, аптырап, Сәлимәгә карап алды. Әллә танымады, әллә үзенең дәшәсе килмиме, дип уйларга да өлгермәде, Сәлимә алгарак килде дә:

– Нурмөхәммәт, син бит бу? – дип, кулын сузды. – Исән генә йөрисеңме?

– Сәлимә, син икәнсең бит... – дип, Нурмөхәммәт хатынның ябык кулын учы белән кысып селки башлады. – Кунакка кайтуыгызмы?

Ирегез кайтмадымыни, дип тә сорарга җыенган җиреннән тукталып калды.

– Бөтенләйгә кайтып килүебез...

– Алай икә-ә-ән, – дип сузды Нурмөхәммәт. Иреннән тагын аерылган, күрәсең, дигән уй аның миен биләп алды. – Нигә, ошамадымыни ул яклар?..

– Бик нык үзгәргәнсез сез, Нурмөхәммәт, – диде хатын, аны бүлдереп. – Чәчләрегезгә чал кергән. Әзрәк утыра да төшкәнсез кебек. Шулай да мин сезне машинага килгәнче үк таныдым.

– Сугыш шулай итте мине, Сәлимә. Сугыштан шулай булып кайттым. Сез дә бик үзгәргәнсез бит, Сәлимә... – Сәлимә диюләре теге вакыттагы кебек үк.

– Булгандыр инде, – диде хатын, ачыла төшеп. – Ике бала белән берүзем Ташкент якларыннан кайтканда, бер атна поездда гына җәфаландым.

Аерылып кайта икән, дип күңеленә беркетте ир кеше.

– Бу малайлар сезнекемени? – Нурмөхәммәт, борыла төшеп, малайларга карады. Әтиләренә охшаганнардыр инде, бик каралар.

– Кил, утыр шунда, тартынмасаң, – дип, Нурмөхәммәт үзе янында урын күрсәтте.

– Нишләп тартыныйм, – диде Сәлимә, ачыла төшеп, – без бит бергә үстек...

– Алайса, кил, утыр, яшь вакытларны искә төшереп алырбыз, – дип, ир, читкәрәк тартылып, урын бирде. Сәлимә елмайгандай итеп аның янына кысылып утырды да:

– Шул, искә алып сөйләсәк кенә инде. Ул вакытлар кире кайтмас инде, яшь чаклар, тиле чаклар, – дип көрсенде хатын. – Җүләр булынган инде. Хәзер шуның... – Хатын кинәт туктап калды. Ул хәзер шуның җәзасын күрәбез дияргә уйлаган иде дә, чү, нәрсә соң әле мин дип, туктапып калды.

– Әгәр ул вакытлар кире кайтса, нишләргә икәнен белер идек, ә? – Нурмөхәммәт хатынның ябыгып калган муенына, җилкәсенә күз төшерде. «Элеккеге матурлыгы сулган, күзләре моңлы, нужаны күргән».

– Акыл булмаган инде, җүләрләнгән булганбыз, – диде Сәлимә аска караган килеш. – Сез, Нурмөхәммәт, теге вакытта миңа бик нык үпкәләгәнсездер инде – диде дә кызарып чыкты.

«Оятыннан ничек кызарып чыкты, теге вакытта миңа көмәне белән тагылырга уйлаганын онытмаган...»

– Үпкәләрлек эшләр торгызган идек бит, – диде ул, Сәлимәгә туры карап. – Мин ашкынып кайттым, син «кияүгә чыгып куйгансың». Мин бит сине үземнеке булырсың дип, күз карасы кебек саклаган идем...

– Чыга алмадым шул, Нурмөхәммәт... – Хатын, алдандым, дияргә көче җитмичә тыелып калды. – Ашыккан ашка пешкән, диләрме әле? Минем белән дә шулай булды инде.

– Сабыр иткән морадына җиткән дә дип әйтәләр, анысы. Йә, ярар, – диде Нурмөхәммәт. – Үткән – беткән. Гөнаһ куып тормыйк инде. Мин үкенмим, анысы, – диде ул, мәсьәләгә ачыклык кертер өчен. – Җәүһәрия ифрат яхшы хатын булды.

Җәүһәрия турында сүз чыккач, ул үзенең гаилә хәле белән таныштырды да тагын сорап куйды:



– Сабанчыга кемгә кайтасыз соң, Сәлимә? Анда сезнең нигез юк түгелме соң? Ике бала белән.

– Бер җае чыгар әле, – дип көрсенде хатын. – Илдә чыпчык үлми.

– Шулай инде, анысы, – дигән булды Нурмөхәммәт, сүзне озынга сузмыйча гына. Ул малайлар янындагы әйберләргә күз салды. «Үзе бөтенләйгә кайтабыз, ди. Бар багажы шул гына булса, бик ярлы...»

Мөслим аермасында, машинаны туктатып, тагын берничә кеше утырды. Алар арасында Нурмөхәммәт укыта торган авылдан да кешеләр бар иде. Алар: «Исәнме, абый!» – дип исәнләштеләр дә комиссия хәлләрен сораша башладылар.

Машина сикертеп-сикертеп ала. Нурмөхәммәт белән янәшә утырган Сәлимә, сикерткән саен, кабина артындагы рәшәткәгә тотынмыйча, кайчандыр үзенеке булырга тиешле булып та, кулдан ычкындырган егеткә ике куллап ябыша. Тотынган саен йөрәге түрендә үкенечле хатирәләр яңара бара: «Кыш буе сагыну хатлары язып торды бит. Мин җүләр...» Ул тагын иргә карап алды, тагын аның беләгенә ябышты. Торган саен теге вакытта ясаган хатасы өчен йөрәге әрнеде. «Нинди кешене югалттым бит... Сугыштан да кайткан. Бәхете бар. Аксак булса ни... Аның белән булсам, мин дә бәхетле булган булыр идем...»

Шул хатаны төзәтер өчен генә булса да, яшьлегенә кире кайтасы килде аның.

ХИКӘЯЛӘР



# ГӨЛНИСА

Чирмешәнгә кер чайкарга төшкән ике хатын сүз куертты:

– Сара апаның Дауты кайткан икән...

– Шулаймыни? Әле кайчан гына озаткан идек. Гомер дигәнең бигрәк тиз үтә...

– Өйләнәм дә Казанга китәм, дип әйтә, ди.

– Кемгә өйләнмәкче була икән соң?

– Гаделша бабайның Нисасына күз атып йөри, диләр.Тик Гаделша бабай кызын авылда тормаган егеткә бирерме икән?

– Нигә бирмәсен? Даутның кай җире ярамаган? Акылы, төсе-буе, дисеңме, уңганлыгы, дисеңме? Бар яктан килгән.

– Ниса да аннан ким түгел. Авылда бер уңган, акыллы, инсафлы кыз. Гаделша бабай, картлыгымда янымда булыр дип, кызын авылда калдырасы килә...

– И-и, Галимә, сөйләп торасың шунда. Кызы ни дияр бит әле? Хәзер бит кызлар ата-анадан сорап тормый. Тоталар да ябышып чыгалар. Сара апаны әйтәм, шәһәргә җибәрергә риза, күрәсең?

– Риза булмыйча нишләсен? Даут армиягә киткәнче үк ике ел Казанда эшләп китте бит...

– Кара әле, Галимә, әнә бит, Даут үтеп бара түгелме? Бигрәк килешә дә икән үзенә моряк киеме.

– Чынлап та, әллә тегермәнгә, Гаделша бабай янына баруымы егетнең?

– Шул инде, Галимә, әнә бит тегермән сукмагына борылды...

...Чирмешән болыннары аша искән көньяк җиленнән алты канатлы тегермән әкрен генә әйләнеп тора. Тегермәнгә якынлашкан саен Даутның күңелендә борчулы уйлар арта барды: «Карт үзе генә булса ярар иде, – дип уйланды ул, – ничек сүз башларга? Әллә болай гына, хәл белергә барган булып кына сөйләшергәме? Юк, картның кылларын тарткалап карарга кирәк. Ни дияр. Бәлки, берәр акыллы сүз әйтер? Нисаны туй ясамыйча бирмим дисә, нәрсә эшләргә? Мин бит, ике атнадан эшкә чыгам, дип ышандырып кайткан идем. Сузарга ярамый...»

Даут киң итеп ачып куйган капкадан эчкә үтте дә таш каршысында он капшап торган тегермәнче картка кычкырып сәлам бирде:

– Исәнмесез, Гаделша абзый. Исән генә эшләп буламы?

– Аллага шөкер, кем, Даут, синме бу? – диде карт, диңгезче формасында киенгән егетне баштанаяк карап. – Исән-сау гына кайттыңмы? Сине танырга да юк.

Карт онлы куллары белән егетнең ике кулын учына алды.

– Кунакка гына кайттыңмы, әллә, әниең ялгыз дип, бөтенләйгә җибәрделәрме? – диде карт, он кунган кашлары астыннан гына егеткә карап.

– Бөтенләйгә кайттым, Гаделша абзый, өч ел булды бит инде.

– Инде авылда кала торгансыңмы?

– Казанда, армиягә киткәнче эшләгән җиремә урнаштым...

– Алай икән, авылда калмыйсың икән, – диде карт, чыраен сытып. – Үзең бердәнбер малай, әниең монда ялгыз чиләнсенме? Картлык көнендә әниеңне ялгыз калдырып ялгыш эшлисең, энем. Егетлек түгел бу...

– Гаделша абзый, мин бит әнине алып китәргә каршы түгел. Ул үзе шәһәргә барырга теләми.

– Дөрес эшли. Туып-үскән, гомер иткән ата-баба җирен нигә ташлап китсен. Буыннан-буынга күчеп килгән хәтер шунда, – дип сөйләп китте карт. – Сез, яшьләр, җиңел исәпле, берни белән дә санлашмыйсыз. Адәм баласы гомер-гомергә ата-баба туфрагында туып-үскән җирен хөрмәтләп яшәргә тырышкан. Сез, яшьләр, шәһәрдәге әзер матурлыкка кызыгып, шунда таю ягын карыйсыз. Матурны, рәхәтне эзлисез. Кан-кардәш бабаларыбыз бер дә алай итмәгән. Килмешәк илбасарлар бу җирдәге халыкларны кырып, шәһәр һәм авылларны җир белән тигезләп киткәннәр. Берничә кат шулай кабатланган. Әмма ләкин качып-посып калган бабаларыбыз ата-баба җирен онытмаганнар. Еллар үткәч булса да, яңадан кайтып, зур-зур авыллар, калалар төзегәннәр. Инде килеп, без шул авылларны таратырга тиешме? Яшьләр китсә, авыл картая. Аннан тарала, бетә. Юк, энем, китмә син авылдан. Син дә китсәң, башка да китсә, авылда кем кала? Кем икмәк үстерә? Кем авыл тормышын дәвам итә? Авыл булмаса, кала да яши алмый. Икмәк ул – дөнья тоткасы. Икмәктән башка тормыш юк.

Карт кинәт, сөйләвеннән туктап, тегермән эченнән күренеп торган Чирмешән болыннарына, аргы якта дулкынланып торган иген кырына карады. Аннан уң кулын алга сузып дәвам итте:

– Кара син, энем, чәчәккә күмелгән болыннар, уңдырышлы кырлар уртасында яшибез. Без картайдык, сез, яшьләр, шәһәргә китсәгез, бу җирләр, бу болыннар хуҗасыз кала бит! Хуҗасыз калган җир ташландыкка әйләнәчәк, җиргә аңарга хуҗа кирәк, энем. Чын хуҗа. Җир өчен, табигать өчен янып-көеп яши торган хуҗа. Юк, энем, китмә син авылдан.

Гаделша карт он кунган калын кашлары арасыннан егеткә текәлеп карады да, аннан җылы сүз чыкмагач, күңеле төшеп, яңадан тегермән эченә кереп китте. Ул: «Үз малаем булсаң, мин синең белән бүтәнчә сөйләшер идем әле», – дияргә уйлаган иде дә тыелып калды. Таш каршысына килеп, онны капшап карады да чүмәләләнеп өелгән онны калак белән бер читкә этәрде. Аннан яңадан Даутка борылды:

– Синең әтиең, мәрхүм, чын крестьян, чын җир хуҗасы иде. Каһәр суккан сугыш нинди алтын кешеләрне харап итте. Минем Газизуллам да әйләнеп кайтмады. Ул кайткан булса, мин аны ике дә сөйләтмәс идем. Үзе дә җиргә чын хуҗа буласы егет иде...

– Тартасыңмы, Гаделша абзый? – диде Даут, картка «Беломор» пачкасын сузып. Тегермәнче дәшмичә генә бер папиросны алды да, күптән тарта торган кеше шикелле, онлы бармаклары белән әйләндереп йомшартты. Аннары, колак артына кыстырып куйганнан соң, егеткә эндәште:

– Үзең «Беломор» гына тартасың, – диде ул, хәйләкәр елмаеп. – Анда, шәһәрдә диюем, моны тартмый торгансыз әле?

– Төрлесе туры килә инде, Гаделша абзый. Мин үзем алай бик мавыкмыйм.

– Дөрес эшлисең, энем.

Гаделша карт Даутның авылга өйләнү нияте белән кайтканын ишеткән иде. Кичә кич карчыгы Миңсылу аңа шул турыда сөйләп торган

иде. Шуның өчен ул, тегермән ишегендә матрос киемендәге егетне күрү белән: «Нишләп йөри монда бу егет?» – дип, Даутның ерактан сәлам бирүеннән үк ниндидер яңалык белән йөрүен үзенчә юрап, егетнең кылларын тарткалап карарга булды.

– Он ясатырга дисәм, ашлыгың юк, балыкка дисәм, кармагыңны күрмим, кем, энем Даут, берәр җиргә баруыңмы әллә, дим?

Карт тартырга әзерләнгән кеше шикелле «Беломор»ны кулына алып, күзләрен кысып, егеткә карады. Аннары папиросны яңадан колак артына кыстырды.

– Мин, Гаделша абзый, сезнең янга килгән идем, – диде Даут, картка туры карарга тырышып.

– Нәрсә, әллә әниең Сара берәр йомыш белән җибәрдеме?

– Юк, Гаделша абзый, үземнең сүзем бар...

Егет кызара башлап, тотлыгып калды.

– Алай икән, йә, сөйләп кара, алай булгач.

– Мин, Гаделша абзый, өйләнү нияте белән кайткан идем... – Егетнең колакларына кадәр кызарып чыкты. – Гөлнисага... Ничек итәрбез икән?

– Алай икән... – дип тукталып калды карт, чыраен сытып. – Авылда торсаң, мин, энем, сиңа берсүзсез кызымны бирергә риза булыр идем. Болай узең уңган да, инсафлы да күренәсең. Тик шуны бел: мин кызымны читкә җибәрергә дип үстермәдем.

Тегермәнче, калак алып, тарткан онны капчыкка тутыра башлады. Аның кәефе киткәне сизелеп тора иде. Онны тутырып бетергәч, кинәт борылды да Даутка соңгы сүзен әйтте:

– Монда карт әниең бер ялгызы чиләнә. Кайт авылга, ул вакытта сөйләшеп карарбыз... Ә болай авызыңны да ачма! Гөлнисага күз салып, аның да башын әйләндермә!

Карт, корт чаккан шикелле, тиз-тиз атлап өскә менеп китте.

Даут һич тә болай килеп чыгар дип уйламаган иде. Картның кинәт үзгәреп киткән ачулы йөзен күреп, аптырашта калды. «Берәр төрле җылы сүз чыкмасмы?» – дип, бераз басып торды да, картның «акылга киләсенә» бөтенләй өметен өзеп, күңелсезләнеп, тегермәннән чыкты. Чирмешән буена килеп, тәмәке кабызды. Элек балык тотып йөргән урыннарга карап торды. Гаделша карт авызыннан чыккан һәр сүзне кат-кат башыннан кичерде: «Әллә соң Гаделша бабай дөрес әйтәме? Чынлап та авылга кайтыргамы?» Ләкин армиядән үк күңеленә беркеткән: «Кайтам да Гөлнисага өйләнеп, Казандагы иске эшемә урнашам. Әгәр риза булса, әнине дә үзем белән алып китәм», – дигән иске хыялларыннан арына алмады. Аннары бер нәтиҗәгә килде: «Әй, нәрсә соң әле, тотам да Нисаны ябыштырып чыгарам, калганы барысы да үзеннән-үзе хәл ителер. Барыбер кияү дияр әле».

...Көттереп кенә кич булды. Урамда тальян тавышы ишетелү белән, Даут шул якка ашыкты. Тыкрыкта яшьләр җыела торган бүрәнәләр өстендә утырган кызлар арасыннан күзләре Гөлнисаны эзләде. Ләкин ул көткән кыз күренмәде. «Әллә инде бүген дә чыкмый?» Минутлар сәгатьләр булып тоелды. «Әллә инде Гаделша карт минем уйларымны сизеп, кызын чыгармаска булганмы?»

Даут армиягә китәсе җәйне үк, отпускга кайткач, Гөлниса белән танышкан иде. Кыз аны кире какмады. Һәр кичне аны шатланып каршы алды. Чын дусларча сөйләшеп утырды. Ләкин шул ягы бар иде: Гөлниса бер вакытта да, кул биреп күрешүдән ары, егетне якын җибәрмәде. Даут аның янына ук килеп утырганда да, кыз, кул сыярлык ара калдырып, күчеп утыра иде. Кичке уеннарда да үзен тыйнак тотты. Кайбер кызлар кебек артык чытлыкланмады. Чамалы булды. Бары тик татар кызларына гына хас саф күңелле, инсафлы кыз булып, үз абруен саклый белде. Даут армиягә китәсе кичне Сара апа яшьләр җыйган иде. Шул кичне ул Гөлнисага үзенең соңгы сүзен әйтте:

– Гөлниса, син акыллы кыз, мин сине яратам. Шуның өчен әйтеп китәм: минем армиядән кайтканымны көт. Мин синнән башкага өйләнмим, – дип, кызның ике кулыннан алып күзләренә карады. Гөлниса, Даутны үлеп ярата да, аның муенына сарылмады. Тыйнак кына итеп:

– Бар, Даут, хезмәт итеп кайт. Мин беркая китмәм. Тыныч бул, – дип, егетнең күкрәк кесәсенә үзе чиккән хуш исле кульяулык кыстырды да, үбеп алырга чиктән тыш зур теләге булса да, үз-үзен тыеп, кызлар янына йөгереп чыкты.

Иртә белән Даут киткәндә, Гөлнисаның нурлы күзләре гел аңарда булды. Шул нур сибеп торган сөйкемле караш, кул болгап калулардан Даут кызның үзен һичшиксез көтәчәгенә ышанып китте. Зур өмет белән өч ел хезмәт итте...

Даутның кайтканына икенче кич. Икенче кич егет түземсезлек белән Гөлнисаны көтә. Ә ул һаман күренми. Ни булган? Әллә башка берәүгә күзе төшкәнме? Бу минутларда Даут өчен дөньяда бернәрсәнең дә кирәге юк. Күңелендә бары бер генә кеше – аның өчен бик тә кадерле булган Гөлниса гына...

Кичә ул, соң гына кайтып, яшьләр янына да соңгарак калып чыккан иде. Шуның өчен моряк егетнең кайтканын күпләр белми дә калды. Бүген аның тирәсендә чуалучы бала-чага гына түгел, яшьләр дә шактый.

һәрберсе: «Моряк кайткан, моряк!» – дип, ачык йөз белән күрешә. Хәләхвәл сораша. Кайбер шаяннары: «Моряк, штаны горят!» – дип, шаяртып та ала. Даут берсенә дә үпкәләми. Шат елмаеп, «Беломор» белән сыйлый.

Ул шәһәргә, армиягә киткәнче үк, култыклашып, гармунга җырлап, урам әйләнергә ярата иде. Балачактан ук җырлап урам әйләнүче яшьләр артыннан бер дә калмыйча ияреп йөрде. Шуның өчен дә ул гармунчы Гаптулла:

– Әйдәгез, егетләр, җырлап урам әйләнәбез! Даутны күрсәтергә кирәк, – дигәч, кызу эш вакыты, килешмәс, дип уйласа да, каршы килмәде. Киресенчә, Гөлниса минем кайтканны ишетмәгәндер, ишетер дә чыгар, дип шатланды гына.

Гармунын тартып Гаптулла алга чыккач, егетләр Даутны уртага алып култыклаштылар да Чирмешән очына таба кузгалдылар. (Гөлниса да шул очта тора бит.) Гаптулла култыклашкан егетләргә алды белән борылып атлаган хәлдә «вараксин»ны тартып-тартып сайрата башлады. Кичке тынлыкта йөрәкләргә чиксез дәрт бирүче моң бөтен авылга таралды, күңелнең нечкә кылларын кузгатып, ачык тәрәзәләрдән өйләргә керде. Арганнарга ял бирде, ятарга җыенган кызларны сискәндереп, тәрәзә пыялаларына кагылды, йортларны, киң урамнарны үтеп, Чирмешән болыннарына таралды.

Тальян тавышы тәэсир итмәгән кеше авылда бармы икән? Ачылмаган тәрәзәләр ачылды. Капка төпләрендә кешеләр күренде. Яшьләр урам әйләнә, Даут кайткан, диючеләр дә булды. Гаделша карт та ятарга җыенган җиреннән муенын сузып тәрәзәгә үрелде. Эх, яшь вакытлар... Урамда исә җыр яңгырады:

*Гармуныңны тартып уйна,*
*Җырлаучыга хут булсын.*
*Йоклап яткан яшь кызларның*
*Ике күзе ут булсын.*

Гөлниса үткән төнне җәйләүдә дежурда иде. Бүген кичтән ятып ял итәргә җыенып йөргәндә, кинәт колагына ишетелгән тальян тавышы, төрттереп җырланган җыр сискәндереп җибәрде. Чолан ишеген дә япмыйча, капка төбенә атылып чыкты. «Әнекәем, әллә Даут кайткан инде?..» Ул яшьләр арасыннан ак матрос киемендәге егетне шәйләп алды. «Даут... Даут кайткан. Башка беркем дә түгел...» Кыз атылып чоланга керде, кич чыкканда кия торган зәңгәрсу күлмәген җептә эленеп торган җиреннән алып киде дә, косынкасын кулына тотып, урамга ашыкты...



Гөлниса килгәндә, егетләр, кызлар Чирмешен буендагы бакчада төркем-төркем булып сөйләшеп торалар. Уеннар башланмаган иде. Даут кызны читтән үк күреп алды. Атылып барып Нисаны кочаклап алырдай булып сабырсызланса да, түзде, кыз янына ашыкмады. Ләкин бу хәл озакка бармады, сөйгәненең күзләре гел үзе ягында икәнен сизгән күңел егетне тартып диярлек кызлар янына алып килде.

– Әллә бүген Гөлниса да чыккан инде? Исәнме, Гөлниса! – дип, егет, ике кулын күрешергә сузып, очлы күзләрен кызга текәде.

– Исәнме, Даут, исән-сау кайттыңмы? – Кыз, сөйкемле елмаеп, ике кулын күрешергә сузды. – Кайчан кайттың, Даут?

– Икенче көн инде. Сез генә күренмисез.

Ул кызның йомшак һәм кайнар кулларын учына алды...

Гармун уйнап җибәрделәр. Даут кызлар-егетләр җырлашып, биешеп, төрле уеннар уйнап үткәргән авыл кичләрен сагынып кайткан иде. Кызның кайнар кулларын учына алып, аның сөйкемле дә, иркәле да карашыннан күзләрен ала алмый бер мизгел ләззәтләнеп торганнан соң, телгә килде. Бу минутта кызлар җыр башлап җибәргәннәр иде.

– Гөлниса, әйдә әле җырла! – диде ул, кызның кулларын учында тоткан килеш. – Тавышыңны сагындым.

– Үземне сагынмадыңмы, Даут? – дип шаяртты кыз. Нурлы карашы белән егетнең күңелен бер өтеп алды да, җавапны да көтеп тормыйча, кызлар янына барып җырга кушылды.

*Кичкә керсәм, иртә торсам,*
*Син генә уйларымда.*

Гөлниса үзе җыр башлады:

*Агыйделгә төшкәнем юк,*
*Суларын эчкәнем юк.*
*Синнән башка берәүгә дә,*
*Серемне чишкәнем юк.*

Җырлаганда да кызның шат, сөйкемле күзләре Даутка карыйлар иде. Бераз җырлаганнан соң, гармунчы бию көен башлап җибәрде.

– Йәгез әле, егетләр, кызлар, тузаннарны кагып алыйк!

– Даут биесен, Даут! – диеште кызлар. – Матрос биесен!

Егет ялындырып тормады. Ул электән үк авылда иң оста биючеләрдән иде. Үзенең яңа һөнәрен күрсәтеп, бер-ике әйләнде дә Гөлнисаны биергә чакырды. Кыз да төшеп калганнардан түгел, зәңгәрсу күлмәге белән җилфер-җилфер очынып, матрос тирәсендә әйләнде...

Биюләр беткәч, уеннар башланды. Яшьлар беренче әтәчләр кычкырганда гына таралыша башладылар.

Алар икәү генә калды.

– Исән-сау гына тордыңмы? – дип сүз башлады егет.

– Исән булмасам, чыкмас идем, – дип шаяртты кыз. – Хәлләрем ал да гөл – калганын үзең бел. Даут кайткан, диделәр дә, чыкмас җиремнән чыктым...

– Көттеңме, сагындыңмы, Гөлниса? Мин сине өзелеп сагындым. Белсәң, мин сине кичәдән бирле көтәм...

Егет, хискә бирелеп, кызны кочаклап алды.

– Чү, ашыкма, – диде кыз елмаеп, егет куеныннан чыккач. – Алай бик сагынгач, кичә үк турыбызга килеп җырлыйлар аны. Хәлил кебек...

– Җырларсың синең әтиең белән...

Даут тукталып калды. «Әтисенең мине ничек борып җибәргәнен әйтергәме-юкмы», – дигән уй борчый иде аны. Һәм егет көндез булган сөйләшүне кызга әйтмәскә булды.

– Җырлар идем дә, әтиең кабыргаларымны санар, дип курыктым.

– Сагынсаң, аннан гына куркып тормас идең әле...

– Йә инде, шаяртма, – диде егет, кызның кулларыннан алып. – Мин бит армиягә киткәндә үк сиңа соңгы сүземне әйтеп киткән идем. Мин сине алып китәргә дип кайттым, Гөлниса!

– Шулаймыни, кайчан алып китәсең соң?

Даутның йөзе яктырып китте. Ул, шатланып, кызны күтәреп алды.

– Менә шулай, кочагымда йоклатып, хет өйгә, хет Казанга кадәр алып барам...

– Чү, чү, ашыкма, Даут, үзем барсам, алып барырсың, – диде кыз. «Мин мәче баласы түгел», – дияргә дә уйлаган иде, әмма теленнән икенче сүз чыкты:

– Мин әле хәзер үк кияүгә китәргә, дип чыкмадым.

Кызның күзләре, үз итеп, сөйкемле елмаялар иде. Шул нурлы елмаюны күреп, Даут үпкәләргә җыенган җиреннән, кызның кулларыннан алып, күзләренә текәлде.

– Кайчан соң, Гөлниса? Мин бик озак тора алмыйм...

– Юк, Даут, киңәшик әле, ашыкмыйк, – диде кыз, егеткә җитди карап. – Кайда, ничек яшәрбез соң без?

– Казанда эшләгәнемне беләсең бит инде, Гөлниса. Анда минем бүлмәм дә бар. Өйләнешәбез дә китеп барабыз. Калганы үз җае белән булыр.



– Әниеңне шулай ташлап китәбезме? Картлык көнендә?

– Аның барасы килми шул. Ялгыз торасы килмәсә, барыр...

– Барасы килмәс шул. Малае, килене белән башка-баш куеп ятарга. Аннары, шуны да әйтим: минем дә әти-әни бар бит әле. Дөрес, мин аларны сиңа тагасым килми. Ләкин мин аларны ташлап та китә алмыйм, Даут. Без үстек инде, сездән башка да яши алабыз, дип аларны олыгайган көннәрендә ташлап китү дөрес эш түгел. Андый намуссызлыкны мин эшли алмыйм, Даут. Сиңа да киңәш итмим.

– Нишләргә соң, Гөлниса? Мин бит сиңа чын күңелдән ышанып кайттым. Сүземне тыңларсың дип, алып китәргә дип кайткан идем!

– Дөрес эшләгәнсең, Даут, – диде кыз, егеткә нурлы караш ташлап. – Яратуым да, сиңа чыгарга әзер торуым да хак. Ышанып кайтуыңа да рәхмәт. Тик минем фикерләремә дә колак сал әле, сөйгәнем. Аңлашыйк, киңәшик. Минем әти, киңәшле эш таркалмый, ди. Картлык көннәрендә аларны ташлап китеп, без бәхетле булырбызмы соң? Сырхаулаган, ярдәм кирәккән вакытлары булыр. Утынын, печәнен кем кайгыртыр?

– Кайтып булышырбыз. Казан җир читендә түгел...

– Бик күп булышалар әнә Минсафа әби балалары. Малае, килене, ике кызы, ике кияве. Җитмеш җидедәге әниләре утын, печән артыннан йөреп иза чигә. Ит, йомырка кирәксә, еш кайталар да бит, кеше баласына әйтеп булмый. Без дә шулай йөрергә калдырабызмы? Алай дөрес булмас бит, Даут?

Гөлниса егеткә якын ук килде дә, аның ике кулыннан алып, күзләренә текәлде.

– Калыйк авылда, сөйгәнем.

Кызның күз карашы шундый эчкерсез, шундый сөйкемле иде. Даут чак кына:

– Мин риза, Гөлниса, – дип әйтеп ташламады.

Шулай да әнисе белән булган сөйләшүнең нәтиҗәсен әйтергә булды.

– Әнием миңа үзе бит: «Теләсәң нишлә, улым», – диде. Үзе шулай дигәч...

– Шулай инде, әниләр һәрвакытта да, үзләренә авыр булса да, безгә уңай булсын дип, каршы төшмиләр. Без аларның мәрхәмәтеннән файдаланып, үзебезгә җайлы якны гына карыйбыз, шулай итеп, картлыгыбызда таянычым булыр, дип үстергән әти-әниләр кәкре каенга терәлеп калалар. Әнә, сезнең күрше Гайшә әбине генә ал. Малае, килене бар өстеннән ялгыз тилмерә, мескенем. Юк, Даут, мин алай итә алмыйм. Син дә әниеңә бер генә бала, мин дә бер генә. Аларның картлыклары

безнең өстә. Мин үзем дә шатланып, аларны да шатландырып, бергә-бергә яшәргә телим.

Кыз егетнең күзләренә туры карап дәвам итте:

– Калыйк, сөйгәнем, авылда! Шикләнмә, кулыңа ни тотсаң, шуны булдыра аласың бит син, Даут. Машинада да, тракторда да эшләгәнең бар. Икебездә авылда иген игеп, терлек карап үстек. Мин эштән курыкмыйм. Тормышны бергә тартырбыз. Йортны яңартып, җиләк-җимеш агачлары утыртырбыз. Үзебезгә җир алып, мал-туар үрчетербез. Хәзер бит җир алырга да, теләгәнчә мал асрарга да мөмкин.

– Фермер булыпмы? Белмим шул.

Даут кинәт Гөлнисага күтәрелеп карады. Аның йөзендә нинди дер кызыксыну барлыгы чагылып китте.

– Нәрсәсен белмисең ? Теләгең генә булсын, – кыз тагын да дәртләнеп сөйли башлады. – Әнә Миңнехан абзыйның малае, кызы, кияве, берләшеп, илле гектар җир алдылар да, икенче ел инде үзләре хуҗа булып, гөр килеп эшләп йөриләр. Үзләренең машиналары, тракторлары бар. Арендага, диме шунда, сыерлар алдылар. Терлек абзары төзеделәр. Без кемнән ким? Әллә иген икмәгәнме, терлек асрамаганмы?..

– Син, Гөлниса, Миңнеханнныкыларга карап, чыннан да Наполеон планнары корып куйгансың да бит, – дип елмайды Даут. – Тик аларга карап эш итеп булмый, минемчә. Алар – ике-өч гаилә. Без синең белән икәү генә ни эш чыгарырбыз икән соң?

– И-и, сөйгәнем, теләгең генә булсын.

Кыз Даутның киңәшкә килергә әзер булуын сизеп, ике кулы белән аның беләген кысып үзенә тартып, аңа шат йөз белән карап дәвам итте.

– Җае табыла аның, җаныем. Мин әле боларны аң булып тор дип, оеткы салыр өчен генә сөйлим. Хәзер авылда әллә нинди яңалыклар бар. Фермер, дисеңме. Арендатор, дисенме. Крестьян хуҗалыгы берләшмәсе, дисеңме...

Гөлниса, бүрәнә өстеннән торып, Даутның каршысына басты.

– Әниең белән киңәшләшеп кара, сөйгәнем. Белеп торам, Сара апа моңа шатлана гына. Иртәгә уенга чыккач, үз фикереңне әйтерсең, – диде кыз, сөйләшеп беткәнгә санап. – Хәзер бар, кайт. Мине озатып йөрмә. Хәерле төн, татлы йокы, – дип, егетнең кулларыннан кысты. Аннары кайнар иреннәре белән чуп иттереп үбеп алды да, егетнең йөрәгенә ут салып, төнге караңгылыкка кереп югалды.

– Тыныч йокы, Гөлниса...

Даут сихерләнгән шикелле, урыныннан торырга да өлгерә алмыйча, кызның сылу гәүдәсе кереп югалган караңгылыкка карап торды.



Шәфәкъ тынлыгын бозып, әтәчләр кычкыра башлады. Егеткә ямансу булып китте. Гөлнисаның кыйгач кашлары астыннан сөеп, нур чәчеп торган карашы күз алдыннан китмәде. Куллары кызның йомшак, кайнар кулларының җылысын тойды. «Төпле, уңган хатын буласы», – дип уйлады ул, үзе сайлаган кызның акыллы киңәшләрен хәтерләп. Күңеленнән ул инде авылда калырга да каршы түгел иде. «Нигә соң әле мин Гөлнисага шунда ук, мин риза, китмим, авылда калам, димәдем?» – дип үкенеп тә куйды. «Ярар, әнигә барысын да сөйләп киңәшләшергә кирәк. Ул ни дияр».

Яктыра башлаган авыл урамыннан Даут, шатлыклы уйларга чумып, әкрен генә кайтты. Болын ягыннан хуш исле таң җиле килде. Шул якта атлар кешнәгәне ишетелде. Авыл артындагы басуда трактор гүләде. Кагына-кагына әтәчләр кычкырды...

...Даут Гөлнисаны тыкрык чатында ук елмаеп каршы алды.

– Китмибез авылдан, әни дә...

– Шулаймы? – диде кыз, кояштай яктырып һәм, очып килеп, Даутның иңнәренә кулларын салды да кайнар иреннәре белән ике битеннән үбеп алды. – Рәхмәт, сөйгәнем, шулай итәсеңә шикләнмәгән идем.

– Әни дә бик шатланды, – диде егет, кызны култыклап алып. – Мин Гөлнисага өйләнәм, авылдан китмим, дигәч.

– Акыллым син минем, – диде кыз, Даутны нур чәчеп торган күзләре белән иркәләп һәм үзенең яратуын белдерер өчен беләгеннән кысып, аңа сыена төште.

Яшьләр янына алар кулга-кул тотынышып килделәр. Икесенең дә күзләреннән нур бөркелә, иреннәре шатлыклы елмая иде.

– Союзмы әллә, Даут? – дип каршы алды аларны гармунчы Гаптулла.

– Союз, малай, союз, – диде егет, шатлыгын яшәрмичә, кызны култыклап янәшә барып. – Китмибез...

– Дөрес эшлисез. Котлыйм алайса, – дип, тальянын тартып уйнап җибәрде Гаптулла. Җәйге авыл киченең рәхәтен тоеп, яшьләр клуб янынннан озак таралмадылар. Таңга кадәр клуб яны шаулап торды. Җырладылар, биеделәр, төрле уеннар уйнадылар. Таң әтәчләре кычкыра башлагач кына, Даут, Гөлнисаны култыклап, читкә алып китте.

– Киттекме, Гөлниса? – диде ул, кызның каршысына басып.

– Шул килешме? – диде кыз, ике кулының да буш икәнен аңлатып. – Бер әйберсезме?

– Әйберләреңне соңыннан алып килербез, Гөлниса. Мин сиңа туй киемнәре алып кайттым.

– Әниеңә әйттеңме соң? Әзерләндегезме?

Даут аптырап калды. «Бүген килен алып кайтам», – дияргә аның уена да килмәгән иде. Ләкин әйтмәдем дияргә дә батырчылык итмәде.

– Анда әни көтеп тора...

– Үзе генәме? – диде кыз, уйга калып.

– Үзе генә. Тагын кем кирәк?

– Тагынмы? – диде кыз, җитдиләнә төшеп. – Тагын минем Сара малае Даутка хәләл җефетлеккә чыгып, авылда калуыбызны белеп торучы шаһитлар кирәк.

– Миңа ышанмыйсыңмы, Гөлниса? Аларсыз да ярар...

– Ышанам да, ышанмыйм да. Син шәһәргә китәм дисәң, минем авылда каласым килә.

– Мин шундый ышанычсызмы, Гөлниса? Яратуымны беләсең бит. Утыз ай көттем бит мин бу көнне. Утыз ай. Көннәргә, сәгатьләргә әйләндерсәң, чуты юк. Камчатка бураннары, давыллары эченнән очып кайтып китәрдәй вакытларым булды. Синең киткәндә биргән бүләгеңне күкрәк кесәмдә йөрттем. Шул миңа зур ышаныч бирде. Исән-сау кайтсам, синнән бер сәгатькә дә аерылмас идем, дигән вакытларым күп булды...

Егет үзләренең, штормга эләгеп, карлы-бозлы дулкын белән палубадан очып төшүләрен, үпкәсе җилсенеп, госпитальдә ятканда кызны күрәсе килеп, төшләнеп яткан вакытларын сөйли-сөйли килә торгач, Даутларның капка төбенә килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар.

Карасалар, өйдә көтеп тору түгел, ут та юк. Кыз, шуны күреп, шып туктап калды да: «Бу ни дигән сүз?» – дигәндәй Даутка карады.

– Әнинең башы авыртып тора иде. Көткән-көткәндер дә яткандыр. Таң ата бит инде, Гөлниса, – диде егет, кызның ике кулыннан алып. – Әйдә, керәбез, – кызның икеләнеп торганын күреп дәвам итте. – Әйдә, Гөлниса, керик. Анда яшьләр белеп калды. Әллә ни уйлаулары бар. Иртәгә иртән үк авыл советына барып язылышып кайтырбыз.

– Иртәгә, димә инде, Даут, бүген дип сөйлә, – диде кыз, егеткә нурлы караш ташлап. – Минем бер үтенечемне үтәсәң, керәбез!

– Үтим, Гөлниса, әллә шикләнәсеңме?

–...

Алар сөйләшмичә генә, ишек алдына үттеләр.

– Менә безнең урын шунда булыр, кызый, – диде егет, агач караватны капшап.

– Бүгенгә урынга ятмабыз, Даут, – дип пышылдады кыз. – Әниең торганчы, сөйләшеп утырырбыз. Хәзер яктыра инде. Әниең торып, безне каршылыгач, советка барып, никах кәгазе алып кайтырбыз. Аннан мин – синеке.

– ...

– Кил, утыр яныма, – диде кыз, аптырап калган егетнең кулыннан алып.

– Әллә ниләр уйлап чыгарасың үзең, – дип, Даут кәләшенең беленнән алды.

– Вакытсыз өзелгән чәчәк тиз шиңә, – диде кыз, кайнар сулышы белән Даутның колагына пышылдап. – Мин синнән шуны сорыйм, сөйгәнем, вакытыннан алда сузылма!

– Вакыты кайчан соң? – диде кайнар сулыш.

– Никахтан соң, – диде тагын да кайнаррак сулыш. – Егет куенына никахсыз керү – әдәпсезлек, ди минем әнием. Сабыр төбе сары алтын, диләр түгелме? Сабырыңны җый, сөйгәнем...

Сара апа кичтән бик озак уйланып ятты. Өйләнеп китәргә дип кайткан малаеның кинәт: «Әни, син ни диярсең икән, мин, Гөлнисага өйләнеп, авылда синең янда калырга уйлыйм, – дигәч: «Чынлап сөйлиме икән?» – дигәндәй малаена бер тутырып карап алды да, шатлыгын яшермичә:

– И-и, улым, балакаем, ни дип әйтим, мин бик шат. Бик риза. Кайсы ананың баласын үз яныннан җибәрәсе килсен инде? Дөрес, бик дөрес эшлисең, улым. Картлыгымда калган гомеремне туган җиремдә, әтиең нигезендә оныкларымны карап, бергә-бергә үткәрермен, ичмасам. Әтиең нигезен ташлап, калага китеп баруыңа каршы килмәсәм дә, күңелем тартмый иде, улым, – дип, күз яшьләрен сөртеп алган иде.

Аштан соң Даутның, йортка чыгып, аны-моны рәтләп, йорт эчен, капка төпләрен себереп йөргәнен күреп, аңа тагын бер шатланып куйды. Аннан үзе дә, килен кайта калса дип җыйган каймакларын алып чыгып, май язды. Өйне җыештырып, идәннәрен юып алды. Кич көтү кайту белән, сөтләр җыештырып, корт кайнатырга куйды. Мич ягып, җәймәләр, бавырсаклар пешерде. Даут киенеп-ясанып яшьләр янына чыга башлагач: «Улым, кайчангарак кайтырсыз икән?» – дип сорарга да уйлаган иде дә: «Йә, үз вакыты белән алып кайтыр әле», – дип, ул уеннан кире кайтты. Даут чыгып киткәч, эшен бетереп, ятар алдыннан ишек алдына чыгып, караватка ике кешелек итеп урын җәйде. Шуннан соң гына, тынычлап, йокларга ятты.

Ләкин тиз генә йокыга китә алмады. «Ничек болай килеп чыкты соң әле? Нилектән бу малай кинәт үзгәрде? Әллә берәр олы кеше акыл бир-

деме?» – дип уйланып ята торгач, төн уртасы узганда гына изрәп йокыга китте.

Башка көннәрдәге шикелле Даут кайткач, капка шыгырдаганын да, егет белән кызның мөлдер-мөлдер сөйләшеп утырганнарын да сизмәде. Уянып китеп, ишекне ачып җибәргән иде, Даут биленнән кочаклап утырган Гөлнисаның башын егет күкрәгенә төртеп, йокымсырап утырганын күреп:

– Бәрәкалла, малаем килен алып кайткан, мин йоклап ятам! – дип кычкырып җибәрде.

Егет белән кыз икесе берьюлы торып бастылар.

– Әни, син торганны көттек, – диде Даут. – Сиңа – килен итеп, үземә хәләл җефетлеккә Гөлнисаны алып кайттым...

– Бигрәкләр дә яхшы булган, улым, төкле аягың белән, кызым, – дип, Гөлнисаны кочаклап алды. Аннары ашыгып өйгә кереп китте дә, тун алып чыгып, яшьләр аяк астына җәйде.

– Басыгыз шунда, сандугачларым!

Егет белән кыз тун өстенә янәшә баскач, тагын нишләтә икән бу әни дип, бер-берсенә елмаешып торган арада, Сара апа, өйгә кереп, корт өстенә куелган май алып чыкты. Яшьләр каршысына басты да:

– Кабыгыз, җанкисәкләрем! Улым, син дә кап, кызым, син дә кап. Бергә-бергә тату яшәргә булсын! Бәхетегез белән! Кызым, син кояш чыкканда өемә килен булып керәсең, хәерле сәгатьтә булсын!



# ЙОЛДЫЗ КАШКА

Илгиз капкадан чыкты да, Гаяз күренмиме дип, дусты яшәгән урам ягына карап торды. Берәү дә күренмәгәч, әле көтүгә барырга иртәрәк дип, тыкрыкка чыгып, бакча артындагы тиреслектән суалчаннар карарга булды. Алар иртәгә, бик иртә торып, Гаяз белән балыкка барырга сөйләшкәннәр иде. Тыкрык башындагы тирән коены үтеп борылуы булды, капка астыннан атылып чыккан Шарик аны куып җитте дә, нигә мине калдырып, үзең генә китеп барасың дигәндәй, Илгизгә карап, һау дип өреп куйды.

– Ә-ә, килеп җиттеңмени, әлдем кисабы? Иярчен булып йөрергә яратасың үзең, – дип елмайды малай.

Шарик иркәләнеп сикергәләде, ялагайланды. Илгиз аның башыннан сыйпады. Аннан алар бергә бакча артына таба йөгерделәр.

Шулвакыт Илгиз уң яктагы читән буенда бер көтү ала карганың нидер чукып, каркылдашканын күреп алды. «Берәр нәрсә үлгән дә, каргалар шуңа җыелганнардыр», – дип узып бара иде, кинәт җирдәге хайван селкенеп куйды. Чү, әллә инде тере хайван? Кайдан килгән ул монда? Илгизнең ун көнләп тыкрыкка чыкканы юк иде.

– Шарик! – диде ул, шул якка күрсәтеп. Эт шунда ук хуҗасының ни әйтергә теләгәнен аңлап, һау-һау өреп, каргаларга ташланды. Каргалар,

пыр килеп, һавага күтәрелеп очып киттеләр дә арырак читән өстенә куна башладылар. Шарик, алар артыннан чапмыйча, кире борылып килде дә, тагын ни эшләргә кушасың дигәндәй, хуҗасына карап сикергәли башлады.

– Әйдә әле, нинди тай ул анда?

Эт тай янына томырылды. Җирдә хәлдән таеп яткан тайны исни-исни әйләнеп чыкты да, тайның баш очына килеп, бер тайга, бер Илгизгә карап шыңшый башлады.

Илгизләрнең күршесендә урман караучы Краснов Иван абыйлар торалар иде. Үткән җәйне алар, йортларын сатып, кайдадыр туганнары янына китеп бардылар. Иван абый күченгәндә яңа гына колынлаган карт биясен колхозга калдырып китте. Карт биянең соңгы колыны иде ул. Башка тайларга караганда ул матуррак та, буйга да озынрак, аяклары да нәфисрәк иде. Карт бия, тәрбия җитмәүдәнме, авырыпмы, кыш көне үлеп китте. Әнисез калган яшь тай, башка тайлар шикелле, ике яшькә кадәр сөт имеп үсә алмады. Тәрбиячесез калган ятим бала кебек ябык, чирләшкә булып үсте... Икенче җәйне сака (күбрәк тайларда була торган авыру: малның сулыш, йоткылык юллары астындагы лимфа төеннәре шешә, бизгәк тоткан кебек калтырата, авыру хайванның ашау-эчүе начарлана) белән авырды. Мескен тай инде ничә көннән бирле плеврит белән авырып ята. Узып йөрүчеләр, бу тай әле һаман үлә алмый ята икән дип, малның терелеп китүенә өмет итмичә узып китәләр. Тире белән сөяккә калган бу мескен тайның хәле шулкадәр авыр ки, инде ничәнче көн су эчә, үлән ашый алганы юк. Яткан җирендәге үләннәрне җиренә кадәр кырып бетергән, урыныннан кузгала алырлык хәле юк. Июнь кояшы астында ачлык һәм җаны сусаудан үләр хәлгә килгән. Хәтта, өстенә иелеп, тере килеш үзен чукый башлаган каргаларны куарлык та хәле юк. Ә каргалар шундый ерткычлар, тайны тере килеш ашарга керешкәннәр.

Илгиз җирдә хәлсезләнеп яткан тай яныа килеп баскан иде, исе китте: каргалар тайның арт ботын тишеп-чукып, итен кып-кызылга чыгарып бетергәннәр.

Тай нурсызланып калган эренле зур күзләре белән Илгизгә карап башын күтәрде. Бу күзләр аңа ялварып карыйлар...

– Вәт сиңа мә! Ерткычлар икән! – дип кычкырып җибәрде малай. – Мескенемне тереләй ашарга керешкәннәр! – Шарик тагын бер кат тай тирәли әйләнеп чыкты да, башы очына утырып, шыңшырга тотынды.

– Нишләргә? – Аптырашта калган малай як-ягына каранды. Каргаларның әле һаман китмичә, читән өстендә утырганнарын күреп: «Бу



ерткычлар әле тагын чукырга исәпләп торалар», – дип, юл читеннән оешкан җир кисәкләре алып, каргаларга тондыра башлады.

– Ах, явызлар, ерткычлар! Кө-өш-ш! Чебеш-бәбкә урлаганыгыз гына җитмәгән! Шарик! Ө-өс! Шуларны ө-өс! – Шарикка шул гына кирәк иде, ул хуҗасыннан алга чыкты да яңадан җиргә төшәргә чамалап түбәннән очкан каргаларны куып китте. Һау! Һау! Илгиз дә аннан калышмады, оешкан җир кисәкләрен тондыра-тондыра, каргаларны кыр артына очып киткәнче куып барды. Мышнап бетеп, тай янына яңадан килделәр. Шарик, тагын нишлибез дигәндәй, хуҗасына карады. Ә Илгиз үзе дә ни эшләргә белмичә аптырап калган иде.

– И-и, мескенем, кара инде нишләтеп бетергәннәр үзеңне? – дип, тайның баш очына чүгәләп, аны сыйпап алды. Тай исә, минем торасым килә дигәндәй, башын калкытып, алгы аякларын бөкләп, тезләре өстенә күтәрелергә теләп карады. Ләкин тора алмыйча, башын кире җиргә салды.

– И-и, мескенем, торасың киләме? Тора алмыйсыңмы? – Малай тай тирәсендә угаланды. Үз чиратында Шарик та, койрыгын болгап, тайның бер артына, бер алдына чыгып, башын кырын салып, карап торды. Илгиз тайның башыннан сыйпаганда, ул да аның борынын ялап алды. Тай, торырга теләп, тагын бер талпынып карады. Тик бу юлы да, арт санын күтәрә алмыйча, кире ятты.

– Йәле, йә! – диде малай, тайның арт саныннан булышып. – Йәле, әйдүк! Әйдүк! – дип көчәнде ул. Тай тагын бер талпынып карады да авырлык белән генә торып басты, хәлсез аякларын калтыратып, бер-ике адым ясады да озынаеп калган муены белән үләнгә үрелде. Ул шундый ябык, шундый хәлсез, бармак белән орынсаң да аварга тора иде.

Тай торып басып үлән чүпли башлауга, Шарик шатлыгын белдереп, һау-һау килеп, тай тирәли сикергәләргә тотынды.

– Шарик, җитте сиңа! Күрәсеңме, аның ашыйсы килгән.

Илгиз якынрак килеп, тайны сыйпап, яраларын карады. Арырак китеп, тай алдына үләннәр йолкып салды. Ләкин, ни хикмәттер, бераздан тай үлән ашаудан туктады да Илгизгә карап тора башлады.

– Нигә ашамыйсың? Аша, менә нинди тәмле үләннәр алып килдем, – диде малай, тайның башыннан сыйпап. Маңгаенда ак кашкасы барын күреп: «Сиңа Кашка кушарга кирәк. Кашкаң бар икән», – диде. Үзе йолкып килгән үләннәрне тайның авызына китерде. Ләкин тай үләннәрне иреннәре белән эләктергәндәй итте дә кире җиргә төшерде.

– Әллә муенның авыртамы? – диде Илгиз, тайның муенында эрен килеп торган яраны күреп. Ул тагын икенче төрле үләннар алып тайга сузды. Колын бу юлы да үләннәрне чәйнәмәде, кире җиргә төшерде. Үзе гел иреннәрен теле белән ялады. Кинәт малай, тайның эчәсе килгәнен чамалап, як-ягына каранды. Каргалар күренмәгәч:

– Шарик, син шунда кал! – дип, өйләренә йөгерде.

Капкаларын ачып керү уңаена, лапас янында торган буш чиләкне күреп, чүпләнеп йөри торган тавыкларны пыр туздырып, йөгереп барып чиләккә үрелде. Шунда торган зур кикрикле ак әтәч, нишләп минем тавыкбикәләремне куркытып йөрисең дигән шикелле, котыйк-котыйк итенгәләп, Илгизнең җилкәсенә кунды да, канатлары белән шап та шап сугып, малайның муенын чукый башлады. Илгиз:

– Әни-и! – дип кычкырып җибәргәнен дә сизми калды.

Нәкъ шул минутта капка астыннан атылып кергән Шарик, һау-һау килеп, әтәчкә ташланды. Йорттагы тавышка әнисе чыкканда, малай өстеннән Шарик куып төшергән әтәчне кулындагы чиләге белән бәрепбәреп куа башлаган иде.

– Ни булды, улым, нигә тавышланасыз?

– Әнә әтәч өскә сикерде. Бәреп үтерермен әле! – диде малай, еларга җитешеп.

– Тавыкларны куркыткансың әле. Яхшы гына йөрсәң, тими ул.

– Тими сиңа. Миңа әллә ничә ташланды инде. Әнә Шарик кына коткара тора, – диде Илгиз, әтәч чукыган муенын уып.

Шарик, үзе турысында сөйләгәнне ишетеп, һау-һау килеп, яңадан әтәчкә ташланды. Әтәч арт бакчага чыга торган капка башына очып кунды да, исем китте синең эт кебек өргәнеңә дигәндәй, канатларын кагып: «Ки-кри-күк!» – дип сузып кычкырып җибәрде.

Илгиз әтәчкә тидерим дип ташлаган чиләген барып алды да яңадан урамга чыгарга йөгерә башлаган иде, әнисе туктатты.

– Нишләп болай чабасың, улым? Чиләк белән кая барасың?

Илгиз, туктап, әнисенә таба берничә адым ясады да:

– Әни, безнең тыкрыкта Иван абыйлардан калган тай тора алмый ята, – дип, тыкрыктагы хәлне сөйләп китте. – Су эчерик әле, ул мескеннең эчәсе килгән, җаны көйгән...

– Көннәр бик эссе тора шул, эчер, улым, эчер. Эчәсе килгәндер, – диде Гайниҗамал апа, улына мөлаем карап.

Илгиз капкадан чыгу белән, кое янына йөгерде. Ул коедан су тартканда, Шарик, аның каршысына утырып, менә бит, мин булмасам, әтәч



үзеңне нишләткән булыр иде дигән шикелле, койрыгын болгап, башын кырын салып, хуҗасына карап утырды.

Кашка аларны иреннәрен ялап каршы алды. Үзе дә, каршы килергә теләп, бер-ике адым атларга тырышты. Илгиз чиләкне ике куллап тотып тайның борынына китерүе булды, ул, голт-голт китереп, суны сулыш та алмыйча эчеп бетерде.

– Мескенем, бигрәк җаның көйгән булган. Тагын алып килимме? Эчәсеңме? – диде малай, бер тайга, бер бушап калган чиләгенә карап. Кашка суны тамчысына кадәр суырып бетерде дә, башын чиләктән алуга, үләнгә үрелде.

Илгиз тагын суга йөгерде. Бу юлы тай күп эчмәде, иреннәрен тидереп бер-ике суырды да яңадан үлән ашарга кереште.

«Әнидән ипи сорап алып килим әле», – дип, Илгиз яңадан өйләренә йөгерде.

– Эчерденме, улым? – диде Гайниҗамал апа, каршысына малае килеп баскач. – Эчтеме?

– Эчердем, әни, әй эчәсе килгән мескенемнең, бер сулышта чиләктәге суны ялт иттерде. Әни, ул Иван абыйлар тае нигә алай ябык икән? – диде малай, ничек итеп ипи турында сүз башларга аптырап.

– Тәрбия җитмәгәнгә ул, улым. Тәрбия юк аңа. Ул бит бала гына. Өстәвенә, ятим. Әнисе булса, сөт имеп үскән булыр иде...

– Тайның муены нишләгән икән әни, эрен агып тора?

– Ул, улым, сака белән авырый торгандыр.

– Нәрсә соң ул сака?

– Ат авыруы ул, улым. Яшь атлар шуның белән авырыйлар.

– Шуның өчен ашый да алмыйлармы, әни?

– Авырса, кеше дә ашаудан кала бит, улым.

– Әни, ул тайның кашкасы бар. Мин аны Кашка дип атадым. Үләннәр йолкып бирдем. Мин биргән үләннәрне дә ашый, мескенем.

– Шулай кирәк, улым, шулай, кешегә дә, хайваннарга да мәрхәмәтле, миһербанлы булырга кирәк, – дип, Гайниҗамал апа улының аркасыннан сөйде.

– Әни, мин таган Кашка янына чыгыйм әле? Ул явыз каргалар аны тагын чукый башламасыннар. Сыртын чукып, канатып бетергәннәр...

– Хайван аягурә булганда, алар бик тимиләр, улым. Син тагын мавыгып, көтүне каршы алырга онытып җибәрмә. Хәзер көтү кайтыр вакыт җитәдер.

– Юк, әни, онытмыйм, – диде Илгиз, ишек төбендә таптанып. – Әни, ни, бер кисәк ипи алып чыгыйм әле тайга?

– И-и, улым, ипинең үзебезгә дә такы-токы гына икәнен беләсең бит инде. Ничек итеп яңа өлгергәнне җиткерик дип торабыз бит, улым, – диде Гайниҗамал апа, бәйли торган оекбашын читкә куеп. – Йә алайса, хайван хакы бар. Әз генә булса да, бирим инде.

Илгизнең шатлыктан авызы ерылып китте, ул әнисе артыннан почмакка керде. Әнисе, почмак сәкесе өстендә шакмаклы ашъяулыкка төрелгән ярты ипине алып, юка гына бер телем кисте дә улына сузды.

– Әни, печтик кенә итеп, үземә дә кис инде?

– Менә бит, улым, яртысын үзең аша, яртысын таеңа каптыр, – диде Гайниҗамал апа. Ә үзе, улының сүзен кире какмыйча, аңа да бер телем ипи кисеп бирде. – Туеп куймасаң да ярар. Хәзер аш өлгертәм.

– Әни, рәхмәт! – диде Илгиз, сикерә-сикерә ишеккә атлап.

Шарик аны капка артында, кулындагы ипиләрен күреп, сикерә-сикерә каршы алды.

– Каргалар килмәдеме? – диде малай, Шарикка да бер кисәк ипи биреп. Әлегә кадәр беркем кулыннан да әйбер алмаган Кашка аны битараф кына каршы алды. Башта Илгиз биргән ипине теләр-теләмәс кенә алган иде дә, чәйнәп карагач, тәмен белеп, үзе үрелә башлады.

– Башка юк шул, – диде малай, кулындагы ипи кисәгенең бетүенә уңайсызланып. – Ярар, мин сиңа хәзер тау астыннан тәмлерәк үләннәр алып менәм, – дип, урам аша чыгып, тау астына йөгерде.

– Илгиз! Кая барасың!?

Урамнан дусты Гаяз килә иде. Ул, туктап, аны көтеп торды.

– Кая барасың? Әйдә, көтү каршыларга соңга калабыз. Әнә көтү керә!

– Тау астына үлән йолкырга дип төшә идем. Ярар, көтүдән соң йолкып менәрмен инде...

– Нәрсәгә соң ул үлән, әллә куян ашатасыңмы?

– Үләнне куянга гына йолкыйлармы? Әнә тыкрыкта Иван абыйлар тае үлә язып ята...

– Нигә аңарга йолкып ашатасың? Үзен генә шунда куып төшер!

– Бөтен хикмәт тә шунда шул: ул төшә алыр хәлдә түгел. Үлә язып, ашарга-эчәргә тилмереп яткан... Авырый, муены шешкән.

– Шулаймыни? И мескен тай. Нишләде икән? Әйдә, карыйбыз!

– Әйдә, көтүне алып кайтыйк әле. Аннан соң күрсәтермен.

– Нигә карамыйлар икән аны?

– Кем карасын? Әнисе үлгән...



– Атларны конюхлар карыйлар бит. Тайлары да аларгадыр инде?

– Белмим шул, – диде Илгиз. – Кичкә этидән сорармын әле. Ат духтыры чакыртсыннар.

– Әйе шул, әйт. Этиең бит кәнсәләрдә счетовод. Кичке уенга чыгабызмы, малай?

– Юк, чыкмыйм. Әле минем Кашкага үлән йолкыйсым да бар. Аннан тиз кайтып булмый. Син дә чыкма. Үзең иртәгә иртүк балыкка барабыз дидең... Әллә бармаска булдыңмы?

– Ярар, сөйләштек! – диде Гаяз. – Әйдә, хәзер көтүне алып кайтабыз да, мин сезгә киләм. Тайны да бергә ашатырбыз.

– Әйе шул. Безнең тыкрыктан суалчаннар да казып алырбыз.

– Йөгердек! – диде Гаяз, дустының җиңеннән тотып. – Көтү кайта.

Чишмә очында сыерлар мөгрәгән, кәҗәләр, сарыклар, бәрәннәр кычкырган тавыш белән бергә күтәрелгән тузан болыты күренде. Иң алдан тузан болыты эченнән, сакалларын селкеп атлаган кәҗәләр белән аралашып, борыннарын җиргә төртеп, пошкыра-пошкыра сарыклар килә. Арттараклары тузан эченнән күренмиләр дә. Иң арттан читкә чыгып калырга тырышучы азгын сыерларны тирги-тирги көтүче Гәрәй абзый кайта. Аның шарт та шорт чыбыркы шартлатканы ишетелеп тора.

Гаяз – Илгизнең якын дусты. Алар Гаязлар Сабанчыга күчеп килгән җәйне Чирмешән буенда балык тотканда дуслашып киттеләр. Гаяз яңа дустын, үзләренә алып кереп, әнисе белән таныштырган иде. Кәримә апа аларны баздан алып чыккан каймаклы катык белән сыйлады. Гаяз белән Илгиз яшьтәшләр булу белән бергә, аларның төс-буйлары, хәтта бит төзелешләре белән дә бер-берсенә охшаган. Тик Гаязның чәчләре кара, күзләре соры, ә Илгизнең чәчләре соры, күзләре зәңгәр булуы белән генә аерылалар. Шуның өчен Кәримә апа аларны күп вакытта, игезәкләрем дип, сөеп тә куя.

Җәй көннәрендә алар Илгизләрнең салам куыш ясап ябылган кар базы өстендә, йә булмаса, тезмәләрендә йоклыйлар. Бүген дә Гаяз көтүне кайтарып япты да, әнисеннән сорап, Илгизләргә кунарга килде.

– Менә күрәсеңме? Каргалар нишләтеп бетергәннәр тайны, – дип каршы алды Илгиз Гаязны.

– Вәт, ма-ла-ай, кара инде нишләтеп бетергәннәр, – диде Гаяз, тайның каргалар чукыган җирләрен карап. – Берәр дару сипсәң, чебеннәр килмәс иде инде...

– Даруны каян аласың? Әйдә, әрекмән яфрагын ябып карыйбыз.

– Әрекмән төшә бит ул, бәйләп куймагач.

– Ятып торганда ярар, – диде Илгиз, читән буеннан зур әрекмән яфрагы алып килеп. – Менә булды. Әйдә, малай, үлән йолкып менәбез. Син төшә тор. Мин чиләк алып чыгам.

Сусыл үлән белән басып-басып тутырган чиләкне икесе ике яктан тотып, тай янына килгәндә караңгы төшеп килә иде.

– Илгиз, малай, әйдә, караңгыга кадәр суалчаннар җыеп калыйк!

– Әйдә, хәзер җыябыз аны. Анда безнең тирес янында карандаш буйлылары бар. Киттек!

Ике малай, суалчан җыеп, әрекмән яфрагына төреп, Илгизләргә кайтып кергәндә караңгы төшеп, күз бәйләнеп килә иде.

– Шул гомер йөрмәсәгез ярамадымы? Ачыгып беткәнсездер инде, – дип каршы алды аларны Гайниҗамал апа. – Барыгыз, кулларыгызны юып керегез. Аш салам.

– Әни, без суалчаннар казып соңга калдык,– диде Илгиз, өстәл артына утыргач. – Иртәгә без балыкка барабыз. Гаяз да бездә куна.

– Кайвакыттарак китәсез?

– Көтү артыннан ук, – диде Гаяз.

– Ярар, уятырмын.

Иртә белән Гайниҗамал апа терлекләрен капкадан чыгарды да малайларны уятырга килде:

– Тор-торлардан хәбәр килгән. Тор-тор, улым, тор инде! – дип көйләде ул. Тик малайларның тыннары да юк иде.

– Илгиз, Гаяз, балыкка барабыз дигән идегез, торыгыз! – дигәч кенә Илгизнең тавышы килде:

– Гаяз, әйдә, малай, көтү киткән! Кашканы да карап китәсе бар! – диде ул, ачылырга теләмәгән күзләрен угалап.

...Иртәнге тынлык. Чирмешән өстендә әле томан да таралып бетмәгән. Тыныч кына аккан елга өстендә, әле анда, әле монда, чулт-чулт балык чиертә. Чирмешән талларында сандугач сайрый. Ике дус, тавышланмыйча, сөйләшмичә генә су буена төштеләр дә, кармакларына чуалый эләктереп, суга ташладылар. Бер минут үттеме икән, Гаяз бер алдауканы ком өстенә чыгарып та салды. Балык шундый чиертә, иртәнге тынлыкта кармагың су өстенә чулт итеп төшүе була, шунда ук калкавыч сикерә дә башлый. Кояш югары күтәрелеп кыздыра башлаганда, малайлар берәр табалык балык тотып алганнар иде инде. Әле кайтырга уйларында да юк. Көтмәгәндә Чирмешен өстеннән берничә карганың очып үткәне күренде. Илгизнең тынычлыгы югалды.Тыкрыкта кичә күргән хәлне исенә төшереп, йөрәге жу итеп китте. Ул шунда ук:



– Гаяз, җитәр, малай, бүгенгә. Әйдә, кайтабыз! – дип, кармагын җыя да башлады.

– Әле иртә бит. Нигә ашыгасың? Тагын бераз тотыйк! Теземнәрне тутыргач, бергә кайтырбыз.

– Кашканы карыйсы бар...

– Кашканың нәрсәсен карыйсың? Печәне бар, әле генә су эчереп килдек.

– Теге каргалар тагын килерләр. Ятып калды бит ул...

– Ятып калса ни булган? Торасы килсә, торыр әле.

– Әйттем бит инде, ул үзе тора алмый. Син кайтмасаң, мин үзем генә кайтам!

Гаяз:

– Бар кайт! – дигәнен үзе дә сизми калды.

Илгиз кармагы белән балыкларын алды да, минут эчендә яр башына менеп, күздән югалды. Гаяз, исенә төшеп:

– Илгиз, тукта, бергә кайтабыз! – дигәндә, ул инде әллә кайда иде.

Дустының китеп баруын күреп, Гаяз уңайсызланып куйды. «Үпкәләттем, ахыры», – дип уйланды. Юкка үпкәләттем, балыгы минекеннән азрак булса да, тагын тотыйк әле, димәде дип, дусты өчен борчылды.

Илгиз бакча артына килеп җиткәндә, читән өстендә бер көтү карганы күреп, тиз кайтуына шатланып куйды.

– Кө-өш! Кө-өш! Каргалар! – дип, шунда ук аларны куа да башлады. Каргалар түбәннән очып җиргә төшә башлаганнар иде, ул, балык чиләген читәнгә элеп, каргаларны еракка очканчы куды. Шуннан соң балыкларын өйгә кертеп чыгарга булды.

Шарик капка төбендәге күләгәдә башын аяклары өстенә куеп яткан да урамны күзәтә. Тыкрыктан Илгиз кайтканны күрде дә, торып, койрыгын болгый-болгый, ялагайланып аңа каршы килде. Илгиз, Шарикның капка төбендә ятып торганын күреп, әнисенең өйдә юклыгын белде. Тагылып барырга дип чыккач: «Йөрмә, йортны кара!» – дип калдырсаң, Шарик шулай, капка астыннан әтәчне дә чыгармыйча, йортны күзәтеп, хуҗасы кайтканны көтеп утыра.

– Кашканы карарга иде сиңа. Йортка чуртым да булмас иде, – дип каршы алды Илгиз Шарикны. Шулай да, теземеннән бер балыкны алып, аңарга каптырды. Аннан, капканы ачып, йортка керән иде, капка түбәсе астына менеп, җиләскә яткан Шаян да балык исен сизеп алды бугай. Песи, урынннан торып, сары төлке буйлы булып, авызын ачып киерелде дә, багана буйлап, күз ияргесез тизлек белән шуып төште. Аннан Ил-

гизнең аяк арасына кереп сырпаланырга кереште. «Мияу!» – дип, балык сорарга тотынды. Илгизгә тагын бер балыкны бирергә туры килде.

– Мә, Шаян, бүтән сорама!

Балыклары өйгә кертеп, табак белән каплап, Шаяннан яшергәннән соң, Шарикны ияртеп, тыкрыкка чыккан иде, каргалар тагын килеп кунганнар.

– Ах, явыз икәнсез! Килеп тә җиткәннәр. Шарик, өө-өс шуларны!

Шарик аңдыйга бик күндәм. Шунда ук каргаларны пыр туздырып, һау-һаулап куып китте. Аннары бик зур эш башкарган төсле, шат сикергәри-сикергәли, Илгиз янына килде.

– Маладис, Шарик! – диде малай, дустын мактап. – Нишләргә соң ул каргалар белән?

– Һау! – дип җавап бирде Шарик.

– Һау шул менә. Саклап утыр менә шунда тайны. Беркая китмә!

Кашка аларны аягына басарга теләп каршы алды. Зур күзләре белән Илгизгә карады. Шарикның үзе тирәсендә иснәнеп йөрүенә дә, һау-һау килеп сикергәләвенә дә ачуланмый иде ул.

– И-и, мескенем, тора алмыйча ятасыңмыни? Безне көттеңме, Кашка? Әйдә, булышам, тор, Кашка, тор! – диде, Илгиз тайның арт саныннан күтәреп. Бер-ике талпынудан соң, икәүләп тырыша торгач, тай торып басты. Илгиз өйдән алып чыккан бер кисәк ипине Кашкага әзләп-әзләп кына каптыра башлады. Тай бу юлы ипине үзе сорап тора. Биргән кисәкне кабуга, тагын бир дигән шикелле, борынын суза бара иде.

– Әһә, тәмен сиздеңме, Кашка? Ипи бит ул, ипи! Ипи, диләр аны! Мә, Кашка, бүтән сорама! Бетте, – диде малай, ике учын да тайның йомшак иреннәренә куеп.

– Илгиз, синме бу? Әллә тайга ипи каптырасың инде, улым? – диде әле генә килеп җиткән атлар караучы Галимҗан карт. – Бик күркәм эш, улым, бик дөрес эшлисең.

Галимҗан бабай башына, төсе китеп, ямьшәеп беткән киез эшләпә кигән. Алдына киндер алъяпкыч бәйләгән. Ул тайны тирәли әйләнеп чыкты да башыннан сыйпый башлады:

– Әллә терелергә җыенасың инде, хайван! – диде ул, тайның күзләрендәге эреннәрне алъяпкыч чабуы белән сөртеп. – Кичә Нәҗип килеп: «Иван абзый тае үлгән», – дип әйтеп киткән иде. Алдаган икән, мәлгунь. Мин, карт тиле, шул явызның сүзенә ышанган идем. Ә син, хайванкай, терелергә телисең түгелме соң?



Карт тай тирәли тагын бер кат әйләнеп чыкты. Аның каргалар чукыган җирләрен, муенының эрен килеп торган ярасын карады, башыннан сыйпады.

– Улым, Илгиз, бар әле чиләк алып чык. Бу мескенгә су биреп карарга кирәк... – дип, карт малайга карады. – Эчәсе киләдер.

– Мин эчердем инде аны, Галимҗан бабай. Үлән дә йолкып китердек тау астыннан. Без инде аны ике көннән бирле карыйбыз, Галимҗан бабай. Гаяз да булышты.

– Шулай кирәк, улым, шулай кирәк. Мин тагын Нәҗип сүзенә ышанып, аның янына килми торам. Рәхмәт, улым. Яхшы күңелле булып үсәсең икән. Хәзер аның кризисы үткән, терелер. Терелү ягында. Менә бу яраларын, керосин белән майлыйсы иде, улым.

– Керосин авырттырыр бит, Галимҗан бабай?

– Керосин ул, улым, самый первый дару, беләсең килсә. Менә мин үзем, кулым киселсә дә, җәрәхәтләнсә дә, керосинга гына тыгам. Авырттырмый ул, улым, төзәтә генә.

– Чебеннәр дә килмиләрме?

– Чебеннәр дә тими шул, керосинлы чүпрәк белән каплап куйсаң.

– Керосин алып килимме, Галимҗан бабай?

Илгиз, карт әйткәнне көтеп тормастан, өйләренә йөгерде. Шарик та аңардан калмады. Бер-ике минуттан алар әйләнеп тә килделәр.

– Менә рәхмәт, улым.

Карт малай улыннан чүпрәк белән керосин шешәсен алды да, чүпрәкне керосинга манып, тайның яраларына сөртә башлады.

– Нигә ат духтыры чакырмыйсыз, Галимҗан бабай?

– И-и, улым, кайдан аласың аны? Председатель Биләргә барган иде, духтырны ике айга укырга җибәргәннәр, ди. Менә, улым, даруладым, болай булгач терелә инде бу мескен тай. Аңарга әзрәк тәрбия генә кирәк булыр. Син, улым Илгиз, иренмә инде, карый тор бу тайны. Терелеп китсә, таный да алмассың әле. Менә дигән кырыкмыш булыр. Әнә, аяклар, гәүдә, күкрәк нинди. Узыш атымыни...

– Галимҗан бабай, мин аны үзем карыйм. Үскәч, миннән башка бирәүгә дә бирмәссең. Үземә генә. Сабан туена да үзем атланып барам...

– Атланырсың, барырсың, улым, терелеп кенә китсен. Йә, улым, мин китим әле. Атлар төшкә кайта башлар. Бутап бирәсем бар. Син, энем, бу тайны ташлама инде. Кара. Яхшылык җирдә ятмый ул, – диде карт, малайның аркасыннан кагып. – Соң булса да, әҗерен күрерсең.

Карт китә башлаган җиреннән кире борылды:

– Әйдә әле, улым, минем белән! Мин сиңа бераз фураж онын биреп җибәрермен.

– Ипи пешерергәме, Галимҗан бабай?

– Әниең күптермә яки көлчә пешереп бирер. Һич булмаса, җылы суга салып, апара ясап эчерерсең! Буламы шулай?

– Нигә булмасын, була, Галимҗан бабай, – диде Илгиз, шатланып. – Мин хәзер керосин шешәсен кертеп чыгам да барып җитәрмен.

– Шарик! – диде ул, этнең үзенә ияргәнен күреп. – Беркая китмә! Утыр шунда!

Эт, мин дә барыйм әле дигәндәй, ялагайланып, артыннан кузгалып киткән иде дә, Илгизнең:

– Утыр шунда! Каргалар килмәсен! – дигән боерыгын ишетеп, күңелсезләнеп барып ятты да, башын аяклары өстенә куеп, хуҗасының китеп барганын карап калды.

Илгиз, Галимҗан бабасының үзенә шундый ышаныч күрсәтүенә шатланып, өйләренә йөгереп керде дә әнисенә әле генә булып үткән хәлләрне сөйләп бирде. Аннары он алып кайтырга чиләк сорады.

– И-и, улым, болай булгач, атлар караучы булып китәрсең инде, – диде Гайниҗамал апа, улының аркасыннан сөеп.

– Мин, әни, атлар духтыры булам, – диде малай, шат күңел белән чиләкне кулына алып, һәм шунда ук ишектән чыгып йөгерде. Берничә минуттан Илгиз әрекмән яфрагы белән капланган онны әнисе каршына алып кайтып куйды.

– Менә, әни, моннан ничә ипи чыга?

Ул он өстендәге әрекмән яфрагын алып куйды.

– Бормак белән отход бодай кушып тарттырган, ди.

– Суга салып, апара ясап кына эчерерсең, улым.

– Көлчә яки күптермә ясап ашатсаң, яхшы булыр, дигән иде шул Галимҗан бабай, – диде малай, күңеле төшеп.

– Ярар алайса, – диде Гайниҗамал апа, улының теләгенә каршы килмичә. – Бүген кичкә ипием дә бар. Шунда берәр нәрсә пешереп бирермен. Хәзер менә апара ясап бирәм. Шуны эчереп карарсың.

Илгиз әнисе ясап биргән ике генә чүмеч апараны алды да Кашка янына йөгерде. Шарик, хуҗасының чиләк тотып килгәнен күрү белән, менә күрдеңме, бер карганы да китәрмәдем дигәндәй, тай янында яткан җирәннән торып, һау-һау өреп, сикергәләп каршы алды.



– Каргалар китермәдеңме, Шарик? Шулай кирәк, маладис, – дип мактаганны ишеткәч, тагын да биегрәк сикергәли башлады. Беренче булып чиләктәге апараны авыз итәргә үрелде.

– Чү, Шарик, баштан авыру Кашка эчсен әле. Аннары сиңа.

Йолдыз Кашка, башын күтәреп, иреннәрен ялап каршы алды. Ләкин ни өчендер чиләктәге апараны авыр эчте. Яртысыннан артыгын эчкәч, бөтенләй туктап калды. Илгиз:

– Нигә эчмисең, Кашка? – дип аптырап торган арада Шарик аның каршысына килеп басты. Башын кырын салып карап торды да:

– Һау, – дип хуҗасына эндәште. Бу аның: «Тай эчми бит инде, нигә миңа бирмисең?» – диюе булса кирәк.

– Шулаймыни? Сиңа бирергәме? Мә, алайса, – диде Илгиз, чиләкне Шарик алдына куеп. – Кашка сиңа дип калдыргандыр. Үзен саклаган өчен...

– Каргалар тимәгәннәрме, Илгиз? – диде Гаяз, алар янына йөгереп килгән уңайга кесәсеннән бер телем ипи чыгарып. – Менә тайга дип алып килдем.

– Менә монысы шәп булган, – диде Илгиз, шатланып. – Апара биреп караган идем дә, нигәдер яратып эчмәде...

– Бәлки, муены, тамагы авыртадыр, – диде Гаяз. Үзе алып килгән ипинең бар кисәгән тайга сузып. Тай, ипинең исен сизүгә, үзе сузылып алды.

– Ипи ярата икән,– дип шатланды Илгиз. – Ипи шул ул. Ипи тәмле икәнне, тай булса да, апарадан аера.

Аннан соң алар икәүләшеп тау астына яшел үлән йолкырга төшеп киттеләр. Илгиз үзе кайтканда бар көтү карганың читән башында булуын, Галимҗан бабай белән булган эшләрен шатлана-шатлана дустына сөйләде.

Шулай тагын өч көн үтеп китте. Илгиз үзенең күп вакытын тай янында үткәрде. Малайларның тырышлыгы белән Йолдыз Кашканың да хәле көннән-көн уңайлана барды. Бер атнадан соң, тай Илгиз булышлыгыннан башка аягына торып баса, тәмлерәк үлән чүпләргә урынынннан күчә башлады. Илгиз, чиләк тотып, йә булмаса әнисе пешергән көлчә алып килгәндә аңа каршы атлады. Бәрхеттәй йомшак иреннәре белән малайның кулына кагылды, җиңнәреннән эләктереп тарткалады. Шулай итеп тай тәмам кулга ияләште.

Беркөнне Галимҗан карт килеп Илгизне мактады, кыргыч алып килеп, тайның өстен кыргычларга өйрәтте. Тагын берничә көннән Йолдыз

Кашка, тыкрыктан чыгып, тау астына тәмле үлән ашарга үзе йөри башлады. Хәзер инде Илгизгә дә, Шарикка да Кашканы каргалардан саклап утыру кирәкми. Хәтта суны да тау астындагы ермактан үзе эчәрдәй хәлгә килде.

Берничә көннән малайлар колхозга эшкә йөри башладылар. Ләкин Илгиз Кашканы ташламады. Һәр көнне таңнан торып эшкә йөрсә дә, төшкә кайткан арадамы, кичме, тайның хәлен белеп торды.

Беркөнне, төшкә кайткач, тайның хәлен белеп килим әле дип тыкрыкка чыккан иде, Илгиз аптырап калды. Кашка тыкрыкта юк. «Әллә иген кырына чыкканмы?» – дип, кыр ягына йөгерде. Ләкин тай анда да юк иде. Аннан тау астына йөгереп төште. Кашка анда да күренмәде. Аннан Чишмә ягында үлән ашап йөрүче атлар янына йөгерде. Барса, Кашка тайлар арасында үлән ашап йөри.

Башта, тайны таба алмагач, бик борчылган иде малай. Кашканың тайлар янында үлән ашап йөргәнен күргәч, бик нык шатланды:

– Кашка! – диде ул, шат аваз белән. Тай шунда ук башын күтәреп карады да: «Миңа кычкырасыңмы?» – дигәндәй, Илгизгә карап тора башлады.

– Кашка! Син мондамыни? Мин сине, югалтып, эзләп йөрим!

Тай дустына таба берничә адым ясады.

– Ялгыз күңелсезмени, Кашка? Тайлар янына килдеңме? – дип, Илгиз кулындагы көлчәсен тайга сузды. Кашканың бавыннан сыйпады, муенындагы ярасын карады. Ярадан эрен килүе туктаган. Ул инде төзәлеп килә. Каргалар чукыган яралар да кутырлаганнар.

...Август ахырлары. Укырга китәргә ике көн калгач кына малайлар эштән туктадылар. Таңнан торып эшкә бару, төш вакытында су коену, кичке уеннарга чыгулар белән җәй үткәне сизелмәде дә. Күрше авылга, интернатта торып укырга китәсе кичне Илгиз атлар йортына Йолдыз Кашка белән саубуллашырга килде. Тай Илгизгә шулкадәр ияләште, аның кулында бертөрле күчтәнәче булмаса да, аның үзен сыйпап, иркәләп китүе өчен генә булса да, дустын көтеп ала иде. Бүген Илгизнең кесәсендә бер телем ипи янына, чәй эчкәндә алып калган ике «мендәр конфет» та бар иде.

Ике ай эчендә Йолдыз Кашка яхшы гына көрәеп китте, тырпаеп торган сөякләре ит белән капланып, түгәрәкләнә башлады. Озын йоннарын койды. Аның урынына карасу-кызыл, ялтырап торган кыска йон чыкты. Ярыйсы ук ныгып өлгергән озын аяклары, чандыр гәүдәсен бик җиңел йөртә башлады. Чапканда, оча торган кош шикелле, башын алга сузып, койрыгын артка җибәрә дә үзеннән алдагы тайларны куып җитеп алга



чыга. Читтән карап торганда Кашканың аяклары җиргә тими дә кебәк. Әйтерсең лә әкиятләрдә сөйләнә торган канатлы ат.

Саубуллашып китеп барганда, Илгизгә Йолдыз Кашканың күзләре дымланып киткән кебек күренде. Әнисез үскәнгә, малай аны бик нык кызгана. Илгиз тайның зур күзләренә карады. Әйтерсең лә ул күзләр: «Нигә мине озакка ташлап китәсең?» – дип ялына иде. Китәргә дип борылган җиреннән тайга караган иде, аның үзе артыннан килгәнен күреп, борылып, Кашканың муеныннан кочаклап алды.

– Миңа бит, Кашка, укырга китәргә кирәк. Киләм әле мин синең янга, киләм, – дия-дия, дустын иркәләргә кереште.

Бу юлы алар шулай аерылышты.

...Кыш үтеп китте. Язгы ташу вакытында укучылар кайтып йөри алмадылар. Илгизнең соңгы мәртәбә Йолдыз Кашка янына баруына айдан артык. Май бәйрәменә кайткач, Илгиз шул ук көнне дусты янына ашыкты.

– Кашка! – дип эндәшүе булды, икенче бер тай белән уйнаклап торган Йолдыз Кашка, шаяруыннан туктап, Илгизгә карады.

– Көттеңме, Кашка?! Сагындыңмы? – диде малай, каршы борылган кырыкмышның муеныннан кочаклап алып. – Мин сагынып беттем үзеңне.

Ул дустының муеныннан, башыннан сыйпады. Үз чиратында кырыкмыш та үзенең бәрхеттәй йомшак иреннәре белән Илгизнең битенә, башына орынды, җиңнәреннән тарткалады. Кесә тирәләрен капшады.

– Күчтәнәчең кайда, дисеңме? Бар ул, бар, Кашка.

Илгиз, кесәсеннән ипи кисәге алып, кырыкмышка каптырды. Аннары атналар буе кесәсендә йөреп йомшарып беткән шикәр кисәген дустының иреннәренә кыстырды.

Кашка кытыр-кытыр китереп шикәр чәйнәгән арада аның күкрәгеген чәбәкләде.

– О-о монда күкрәкләрең нинди булган, – дип шатланды ул. – Каникулга кайткач, су коенырга алып барырмын үзеңне. Атланып йөрергә, йөзәргә өйрәнерсең...

Кыргыч алып, өстен кыргычлаганда да Йолдыз Кашка рәхәтләнеп торды.

## КАШКА – САБАН ТУЕ БАТЫРЫ

...Шулай тагын бер кыш үтеп китте. Яңа яз Илгизгә зур шатлык алып килде. Район Сабан туена карт узыш аты Атлас белән бергә Йолдыз Кашканы да куярга булдылар. Үткән җәйне, Илгизнең күп мәртәбәләр үтенеп

соравына карамастан, Кашканы Сабан туена узышка куймадылар. Колхоз рәисе Ибраһим Гайфуллин: «Үссең әле, ныгый төшсен, яшьтән биртелмәсен», – дигән иде. Бәлки, шулай дөрес тә булгандыр.

Быел менә Илгиз Гаяз дусты белән икәүләп катнашачак. Гаяз – Атлас белән, Илгиз – үзенең Кашкасы белән. Гаяз инде Атлас белән бер Сабан туенда узышып беренче урынны алырга өлгергән иде. Илгизнең әле беренче ярышы. Дөрес, ул үткән җәйне үзенең Кашкасы белән Атласны әллә ничә мәртәбә узган иде. Ләкин бит ул бер километр арада гына. Монда бит тугыз километрлап чабасы. Шундый ерак арадан чабарга Йолдыз Кашканың көче җитәрме? Өстәвенә, район Сабан туенда башка авылларныкында җиңгән тагын әллә ничә чабышкы катнаша. Илгизнең андый чабышкыларны күргәне дә бар.

Район Сабан туена дип әзерләнеп килгән дистәдән артык чабышкыны күргәч, Илгизнең шикләнүләре тагын да артты. Берсеннән-берсе өметле узыш атларының ниндиләре генә юк биредә: Йолдыз Кашка кебек карасу-кызыллары, дисеңме, маена чыдаша алмыйча, аяклары белән җир казып торучы ярсу айгырлар, дисеңме, шомырттай кара, сөлектәй шомалары, әкияттәге кебек ап-ак елгыр юрталар, дисеңме – барысы да бар.

Илгиз белән Гаяз, атларын янәшә тотып, гел бергә йөрделәр... Узышта катнаша торган атлар арасында күрше районнан килгән сөлектәй шома, нечкә билле җирән алаша малайларның күңеленә шик салды. Шул җирән алаша очраган саен, бу хәзер безнең борынга чиертмәгәе, дип шикләнеп карадылар.

Ниһаять, узышка бара торган атларга: «Старт буласы җиргә барырга!» – дигән игълан булды. «Ачык юл» колхозы рәисе Ибраһим Гайфуллин, малайлар янына килеп, соңгы күрсәтмәләрен бирде. «Хәерле юлга!» – дип озатканнан соң, үзе финиш буласы җиргә ашыкты.

Узыш атлары, бер-берсен уза-уза, старт бирүче абыйга ияреп бардылар.

Илгизнең шикләнүләре юкка гына иде: Йолдыз Кашка, нәселле ат булып саналмаса да, табигать аңарга чабышкы булу өчен барысын да биргән – тыгыз, нәзек аяклар, түгәрәк нечкә бил, озынча бәкәлләр. Алга чыгып торган киң, калку күкрәк, озынча муен, уклау сыярдай иркен борын тишекләре – барысы да чабышкы булу өчен яратылган.

Менә атлар старт буласы җиргә барып җиттеләр. Гаяз белән Илгиз маңгайларын ак тасма белән урап бәйләделәр. Узышны башлап җибәрүче абый, исемлек буенча барлап, җайдакларны старт сызыгына тезеп бастырды. Илгиз белән Гаяз янәшә. Илгизнең сул ягында теге җирән алашага



атланган малай. Ул кара чутыр малайның күзләре белән очрашкач, Илгизнең шикләнүләре тагын да артты. Ул өстәнрәк көлеп карый сыман тоелды. Йолдыз Кашка да тынычсызланды. Илгиз, атының муенынnan сыйпап, тезгенен тартыбрак тотты. Аннары: «Тыныч бул, Кашка!» – дип, сул кулы белән атның ялына тотынды да тезгенне тагын бушатты. Малай шундый дулкынланган иде, бу минутларда хәтта йөрәгенең дөп-дөп тибүен күршедәге кара малай да ишетәдер кебек булып китте.

Стартер абый, бер читкә чыгып, атларның тигезлеген карады да, кулындагы кызыл флагын изәп: «Поехали!» – дип кычкыруы булды, атлар күтәрелеп тә киттеләр. Йолдыз Кашка бераз соңгарак калып кузгалды, ахрысы. Ләкин ул кинәт алга ыргылды, Илгиз сул кулы белән атның ялына тотынмаган булса, һичшиксез, шуып төшеп кала иде.

Колхоз рәисе Ибраһим абыйлары малайларга:

– Атларны баштан ук кысрыкламагыз! Алга да чыкмый, артка да калмыйча килегез. Финишка ике чакрымлап ара калганда бар көчләренә куыгыз! – дип кисәткән иде.

Илгиз Йолдыз Кашканы бер дә кумаса да, ул берничә телефон баганасын узуга, алга бәреп чыкты. Шуннан соң бер дә беренчелекне бирмичә килде. Финишка якынлашкан саен ул шәбрәк чапты. Илгиз артына борылып карамаса да, башка атларның тояк тавышы үзләреннән ераклаша барганны сизде. Тик артыннан кем килгәнен – теге җирәнме, әллә үзләренең Атласларымы икәнен генә белә алмады. Йолдыз Кашканың ялына сыланып бары тик алга гына карады. Борылып караса да, атына комачаулар кебек иде аңа...

...Чабышкы атларның старт алырга киткәннәренә бер сәгатьләр булып килә. Сабан туе халкы, атлар киткәннән бирле, алар килергә тиешле юлга агыла. Юлның ике ягында да бер километрга сузылган арада кара болыт кебек халык атлар килгәнне көтә. Күбесе җиккән атларга төялеп килеп, юлдан читкә чыгып туктаганнар да, яхшырак күренсен өчен, арбаларына менеп басканнар. Һәркем үз авылы, үз колхозы аты узганны тели. Кем узар? Тизрәк килсеннәр иде!

– Менә, күрерсез безнең Атлас узачак. Үткән атнада Чаллы Сабан туенда да ул беренче булып килде...

– Әй, сөйләмәсәнә! Ул карт алашагызның рәте беткән инде! Менә күрерсез, безнең җирән алаша узачак! Күргәнсездер, нинди шома, сөлек кебек.

– Ярар, ашыкма әле, кем, энем, чебешне көзен саныйлар! – диде Галимҗан бабай. – Бер дә белмәгән яшь ат узып куймасын әле, сабыр итик.

Мәйдан уртасында утыртылган озын колга башындагы кызыл әләм талгын гына селкенеп ала. Багана башларына куелган микрофонда бөтен Чирмешән буен яңгыратып Сәйдәш музыкасы агыла. Кинәт музыка тынып калды да: «Атлар килә!» – дигән аваз ишетелде.

– Атлар килә! Атлар килә! – дип, телдән-телгә күчеп кабатлана башлады. Бөтен Сабан туе мәйданы гөж килде. Кешеләр, берсен берсе этләләп, алга чыгарга тырышты. Яшьрәкләр алга чапты. Күбесе, яхшырак күренсен өчен, арба өсләренә тулдылар. Һәркемнең күзе атлар киләсе юлда. Һәркемнең алдан килгән атны беренче булып күрәсе килә.

Бераз вакыт һавада тузан болыты гына эленеп торды. Аннан соң юл борылышында тузан болыты алдыннан килгән ике ат күренде.

Халык арасында шау-шу башланды. Коштай очкан ике ат, бер-берсеннән калышмаска тырышып, күз иярмәс тизлек белән борылышны үтеп, туры килә башладылар. Кемдер:

– Алдан безнең җирән алаша килә! – дип кычкырып җибәрде.

– Юк, бу безнең Йолдыз Кашка! – диде Ибраһим Гайфуллин.

– Юк, безнең җирән алаша! Арбага менеп, күзләреңне ачып кара!

– Безнең Кашка беренче килә! Өченчесе безнең Атлас! – диде Галимҗан бабай. – Әйттем бит, яшь ат килә дип!

Атлар артыннан күтәрелгән тузан болыты белән бергә тупыр-тупыр килгән тояк тавышлары да якынлаша бара. Йолдыз Кашка шундый җилле чаба, артыннан килә торган ат белән аның арасы арта бара. Шул ук вакытта өченче килә торган ат та араны киметә бара.

Алдан килгән Йолдыз Кашка шундый җиңел чаба, аның аяклары җиргә тими дә, һавадан оча, диярсең.

Финиш сызыгыннан алга чыгып тезелгән халык турысына килеп кергәндә, Кашка үзеннән соң килүче җирән алашаны, ким дигәндә, өч дилбегә буе артта калдырган иде. Ул шундый ярсыган, финиш сызыгын үткәннән соң Илгиз аны көчкә туктата алды.

Шул арада өченче булып килә торган Атлас җирән алашаны куып җитте. Беравык алар янәшә килделәр. Юл буендагы авылдашлары:

– Атлас! Атлас, давай! Давай! – дип көч биреп торсалар да, финиш сызыгын узганда, җирән алаша бер башка алда булып чыкты.

Мәйдан уртасына керү белән, Йолдыз Кашканың муенына баш-башлары челтәрләп чигелгән озын сөлге салдылар. Бәйгедән кайткан чабышкылар, ничек килгән булсалар, шул тәртиптә мәйдан йөри башлады. Һәркемнең күзе Йолдыз Кашкада:

– Иллә дә шәп чаба соң бу яшь алаша...



– Чаба, димә, оча, диген.

– Ат түгел бу, оча торган кош.

– Кайсы колхоздан дидегез әле?

– Исеме ничек икән бу елгырның?

Микрофонда белдерү яңгырады:

– Иптәшләр, призлы урыннарны алган җайдакларны атлары белән комиссия өстәле каршысына килүләрен сорыйбыз!

Өч җайдак комиссия өстәле каршысына килеп туктады.

– Иптәшләр, «Ачык юл» колхозыннан килгән яшь алаша – Йолдыз Кашка тугыз километрдан куелган атлар узышында беренче урынны алды. Җайдагы – Илгиз Мансуров. Колхоз рәисе – Ибраһим Гайфуллин! Бүләкләнә зиннәтле ат дирбиясе белән, җайдагына – укалы түбәтәй!

Бөтен мәйданның гөр килеп кул чабуы астында Илгизнең башына укалы түбәтәй менеп утырды. Колхоз рәисе, уйнаклап торган Йолдыз Кашканың башыннан тотып, комиссия өстәленә якынлашты да микрофонны үзенә бирүләрен сорады.

– Иптәшләр! – диде ул, халыкка таба борылып. – Ике ел элек бу тайдан каргалар калдыгы дип, көлеп йөриләр иде. Менә бу малай тыкрыкта хәлсезләнеп яткан шушы тайны, каргалардан саклап, ашатып-эчертеп, үлемнән алып калган иде. Күрәсез, тайдан нинди чабышкы үсеп чыкты!

Мәйдан тагын бер тапкыр гөрләтеп кул чапты:

– Маладис!

– Рәхмәт, улым!

– Шулай кирәк! – дигән мактау сүзләре ишетелде.

Чабышкылар, бүләкләрен күрсәтеп, тагын бер кат мәйданны әйләнделәр. Малайлар чиктән тыш бәхетле иде бу минутларда. Илгизнең ике елдан артык хыялында йөрткән уйлары чынга ашты. Йолдыз Кашканың чын Сабан туе батыры булуына хәзер инде ул шикләнми иде. Гаяз да үзенең өметләре аклануга кинәнде. Ун елдан артык узышып килгән Атлас та әле бирешә торганнардан түгел икән...

Моннан соңгы елларда да Кашкага тирә-яктагы Сабан туйларында тиң торырлык ат табылмады. Үзеннән соңгы атны бер дилбегә буе артта калдырып килде. Тик бу узышларда Илгиз катнаша алмады. Җидене бетергәнннән соң, күптәнге теләген тормышка ашырып, ул ветеринария техникумына укырга кергән иде. Укулар беткәннән соң да, техникум хуҗалыгына эшкә калганлыктан, Илгиз авылга Сабан туйлары үткәннән соң гына кайта иде. Шулай да ул Йолдыз Кашканы ташламады. Атлар йортына барып, бахбайларның хәлен белешеп

торды. Ветеринария ярдәме күрсәтте. Ат җигәргә туры килгәндә, Йолдыз Кашканы сорады.

Техникумны бетереп, авылга кайтасы елны ил өстенә афәт килде. Бик күпләр шикелле Илгиз дә сугышка китеп барды. Генерал Белов армиясендә хезмәт итеп, фашистларга каршы сугышта әллә ничә мәртәбә яраланды. Сугыш беткәннән соң, авылга култык таяклары белән кайтып керде.

Сугыш елларында Йолдыз Кашка да, авылдагы бик күп башка атлар кебек, еллар буена бер бөртек он күрмичә, кышкы айларда салам һәм печәнгә дә туймыйча, тормыш нужасы тартты, җир сөрде, авыр, сазлы юллардан фронт өчен икмәк ташыды, кайда җиксәләр, шунда эшләде.

...Сугыштан соң булган беренче Сабан туена Йолдыз Кашканы яңадан узышка куярга булдылар. Илгиз бу юлы да чабышкыны Сабан туена үзе әзерли башлады. Тик бу юлы да узышка үзе бара алмады. Аяклары төзәлеп бетмәгәнлектән, Йолдыз Кашкага җайдак итеп сугышта һәлак булган абыйсының малаен атландырды.

Сугыштан соңгы беренче Сабан туе, беренче шатлык... Атлар киләсе юл буенда халык тезелгән. Ирләре кайтмаган тол хатыннар, ярым ятим калган үсмерләр, егетләр, кызлар. Исән калып, яраланып кайткан ирләр. Сугыш елларында шактый бирешкән картлар. Тик арада Галимҗан карт кына күренми. Барысы да атлар узышын карарга килгән. Һәркемнең күзе атлар киләсе юлда.

– Атлар килә! Атлар! – Халык диңгездәге дулкын шикелле тибрәләп алды. Кемнәрдер алга үтәргә тырышты. Кемнәрдер биегрәк урынга күтәрелде. Ат, арба өстенә менделәр. Еракка сузылган тузан болыты алдыннан килгән ялгыз җайдак искиткеч тизлек белән якынлаша башлады. Йолдыз Кашка иде бу. Финишка җитәргә ике йөз метрлар калганда, юл кечкенә үзәннән бераз әйләнеп үтә. Җайдагы шулай эшләдеме? Әллә бик зур тизлек белән килгән ат тыела алмыйча үзе турыга киттеме? Чабышкының елгырлыгына халыкның исе китеп торганда, ат чокыр аша сикердеме, әллә очып чыктымы – Йолдыз Кашка кинәт өч аякта калып, җайдагы белән җиргә килеп төште.

Мәйдан ах итеп куйды. Кемдер:

– Харап булды! – дип кычкырып җибәрде.

– И Аллам, ни булды икән?!

Халык, ярга якынлашкан диңгез дулкыны шикелле өерелеп, Йолдыз Кашка егылган урынга ташланды. Минут эчендә аягына торып баскан җайдак малай янында ыңгырашып яткан ат халык төркеме эчендә калды.



Йолдыз Кашка ерымны сикергәндә арт аягын ничек артка сузып сикергән булса, шул килеш калтыранып җирдә ята. Ул өзек-өзек кенә, йөрәк түреннән ыһ, ыһ итеп ыңгыраша. Ни дияргә дә белмичә аптырап, өнсез калган халык төркемен ерып, таякка таянып, Илгиз килеп керде. Ыңгырашып җирдә яткан атка күз төшереп алды да җайдак малайга:

– Бетердең атны, малай актыгы! – дип, теш арасыннан гына ыслап алды. – Күзең чыккан идеме? Нигә юлдан тотмадың?

– Үзе турыдан кит-т-е-е! – дип елап җибәрде өне алынган малай. – Ми-и-н тартып өлге-р-рә алмады-ым...

Илгиз, ашыгып килеп, атның аягын тотып карады:

– Калын сеңере өзелгән... – Аның тавышы калтыранып чыкты, ул атның алдына килеп тезләнде:

– И канатсыз кошым, нигә генә соң моннан килдең? Харап булдың бит, җан кисәгем, харап булдың.

Илгиз чиктән тыш үкенү һәм кызгану белән атның муенынннан кочаклап алды, башы-бите белән аның ялларына сыенды, аның ялларыннан, башыннан сыйпады. Ат Илгизгә генә аңлаешлы ыңгырашу авазы чыгарып башын күтәрә төшкән хәлдә дустына карады. Атның чынаяк өсте кадәрле зур күзләре белән Илгизнең күзләре очрашты. Шул мизгелдә Илгиз сискәнеп китте. Теге чакта, сака белән авырып тыкрыкта үлеп яткан вакытында да, бу күзләр аңа шулай ялварып, өмет белән караган иде. Бүген дә атның күзләрендә шундый ук ялвару, шундый ук ышаныч күрде. Күрде дә, үзенең җандай якын дустына бертөрле дә ярдәм итә алмаудан туган йөрәк әрнүен тыя алмыйча, капланып елый башлады:

– Нишлим соң? Нишлим? Бер генә дә ярдәм итә алмыйм бит, малкаем...

Аның тавышы чиктән тыш әрнүдән калтыранып чыга иде.

# ҖАМАЛИЯ АПА СӘХИПКӘ КЕМ БУЛА?

Әле кояш та чыкмаган иде. Илдар әтисенең:

– Илдар, торырга вакыт! – дигән тавышын ишетеп уянып китте. Ул, йокы пәрдәсен ерта алмыйча, бераз черем итеп алырга да уйлаган иде дә, әтисе келәт ишеген тутырып ачып куйгач, үрмәләп диярлек ишеккә килде. Күзләрен ачмыйча гына, ачык ишектән аякларын салындырып утырды.

– Тордыңмы, улым? Әйдә, битеңне ю да кер! Чәем кайнаган.

Илдар, әнисенең йомшак тавышын ишетеп, җиргә төшеп басты. Келәт ишеген ябып, әвеш-тәвеш килеп, әнисе артыннан иярде. Баскыч төбендәге комганнан салкын су белән битен чылатканнан соң өйгә керде.

– Улым, утырып чәй эч! Әнә, ашарыңа алып барырга көйләп куйдым, – дип, әнисе көтү куарга чыгып китте. Ишектән чыккач кына: – Әтиең чәйләп китте. Аны көтмә! – дип өстәде.

Илдар аннан-моннан гына капкалады да, бер чынаяк чәй эчеп, әнисе әзерләп куйган төенчекне алып, атлар йортына ашыкты. Ул үзе шикелле унбиш-уналты яшьлек малайлар белән пар сукаларга йөри.

Урамга чыккан гына иде, арттан Хәбиб тавышы ишетелде:

– Илдар, бергә!



Илдар аны көтеп алды да:

– Нишләп кичке уенга чыкмадың? – диде, үпкә белдереп, – үзең чыгабыз дигән идең. Без чыктык, әй кызык булды. Әтәчләр кычкырганчы уйнадык.

– Аш өлгергәнче ятып торыйм дип яткан идем дә, шуннан йоклаган. Әни әйтә, уянмадың, ди.

– Йокы симерткәнсең икән, йокы капчыгы... – диде Илдар. Дустының чыннан да йокларга батыр булуын белгәнгә, сүзне әллә ни озайтмыйча гына.

Ял көннәрендә әнисенең Хәбибне ике төн, бер көн йоклаганнан соң да көчкә уятып эшкә җибәргәнен Илдар яхшы белә иде.

– Бүген тагын йоклап калма... – дип кисәтте Илдар, – кызлар юксындылар үзеңне.

– Үземнеме, гармунымнымы?

– Үзеңне дә, гармуныңны да.

Хәбиб шундый малай инде ул, башкалардан ике яшькә кече булса да, малайларны-кызларны авызына гына каратып тора. Гармунны кыстатыбрак уйнаса да, сөйләргә оста. Аның сөйләү рәвеше дә үзенә бертөрле. Юк кына нәрсәдән дә кызык табып көлдерә белә. Төрле мәзәкләр сөйләргә дә маһир. Шуның өстенә авылда иң тәвәккәл малайлардан санала. Авыл башындагы кырык метр биеклектәге иске завод морҗасы башына менүчеләр бик сирәк. Менгән малайлар да морҗадан башларын тыгып түбән карарга куркалар. Хәбиб исә морҗаның башына менеп баса да, кулларын болгый-болгый, түбәндәге малайларга нотык сөйли. Әйтерсең лә, өстәл өстендә басып тора. Аннан еракка карый да:

– Ә-ә-ә-н-ә Көрән тавыннан бер атлы төшеп килә! Муллавыл умарталыгында марҗалар җиләк җыя. Ниалау (Урыс Морасасы) кибете каршысында кешеләр җыелган... – дип, әллә ничә километрдагы күренешләрне саный башлый. Әллә ул чыннан да күреп сөйли, әллә теленә ни килде, шуны кычкыра? Түбәндәге малайлар, узып баручы кешеләр исләре китеп, морҗа башыннан биш-алты яшьлек бала кадәр генә булып күренгән Хәбибкә карап торалар. Хәбиб, әллә нинди сораулар биреп, малайларны, кызларны аптыратып бетерә. «Без җавабын таба алмадык инде, Хәбиб, үзең әйт» дигән вакытларда: «Һе, җиңел генә белмәкче буласызмы? Юк инде, бераз баш ватыгыз әле, – дигән була, – шуны да белмәсәгез, тавык көләр!» дип, сүзне җиңел генә икенче якка борып җибәрергә дә күп уйлап тормый.

– Малайлар, кәҗәгә җиде тулгач нишли? Бозау ни өчен койрыгын күтәреп чаба? Кемнең туган көне дүрт елга бер генә була? – Шундый сорауларны кайдан табып бетерә диген.

Илдар белән Хәбиб килгәндә, атлар йортында сукага баручы малайлар җыелып беткәннәр иде.

– Кузгала башлагыз, малайлар! Атлар ашаган, – диде ат караучы Хәбибулла абзый, Илдар белән Хәбибне күргәч. – Карагыз аны, атларны куып бармагыз!

– Ярар, Хәбибулла абзый. Әйдәгез, малайлар киттек! – диде Илдар.

– Киттек! – дип, барысы да өйдән чыктылар.

Малайлар, һәркем үзе эшли торган атның берсенә атланып, икенчесен янга тагып, тау астына, чишмә буена төштеләр. Чишмә суы белән мөлдерәмә тулып торган улактан атлар эчерә башладылар. Сәхип һәрвакыттагыча артка калып төште дә, чишмә янына килеп китмичә, тау өстендәге өйләренә карап, апасына кычкыра башлады:

– Апа! Апа! Ашарга чыгар!

Ләкин Сәхипнең апасы тиз генә күренмәде. Малайлар, атларын эчереп, китә башлагач кына, тау башында ак алъяпкыч япкан Хәмидәнең йөгергәне күренде. Ул йөгереп төште дә шакмаклы яулыкка төргән төенчекне Сәхипкә сузды.

– Сәхип, әйдә, тизрәк! Нәрсә анда үбешеп торасың?! – дип кычкырды шаяртырга җае чыкканны күреп торган Хәбиб.

Хәбиб – ерык авыз, аңарга көләргә сәбәп кенә булсын. Ул, барлык малайларны да туктатып, Сәхипне көтеп алды да башлап җибәрде:

– Күрдегезме, малайлар? Берәүгә шакмаклы төенне чыгарып кына бирәләр. Хәмидә апаның хәйләкәрлеген кара, без чишмә яныннан киткәнне капка ярыгыннан карап кына торган. Без китүгә, төенен тотып йөгереп төште...

– Әйе шул, – диде Гаптулла, Хәбибне куәтләп. – Сәхибе дә хәйләкәр, төенне үзе белән алмаган, Хәмидә ападан төшертә...

– Күрдегезме, Хәмидә апа Сәхипне ничек муеныннан кочаклап үбеп алды? – дип дәвам итте Хәбиб. – Йә, Сәхип, әйт, кочакладымы Хәмидә апа?.. Ә-ә кочаклаган, кочаклаган! Әнә, күрәсезме, Сәхип кызарып чыкты... Мин үзем дә күрдем, сез күрмәдегезме?

– Күрдек, күрдек! – диде Гаптулла. – Сәхип төенне алырга дип иелгән иде, шунда тегесе кочаклап алды. Әле үбеп тә алмадымы икән?

– Әйе шул, үбеп тә алды. Мин дә күрдем!..



...Кояш иртәдән үк кыздыра. Күк йөзендә ашъяулык кадәр дә болыт әсәре юк. Чирмешән болыннары, аргы яктагы иген басулары, сыек рәшә булып, зәңгәрләнеп күренә. Хәтта ачык болында да яфрак селкенерлек тә җил юк. Атларга атланган малайлар каенлык буеннан үтеп, Латра болынына килеп чыкканда, чыпчыктай эре кигәвеннәр, умарта күче кебек, атларны сырып алалар. Күлмәкләре аша энәдәй борыннарын кадап, малайларны үрле-кырлы сикертәләр.

Малайлар сукалый торган Озын җирнең бер башы Чирмешәнгә килеп терәлә. Икенче башы, Чирмешәннән ераклаша барып, елга белән Кәкре күл арасыннан сузыла. Кәкре күл кайчандыр Чирмешәннең иске юлы булган, диләр. Күл тирәсе төрледән-төрле (карлыган, балан, миләш, алма, шомырт, кара җиләк, камырлык, гөлҗимеш) кыргый җимеш агачлары белән тулы.

Малайлар килгән уңайга атларын сабанга җигеп, Озын җирне өч әйләнгәннән соң, ялга туктадылар.

– Әйдәгез, карама төбенә! – диде Илдар, башындагы кепкасын салып битен җилләндерә башлап. – Анда, Чирмешән буенда, җиләсрәк булыр.

Барысы да, төеннәрен тотып, карама астына йөгерде. Иң арттан, кызыл шакмаклы төенен тотып, Сәхип килде.

– Сәхип, малай, су эчер әле? – дип каршы алды аны Хәбиб. – Синең суың баллыдыр әле? Әйеме? – диде ул, Сәхипкә хәйләкәр карап.

Тагын нindider кызык чыгарырга уйлаганы аның сөйләү рәвешеннән үк күренеп тора иде.

– Сәхипкә баллы су кайдан килсен? – дип, Гаптулла Хәбибне куәтләп җибәрде. – Аның әнисе әчегән катык та бирмидер әле.

– Һе, шуны да белмисезме? Анда бит Хәмидә апа бар әле. Җыен тәмле-томлыны Сәхипкә ул ашата бит. Беләсезме, малайлар, Хәмидә апа авылда Сәхипне генә ярата икән. Шул кара чутырның кай җиренә күзе төшкәндер? – дип тезеп китте Хәбиб, хәйләкәр елмаюын дәвам итеп...

– Кит инде, кайдан беләсең?

– Кайдан беләмме? Беләм инде... Беркөнне Хәмидә апа белән Зиннур абыйның сөйләшкәнен тыңлап тордым. Кемнәр сөйләшәләр икән дип, читән артыннан килсәм, Зиннур абый Хәмидә апа янына утырган да:

– Хәмидә, мин читкә китәргә уйлыйм, – ди.

– Китсәң ни, китә бир, – ди Хәмидә апа.

– Әйдә, Хәмидә, бергә китәбез? – ди Зиннур абый.

– Киткән кушарлар, – дип көлде Хәмидә апа.

– Мин чынлап әйтәм, Хәмидә, – ди Зиннур абый. – Мин сине генә яратам. Әйдә, өйләнешик тә китеп барыйк?

– Миңа ышанып өйләнмичә калма, – да тегесе. – Минем күңелем башкада...

– Кем соң ул? – ди Зиннур абый.

– Әйтмим, үзең бел, – ди тегесе.

– Әйт инде-е? – дип ялына Зиннуры.

– Син аны белергә тиеш, без бер түбә астында торабыз... – ди Хәмидә апа.

– Йә, әйтегез, кем була инде ул Хәмидә апа белән бер түбә астында торучы? – дип, хәйләкәр елмайды Хәбиб. – Сәхип, синдер бит? Шулай бит, малайлар?

– Шулай инде, сөйләп торасы ди юк, – дип куәтли Гаптулла. – Сәхип ул бездән яшерә генә! Шулай бит, Сәхип?

– Китегез, малайлар, ул бит минем апа! – ди Сәхип, үзе, ниндидер канәгатьләнү, шатлык билгеләре чыккан йөзен күрсәтмәскә теләп, читкә карый.

– Пәрәч, апа дисең инде аңа, үзеңнән өч яшькә олы булгач, – дип дәвам итә Хәбиб, хәйләкәр карап. – Ул бит сиңа бертуган апаң түгел. Әниегез дә, этиләрегез дә башка. Хәмидә апаның әнисе – Җамалия апа, синең этиеңне йортка керткән. Әтиеңә – Җамалия апа, сиңа Җамалия апаның кызы була...

– Сәхип, син бездән яшереп торма инде, – ди Гаптулла, – күреп торабыз бит, Хәмидә апа һәр көнне, Чишмә янына төшеп, сине озатып кала...

– Әйе шул, әнә бит бүген дә без атлар эчереп Чишмә яныннан киткәнне көтеп торды да, без китүгә йөгереп төште...

– Бер уйласаң, Сәхип бәхетле инде, малайлар, шундый чибәр кыз белән бер өйдә тор әле. Хәмидә апаның күз карашлары гына ни тора.

– Малайлар, беләсезме Җамалия апа Сәхипкә кем була? – ди Хәбиб. – Әгәренки Сәхип Хәмидә апага өйләнсәме? Һи-и вәт бәхет, вәт рәхәт! Җамалия апа Сәхипкә үги әни дә, бианай да була. Ә Сәхип Җамалия апага улы да, кияве дә була. Ә кызы Хәмидә килене була. Аннан Сахипнең этисе Җамалия апага ире дә, кодасы да була...

– Ул вакытта Сәхип этисенә кем була инде?

– Сәхип этисенә кияү була. Хафиз абзый Сәхипкә эти дә, бабай да булып китә...

– Кызык килеп чыга бит әле бу, малайлар? Ха-ха, буталып бетәләр.

– Вәт б-ә-х-е-т! – ди Хәбиб, исе китеп. – Беркая йөрисе түгел. Эти-әни дә, әби-бабай да, хатын да, килен дә – бөтенесе бер өйдә. Көн дә



коймак-кабартма, көн дә кияү сыйлау. Кортлы май, каймаклы катык, дисеңме – сыйлан да сыйлан. Вәт бәхет кайда!

Сәхип бу юлы да Хәбиб сөйләгәннәргә шатланып кына торды. Күңеле белән ул Хәбиб сөйләгәннәрнең чынга ашуын тели иде...

...Уеннан уймак чыга, диләр, Сәхип белән дә шулай булды. Ерык авыз Хәбибнең тырышуы бушка китмәде. «Хәмидә апа сине ярата икән, мунча якканда син аңа утын илтеп бир, мунчага китсә, аның янына бар», – дип, тегенең колагына көн саен туглый торгач, Сәхип чыннан да, бер тамаша ясап, уеннан уймак чыгарды бит.

Яңгырлы көн иде. Иртәдән эшкә киткән кешеләр, төшкә таба эшли алмыйча, пычранып кайттылар. Сукага йөрүче малайлар да, мәк утарга йөрүче кызлар да төштән соң эшкә бармадылар. Безнең татар халкы яңгырлы көн булдымы, мунча яга бит. Хәмидә дә ул көнне мунча якты. Кичке як иде. Көтү кайтканчы юынып чыгыйм дип, беренче парга Хәмидә үзе китте. Чишенеп керде дә, исе булмасын дип, мунча ташына бер чүмеч су салып, ишекне ачып куйды. Аннан чыгып чәч толымнарын сүтте дә, мунчага кереп, табак белән су алып, чәчен юарга керешкән генә иде, көлмәген салган Сәхип мунчага килеп керде.

Хәмидә ләүкәдә утырган җиреннән:

– Чык, чукынчык! – дип, алдындагы табак белән сабынлы суны Сәхипнең өстенә каплады. Аннан:

– Ах, чукынчык! Әле син шулаймыни?! – дип, кисәү таягы белән кизәнде. – Чык моннан! Оятсыз! Мин сине кызганып, әнидән яшереп ашатам! Оятың да юк икән! Җир бит!..

Хәмидә, ярсыганнан-ярсый барып, Сәхипне дөмбәсләде дә дөмбәсләде. Күзләренә сабынлы су кергән Сәхип ике кулы белән башын тотып ишектән чыкканда башын бәрде. Күзләреннән утлар күренде. Хурлыгыннан ярсыган Хәмидә дә аннан калышмады, мунча алдына чыккач та:

– Чукынчык! Оятсыз! Кадер белмәс кара ишәк! – дия-дия, кыйнавын дәвам итте. Ишегалдында күлмәген алырга чыккан Сәхипнең башына тавык йомыркасы кадәр шеш чыккан, аркасында кара елан кебек корымлы таяк эзләре ярылып ята иде.

Бу хурлыклы хәлне Сәхип тә, Хәмидә дә дөньяга чыгармадылар. Шушы вакыйгадан соң Сәхип өч көн сукага чыкмады. Хәмидә, бер атна эчендә Зиннурга кияүгә чыгып, авылдан китеп барды.

# БҮРЕ БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ

Караңгы төшкән иде. Хәким капка төбенә чыкты да, урам буена карап, кичке эңгердән әтисен көтә башлады. «Һаман кайтмый, атны илтергә соңга калам инде. Кичке уенга да чыгасы бар», – дип уйланды ул.

Менә берничә йорт ары урамнан атлы килгәне, арба шыгырдаганы ишетелде.

– На-а-а! – дигән тавыш килде.

– Әти кайта, – дип, Хәким ашыгып капканы ача башлады.

Авыр йөктән арбасы шыгыр-шыгыр килгән атлы, капка турысына җитү белән, атны капкага борды да, атның башыннан тотып, ачык капкадан йорт ишегалдына керде.

Хәким капканы япты да, түбәсеннән өеп төягән көлтә арбасы яныннан карый-карый, ат янына узды, атның аркалыгын чишә башлады.

– Ай-яй күп төягән, ничек тартып кайттың, Җирән? – диде ул, камыт бавын ычкындырып торган әтисе янынан үткәндә, атның башыннан сыйпап.

– Улым, атларны көтүгә алып киттеләр, сиңа Җирәнне көтүгә, болынга илтергә туры килә, – диде Исхак абый, атның камытын салдырып. – Чишмәдә җирәнне эчерә китәрсең. Чаптырмыйча бар!



– Ярар, әти. Әйдә, Җирән, киттек! – диде Хәким, атның тезгененнән тартып. Ул атны тәртә арасыннан чыгарды да, аны урамга алып чыгып, капка төбендәге эскәмия өстеннән ат өстенә сикерде.

– Әйдә, Җирән, киттек!

Чишмә янындагы атлар эчерә торган зур улак су белән тулы иде. Хәким су эчергәннән соң атны куарга ярамаганын белә. Шуның өчен ул, тау башындагы өйләрне узып, Алмагач тавына кадәр Җирәнне адымга гына алып барды. Шуннан соң гына, түземе бетеп, йөгертә башлады. Менә каенлык турысына җитте. Каенлык буеннан узып, чәчү җирләрен дә артта калдырды, болынга да килеп керде, ә тирә-юньдә тынлык. «Кайда соң бу атлар? Әллә карлыган болынындамы?» – дип курка калды малай. Ул атын адымга калдырды да, берәр төрле тавыш ишетелмәсме дип, тыңлап бара башлаган иде, кинәт янда ат пошкырганы ишетелде. Бер тай да кешнәп куйды.

– Әһә, монда икән. – дип шатланды Хәким һәм шунда ук:

– Нәҗип абы-ый! – дип кычкырып җибәрде.

– Кем ул анда?! Атлар монда! – диде болынның якын түреннән килгән тавыш.

– Бу мин, Нәҗип абый, Җирәнне китердем!

– Нишләп соңга калдың?!

– Әти урманнан хәзер генә кайтты.

– Китер атыңны монда! Тышавың бармы?

– Бар, Нәҗип абый!

Хәким атны тавыш килгән якка алып барды да, аттан төшеп, тышауны ат муеныннан ала башлады.

– Бир әле, энем, үзем тышаулыйм, тазарак тышауларга кирәк, – диде көтүче, Хәким кулыннан тышауны алып. – Югыйсә тышауларын төшерәләр дә иген кырына кереп китәләр... Йә, бар, хайван, аша.

Көтүче атның йөгәнен салдырып алды да Хәкимгә сузды.

– Ярар, Нәҗип абый, мин киттем.

– Әз генә тор әле. Хәзер Хәсән малае килергә тиеш. Бергә кайтырсыз.

– Әй, кайчан килә әле ул. Мин, Нәҗип абый, турыдан гына, каенлык аша кайтам бит.

– Алаймы? Ярар алайса, үзеңә кара.

Хәким йөгәнен җилкәсенә салды да кайту ягына борылды. Юлга чыгып, болын белән чәчүлек җирләр арасындагы таллыкка җитәрәк сызгыргаланып барды. Аннары башына килгән төрле шикле уйлардан арыну өчен кычкырып җырлап җибәрде:

*Ал чәчәк ата илем, гөл чәчәк ата илем;*
*Ал чәчәкләргә күмелеп, яшәсен туган илем...*

Алда тояк тавышы килгән кебек булды:

– Әйдә, хайван! – дигән тавыш килде.

– Сәлим, синме бу? !

– Бу мин әле, – диде Сәлим, атын туктатып. – Ат илтеп кайтасыңмы?

– Әйе шул.

– Хәким, малай, әз генә мине көт әле. Бергә кайтырбыз... Мин хәзер...

– Көткән, ди. Мин каенлык аша, турыдан гына кайтам.

– Соң, мин дә шуннан кайтырмын. Көт инде, малай? Кичә каенлык артында бүре күргәннәр...

– Хәбир сүзенә ышансаң, кырыкалдар бит ул...

– Алдый сиңа. Аны кичә Нәҗип абый этигә сөйләгән... Көтәсеңме?

– Теге көнне кинодан кайтканда, «куркак, куркак», дип тә үртәгән идең әле. Менә хәзер кем куркак икәне беленде, ярый, мин киттем.

Хәким йөгәнен кулына алды да, аны селкә-селкә, каенлыкка таба ашыкты. Тау астындагы каенлыкка җитеп килә иде, үләт базы ягыннан килеп кушыла торган юлдан үзенә таба бер нәрсә килгәнне шәйләп алды.

«Этме соң бу монда? Әллә Сәлимнең эте артыннан киләме? Менә аңарга иптәш...» – дип уйлап та бетермәде, теге нәрсәнең «тычкан уты» кебек янып торган күзләрен күреп, Хәким бер урында тораташтай катып калды. Энекәем, бүре түгелме соң бу? Малайның йөрәге жу-у итеп китте, нишләргә дә белмичә аптырап торган арада, теге нәрсә артына утырды. Хәким, эт булса дип: «Мах! мах!» – дип дәшеп тә карады. «Пошёл!» – дип аягы белән тибеп, йөгәне белән җиргә сугып та карады. Юк, селкенми дә... Хәтта Хәкимгә «фонарьлары» тагы да яктырак янган кебек булып китте. Ул, үзенең каушаганын сиздермәскә тырышып, йөгәне белән җиргә суга-суга, бүрегә таба бер-ике адым атлап та караган иде. Ләкин бүре селкенмәде дә, «фонарьлары»н яндырып утыра бирде.

Инде нишләргә? Хәкимнең бүре күргән, бүрегә очраган кешеләрдән ерткычның шулай, селкенмичә, артына утырып торганы турында ишеткәне бар. Ул бүрегә караган килеш, күзен читкә борырга да куркып, өчдүрт минут басып торды. Авыл ягыннан килүче булмасмы, дип колаклары белән авыл ягын да тыңлады. Ул якка борылып карарга да шикләнде. Күзләрен бүредән алса, бүре аңа сикерер төсле иде. Инде нишләргә? Әллә Нәҗип абзыйга кычкырыргамы? Кычкырсаң, Сәлим анда, ул: «Ә-ә, мине көтмәгән идең. Барыбер миннән башка кайтырга курыккансың?» – дип авыз гына ерачак... Йөгереп китеп барсам, курыкканны сизеп, бүре арттан өч кенә сикерәчәк...



Шундый уйлар белән Хәким урыныннан кузгалып тау астына, каенлыкка төшеп китәргә дә курыкты, чишмә юлы белән кайтсам, бәлки, берәрсе очрар. Аннан кайтсам, Алмагач тавына җитү белән, өйләр башлана. Чишмәгә суга төшүчеләр дә була... Шундый уйлар белән, ниһаять Хәким бер карарга килде: «Курыкканны сиздермәскә. Минем кулда әйбер барны, мин буш кул белән булмаганны бүре ишетеп торсын. Йөгәннең тимерле башы белән берне тондырсам», – дип, үз-үзен тынычландырды. Ул, кулындагы йөгәнен ипләбрәк тотты да, тегермән канаты шикелле әйләндерә-әйләндерә, кулын артка сузып, чишмә юлы белән атлый башлады. Берничә адым атлаган саен йөгәннең тимерен, шап-шап иттереп, җиргә тидереп алды. Янәсе, бүре Хәкимнең буш кул белән булмаганын ишетеп торсын!

Шулай күпмедер барганнан соң, Хәким, туктап, артына карады. Бүре күренми иде. «Эһе, калды бит!» – дип шатланды ул. Шунда ук бүрене тагын да арттарак калдыру өчен, аяк очлары белән генә басып, бар көченә йөгерә башлады, юл тау астына төшә торган җиргә җиткәч, берничә адым атлады да туктап артына карады. Бүре тау өстендә. Хәким тагын куркуга калды. «Юк, болай ярамый икән, бүре минем куркып чапканымны сизгән». Ул яңадан, кулындагы йөгәнен авызлыгы белән җиргә суга-суга, арты белән тау астына таба атлаган иде, аягына таяк кисәге тиде.

Хәким, шатланып, шул агач кисәген кулына алырга иелде, үзе: «Өскә сикермәсен тагын», – дип, тау өстендәге бүредән күзләрен алмаска тырышты. Таяк чыбыркы сабы кадәр генә булып чыкты. «Эх, зуррак булмаган шунда...», – дип уйлап куйды Хәким. Киерелеп торып шул агачны бүрегә җибәргән иде – тимәде. Шулай да бүре урыныннан күчеп утырды.

Шуннан соң гына Хәким бүрене болай гына куркытып булмаганны аңлады. Йөгән тоткан кулын бүре белән ике арада тотып, шап-шап җиргә суга-суга, авылга таба атлады. Ләкин Алмагач тавына якынлашкан саен анын, түземлеге бетә барды. Артына да карамыйча йөгерү турындагы уй йөрәгенең кайсыдыр җирендәге: «Юк, йөгермә, Хәким», – дигән уй белән көрәшеп килде. Шулай да каенлык артында йөгереп караганы исенә төшү белән, ул үзен йөгерүдән тыеп килде.

Менә Алмагач тавы башында этләр өрә башлады. Хәким, авылга якынлашуына шатланып, адымнарын тизләтте. Шунда ул кемнеңдер көянтә-чиләк белән суга төшеп килгәнен шәйләп алды да бөтен көченә

йөгерә башлады. Хатын юлга чыгып, бүре белән үзе арасында калу белән, йөгерүдән туктап, артына карады.

Үзе артында көянтә-чиләк белән суга килүче хатынны күргәч, малай тынычланып калды. Шунда гына ул үзенең тирләп чыкканын, йөрәгенең урыныннан чыгардай булып дөп-дөп сикергәнен сизде. «Гаҗәп, ни дип сикерә башлады соң әле бу йөрәк? Әллә мин аны анда сизмәдемме?» Хәким чишмәгә килеп житте дә бераз чишмә суы эчәргә булды.

– Хәким, синме бу? Нишләп йөрисең болай соң?

– Болынга ат илтеп кайттым, – диде малай, берни булмагандай.

– Әле син идеңмени? Тау астыннан берәү йөгереп узган кебек булды шул. Мин тагын тавыш-тын булмагач, ялгыш күземә генә чалынгандыр дип уйлаган идем...

* * *

...Гайшә апа өйдә эшләрен бетерде дә йортка чыкты. Ире Исхак белән икәүләп бушаткан утыннар янына килеп, сарыкларның усак кайрысы кимергәнен карап торды. Ә үзенең колаклары каенлык ягыннан килгән җыр тавышын ишетергә тырыша иде. Ни кадәр тыңласа да, Хәкимнең җырлаганы ишетелмәде, ул: «Нишләп тора бу бала? – дип, борчылып, урамга чыкты. – Чишмә ягыннан кайтмыймы?» – дип, урам буена карап торды. Аннары, урам аша чыгып, каршы як тыкрыктан тау битенә килде дә, тау астындагы караңгыланып торган каенлык ягына карап тыңланды. Юк, бер тавыш та килми. Башка вакытларда Хәким каенлык аша җырлап кайта торган иде... Әле бер җыры да хәтерендә:

*Сахралардан йөреп кайтам,*
*Урман аша юлларым...*

«Бүген Хәкимнең җырлаганы да ишетелми, үзе дә юк. Әллә чишмә ягыннан кайтамы?» Гайшә апа тыкрыктан борылды да, урамга чыгып, урам буена карап тора башлады, шунда ул урамнан кемнеңдер килгәнен шәйләп алды.

– Хәким, улым, синме?

– Мин, әни, – диде малай, үзен тыныч тотарга тырышып.

– Мин сине каенлык аша көтәм. Курка калдым, берәр хәл булдымы әллә?

– Бүген чишмә буеннан кайттым шул, су эчәсем килде...

– Озак тордың бит, әллә көтүне таба алмый тордыңмы?

– Тау буеннан әйләнеп кайткач, чишмәгә дә туктагач, озак була инде ул, әни.



– Әйдә, кер инде, улым. Ят. Иртәгә урманга әтиең сине дә алып барам диде. Иртәрәк торасың бар, – диде Гайшә апа, улының аркасыннан сөеп.

Урман юлында Хәким белән әтисе Исхак арасында ирләрчә сөйләшү булып алды.

– Әти, бернәрсә сөйлимме?

– Сөйләп кара.

– Әнигә сөйләмәссеңме соң?

– Сөйләмәстәй булса, сөйләмәм.

– Сөйләргә ярамый шул. Ул кичә болай да йокларга ятмыйча, мин кайтканчы, куркып, капка төбендә торган. Миңа чуртым булыр дип белдеме икән?

– Әниләр, әтиләр шулай инде ул, улым, менә син дә зур үсеп балаларың булгач, шулай кайгыртырсың. Алай булмадымы икән, болай булмадымы икән, дип. Кичә нигә озак тордың соң? Кайда йөрдең?

– Йөрдем дип... Бүре очрады миңа...

– Шулаймыни? – диде әти кеше, гаҗәпләнеп. – Шуннан нишләдең? Йөгердеңме?

– Йөгергән, ди. Йөгереп караган идем дә, ул явыз, бер дә калмыйча, арттан элдертә генә.

– Эт булгандыр ул, улым?

– Эт, ди, сиңа, – диде Хәким, әтисенә үпкәле караш ташлап. – Эт булса, мин йөгән тимере белән җиргә сугып аңарга таба атлаганда, фонарь кебек күзләрен яндырып, артына утырган килеш селкенмичә дә утырмас иде. Әле таяк белән бәргәч тә, урыныннан гына күчеп утырды.

– Кай җирдә очрады соң ул сиңа?

Хәким тирән сулап куйды да әтисенә кичтән булган хәлне башыннан алып, ахырына кадәр сөйләп бирде.

– Син, улым, маладис, – диде Исхак абый, улына карап. – Куркып, каушап калмагансың.

– Куркып калсам, өскә сикергән булыр идеме, әти?

– Анысын төгәл әйтә алмыйм, улым. Ялгыз бүре үләр дәрәҗәдә ач булса гына, кешегә ташлана, диләр. Җәй көне бүреләр алай ач булмый. Хәзер аларга кайда да ау.

Хәкимнәр урманнан кайтканда, аларны яңа хәбәр көтә иде. Дәүләтша абзыйларның көтүдән кайтмый калган сарык бәрәннәрен бүре ашаган.

# РӘХМӘТ, МӘСФИЯ АПА

Мәктәптә укулар беткән көнне үк интернатны ремонтка яптылар. Илгизәр, классташ дуслары Гата һәм Рәфгать белән, ун көн буе җиде чакрымга йөреп, мәктәпнең тәҗрибә участогында эшләде. Иртәнге алтыда торалар да, каенлык аша турыга гына чыгып, күрше авылга юнәләләр. Илгизәрләр тыкрыгыннан төшеп, ике йөз метр җәяүле сукмагы белән баргач, кечкенә генә каенлык башлана. Җәйнең эссе көннәрендә монда һава шундый җиләс, шундый саф, һич сулап туя алмассың. Иртә белән өйдән чыкканда әле йокы да ачылмаган була. Каенлыкка керә-керешли, малайлар йокы сөременнән айнып, уңайланып китәләр. Мондагы берсеннән-берсе матур сайраган кош тавышларын тыңлап үтүе үзе бер рәхәт, үзе бер күңелне ача торган хәл.

Якында гына, сукмак буендагы талларда, чыпчыклар сөйләшә. Шунда ук, куерып үскән яшь каеннар эчендә, сандугач сайрый. Сул якта, карт каеннар башында: «Кәк-күк, кәк-күк, кәк-күк!» – дип, күке кычкыра. Ә каенлык артындагы күллектә, узышып-узышып, бакалар сөйләшәләр. Һич тыңлап бетерерлек түгел. Каенлыкны үтеп, тәбәнәк тауны күтәреләсең дә, алда киң болын җәелеп ята. Болын уртасыннан аккан елга исеме белән ул болынны Латра болыны, диләр. Ул болын өч километрга кадәр сузыла.



Бүген малайлар көндәгедән дә иртә килделәр. Алар килгәндә, шул авылдагы классташлары әле күренмиләр иде. Мәктәп бакчасында аларны Мәсфия апалары каршы алды. Мәсфия Гариповна бүген көндәгедән дә матур булып күренде малайларга. Аның өстендә, килешеп, тәненә ятып торган ак бөрчекле сыек яшел төстәге җиңел күлмәк. Яланаякка кигән сары төстәге җиңел туфлие дә килешле. Яртылаш агарган чәчләре, инде иллене тутырып килсә дә, аны бер дә картайтмый.

– Исәнмесез, Мәсфия апа!

– Исәнмесез, укучылар. Килдегезме? Бүген иртәләгәнсез, – диде укытучы, укучыларны каршы алып. – Әйдәгез, мин сезгә ниләр эшләргә икәнен күрсәтәм дә, бераз ял иткәч, эшкә керешерсез!

– Без арымадык әле, апа.

– Шулаймы? Бигрәк тә яхшы.

Моннан ике ел гына элек бу өч малай, Мәсфия Гариповнага килеп:

– Мәсфия апа, безне өченче класска алыгыз әле? Безнең сездә укыйсыбыз килә, – дип ялынганнар иде. Ул вакытта Мәсфия Гариповнаның бөтенләй таныш булмаган күрше авыл малайларын алырга бер дә теләге булмаса да: «Мәсфия апа, безнең икенчедә укыйсыбыз килми, тырышып укырбыз, сүзегезне тыңларбыз!» – дип ялынгач кына, күңеле йомшап, малайлардан «имтихан» алып карарга булды.

– Без бит, балалар, яңа алфавитка күчтек. Сезнең яңа алфавитны укыганыгыз бармы, беләсезме? – дип сораган иде.

– Беләбез, апа, беләбез, – дип, Рәфгать өчесе өчен дә җавап биргән иде. Мәсфия Гариповна берәр бит кәгазь биреп яздырып, укытып карады. Аннары: «Рәсем ясый беләсезме? Йәгез әле берәр нәрсә ясап күрсәтегез!» – дип, дәфтәр битенең икенче ягын әйләндереп куйды.

– Нәрсә ясыйк соң, апа?

– Үзегез теләгәнне ясагыз. Берәр рәсем. Ат, куян, тавык.

Малайлар үзара сөйләшеп алдылар. Рәфгать – ат, Илгизәр – куян, Гата әтәч ясарга кереште. Унбиш-егерме минуттан рәсемнәр әзер иде. Рәфгать ясаган ат белән, Илгизәр ясаган куян Мәсфия Гариповнага аеруча ошаган иде. «Сез яхшы рәссамчылар икән», – дип, рәсемнәрне папкасына ук салып куйды. Аннары малайларга тагын бер кат карап чыкты да:

– Ярар, сүзегездә торыр булсагыз, иртәгә икенче класс китапларын апагызга тапшырыгыз да миңа килегез, – диде.

– Апа, рәхмәт! Рәхмәт, Мәсфия апа! – дип шатланганнар иде малайлар ул вакытта. Сүзләрендә тордылар. Бүген менә Мәсфия Гариповна

классында аларның соңгы көн укулары, мәктәп бакчасында соңгы көн практика үтүләре.

Озын-озын чөгендер, кыяр, помидор түтәлләрен узып, кәбестә участогы белән янәшәдә эшләнмичә калып чүп баскан кишер түтәлләре янына килеп туктадылар.

– Менә, балалар, сезгә шушы кишер түтәлләре. Башта бик тырышып, кишерләрен йолкымыйча гына, чүп үләннәрен утап чыгарсыз. Аннары көрәкләр алып, түтәл araларын чистартырсыз да, чүпләрен, носилкага салып, капка төбендәге чүплеккә илтеп түгәрсез. Шуннан соң, бик үткәреп су сибәрсез!

– Ай-яй, – дип сузды Рәфгать, чүп баскан кишер түтәлләренә карап. Башка малайлар да үзара карашып алдылар.

– Нәрсә? Куркуга калдыгызмы әллә? Сез бит инде киләсе елга бишенчегә килә торган укучылар. Сездәй егетләргә ни тора ул? Йәгез, күз куркыр, кул эшләр, диләр, башлагыз! Бергә эшлисезме?

– Бергә эшлибез, апа.

– Ярый алайса, килештек, – диде укытучы, кәбестә участогына таба атлап. – Мин эшегезне карарга килеп чыгармын.

– Әйдәгез, малайлар, башлыйк. Карап торып эшләнмәс, – диде Гата, киндер букчасын җиргә куеп. – Башта утап чыгарбыз. Аннары түтәл араларын чистартып кырырбыз.

– Әйдә, Рәфгать, без синең белән көрәкләр белән носилка алып килик.

Алар мәктәп йортына таба йөгерделәр. Гата кырыйдагы түтәл башына килде дә, чүгәләп, ике куллап, чүп утый башлады. Берничә минуттан, көрәкләр һәм носилка күтәреп, Рәфгать белән Илгизәр дә килеп җитте.

– Малайлар, чүпләре кишереннән дә биек, карап утагыз! – диде Гата. – Карап утамасаң, кишер дә эләгеп чыга.

– Ой, малайлар, монда кайда кишер, кайда чүп икәнен дә аерып бетерерлек түгел. Карагыз әле, монда нинди чүп баскан!

Баштарак малайлар сөйләшә-сөйләшә эшләделәр. Ун-унбиш метрга сузылган озын түтәлнең берсен утап чыкканчы, малайларның билләре кәкрәеп катты. Соңга таба алар сөйләшмичәрәк, тын гына утый башладылар. Үзара сөйләшүләр бил авыртудан, эсселектен зарлану белән алышынды. Шулай да берсе дә эштән туктамады. Беренче түтәлне баш та күтәрмичә утап чыктылар.

– Карагыз әле, – диде Гата, бер түтәлне бетереп, икенче түтәлгә күчкәч. – Утап чыккач, матураеп калды кишер түтәле.



– Әйе шул. Түтәл арасын кырып, чистартып чыксак, ул әле тагын да матурлана төшәр. Әйдәгез, бу түтәлне дә бетерсәк, тагын бер генә кала, – дип, Илгизәр икенче түтәлгә күчеп утый башлады.

Икенче түтәлнең яртысына житеп килгәндә, алар янына Мәсфия Гариповна яңадан килде.

– Менә куркып торган идегез, яртысын бетергәнсез дә инде. Карап утагыз, укучылар, кишерләре эләкмәсен. Көзгә, интернатта тора башлагач, үзегезгә буласы кишерләр бит алар. Суын да мул итеп, һәр түтәлгә алты чиләктән да ким сипмәгез, укучылар!

– Ярый, апа, сибәрбез. Әле утап бетерәсе бар, – диде Рәфгать, билен уып.

– Бетә инде ул, бетә, укучылар. Әнә кайберәүләр әле эшкә тотындылар гына. Сезнең яртысыннан узган... Йә, армыйча эшләгез!

– Әйдәгез, малайлар, бу түтәлне бетерсәк, бер генә кала, – диде Илгизәр, урыннан торып. Гата да торып басты. Алар ике куллап чүп утый башладылар. Билен тотып киерелгәләп торганнан соң, Рәфгать тә эшкә кереште.

Сәгать унберләр тирәсендә малайлар түтәлләрне утап бетереп, араларын чүптән чистарта башлаганнар иде. Соңыннан Рәфгать белән Илгизәр, чүпләрне носилкага төяп, чүплеккә ташый башлагач, Гата, көрәкләрне илтеп, чиләкләр белән су сиптергеч алып килде.

Өчәүләп бакчаның кәбестәләр утырткан читендәге кечкенә инештән су алырга йөгерделәр. Инеш буенда кулларын юдылар, июнь кояшында пешкән битләрен-муеннарын юешләттеләр... Шаярышып, су чәчрәтеп уйнап алдылар.

– Житте, малайлар! – диде Рәфгать белән Гата су чәчрәтүеннән юешләнгән Илгизәр. – Әйдәгез, кишерләргә су сибик тә, Мәсфия апага күрсәтербез. Бәлки, алдан җибәрер...

– Әйдәгез! – диде Гата, кулына чиләк алып.

– Үзем сиптереп торам, – диде Илгизәр, су сиптергечне кулына алгач. Чиләкләргә су алып, өч малай кишер түтәлләре янына йөгерде. Илгизәр башта һәр түтәлгә дүртәр чиләк сибеп чыкты. Аннары яңабаштан дүртәр чиләк сиптерә башлады.

– Алтышарны гына сипмибезме?

– Алты әз була, – диде Илгизәр, – рәхәтләнсеннәр әле. Кисап буйлы булып үссеннәр. Үзебез үстердек, диярбез...

– Тагын бер барып киләбез дә, син, Гата, апаны чакырып кил, – диде Рәфгать, – мин чиләкләрне илтеп киләм.

Берничә минуттан, бер төркем укучылар ияртеп, Мәсфия Гариповна да килеп җитте.

– Бетердегезме, укучылар? – диде укытучы, ямь-яшел булып матурланып, чистарып калган кишер түтәлләренә карап. – Менә нинди әйбәт эшләгәннәр. Йәгез, укучылар, ни әйтерсез, яхшы эшләгәннәр бит?

– Яхшы эшләгәннәр, апа, яхшы, – диештеләр кызлар.

– Апа! Монда чүп үләннәре калдырганнар! – дип кычкырып җибәрде, соңыннан йөгереп килгән Гарәф.

– Кайда чүп үләне? – диде Илгизәр, Гарәфка ачуланып карап. — Моны әйтәсеңме? Чәчәк үсентеләре алар. Түтәл читендә.

– Дөрес эшләгәннәр, – диде укытучы. – Чәчәкләргә тимәгез, укучылар! Күпмешәр су сиптегез?

– Сигез чиләк сиптек, апа.

– Сигезәр чиләк сипсәң, бөтен дөньясы коеныр иде? Монда бер да агып төшкән җире юк, апа! – дип, Гарәф бу юлы үз сүзен дөрескә чыгарырга тырышты.

– Без, Мәсфия Гариповна, сеңдереп кенә... Башта дүртәрне сиптек. Аннары тагын дүртәрне...

– Сүз әйтерлек түгел. Чиста да, яхшы да. Менә, укучылар, барыгызга да шулай эшләргә кирәк.

Укытучы сәгатенә карап алды да:

– Әле тагын сәгатьтән артык эшләргә бар икән, – дип укучыларга таба борылды. – Менә нәрсә, укучылар, Илгизәр Рәхимкулов, Гата Вәлиев, Рәфгать Атнабаевларның эшләренә «бик яхшы» билгесе куям. Чиреккә дә, еллыкларына да «бик яхшы» чыгарам. Мәктәп бакчасында тырышып эшләделәр алар. Җиде чакрымнан йөрсәләр дә, вакытында килделәр. Бүген мин аларга бер сәгать алдан кайтып китәргә рөхсәт итәм. Кемнәрнең эшләре бетмәгән, барыгыз, бетерегез! Күрдегезме, ничек эшлиләр?

Аннары ул малайларга таба борылды:

– Йәгез, укучылар, яңа уку елына кадәр сау булыгыз! Ял итегез, әти-әниләрегезгә булышыгыз!

– Апа, иртәгә да килергә бит әле?

– Иртәгә килмәгез, укучылар. Бүген соңгы көнегез. Иртәгә мин сезнең авылга укучылар учётын алырга барам. Кайсыгыз минем белән йөри ала? Югыйсә мин сезнең авылны яхшылап белмим.

– Апа, үзем йөрермен! Апа, үзем йөрермен, – диештелар малайлар.

– Апа, безгә дә керәсезме? – диде Рәфгать.



– Кайсы йортта укучылар бар, барысына да керәм. Сезгә дә керәм. Әти-әниләрегезне шатландырмыйча ярамый, – диде укытучы, укучыларына сөйкемле карап. – Йәгез, укучылар, барыгыз кайтыгыз!

– Апа, сау булыгыз!

– Исән булыгыз!

Малайларның шатлыклары шундый зур иде бу минутларда. Ашыйсы-эчәсе килүен дә онытып, кайту юлына ашыктылар. Шатланмаслык та түгел. Укытучы апалары бүген аларны бөтен группа алдында мактап, хезмәттән һәм табигатьтән «бик яхшы» билгеләре чыгарасын әйтте. Өстәвенә, башка укучылардан бер сәгать алдан җибәрде. Җитмәсә, иртәгә көне буена Мәсфия Гариповна алар белән булачак.

Авылны чыгып бераз киткәннән соң, Гата:

– Эчәсе килә, малайлар, әйдәгез тау битеннән кайтабыз, – дип, иптәшләренең исенә төшерде.

– Әйдәгез, су да эчәрбез, чишмә янында утырып, ашап та алырбыз...

– Юк, – диде Гата. – Ашауны кайта-кайта ашарбыз. Юкса балык тотарга вакыт аз кала...

– Дөрес, малайлар, Мәсфия апа да киләсе булгач, балыкны күбрәк тотарга кирәк... Аннары минем көтүгә дә кайтып җитәсем бар.

– Көтүгә барыбызның да кайтасы бар. Өлгерәбез әле, – диде Рәфгать. Алар сөйләшә-сөйләшә тау битеннән чишмәгә таба юл тоттылар. Тәбәнәк тау итәгеннән агып чыккан чишмәнең суы мул булмаса да, берөзлексез агып торганлыктан, зур гына болынның тау бите ягын суландырып, юешләп тора. Моннан, җәйнең кай вакытында узсаң да, акчарлак кебек ак тәкәрлекләр бер дә китмиләр. Малайлар, сазлык өстендә пи-бип, пи-бип килгән тәкәрлекләрне тыңлый-тыңлый, чишмәгә килеп җиттеләр.

Ящик куеп ясалган чишмәнең мөлдерәп торган көмештәй суын беренче булып Гата ятып эчте.

– Эх, суы нинди тәмле, эчеп туя торган түгел, – дип кинәнде ул. – Үзе кечкенә генә булса да, суы авыл чишмәсенең суы кебек.

– Кая инде моңа авыл чишмәсе белән ярышырга! – диде Илгизәр, ятып су эчкән җиреннән торып. – Авыл чишмәсеннән бөтен авыл ташыса да, суы бетми. Моңда нәрсә? Булса, ун чиләк суы бардыр.

– Малайлар, кемнең нәрсә? Минем ипи белән бәрәңге! – диде Рәфгать.

– Минем борчак күптермәсе! – диде Гата.

– Минем җәймә!

– Әйдәгез, башта минем ипи белән бәрәңгеләрне, аннары җәймә ашыйк! Ә борчак күптермәсен балык тотканнан соң ашарбыз!

– Мин риза, – диде Гата, букчасын читкә куеп.

– Мин дә риза.

Рәфгать, шакмаклы яулыгын чишеп, җәеп салды да ипине өч кисәккә сындырып яулыкка куйды. Аннары:

– Йәгез, алыгыз! – дип, дуслары алганны көтте. Гата белән Илгизәр ипи белән бәрәңге алганнан соң гына, калган ипи белән бәрәңгене ашый башлады. Дәшми, сөйләшми генә, биектәге пи-бип, пи-бип килгән тәкърлекләргә карый-карый, Рәфгать төендәге бәрәңгеләрне башкарды. Шуннан соң гына Илгизәр үзенең букчасындагы җәймәләрне алып яулыкка куйды:

– Бүлеп торасы юк, малайлар, кеше саен берәр.

– Әйдәгез! – диде Гата, урыныннан торып. – Җәймәне юлда да ашап була.

Берәү дә каршы килмәде. Өчесе дә тау бите буйлап Көрән тавына таба киттеләр.

Ярты юлда Көрән тавы дип атала торган тау бар. Чирмешән елгасы көньяк-көнчыгыштан шул тауга килеп терәлә да, кызыл балчыклары ишелеп торган текә яр хасил итеп, дуга сыман борылыш ясаганнан соң, көньякка таба ага. Бераздан кинәт саегып калып, төбендә ак ташлары күренеп торган җирдә шаулап ага башлый. Бу урында тау биек булса да, текә булмаганлыктан, Чирмешәнгә төшеп, аргы якка чыгар өчен, кыеклап салынган ат арбасы юлы да бар.

Илгизәрләр шул урында балык тотарга ярата. Мәктәп участогында эшләре беткәч, авылга кайтканда бер көн дә, шунда туктап, балык тотмыйча калган көннәре юк аларның. Кармакларын, суалчаннарын шунда, таллар арасында гына калдыралар. Һәрберсе балык шулпасы – уха, йә булмаса, бөккән пешерерлек балык тотып кайта. Бүген дә, утырып ашап вакыт үткәрмәс өчен, җәймәне юлда ашый-ашый, шунда балык тотарга ашыктылар.

– Малайлар, әйдәгез бүген кояш баеганчы тотабыз, – дип сүз башлады Илгизәр. – Иртәгә Мәсфия апа киләсе булгач, тезмнәрне тутырып кайтырга кирәк. Мин әнидән ул килгән җиргә балык бөккәне пешертәм...

– Көтүгә кайтып җитмәгән өчен әниләр ачуланыр бит?

– Мәсфия Гариповна киләсе булгач, тезмнәрне тутырмыйча кайтмадык, диярбез. Башка вакытта кайтып җитә идек лә!



– Ярар, – диде Гата, – сөйләштек, тезмнәрне тутырып кайтарбыз. Барыбыз бергә.

Көрән тавы өстендә юл бер километрлар читтән уза да Кызыл ярга җитәрәк Чирмешән өстеннан бара. Малайлар яр астына төшә торган юл турысына киттеләр дә бер мизгел тирә-юньгә карап тордылар.

Тау өстеннән караганда түбәндә боргаланып аккан Чирмешән, аның болыннары искиткеч матур иде. Бу якларда нинди җимеш телисең, шундый җимеш үсә. Карлыган сазы, Чирмешәннән арырак, тау өстендә ак чиркәве, зур бакчасы белән Ниалау күренеп тора.

– Әйдәгез, малайлар! – диде Илгизәр һәм ат юлы белән тау астына, кармаклары калган таллар арасына атылып төшеп китте. Аның артыннан Рәфгать белән Гата та йөгерде.

Бер минуттан Илгизәр, кармагын сүтеп, чуалый каптырды да сунык агымы арта барган җиренә ташлады. Калкавыч төшкән җиреннән ике метр да китмәде, мылт-мылт килеп сикерә дә башлады. Илгизәр башта, кармак ак ташларга эләгеп калкавычны агым батыра, дип уйлаган иде. Ләкин шулвакыт калкавыч кинәт күздән югалганын күреп тартып чыгарган иде, дәфтәр битеннән да озын алабуга балыгы ияреп чыкты. Малайлар йөгерешеп килделәр.

– Вәт ичмасам балык, ярты килодан артыктыр! – диде Рәфгать, балыкны алып. Илгизәр көтелмәгән бу уңышка шатланып, ни диярг дә белми аптырап калды.

– Бүген син, Илгизәр, миннән да уздырмакчы буласын, ахры? – дип, Гата да кармагын суга ташлады.

– Жепне өзеп ычкына, дип торам, – диде Илгизәр. – Мәсфия апа бәхете инде бу алабуга...

Ул арада калкавыч сикергәнне күреп, Гата да йомшак кына кармагын тартып чыгарды – ап-ак чабак яр читенә килеп тә төште. Ул шунда ук кармагындагы суалчанны рәтләде дә, юри генә төкергәндәй итеп, аны яңадан суга салды. Ул шундый оста, шундый тиз тота, Рәфгать белән Илгизәр өч-дүрт балык тотканчы, аның тезмендә гадәттә дистәгә якын балык була иде инде. Әйтерсең лә, аның кармагы балыкларны магнит белән үзенә тарта. Ике-өч сәгатьтән аның тезме тулып килә иде. Рәфгать белән Илгизәр Гата янына килделәр.

– Гата, малай, әлле синең төкерегең тәмлеме? Безнең кармакларга да үз чуалыеңны кидертеп, төкереп бир әле?

Гата, сүз дә әйтмичә, дусларның үтенечен үтәде. Тик шулай да алар берәр балык тотканчы, Гата ике балык тотып, кармагын өченчегә салган иде.

– Әллә, малай, син аның берәр әфсенен беләсеңме? – дип, Рәфгать бераздан яңадан дусты янына килде. – Әйдә, кармакларны алышып тотып карыйк әле?

Тик болай иткәч тә, Гата кебек тиз тота алмадылар алар. Кояш баерга ике сәгатьләр калган иде, Гата теземен тутырды.

– Инде, малай, син кайтып китәсеңме? – диде Рәфгать, дустының теземе тулганны күреп. – Күмәчләрне алып?

– Китмим. Нишләп китим. Бергә кайтырга сөйләштек бит...

– Вәт рәхмәт. Чын дус икәнсең. Бергә кайтабыз.

Гата үз теземен тутыргач, иптәшләренең теземнәрен тутырышып, тоткан балыкларын аларга бирә барды. Кармагын салган саен:

– Бусы, Илгизәр, сиңа, ә бусы сиңа була, Рәфгать, – дип, исемнәрен атады. Кичкә таба балык яхшырак чиертә башлады. Бервакыт кармагын тирәнгәрәк салырга дип, калкавычын шуыртты да суның тирәнрәк җиренә ташлады. Калкавыч агым белән агып килде дә, сай җиргә җитә башлау белән, кинәт күздән югалды. Гата гадәттәгечә, ашыкмыйча гына, кармакны кырыйга тартып китергән иде, сайга калган җирдә беләк буйлы кызылканат сикерә башлады, ул шап-шоп сикергән балыкны оста гына тартып чыгарды да ике куллап тотып алды.

– Вәт шәп кызылкана-а-ат! – дип сузды кармагын ташлап йөгереп килгән Рәфгать. – Бу үзе ярты теземгә тора.

– Илгизәр, бәхетең гел зурдан йөри синең бүген! – дип, Гата кармагындагы кызылканатны дустына сузды. – Мә, сиңа аталган иде. Букчаңа салып куй!

Дустының шундый эчкерсез юмартлыгын күреп, Илгизәр Гатага карап торды да:

– Бу кызылканат үзеңә булсын инде, Гата. Минем зур балыгым бар, – дип, кулына алган балыкны кире Гатага бирде...

Кояш баерга бер сәгатьләп вакыт калганда, малайлар, өчесенең дә теземнәрен тутырып, тау башына күтәрелделәр. Тамаклары бик нык ачыккан булса да, күңелләре шат иде.

– Малайлар, көтүгә кайтып өлгерәбез әле!– дип шатланды Рәфгать.

– Өлгерәбез әле. Өлгермәсәк тә, әниләр ачуланырлык түгел, – диде Илгизәр, шатланып. – Күр, күпмешәр балык тоттык!

Кызыл яр турысына җитү белән, Гата букчасындагы төенне чишеп, борчак күмәчен алды да, аны өч кисәккә бүлеп, кулын букча эченә тыкты:

– Бусы кемгә?

– Үзеңә, – диде Илгизәр.



– Бусы кемгә?

– Миңа, – диде Рәфгать, күмәчне алырга кулын сузып.

– Бусы, Илгизәр, сиңа.

Алар, бер кулларына – балык теземе белән кармакларын, икенче кулларына сап-сары күпереп пешкән борчак күптермәсен тотып, ашый-ашый, каенлык артындагы тау башына урнашкан авылларына кайтып киттеләр.

# БОЗ КИТКӘНДӘ

Олы агайлар: «Кышы салкын, карлы-буранлы булды, язы да ашыкмас әле», – дип торганда, кинәт җылытып җибәрде. Берничә көн төнлә белән дә туңдырмыйча, җылы булып торды да яңгыр ява башлады. Бер көн, ике көн яуды. Кыш буена йөргән чана юллары изрәп, баскан саен ишелеп, бата торган булып китте. Үзәннәрне, елгаларны су басты. Урманнардан, ерак үрләрдән төшә торган сызалардагы кар сулары, үзләренең юлларында очраган карларны тәгәрәтә-тәгәрәтә, Чирмешәнгә омтылдылар. Кичен тулып та җитмәгән Чирмешән иртә торганда, ташып, ярларыннан чыкты, болыннарга җәелә башлады.

Күрше авылга барырга тиешле укучылар да ялдан соң бара алмыйча бүленеп калдылар. Алар өчен язгы каникул башланды.

Кояшлы апрель иртәсе. Язгы кояш нурлары шундый иркәләп карый, һич урамнан кермәссең. Илдус тәмле генә итеп йоклап ята иде:

– Тор... Тор инде, Илдус! – дигән тавышка, күзләрен ачмыйча гына, башын күтәрде дә, икенче якка әйләнеп, башыннан томаланды.

– Тор инде, Илдус! Үзең иртән үк безгә кил, су тәгәрмәче ясыйбыз, дидең!

Өстенә томалаган юрганны тартып төшергәч кенә, Илдус күзләрен ертып торып утырды.



– Бик тәмле йоклый идем әле, – диде ул, киерелеп.

– Үзең бит иртә кил, дидең. Әнә тышта нинди матур. Әйдә, тор! Су тәгәрмәчләрен ясап бетерәбез дә Чишмә тау астына йөгерәбез. Анда кичә үк су шәп ага иде.

Алар түбән өйгә төштеләр. Илдусларның өйләре ике катлы нарат йорт авылда бер генә. Өске каты – йокы, ял, уку-язу өчен. Китаплар шкафы белән язу өстәле дә шунда тора. Түбәнге катта кухня, ашау-эчү өстәле. Ишектән кергач, сул якта – столяр верстагы. Киштәдә эш кораллары: ышкылар, өтергеләр, бораулар, шерхебель. Чөйдә – аркылыга-буйга кисә торган пычкылар – җаның ни тели, барысы да бар. Илдусның әтисе дә, кулына ни тотса, шуны эшли торган кеше. Белмәгән эше юк... Агач эшен дә, тимер-калай эшен дә булдыра. Кирәк икән, мич тә чыгара. Бакчасында җиләк-җимеш агачлары да үстерә. Исәп-хисап эшен дә булдыра. Колхоз оештырган елларда хисапчылык эшен дә алып барды. Тимерче дә булып эшләде. Әле дә менә язгы матур көннәрдә, ыштан төбе туздырып, кәнсәләрдә утырмый, тимерчегә язгы чәчүгә әзерләнергә булыша. Анда бармаган көннәрдә колхозга арба, тырма ясый, эш кораллары төзәтә.

Әтисе алачыкта булган көннәрдә Илдуска мач килеп кенә тора. Верстак та, эш кораллары да – барысы да Илдус карамагында. Түбән өйдә көннәр буе тукылдаса да, әнисе ачуланмый. Киресенчә, малаеның эшкә өйрәнүенә, әйбер ясавына шатланып кына тора. Кышкы каникулда бүре куркыта торган шакырдавык ясаган иде. Инде менә Госман белән су тәгәрмәче ясарга керештеләр. Өстәл аягы буйлы чи каен агачы алып кергәләр дә, аны чистартып, урта бер җирен тәгәрмәч бүкәне кебек калдырып ышкыладылар. Шул калын җиренә дүрт тишек тишеп, дүрт калак куйдылар. Дүрт калак кына җитмәс кебек тоелды да, тагын дүрт тишек тишеп, дүрт калак өстәделәр. Икебезгә дә булсын дип, икенчесен ясарга керешкәннәр иде, кич җитте...

– Иртәгә иртә кил! – дип калган иде Илдус дусты киткәндә. Ә үзе ул килгәндә дә йоклап ята.

Түбән өйгә төшү белән, Илдус калаклар беркетер өчен тишекләр тишәргә кереште. Госман калаклар ясый башлады. Бер-ике сәгатьтән икенче су тәгәрмәче әзер дә булды.

Илдусның әнисе:

– Кая ашыгасыз? Уен качмас әле, ныгытып ашап алыгыз! – диюенә дә карамастан, малайлар Чишмә тавы астына ашыктылар. Урамда аларга кулына көрәк тоткан Хәбир очрады:

– Малайлар, нәрсә ул кулыгызда? Илдусның әтисе ясагандыр әле?

– Чишмә тавы астына, буа буып уйнарга. Буа минеке, тегермән сезнеке.

Юлда аларга:

– Кая киттегез? – дип, тагын берничә малай кушылды. Кайсылары, өйләренә кереп, көрәк, кайсылары таяк алып чыкты.

Тәгәрмәчләрне суның карны тирән казып төшкән җиренә урнаштырдылар. Йөгерек суда тәгәрмәчләрнең, су чәчрәтә-чәчрәтә, зыр-зыр әйләнгәннәрен карап торуы малайларга бик кызык булып китте:

– Вәт шәп әйләнә! Вәт шәп тарта! Күз иярми! – дип шатланып карап торганнан соң, Хәбир бер читкә китте дә:

– Малайлар, әйдәгез, буа буып, ташу агызабыз! – диде.

– Тегермәнне ваттырыргамы? – дип, Госман каршы төште.

– Борылышта ермак ясап, тегермәнне шунда күчерәбез, – диде Илдус.

– Әйе шул, хәзер үзем канау казыйм, – дип, Хәбир, көрәген тотып, суның югары агымына йөгерде. Берничә минуттан соң, су тәгәрмәчләрен күчереп урнаштырдылар. Суның карны тирән казыган җирендә, кар ишеп буа будылар. Су шундый йөгерек ага, малайлар буып өлгерә алмыйлар. Буаны буып бетерергә өлгермиләр, өстеннән су ташып, буаны алып та китә.

– Буаны алды! Буаны алды! Ташу китә! – дип кычкырып, малайлар агып киткән зур-зур кар кисәкләре артыннан суның түбәнге агышына йөгерәләр. Кар кисәкләре тарлавыкта тыгылып тагын суны буалар, су җыелып ташыгач, тагын йөгерек суда агып китәләр.

Малайлар тагын сыза буйлап түбәнгә таба йөгерәләр:

– Ур-р-ра! Буаны алды! Ташу китә! Бозлар ага!

Су чишмә янына җитәрәк таралып ага башлый. Малайлар шул җиргә кадәр йөгерәләр дә, кире борылып, яңадан су тәгәрмәчләре калган җиргә кайталар. Аннан яңа буа буалар. Яңадан ташу агызалар.

Көн үзгәренә таба сызаларда су арткан шикелле булды, тау астында малайлар да арта торды. Алты-җиде яшьлекләргә кадәр чыккан.

Хәтта урамда бик сирәк күренә торган Хафиз абзый Сәете дә үги әнисеннән ничектер ычкынган. Аның үги әнисе Җамалия апа, йортта бер эше булмаса да: «Чабата туздырып йөрмә!» – дип, Сәетне беркая да чыгармый. Бүген Сәет, Хәлисә апасының агач башмагын элгән дә, тау астына төшеп, Илдусның су тәгәрмәче әйләнгәнен исе китеп карап тора:

– У-у-у, ш-ә-әп әйләнә! Малайлар, карагыз, күз иярми! – дип, аю биеткәнне караган шикелле, сикерә-сикерә кычкыра. Малайларның күбесе карап туйган. Яңа килгәннәре генә:



– Мин дә этидән ясатам! – дигән булалар.

Сәет, шактый озак карап торганнан соң, Илдус янына килде дә, аның җиңеннән тартып, «л» авазын әйтмичә генә:

– И-дус, И-дус, дим! Миңа бер тирмәнеңне бир әле? – дип, Илдуска карады.

– Аның берсе Госманныкы. Үзең яса. Без үзебез ясадык, – диде Илдус.

– Мин ясый белмим шул, – диде Сәет, моңсуланып.

– Абый дисәң, бирәм, – дип елмайды Илдус.

– Ун йомыркасыз бирмә! – дип кычкырды әле генә килеп баскан Хәбир, авызын ерып:

– Кит, малай, син нәрсә сөйлисең? Каян алсын ул ун йомырканы?

Илдус үзеннән ике яшькә кечкенә Сәетне кызганып куйды. Үги ана кулында аның җәберләнеп үскәнен ул ишеткәне бар иде. Су тәгәрмәчен шулай гына бирергә дә риза иде. Шулай да Сәеттән «абый» дип әйттерәсе килә иде.

– И-дус абый, бирәсеңме? Бир инде, И-дус абый? – диде малай, моңсуланып. Сәетнең борыны һәрвакыт тулы торганга, ул сөйләгәндә кайбер авазлар югалып калалар иде.

– Ярар, – диде Илдус. – Әнә теге читтәгесен алырсың.

Сәет шундый шатланды, шунда ук:

– Тирмән минеке! Тирмән минеке! – дип, урынында сикерә башлады.

Малайлар:

– Гали төшә! Гали төшә! – дип сөрән салдылар.

Кулына күсәк тотып, биредәге иң олы малайлардан да өч-дүрт яшькә олырак Гали таудан төшеп килә иде. Болай карап торырга акыллы гына күренсә дә, чәчәктән калган гадәте бар: үзеннән кечкенәләрне кыерсытырга ярата. Яхшы гына уйнап торган малайлар янына килә дә уенны боза. Тавыш чыгара. Каршы төшүчеләрнең «кәҗә майларын чыгарып», чәчләрен кирегә сыпыра. Тәмам елатканчы үрти. Уенчыкларына, әйберләренә тия. Гали бу юлы да төшкән уңайга күсәген югары күтәрде дә:

– Малайлар, кайсыгызның су тәгәрмәче?! Карап торыгыз, хәзер аны су агызып китә! – дип йөгереп төште дә, күсәге белән сугып, карны ишеп төшерде.

Госман:

– Абыйга әйтәм, тотынасы булма! – дип кычкырганда, су тәгәрмәче көчле агым белән таркалып агып бара иде. Гали, күрдегезме, мин нишли алам дигәндәй масаеп, күсәгенә таянып, авызын ерып, малайларга карады.

Госман еларга җитешеп:

– Гали-мали бармагын ялый! Мин сине Закир абыйга әйтеп кирәгеңне бирдерәм әле. Гали-мали тизәкле бармагын ялый! – дип, тегене үрти башлады.

– Җитте, малай, сиңа! Хәзер, тотып, кәҗә маеңны чыгарам!

– Тотынып кына кара, хәзер кайтып, Закир абыйны алып киләм! – диде Госман, бераз артка чигенеп.

Шул арада Илдус белән Хәбир Галидән ничек үч аласын сөйләшеп өлгергәннәр иде. Хәбир Галинең артына чыгып чүгәләве булды, Илдус тегенең күкрәгенә китереп төртте. Гали, Хәбир өстеннән әйләнеп, агымсуның уртасына ук барып төште. Гали су эченнән чыкканда, Илдус белән Хәбир тау башында иде инде. Гали гарьлегеннән ни эшләргә белми кызарып, бүртеп судан чыгып килгәндә, тирә-юньдәге малайлар, бу кызыкка карап, эчләрен тотып, көлешә башладылар.

Тау башына менеп җиткән Илдус белән Хәбир:

– Гали-мали, карлы суда ауный! – дип кычкыра башладылар.

– Ах, кәҗә тәре! Иманыңны алам! – дип, Гали тау өстендәге малайларга ташланды. Ләкин куып җитәсенә ышанмаганлыктан, билдән юеш килеш урам буена чабага хурланып туктап калды. Борылып килеп күсәген кулына алды да:

– Хәзер икенче тәгәрмәчне дә ташу алып китә! – дип сөрән салды. Шулвакыт Сәет, йөгереп барып, Галинең күсәгенә асылынып кычкырып җибәрде:

– Ваттырма! Ул минеке!

– Кит, малай, суга атам бит! – диде Гали, малайны этеп.

Ләкин Сәет күсәкне шундый кысып кочаклаган, Гали аны тиз генә аерып ала алмады. Сәет исә:

– Ваттырма, ул минеке! Апага әйтәм! – дип, кычкырып елый башлады. Алар шулай тарткалашып торганда тау башында Сәгыйтьнең апасы Хәлисә күренде. Ул чәчәкле күлмәк өстеннән йон кофта кигән, яулыгын арттан бәйләгән.

– Кара әле, күрше, нигә тиясең балага?!

Тау башында чибәр кыз басып торганын күреп, Гали йомшарып калды. Кыз алдында үзенең кемлеген күрсәтәсе килмәде.

– Ә-ә... Ни... Без болай гына, шаярабыз гына! – диде ул, кулындагы күсәген ташлап, һәм берни булмаган шикелле кыз янына күтәрелде.

– Исәнмесез, күрше, – диде ул, Хәлисәдән күзләрен алмыйча. – Бу арада бер дә күренмисез?



– Исәнмесез, – диде кыз. – Күренмим дип, капка төбенә чыгып басыйммы әллә? Минем синең кебек шаярып йөрергә вакытым юк. Нишләп болай юешләндең, салкын суда коендыңмы әллә?

– Ә, ни, – диде егет, бер дә исе китмәгәндәй юеш киемнәренә карап. – Тегендә кар ишелеп китте дә...

– Су тәгәрмәнен ваткан өчен аны Илдус суга төртеп төшерде! – дип кычкырды Госман.

Малайлар тагын көлешә башладылар:

– Гали-мали карлы суда ауный!

– Җитте, малайлар!– дип кычкырды Гали.

– Ә-ә, әле син шулай, егет башың белән, малайлар кыерсытып йөрисеңмени?! – диде Хәлисә, Галигә ачулы карап. – Ничек оялмыйсың?

– Авыз тәме җибәрмик әле, күрше, юк өчен. Кичкә ташу карарга барабызмы?

– Бар, кереп өстеңне киптер! Бу килеш кая бармакчы буласың? – диде кыз һәм кире борылып китте.

Уенның кызыгы беткәнгә, малайлар боегып калганнар иде. Шулвакыт авыл ягыннан кемдер:

– Малайлар, Чирмешәндә боз кузгалган! – дигән хәбәр салды. Бу малайларны яңадан дәртләндереп җибәрде:

– Әйдәгез, малайлар, киттек! Чирмешәнгә!

– Боз кузгалган! – дип кычкырыштылар.

Бер минут эчендә Чишмә тау асты бушап калды...

Авыл урамы Чирмешәнгә килеп терәлә. Шул турыда вак таллар баскан кечкенә утрау бар. Чирмешен тулган. Тугайдагы вак таллар да су эчендә калган. Чирмешән өсте берсе өстенә икенчесе килеп өелгән бозлар белән тулган. Аргы яктагы болыннарга су җәелгән...

Чирмешәнгә килеп терәлгән авыл урамының сул чите бер-ике метрга биегрәк. Кырыйдагы Низамнар йорты эчкә кертебрәк салынган. Ташу карарга килгән бала-чага, яшьләр өеп куелган салам өстендә уйныйлар. Ир-атлар – бер җирдә, хатын-кызлар икенче читтә төркем-төркем булып басканнар, үзара сөйләшәләр, көлешәләр, көнбагыш чиертәләр. Яр читендә ир-атлар ятьмә белән балык сөзә. Бала-чага балык чүпләргә булыша. «Боз кузгалса, яхшырак эләгер иде», – дип сабыр итүче балыкчылар да бар.

– Нишләп килми тордыгыз? Әй, кызык булды. Ике мәртәбә боз кузгалды, – дип каршы алды Рөстәм малайларны.

– Һе, без Чишмә тавы астында ташу җибәреп уйнадык. Су тәгәрмәчләре әйләндердек. Гали-малине кызык иттек. Әй, кызык булды. Син генә булмадың, – диде Илдус.

– Низам бабай әйтә: «Ак тирәкләр су эчендә калса, боз китә башлый», – ди. Әнә, су ак тирәкләргә җитеп килә инде...

Кинәт Чирмешен өсте тавыш биреп алды. Аслы-өсле өелгән бозлар бер-берсен вата-җимерә кузгалып алды. Кырыйлары белән өскә күтәрелгәннәре гөрселдәп ишелеп төште. Чирмешән өсте хәрәкәткә килгән шикелле булды, яр буенда җыелган халык та гөжләп алды:

– Кузгалды! Боз кузгалды!

– Боз китә! – дип сикереште балалар.

– Әнә, карагыз, малайлар, бер боз өскә күтәрелә!

– Күтәрелә, күтәрелә!

– О-о, хәзер ишелә!

– Малайлар, борылыштан нидер килеп чыкты!

– Кибән төбе ич!

Шул арада яшьләр саламнан көлтәләр бәйләп, аларга ут төртеп, сәнәк белән биек яр өстеннән агып барган боз өстенә ташлый башладылар. Бала-чагага шул җитә калды:

– Пароход килә! Пароход килә! – дип сикерештеләр.

Кинәт көлтәләр эченнән ике тычкан йөгереп чыкты да боз өстендә йөгерә башлады.

– Пожар! Тычканның өенә ут капкан! – дип көлеште балалар көлә.

– Янабыз, янабыз! Ярдәм итегез! – дип, Рөстәм дүрт аякланып арлы-бирле кызык ясап йөгергәләде. Илдус белән Госман көлтә бәйләде. Госманның Закир абыйсы көлтәләргә ут төртеп боз остенә ташлап торды. Бераздан Закирның кискен тавышы яңгырады:

– Җитеп торыр, малайлар! Караңгы төшкәч, ягарга калсын!

Малайлар көлтә бәйләүне ташлап, Чирмешән борылышына караганнар иде, алда ниндидер карагай күренде. Килә торгач, ул алынып бетмәгән кибән төбе булып чыкты. Печән өстендә утырып килгән куянны күреп алдылар.

– Малайлар, карагыз әле, куян утырып килә түгелме соң?!

– Малайлар, куян! Куян сәяхәткә чыккан! – дип көлде Илдус.

– Әй, куян, мине дә утырт әле! – дип кычкырды Госман.

– Әстерханга бара ул! – диде Закир абый, көлеп.

– Абый, нишләп ул куян анда калды икән? – диде Госман, абыйсының җиңеннән тартып. – Батып үлә бит инде мескен?



– Төнлә печән ашарга дип килгәндер дә су басканны сизми калгандыр. Хәзер инде әнә Әстерханга бара.

– Әй, шул куян янына утырып китәсе, – ди Сәет.

– Бу бозлар бит Сарытауга да җитми. Эреп бетәләр, кая бармакчы буласың, Сәет?

– Абый, абый, дим! Куян нишли инде, боз эреп беткәч? – ди Госман, һаман абыйсын аптыратып.

– Берәр җиргә кереп утырыр, шунда ташу кайтканны көтәр дә аннары болынга китәр...

Караңгы төште. Чирмешән буеннан китәргә теләгән берәү дә юк. Кызлар, малайлар саламнан көлтә бәйли башладылар. Боз өстендә бер-бер артлы агып торган учаклар төнге караңгылыкта елга өстен яктыртып борылышка кадәр баралар да берәм-берәм күздән югалалар. Тезелешеп агып барган учакларны төнге караңгылыкта карап торуы үзе бер тамаша. Кайбер бозлар борылышта болынга кереп китәләр. Андый вакытларда малайлар:

– Пароход Үсиягә керде! – дип шатланышалар.

– Малайлар, кайсы бозның Үсиягә керәсен белсәм, мин дә утырып китәр идем! – ди Госман.

– Анда бит су диңгезе. Ничек кайтыр идең, тиле, – ди Рөстәм.

– Исең киткән, абый көймә белән барып алыр иде. Барып алмаса, ике көн генә торыр идем әле. Әнә, челюскинчылар котыпта да тордылар бит.

– Әй, Челюскин! – дип кычкырды Госманның абыйсы. – Китер көлтәңне!

– Челюскин! Челюскин! – дип эләктереп алды малайлар.

– Челюскин кушабыз! – дип кычкырды Хәбир. – Челюскин кушабыз сиңа!

– Кушсагыз соң, – диде Госман, бер дә исе китмичә. – Сиңа куш инде кешегә исем тагарга, үзең «Кәҗә» булгач та...

– Кәҗә шул, әллә начар хайванмы?

– Юньле хайван да түгел. Бакча убыры... Кәҗә-кәҗә, мәкәрҗә, кермә минем бакчага! Кысылырсың киртәгә. Сырлы таяк алырмын...

– Йә, җитте! – дип әтәчләнде Хәбир. – Абыең монда дигәч тә, әллә...

– Яхшы гына, үртәшмичә! – дип кисәтте Закир Госманны.

Якында гына гармун тартып җибәрделәр.

– Нәҗип абый килә! – диде Илдус. – Әй шәп тә соң тавышы, күрше авылга ишетеләдер...

– Ул бит «вараксин». Биш планкалы. Андый гармун беркемдә юк.

Нәҗип төрле көйләр чыгарып сайратып алды да, «Авыл көен» тартып җибәрде. Егет-кызлар, гармунга кушылып, җыр башладылар...

*Чишмәләргә, суларга бай*
*Чирмешән үзәннәре.*
*Чирмешән буенда үсә*
*Кызларның эшчәннәре.*

Язгы кичнең дымга туенган саф һавасында тальян моңына кушылган җыр тавышлары су баскан Чирмешән болыннарына тарала. Тал-тирәкләргә барып сарыла. Авыл тәрәзәләренә кагыла. Өйләргә үтеп керә. Кешеләрнең күңел кылларына кагылып, матур язлар килгәнне искә төшерә. Дәртләндерә, моңландыра, уйландыра.

– Эх, шәп тә соң Нәҗип абыйның гармуны, – диде Илдус, саламнан көлтә бәйләүне ташлап. – Әйдәгез, ничек уйнаганын карап торабыз!

Ул Госманның җиңеннән тотты да егетләр, кызлар чорнап алган гармунчының каршысына ук кереп басты. Җыр дәвам итте...

*Язлар җиткәч, бозлар китә,*
*Ага сулар ник болай...*

Өч малай – Илдус, Госман, Рөстәм – Нәҗипнең гармун телләре өстендә күз иярмәс тизлек белән биегән бармакларына карап, ни дә булса отып калырга, «гармунга өйрәнергә» тырыштылар.

– Эх, – диде Илдус, иптәшләренең колагына иелеп. – Ну уйный да соң, Нәҗип абый. Шулай уйный белсәң иде! Кара, аның бармакларына күз иярми.

– Әтиеңә әйт тә син дә алдыр, Илдус.

Нәҗип кинәт бию көе уйный башлады. Егетләр, кызлар түгәрәк ясап бастылар. Малайларга читкә чыгарга туры килде. Госманның Закир абыйсы уртага чыкты да, чүгеп-чүгеп, бии башлады. Аннары Хәлисә турысына тукталып, аңарга типкән иде, кыз да сынатмады, шунда ук чыгып, Закир тирәсендә әйләнеп-әйләнеп биеп китте. Аларны Миләүшә алыштырды. Егетләр-кызлар берсен-берсе алыштырып биеделәр. Чирмешәндә боз яңадан тукталып калды да берсе өстенә икенчесе өелә башлады. Чирмешәндә су күзгә күренеп арта башлады. Кайсыдыр:

– Бозлар буа борылышында тыгылды, – диде. – Ак тирәкләр дә су эчендә калды. Ә бозларның кузгалырга исендә дә юк.

– Әйдәгез, малайлар, кайтабыз, – диде Илдус, иптәшләре янына килеп. – Монда без генә калдык.

– Әйдәгез! – диде Госман.



Алар, өч малай, кайту юлына борылдылар. Берничә йортны узып, Чирмешән буена яңа күчеп утырган өйләргә бара торган тыкрыкка җиткәннәр иде, шомлы тавышлар ишетеп туктап калдылар.

– Анда кемдер кычкыра, – диде Госман.

– Ярдәм итегез, су баса-а!

– Бу бит тегермәнче Фатих кычкыра, – диде Илдус.

Тавыш яңадан кабатланды:

– Ярдәм итегез! Су баса!

– Малайлар, мин абыйлар янына йөгерәм, – диде Госман. Илдус белән Рөстәм тавыш килгән якка йөгерделәр. Ләкин бакчалар артына җитү белән, ары бара алмый туктап калдылар. Кечкенә күпер су астында калган иде.

– Монда көймә кирәк, – диде Илдус. – Мин Низам абыйга чабам, син тиз бул, председатель Ибраһим абыйны чакыр!

Малайлар икесе ике якка йөгерделәр.

– Анда көймә кирәк, – диде Илдус, сулышына кабып. – Көймәсез булмый.

– Көймәне үзем алып киләм, – диде Закир егетләргә. – Сез бара торыгыз!

– Абый, мин дә синең белән, – диде Госман.

– Мин дә! – диде Илдус. Аларның исәпләре көймәгә утырып йөрү иде.

– Йөрмисез. Бу зурлар эше. Барыгыз кайтыгыз! – диде Закир

Ләкин малайлар кайтып китмәделәр. Ничек инде, шундый вакытта, кайтып китәсең? Үзебез кешеләр чакырып йөрик тә, кайтып китегез, имеш? Анда су астында калган кешеләр нишләр? Аларга кем булыша, ди?

Берничә минут эчендә кешеләр җыелды. Колхоз рәисе Ибраһим Гайфуллин да килеп җитте. Ул арада ике ат алып, атлар караучы Гәрәй дә килде.

Киңәшеп алганнан соң, сарыкларны көймә белән ташырга, сыерларны атка атланып, җеп белән тотып, йөртеп чыгарга булдылар. Иданнәренә су менмәгән булса, бозауларны, бәрәннәрне өйгә кертергә, диделәр.

– Гәрәй абый, бер атыңа үзем атланып керим әле? – диде Илдус, андагы кешеләргә бик нык ярдәм итәсе килеп.

– Юк, энем, бу зурлар эше, – диде председатель. – Монда олылар да җитәрлек.

– Сезне чакырганда ярадык бит әле? – диде үпкәләгән Рөстәм. – Хәзер кирәкмибезме?

– Кем әйтте кирәкмисез дип? Менә хәзер терлекләрне алып чыгабыз. Сез әнә якындагы кешеләрне уятыгыз. Терлекләрне каршы алырга әзерләнсеннәр. Сыерларны конюшняларына кертергә, дип әйтте Ибраһим абый, диегез! Судан чыккан терлеккә җылы урын кирәк. Барыгыз!

– Әйдәгез, – диде Илдус иптәшләренә.

Ул төнне колхозның күп кешесе белән бергә, бу өч малай да соң гына кайтып яттылар. Су баскан җирдән алып чыккан сарыкларны, сыерларны урнаштырышырга булыштылар. Кешеләр чакырдылар.

* * *

Кояш биек үк күтәрелгән иде. Илдус сарык бәрәне кадәрлеге йонтәс бохар мәчесенең юеш салкын аягы битенә тиюдән уянып китте. Баш очында мыр-мыр килгән Шаян тышта юешләтеп кергән аякларын юып утыра иде. Аның йомшак сары йоннарыннан салкынча яз исе килеп тора. Илдус күзләрен ачып карады да:

– Кит әле, Шаян, пычрак аякларың белән кая мендең? – дип, мәчесен мендәрдән төртеп төшерде. Аннан, тынычланып, икенче якка борылып яткан иде, кинәт үткән төндәге хәлләр исенә төште дә күзләрен ачып торып басты. Тәрәзәгә килеп, тау астындагы сазга, аның аргы читендәге кечкенә каенлыкка карады да исе китте. Чирмешәннән алып чишмәгә кадәр диңгез кебек су. Каршыдагы каен урманы су эчендә калган.

– Вәт да-а! – дип кычкырып җибәрде Илдус. – Чирмешән буендагы йортларда кешеләр ни эшлиләр инде?

Аннары ул йорт ягындагы тәрәзәгә килде. Әтисенең кар астыннан чыккан чүпләрне тырмалаганын күрде дә, киенеп, әтисе янына чыкты.

Тузик аны сикерә-сикерә каршылады.

– Тордыңмы, улым? Кичтән бик озак йөрдең. Бозларны озатып бетереп кайткансыз инде?

– Әй, әти, анда, Чирмешән буендагы өйләрне су басты. Ярдәмгә чакырып кычкырдылар...

– Ишеттем, улым, ишеттем. Сирәк була торган хәл.

– Әти, Ислам, Фатыйх абзыйлар нишли инде анда, су өйләренә керсә?

– Нишләсеннәр, өйләрендә утыралардыр.

– Су эчендәме?

– Өйләре генә су эчендә бит. Идәннәреннән чыкмаган. Аларның өйләре күтәрә төшеп салынган. Куркыныч үткән инде. Әнә, кырлар



ала-кола була башлаган. Су шуннан ары күтәрелмәс. Син, улым, тырма алып, чүпләрне бер өемгә төрт әле. Мин себерә торам.

Илдус, тырма алып, чүпләрне җыйды. Капка артында кемнеңдер килгәнен ишетеп, Тузик һау-һаулап капкага ташланган иде, капкада Госман күренгәч, туктап калды да, сикергәләп, аның белән шаярырга кереште.

– Исәнмесез, алла куәт бирсен! – диде Госман, Илдусның әтисен күреп.

– Артыннан куа килсен! – диде Мөхетдин абзый, елмаеп. – Исәнмесез, куәтле булыгыз, дип исәнләшергә өйрәнегез. Аннары, таныш олы кешенең исемен әйтеп исәнләшергә кирәк. Улым, бу сиңа да кагыла!

– Ярар, әти, моннан соң шулай исәнләшербез.

– Илдус, әйдә тизрәк ташу карарга! – диде Госман, дусты янына килеп.

– Башта өйгә кереп чәйләгез. Аннары барырсыз! – диде Мөхетдин абзый улына. – Бер китсәгез, төнгә кадәр ач йөрисез.

Ташу карарга килүчеләр бүген дә күп иде. Яр читендәге актарылган салам калдыклары өстендә бала-чага чыр-чу килә. Ятьмәләре булган ир-атлар балык сөзә. Анда-санда гына аккан базлар өстендә кичәге кебек учаклар янмый. Шулай да Чирмешәннең аргы ягындагы өч-дүрт километрдагы авылның түбән очына кадәр җәелгән су диңгезенә, бөтерелеп аккан болганчык сулар белән агып килгән бозларга карап торуы күңелле. Шуның өстенә язгы ташкын күтәреп алган салам, печән калдыклары, кар өемнәре, алар өстенә утырып сәяхәткә чыккан каргалар килеп чыгалар да, ташу караучыларга күңелле булып китә.

Ташу караучылар янына Гали килеп чыкты. Аның бер кулында – ятьмә, икенче кулында – чиләк.

– Малайлар, кайсыгыз минем белән бара? Тоткан балык уртагыннан!

– Гали-мали, алдыйсың бит син? – диләр малайлар, аңа ышанмыйча.

– Билләһи менә, алдамыйм. Мин сөзәм, сез тоткан балыкны чиләккә тутыра барасыз. Чиләк тулды исә, яртысы сезнеке.

– Ышандылар, ди, син кырыгалдарга. Әле кичә тәгәрмәчне дә ваттың, – диде Госман.

– Ышанмыйсызмы? Чиләктер менә, алдамыйм, – ди Гали, чиләген югары күтәреп.

– Чиләктер түгел, ипәйдер, дип әйт! – диләр малайлар.

– Бармыйсызмы? Ярар, кирәгегез бер тиен. Мин сезне балыклы итмәкче булам. Үкенерсез әле! – дип кычкырды Гали, үзе килүче юкмы дип артына карый-карый. Ләкин ике-өч дистә малайның берсе дә Галигә иярмәде.

– Госман, әйдә абыең янына! – диде Илдус, Закирның балык сөзгәнен күреп.

– Кит, малай, безнең ятьмә юк ла, – диде Госман, иптәшенә карамыйча гына.

– Әнә бит, күзләреңне ачып кара, абыең балык сөзә!

– Әйе шул, – диде ул, Госман абыйсының балык сөзгәнен күреп.

– Кем ятьмәсен алды икән? Әйдә, йөгердек!

Алар, икәүләп, яр буйлап Закир абыйлары янына йөгерделәр.

– Абый, ятьмәне кемнән алдың?

– Әнә, Галим абзыйдан алган идем. Йә әле, җиңел аяктан, – Закир көчле куллары белән ятьмә сабының очыннан тотты да суның бөтерелеп аккан җиренә салды. Ятьмә сабының очын җилкәсенә куеп, ике куллап басып ятьмәне суга батырганнан соң, ярга китереп терәде. Аннары ятьмәне әкренләп ярга кыса-кыса, ашыгып, судан чыгара башлады.

– Аягын җиңел булды, энем, – диде ул елмаеп. – Нәрсәдер бар.

Шулвакыт болганчык су белән бергә ятьмә эчендә сикерә-сикерә беләк буйлы чуртан белән берничә вак балык килеп чыкты. Госман, йөгереп барып, ятьмә эченнән чуртанны аралап алды. Илдус вак балыкларны җыйды.

– Ай-яй усал кылана, – диде Госман, кулындагы чуртан җиргә шуып төшкәч.

– Менә ичмасам бу балык. Ике кило бар, – дип, Закир ашыгып чуртанны кулына алып карады. Аннары, ятьмәне кулына алып, яңадан суга батырды. Болганчык су эченнән тагын берничә вак балык килеп чыкты. Малайлар аларын да җыеп алды.

Закир өч-дүрт мәртәбә сөзеп алганнан соң, Госман:

– Бусы, абый, минем исемгә булыр. Менә, күрерсең, тагын бер шәп балык эләгәчәк!

– Эләккән иде, – диде ятьмә хуҗасы Галим абзый, тәмәкесен суырып. – Мин кайчаннан бирле сөзеп тә, балыгым бер ухалык кына.

Госманның абыйсы ятьмәне батырып ярга кысып шуытып чыгарган иде, кып-кызыл канатлы бер зур алабуга балыгы килеп чыкты.

– Әйттем бит! Әйттем бит! – дип сикерде Госман.

– Да, малай, юраганың юш килде...

– Мин юрамадым, юрамадым. Шулай булуын теләдем! – диде шатлыгыннан нишләргә белмәгән Госман, ятьмәдән балыкларны алып.

– Мә, Галим абзый, ятьмәңне, – диде Закир, ятьмәне җиргә куеп. – Рәхмәт, безне балыклы иттең.



– Җиңел кулдан миңа да сөзгәлә инде, – диде ятьмә хуҗасы. – Чыннан да оста сөзәсең икән.

– Госман, сез балыкларны алып кайтыгыз! – диде абыйсы. – Мин бераз Галим абзыйга балык сөзешәм. Әнә тал чыбыгы ал да балыкларны санагыннан шуңа тез.

Ташу караучылар Госман белән Илдус кулындагы балыкларны күреп исләре китте:

– Кайдан алдыгыз да, кайдан алдыгыз? – диештеләр алар.

Хәбир:

– Чәлдергәнсез әле берәрсенең җылымыннан? – дип көлде генә.

– Кит әле, малай, син үзең чәлдергәч тә. Абый тотты, беләсең килсә.

– Берәрсенең җылымыннан эләктерәсең дә, абый тотты була инде ул...

– Китсәнә, синең белән сөйләшеп торган кешесе, – диде Госман, Хәбирне төртеп җибәреп.

Алар кайтып киттеләр. Бераздан Госман чыбыкка тезгән балыкларны Илдуска тоттырды да үзе зур алабуга балыгын кулына алды.

– Сакланып тот, – диде Илдус. – Энәләре керпенеке кебек.

– Шәп бит, малай, бер килолап булыр.

– Шәп, – диде Илдус. – Шәп балык эләксен, дигән идең. Тәки шулай булды. Балыктан бәхетең бар синең.

Госман алабуганы дәшмичә генә кулларында әйләндергәләде. Аннары:

– Кара, нигә болай авызын ачып тора, әллә үлгәнме? Ай-яй тешләре, урак тешләремени... – дигән иде, кинәт: – Ой! – дип кычкырып җибәрде дә, балыкны җиргә атып, бармагына карады.

Уң кулының имән бармагыннан кып-кызыл кан тамып тора башлады.

– Бетерде бармагымны, ерткыч! – дип, Госман юлдагы алабуганы аягы белән тибәреп җибәрде.

– Авыртамы? – диде Илдус, Госманның каны агып торган бармагына карап.

Ике күзеннән бәреп чыккан яшь аралаш Госман, башын кагып, «авырта» дигәнне аңлатты.

– Ни чуртыма бармагыңны анда тыктың соң әле?! – дип ачуланды Илдус дустын. – Күпме алабуга тотканың бар, белми идеңме? Кара инде, бөтен буе белән тыкмасаң ярамадымы?

– Соң, авызын ачып тора иде бит...

– Торса бит, бармагыңны тык дип еламагандыр!

– Тешләре үткенме икән, дип карый башлаган идем, авызын япты да куйды. Сискәнеп китеп, бармагымны тартып алган идем, тиресен сыдырып алып калган, явыз.

– Адәм хурлыгы... Кешегә әйтсәң, бот чабып көләрләр. Инде нишлибез? – диде Илдус, дусты өчен борчылып. – Бар син өйгә йөгер. Мин балыкларны алып кайтырмын.

– Ярар,– диде Госман теш арасыннан гына. Һәм шунда ук кулын читкә тотып, кар өстенә кан тамыза-тамыза, өйләренә йөгерде.



# ҖЕНДЕР БУ, БАЛЫК ТҮГЕЛДЕР...

Язгы кар сулары тартылып, елгалар үз ярларына кайткан көннәр. Кичке якта Әхсән Хәмзәләргә барырга чыккан иде, дусты үзе каршы килеп чыкты.

– Әхсән, әйдә каенлыкка чуртан тотарга төшәбез? – дип каршы алды Хәмзә. – Кичә без абый белән ике чуртан тотып кайттык.

– Хәзер бит соң инде. Аннары минем итегем дә юк.

– Бер дә соң түгел. Алар кояш баеганда коеналар, ди абый... Итек әтиеңнеке бардыр әле. Мин дә абыйныкын киям.

– Ярар, мин өйгә кайтып килим әле. Әтинең итеге өйдә булса...

– Озак торма! – дип калды Хәмзә арттан.

Авыл каршысындагы сазлыкта, каенлыкның Чирмешәнгә караган башында, берничә гектарда гына кисенте бар. Ул кисенте түбәнлектә булганлыктан, мондагы су җәй буена кипми. Ярты җәйгә кадәр әкрен генә Чирмешәнгә таба агып тора. Бередәге таллар, вак каеннар арасындагы камышлыкларда бик күп каен төпләре, судан күтәрелеп торган түмгәкләрдә яз көннәрендә үрдәкләр, йомырка салып, бала чыгаралар. Язгы ташу вакытларында, бозлар аккан көннәрдә бирегә уылдык чәчәргә Чирмешәннән бик күп чуртан балыклары менә.

Әхсән йөгереп кайтты да:

– Әни, әтинең итекләрен киим әле, без чуртан тотарга барабыз! – дип, токмач кисеп торган әнисе янына килде.

– Чирмешәнгәме? Йөрмәгез, йә суга төшәрсез!

– Юк, әни, без каенлыкка гына төшәбез. Кичә Хәмзәләр ике чуртан тотып кайтканнар.

– Шулаймыни? Монда гына булса, ярар. Әтиең кичә итекләрен ару дегет белән майлап куйган иде әле, – дип, Мәрьям апа иренең итекләре белән аяк чолгавычларын алып бирде. – Карап йөрегез алай да!

– Ярар, әни. Без Хәмзә белән барабыз. Ул кайда икәнен белә.

Әхсән итекләрне киде дә, йортка чыгып сәнәкне алганнан соң, Хәмзәләргә йөгерде. Хәмзә аны капка төбендә каршы алды.

Алар урам аша чыктылар да, Фазлый абыйлар тыкрыгыннан төшеп, әле сулары тартылып бетмәгән саздагы тетрәп торган түмгәкләр өстеннән сикерә-сикерә, каенлык борынына юл тоттылар.

– Әй анда күрсәң, малай, исең китәр иде, – дип сүз башлады Хәмзә. – Шулкадәр суны кеше биекле чәчрәтеп коеналар. Тик ул таллар арасына кереп булмый. Су тирән... Син ишеттеңме, кичә Кәли Гаптулласы биш чуртан тоткан. Ә теге балыкчы Сөнгатулла абзыйлар әллә уникене тотканнар, ди.

– Алар бит куна-төнә Латра елгасында яталар. Аларныкы кебек «вәтелләрем» булса, мин дә тотар идем. Йә, ярар, сөйләшмичә барыйк, чуртаннарны куркытабыз, – диде Хәмзә, бик белдекле булып. – Анда, суга кергәч, тавышланмыйча, аягыңны шуытып кына күчер. Сәнәгеңне менә шулай алга сузып тотасың да... Чуртан камыллы түмгәккә борынын төртеп тора торган була. Тавышсыз гына якынлашасың да сәнәк белән – булты-ых!

– Йә, ярар, сөйләшмә инде, – диде Әхсән. – Беренче тоту түгел. Үткән ел Тәре сазында Гәрәй белән тоттык...

– Әкрен. Ишетәсеңме? Әнә чуртаннар коена, – диде Хәмзә. – Мин әнә теге якка таба керәм. Син бу яктан кереп китәрсең!

– Ярар сана! – диде Әхсән. – Күп сөйлисең. Үзем дә беләм...

Алар каенлыктагы суның Чирмешәнгә агып чыга торган читенә килделәр дә әле бозлары да эреп бетмәгән куе үләндәге түмгәкләр арасыннан, аякларын шуытып кына атлап, су эченә кереп киттеләр.

Әхсән сәнәген алга сузган килеш, чыпчык тотарга әзерләнгән мәче шикелле, шундый әкрен, шундый озак барды. Инде куллары да талды. Ә балык һаман күренмәде. Инде ул монда балык барына да шикләнә башлаган иде, кайдадыр таллар арасында суга кирпеч белән бәргән шикелле булып китте. Әллә инде Хәмзә берне эләктерде дип, шул якка карап алды. Юк, ул да бер урында хәрәкәтсез тора. Әхсән алдына карап аягын шуыткан иде, өч-дүрт метр алда түмгәк төбенә башын төртеп хәрәкәтсез торган нәрсә күреп катып калды. «Балыкмы соң бу, әллә каен кисәвеме?» – дип, лышт иттереп борынын тарткан иде, беләк буйлы чуртан җәядән атылган ук шикелле тавышсыз-нисез алга китте дә барды. Чуртанның койрыгы селкенгән җирдә су гына бөтерелеп калды.

«Ычкындырдым чуртанны, ачык авыз», – дип, үз-үзен тиргәп куйды Әхсән. «Күреп алу белән сәнәкне ташлыйсы гына булган...»

Хәмзә киткән якта сызгырган тавыш ишетелде. Караса, Хәмзә беләк буйлы чуртанны сәнәккә чәнчеп алган да югары күтәреп тора. Әхсәннең гарьлеге тагын да артты. Йөрәге чәнчешкәндәй булды. «Әнә ул минем кебек борын төбендәге чуртанны ычкындырмаган. Эләктергән...». Әхсән әкрен генә итекләрен шуытып тагын алга китте. Кайдадыр эчтә, таллар арасында, үрдәк бакылдаганы ишетелде. Аннары ул хәвефле кычкырып җибәрде, шунда ук су шаптырдаганы ишетелде дә, үрдәк, бак-бак килеп, һавага күтәрелде. Әллә инде суда йөзә торган булып, чуртан үрдәкне аягыннан эләктердеме? Булыр да, Хәмзә бит сәнәк сабы буйлы чуртаннар бар дип сөйләде... Үткән җәйдә балыкчы Сөнгатулла абзыйдан да шундыйрак сүз ишеткәне бар иде Әхсәннең.

Ул арада кояш, түбән төшеп, Мулла авылы умарталыгы каеннары артына кереп яшеренде. Әхсән, борын тартырга да куркып, баганадай катып калды да камышлы түмгәкләр арасына карап торды.

Артта тагын сызгырган тавыш ишетелде. «Әллә инде теге тагын берне эләктергән?» – дип, Әхсәннең йөрәге кысылып куйды. Артына борылып караган иде, Хәмзәнең судан чыгып читтә басып торганын күрде.

– Әхсән, мин китәм! – диде Хәмзә, ул борылып карагач.

Әхсән су эченнән чыкты да иптәшенә якынлашты.

– Нишләп китәсең? Иртә бит әле. Шәп балык тоткансың, – диде ул, иптәшенең чуртанына кызыгып.

– Аяк өши, итеккә су үтте, – диде Хәмзә. – Бүгенгә җитеп торыр. Менә берне эләктердем. Сиңа бер дә туры килмәдеме?

– Юк, – диде Әхсән, гарьлеген яшерергә тырышып.

– Шәп бит, малай? Ике килодан артыктыр. Син кайтмыйсыңмы?

– Юк әле, кайтмыйм, – диде Әхсән. – Бар китсәң кит, тавышланып торма.

Ул кире борылды да, түмәкләр арасыннан бер дә күзләрен алмыйча, эчкә таба керде. Шактый озак бер урында басып көтте. Юк, берни дә

күренмәде. Аннары аның түземе бетеп, Хәмзә йөргән якка күчеп китте. Тик анда да булмады. «Булмады инде, кайтырга кирәк», – дип, судан чыкты да сәнәген җиргә ташлады. Таллар арасына очып килгән бер төркем үрдәкләргә карап торды. «Вәтел» куеп, көненә унар чуртан тотучылар исенә төште дә: «Эх, «вәтелем» булса, мин дә буш кул белән кайтмас идем», – дип хыялланып, каенлыктан агып чыккан суның Чирмешәнгә таба ага торган сай җиренә килде.

«Монда вак-төяк тал чыбыклары китереп тутырсаң, чуртанны көтеп кенә торасы. Күз нурларыңны талдырып эзләп тә йөрисе түгел», – дип уйланып торды ул.

Кинәт шул сай җирдә шапор-шопыр килгән үзе буйлы чуртанны күреп алды. Балык шундый шәп, сайлыкта аның корсагы гына суда, калган бөтен гәүдәсе өстә. Әхсән шундый галәмәт зур балыкны ычкындырудан куркып каушап калды. Сәнәгенә карады, ул ерак иде. Аны алып килгәнче, чуртан бу сай җирне үтеп ычкыначак.

Ул аптырап бер сәнәккә, бер балыкка карады да, бишмәтенең чабуларын җыеп, йөгереп килгән җайга чуртан өстенә лачт иттереп ятты. Балыкны кочагына алдым дигәндә генә зур чуртан, койрыгы белән селтәнеп, Әхсәннең кочагыннан ычкынып китте. Кирегә борылып каенлык ягына китәргә теләде. Әхсән яңадан колачларын җәеп балык өстенә ташланды да, чуртанны кочаклап алып, читкә таба ике генә атлаган иде, тегесе тагын койрыгы белән бер генә селтәнде, кочактан ычкынып, тиз-тиз тагын суга таба шуыша башлады. Әхсән тагын чуртан өстенә ятты, тагын да катырак кысып, балыкны читкә алып китә башлады. Чуртан тагын Әхсәнгә иркенләп атларга ирек бирмичә, көчле койрыгы белән ике генә селтәнде дә яңадан ычкынды. Сугышып тәмам хәлдән тайган Әхсән, ачуы килеп, балыкның башына тибеп җибәрмәкче булган иде, чуртан койрыгын болгап шуып китте дә, итек аның башына тимичә, сыртына гына эләкте. Аптырагач, Әхсән тагын чуртан өстенә ташланды, ике кулын саңакларына батырып, балыкны тагын күтәреп читкә өстерәде. Бу юлы балык тиз генә ычкына алмады. Әхсән, чуртанны судан тагын да читкәрәк алып килде дә, сәнәген алып килеп бар көченә балыкның башына ике мәртәбә сукты. Шуннан соң гына чуртан суга таба шуышуыннан туктады.

Әхсән, үзе кадәр чуртан белән сугышудан тыны бетеп, узыштан кайткандагыдай дөп-дөп сикергән йөрәге тынычланганны көтеп, балыкка карап торды. Чуртан бер урында берничә мәртәбә сикергәләгәннән соң, ул аны судан тагын да читкәрәк алып китте. Аннары, таллар янына барып, таза гына тал ботагы сындырып алып килде. Шунда гына ул үзенең җеп



бөртегә калмыйча, сазлы суда пычранып беткәнен, итек эчләренә кадәр су кергәнен сизеп алды. Ботаклы тал чыбыгын чуртанның саңагы аша кертеп авызыннан чыгарды да, балыкны җилкә аша салып, сәнәген кулына алганнан соң, кайтырга чыкты. Чуртанның койрыгы җиргә сөйрәлгәнгә, атлап кайтырга уңайсыз иде. Ярты юлга җиткәч, балыкны җиргә салып ял итте. Аннары түбәннән үзләренең бакчаларына турылап кына менеп, урам аша чыкты. Ишегалдындагы озын өстәлгә чуртанны сузып салды да өйгә керде.

– Кайттыңмы, улым, нишләп бик озак? И-и Ходаем, әллә суга төштеңме? Кара инде, бөтен җирең пычрак су! – дип, әнисе Әхсәнне куркынып каршы алды. – Йөрисең бит шунда булмаганны!

– Чуртан белән сугыштым, – диде Әхсән, шатлыгын яшерә алмыйча елмаеп. – Әни, әни, кара! Ниндиен алып кайттым! – диде ул, ишекне ачып куеп.

Мәрьям апа, ишеккә килеп, өстәл өстендә сузылып яткан чуртанга исе китеп карап торды.

– Балакаем, ничек курыкмадың, ничек җиңдең? – дип, бер өстәлдәге балыкка, бер пычранып беткән малаена карады. – Бар, улым, чишен дә, суынып, өстеңне алыштыр. Салкын тидерерсең.

Аннары ул, почмакка кереп, пычак алып чыкты да, караңгы төшкәнче, чистартып, тоз сибеп куйыйм дип, чуртанны эшкәртергә кереште.

Башта ул яхшылап тәңкәләреннән чистартты. Аннары эчен ачып җибәргән иде, аннан бер ярыйсы гына зур кызылканат, бер ертыш балыгы килеп чыкты. «Яңа гына йоткан, ахрысы», – дип, ул аларны да эшкәртергә булды. Балыкларны чистартып, эшен бетергәч, Мәрьям апа, өйгә кереп, зур пычак белән табак алды да, турап, тоз сибеп куйыйм дип, балык янына чыкты. Шулчак өстәлдәге чистартылып эше беткән чуртан койрыгын күтәрде дә, сикереп китеп, идәнгә, Мәрьям апаның аяк астына килеп төште.

– Әнекәем! Әстәгъфирулла! – дип кычкырып җибәрде Әхсәннең әнисе. – Җендер бу, балык түгелдер! Тьфу-тьфу, Илаһым, үзең сакла!

Куркуыннан кулындагы агач табагы да җиргә төшеп китте.

– Әни, нәрсә булды? – диде Әхсән, өйдән йөгереп чыгып.

– Нәрсә булды? Нигә тавышланасыз?! – дип, Әхсәннең әтисе Мөхетдин абзый да кайтып керде. Идәндә яткан ярык табакны алып өстәлгә куйды. Аннары зур балыкны өстәлгә алып салды.

– Әхсән тотып кайтты, – диде Мәрьям апа, тынычлана төшеп. – Өстендәге тәңкәләрен чистарттым, эчен ярдым, тыны да булмаган иде.

Әле, торарга дип чыккан идем, сикереп, котымны алды. Табагымны харап иттерде хәерсез...

– Әти, күрдеңме? Нинди шәбен тотып кайттым!

– Шәп, улым, шәп. Ничек җиңдең моны? Үзең кадәр бит!

– И-и, моны да җиңмәсәң... Синең кадәр булса менә, җиңә алмас идем. Алай да әллә ничә мәртәбә кулдан ычкынды. Мин кочаклап алам, ул койрыгы белән бер генә селтәнә. Шундый көчле...



# КЕЧКЕНӘ ХИКӘЯЛӘР

# ӘТӘЧ КҮПМЕ ТОРА?

Биләр райкомына «утызмеңчеләр» исәбеннән шәһәрдән яңа килгән икенче секретарь белән бервакыт мине Олы Тигәнәлегә вәкил итеп җибәрделәр. Безне бер тол хатынга фатирга куйдылар.

Иртән сәгать дүрт тә тулмаган иде, хуҗабикә көтү куарга киткәч, секретарь кеше ашыгып торды да тышка чыгып китте. Күп тә үтмәде, бу чалбарын каптыра-каптыра, хафаланып, мышнап өйгә йөгереп керде.

– Әтәч күпме тора икән? – дип, күзләрен зур ачып, миңа текәлде.

– Нигә? – мин әйтәм. – Әтәч ите ашыйсың килдеме әллә?

– Апаның әтәчен үтердем, – ди бу, тавышын әкренәйтә төшеп. Күрәм, бик нык куркуга калган.

– Нишләп?!

– Лапас буена чыгып утырган идем, әтәче арттан килеп җилкәгә утырды да, үзе муенымны чукый, канатлары белә шап-шап суга. Явыз! Һич төшми жилкәдән. Ярый әле якында гына көрәк тора иде... Җилкәдән бәреп төшергән идем, артымны чукый башлады. Вәт явыз, вәт ерткыч!.. Әллә чәчемне йолкып алды, – ди бу, башын капшап.

Шундый кычкырып көләсе килә. Яңа, җитмәсә, секретарь кешедән көләргә яхшы түгел.

– Урынсыз җиргә утырмыйлар аны. Ирлегеңне өзеп алса, ни хәлең бар, – дим мин, кычкырып көлүдән үземне чак-чак тыеп.



# МИҢА ДА «УТЬ» ИТТЕРЕП ЯСА ӘЛЕ...

Килгән кунак белән бик саран хуҗа икәү генә чәй эчеп утыралар икән. Самавыр янына утырган хуҗа кунакка салам сарысы кебек кенә чәй ясап бирә дә, үзенә агыза башлагач: «уть», «уть» дигән булып чәйнекнең борынын түбәнәйтеп (чүктереп) җибәрә икән (янәсе, ялгышып кына түбәнәйтә була). Мыек астыннан гына елмаеп карап торган кунак икенче чынаягын ясарга биргәч:

– Мина да «уть», «уть» иттереп яса әле, эчкән чәемнең бер дә тәме булмады, – ди икән.

# КАРАМАЛЫ МАЕ

Элекке вакытта Карамалыдан бер агай Мораса базарына атна саен чабата сатарга килә икән. Бу кеше Морасадагы танышын очраткан саен үзенең сыеры булуы, сөт-катыктан өзелмәвен сөйләп мактана да тегене үзләренә кунакка чакыра икән. Бервакыт, салкын кыш көнендә Мораса агае, йомышы төшеп, Карамалыга барып чыга. Бик өшегәч, танышына кереп җылынып чыгарга уйлый.

Кунак килгәч, чәй куялар. Сәкегә ашъяулык җәелә. Самавырны чыгарып утырталар. Чәйгә салырга дип, кәнди белән сөт, агач кашыклар, ипи турап куялар. Чәйгә утыргач, кына хуҗабикә, исенә төшеп, чоланга чыгып китә дә, бер йомарлам май алып кереп, сай тәлинкәгә куя.

Чәй янында килгән кунак үзенең сыерсызлыгыннан зарланып ала. Хуҗа белән хуҗабикә кунакны гел кыстыйлар икән:

– Мае белән аша, кунак, мае белән...

– Маеннан да авыз ит, – дип өсти икән хужабикә.

Күптән май күрмәгән кунак кашык алып майга орынуы була, түм-түгәрәк каткан май, тәлинкәдән чыгып китә язып, әйләнеп кенә йөри икән. Кунак бер сузыла, ике сузыла да, майдан авыз итүдән өмет өзеп, кашыгын кире куя. Хуҗа аның саен кыстый икән... Ә үзе пычак алып майны кунак кабарлык итеп кисеп куярга уйламый да икән.

Бик кыстагач, кунак, кашык алып, бәлки йомшаргандыр дип, тагын сузылуы була, май терекөмеш кебек тәлинкәдә йөгереп кенә йөри икән, кашыкка тырнак очы кадәр дә эләкми.

Кунак, бер-ике телем ипи ашап, ике-өч чынаяк чәй эчә дә, бисмилласын әйтеп, табын яныннан тора.

– Ашарга иде әле, эчәргә иде, – диләр икән хуҗа белән хуҗабикә.

– Ашадым да, эчтем дә, маегыз бик тәмле булды, – ди икән кунак, мыек астыннан елмаеп.

Шуннан бирле бу якларда кунак алдына куйган андый майны «Карамалы мае» дип йөртә башлаганнар.

# МӘТЫГЫ ТӘМЛЕ БУЛДЫ...

Әти сөйли иде: элекке вакытта бер кияү әбисендә кунакта була. Әби кеше, кияве килгәч, зур агач савыт белән каймаклы катык чыгарып куя. Сөт-катык күрмәгән кияү катыкны шундук ашап бетерә дә:

– Әби, бик тәмле булды бу нәрсәң, тагын юкмы? – дип сорый.

Әби кеше, базга төшеп, актык катыгын алып чыга да:

– Мә, тыгын инде! – дип, туймас кияү алдына куя.

Өйгә кайткач, әнисе сорый икән:

– Йә, улым, ничек, әбиең сыйладымы үзеңне?

– Сыйлады, әни. Иң тәмлесе мәтыгы булды, – ди икән улы.

# ЮЛГА САЛГАН...

Сугыш вакытында була бу. Карт коммунист Хәниф абзыйны Яңа Эмҗә авылына колхоз рәисе итеп җибәрәләр. Бер елдан соң ул үз авылларына әйләнеп кайта. Авылдашы Хәлиулла аны очраткач:

– Йә, Хәниф абзый, хәлләр ничек? Эмҗәне юлга салдыңмы? – дип сорый икән, хәйләкәр генә елмаеп.

– Юлга салдым...

– Ничек?

– «Уфалла» тартып, төрлесе төрле якка чыгып киттеләр, – ди икән сүзгә саран элеккеге рәис.



# ЭЧӘСЕҢ КИЛӘМЕ, ХӘНИФ АБЗЫЙ?!

Авыл советы рәисе Хәниф абзый белән мәзәк оештырырга яратучы Хәлиулла Урман асты Шонталысына барырга чыгалар. Кышның бик суык көннәре була бу. Ун километр араны үткәнче, икесенә дә бик нык суык үтә. Суык үзәгенә үткән Хәниф абзый әледән әле:

– Ку атыңны! – дип, Хәлиулланы ашыктыра икән. Урманны чыккач, каршы җил тагын да ныграк үзәккә үтә башлый. Авылга килеп кергәч, алда сиртмәле кое күренә. Хәлиулла атын чаптырып килгән уңайга кое янына борып туктата да:

– Эчәсең киләме, Хәниф абзый? – дип, чанадан сикереп төшә дә бозланып туңган кое чиләгенә барып тотына.

Иреннәре сүз ясый алмас булып өшегән рәис:

– Та..тың шаярыр вакы..! – дип сүгенә икән. – Ти.. бу...!

# ХИКМӘТЕ НӘРСӘДӘ?..

Урып-җыю алдынгыларын Биләргә ударниклар җыелышына чакыралар. Хәлиулла урып-җыю вакытында лабогрейкадан учма төшерүче булып эшли. Алдынгылар җыелышында моны трибунага чакыралар да:

– Сез, иптәш Батров, урып-җыюда икешәр норма урдырып учмаларга салгансыз икән. Сезнең уңышның хикмәте нәрсәдә? Шуны сөйләп бирегез әле, – дип сорыйлар.

– Хикмәтеме? – дип елмая Хәлиулла, бер күзен хәйләкәр кыса төшеп. – Хикмәте аның бик саллы ике япьле карама таягында, шуның янына бер кило сарык ите белән ике кило бодай ипиендә! – дип, залдагы бөтен халыкны көлдерә.

# КАЙГЫРТУЧАН КЫЗ

Дүрт яшьлек Әлфияне әти-әнисе үзләре эшкә киткәндә күршегә кертеп калдыралар. Бервакыт хуҗабикә апа кызның матрас тишегеннән салам суырып алып панамасына тутырганын күреп ала.

– Кызым, нишләвең бу? Болай ярамый бит, – дип, кыз янына килә.
– Сыерга печән җыям, – ди икән кыз, матрас тишегеннән салам алуын дәвам итеп.

* * *

Әлфия нидер чәйнәгән бозау янында басып тора икән. Башында панамасы юклыгын күреп:
– Панамаң кайда, кызым? – дип сорый әнисе.
– Әнә, – ди кыз тыныч кына, – бозауның ашыйсы килгән. Бозау ашый.

## МИН ЗУР ИНДЕ-Е...

Әлфияне биш яше тулгач та бишектән аера алмыйлар. Бишек кечерәеп, кызның аяклары бишектән чыгып тора башлагач, әтисе, чана кадәр бишек ясап, өй уртасына элəргә мәҗбүр була. Җәй көне дәү әниләренә кунакка баралар. Кич була. Кыз һич йокларга ятмый, дәү әнисеннән бишек таптыра.
Дәү әнисе аңа:
– Кызым, син зур инде, зур кешеләр бишеккә ятмыйлар. Караваткa, диванга яталар. Бишектә кечкенә бәбәйләр генә ята, – дип, кызны үзе янына диванга ятарга күндерә.
Өйгә кайткач, кызны бишеккә салулары була, кыз:
– Мин зур инде-е, бишеккә ятмыйм! – дип, бишеккә ятудан баш тарта. Шулай итеп зур бишекнең кирәге калмый.

* * *

Яхшы ук кәефләнеп кайткан ир хатынына:
– Әнисе, угадай, минем уң як кесәмдә нәрсә? «А» хәрефенә башлана, – дип, пәлтә бавын чишмичә тора.



– Ә-ә, беләм-беләм. Бүген айның унынчы көне, аванс ул, кая, китер монда!
– Нет, не угадал. Ә менә сул як кесәдә нәрсә бар?!
– Нинди хәрефкәдер бит?
– «Б» хәрефенә монысы. Йә әйт, нәрсә була инде ул?
– Бүләк биргәннәрдер инде, әтисе, аванс булмагач...
– Юк шул, хатын, ялгышасың. Беренчедән, аванс бирергә заводның акчасы юк, завод кәкре каенга терәлгән. Икенчедән, безне үз хисабыбыздан ун көнгә ялга җибәрделәр.
– Алай булгач, кесәләреңдә нәрсә соң синең?
– «А» хәрефенә – аракы, уң як кесәдә. Монда буш бутылка гына шул, хатын.

Чыгарылыш өчен җаваплы: Л. Р. Колесникова
Корректоры: Ф. Ш. Әхмәтҗанова
Биткә салучы: Г. С. Яковлева
Техник редакторы: Г. А. Саморядова
Тышлыктагы фоторәсем: М. Ф. Гарифҗанов

Литературно-художественное издание
Ахмет Махмутович РАФИКОВ
Ещё соскучитесь...
(повести и рассказы)
(на татарском языке)

Әдәби-нәфис басма
Әхмәт Мәхмүт улы РАФИКОВ
Сагынырсыз әле...
(повестьлар һәм хикәяләр)

---

«Заман» нәшрияты
420111, Татарстан Республикасы, Казан ш., ул. Астрономия ур., 8/21
Тел.: (843) 292 29 69, 246 02 21;
www.zaman-izd.ru; e-mail: info@zaman-izd.ru
Басмага кул куелды: 22.03.2024
Тиражы: 100 экз. Заказ №
2024